ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Г.С. Хаҗиева-Демирбаш**

# ТАТАР АНТРОПОНИМИК СИСТЕМАСЫНЫҢ ҮСЕШ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

Казан
2018

**УДК 811.512.145**
**ББК 81.2Тат**
**Х 40**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редактор**

филология фәннәре докторы **М.З. Зәкиев**

**Рецензентлар:**

филология фәннәре докторы **А.Ә. Тимерханов,**
филология фәннәре докторы **Л.Х. Мөхәммәтҗанова**

**Хаҗиева-Демирбаш Г.С.**
**Х 40 Татар антропонимик системасының үсеш тенденцияләре** / Г.С. Хаҗиева-Демирбаш. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 220 б.
ISBN 978-5-93091-262-3

Әлеге монография – татарларның исем системасын күзаллауга, барлауга, тикшерүгә, шуңа бәйле рәвештә бүгенге чор мәсьәләләрне фәнни яссылыкта хәл итүгә юнәлдерелгән хезмәтләрнең берсе. Хезмәт тел тарихы, халык авыз иҗаты, этнография, диалектология өлкәләрендәге казанышларны исәпкә алып, шушы һәм башка фәннәр кисешендә барлыкка килгән этнос, тел, мәдәни бәйләнешләр яссылыгында татар исемнәрен өйрәнүне максат итеп язылды. Глобальләшү шартларында гомуми тел белемендә тел берәмлекләрен аерым анализлау түгел, ә этномәдәният кысаларында тел моделе буларак карау, фәннәр кисешендә барлыкка килгән юнәлештә этнос, тел һәм мәдәни мәсьәләләрне системалы-бәйләнешле рәвештә өйрәнү бүген яңа фәнни нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Әлеге хезмәт, әнә шул максатлардан чыгып, дисциплинаара бәйләнештә телнең этномәдәни тирәлегендә антропонимик берәмлекләрнең үсешен башка төрки телләр белән дә чагыштырып өйрәнүне күздә тота.

**УДК 811.512.145**
**ББК 81.2Тат**

**ISBN 978-5-93091-262-3**

© Хаҗиева-Демирбаш Г.С., 2018;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2018

# КЕРЕШ

*Үлемгә дучардыр тумыш һәр инсан*
*Ләкин атың калыр, чын кеше булсаң...*
Йосыф Баласагуни «Котадгу белек»

Татарлар гомер-гомергә балага исем бирүгә җитди якын килеп, исемнең мәгънәсенә аеруча зур игътибар юнәлткәннәр. XI гасырга караган «Котадгу белег» исемле бәхеткә ирештерә торган белем трактатында Йосыф Баласагуни болай дип язып калдыра: «Яшәвең бер тотам, бер дулкын-ялкын, яманмы-яхшымы калыр тик атың». Шагыйрь әлеге юлларда исемнең үлемсезлегенә ишарә ясый. Дөньяны уратып алган һәр җан иясенең, предмет-әйбернең – кешеләрнең, кошларның, хайваннарның, табигать күренешләренең – гомумән, һәрнәрсәнең үз атамасы, исеме бар. Дөньяга аваз салганнан алып, фани дөнья белән саубуллашканга кадәр исем кеше белән бергә яши һәм ата-ананың балага биргән иң зур ядкәре булып кала. Мөхәммәд пәйгамбәр: «Балаларыгызга матур исемнәр бирегез! – дип әманәт әйтә. – Сорау алырга исемнәрегез белән чакырырлар», – ди. Шәригать кануннары нигезендә балага матур, мәгънәле исем бирү һәрбер ата-ананың зур бурычы булып тора.

Татар халкының исем кушу йола-гадәтләрендә исем кешенең җаны һәм инсаниятнең әхлакый төшенчәләре белән бәйләнеш-мөнәсәбәттә чагылыш таба. Орхон-Енисей язмаларында ук инде исемгә, исем кушу йолаларына зур игътибар бирелә. Борынгы төрки бабаларыбыз бала дөньяга аваз салгач кушылган исемне *ада атым, оглан атым* дип атасалар, яшүсмер чакта, батырлыклар күрсәткәннән соң бирелгән исемгә *эр атым* дигәннәр, җан-тәслим кылгач бирелгән исем исә *айаг ат* дип күрсәтелгән. Борынгы Орхон-Енисей язмаларында кешенең иҗтимагый дәрәҗәсе үзгәрүе, югарырак баскычка күтәрелүе дә исемдә чагылыш тапкан.

Төрки халыкларның мәкаль-әйтемнәрендә, тотрыклы һәм канатлы гыйбарәләрендә исемгә зур мәгънә салына: азербайҗаннар «исеме матурның – үзе матур» дисә, төрекләр – «исеме тугыз мәртәбә искә алынса, соңыннан инде сигезгә төшмәс» (ягъни бер даны чыккан кешегә икенче тапкыр ышанмаслар), үзбәкләрдә – «исеме телләрдә дастан булды», калмыкларда «исемгә тап төшергәнче, үлем яхшырак» диләр. «Исеме

җисеменә туры килә!» ди бөек халкыбыз. Татар халкының милли үзенчәлеген билгеләгән, аның бөтен уй-кичерешләрен чагылдырган кеше исемнәренең саны бүгенге көндә 20000 нән артып китә. Халкыбызның исемнәрендә аның мәдәнияте, дөньяга карашы, гореф-гадәтләре, традицияләре, туган теленә мәхәббәте чагыла. Тарих төпкелләрендә калган исемнәрне барлап, теркәп, аларны эзлекле фәнни яссылыкта тикшергән, шулай ук исемнәребезне үткән һәм бүгенге көн ноктасыннан якын килеп өйрәнгән фәнни хезмәтләргә ихтыяҗ һәрдаим үзен сиздереп килә. Россия күләмендә кеше исемнәрен куллануны аерым бер тәртипкә салу, кеше исемнәрендә чагылыш тапкан элеккеге сәяси-идеологик ышанулардан арыну нияте белән кайбер төрки-татар чыгышлы исемнәрне дә тыюны күз уңында тоткан закон проектының тәкъдим ителүе, шул ук вакытта, әйтик, яңа туган балаларына туу турында таныклык алганда, ата-аналарның тупас, мәгънәсез исемнәр сайлау очраклары һ.б. – болар барысы да татар җәмәгатьчелеген, киң даирә галимнәрне тирән борчуга сала торган, уйланырга, проблеманы төрле яктан максатчан рәвештә фәнни нигездә тикшерергә, өйрәнергә этәрә торган гамәлләр.

Исем – ул тарих. Борынгы бабаларыбыз исемнәрен ташларга, кыяларга уеп, шәҗәрләргә язып-теркәп калдырганнар. Тарихи чыганакларда теркәлгән борынгы төрки исемнәрне күреп, чыннан да бу эш-гамәлләрне безнең борынгы бабаларыбыз тарихка уеп калдырган дип уйлыйбыз, алар белән горурланабыз. Аларның исемнәре нәселебезнең ерак тамырларын күрергә мөмкинлек бирә.

Антропонимика – антропонимнарны, аларның барлыкка килү закончалыкларын, үсешен өйрәнүче ономастиканың бер бүлеге [Подольская, 1978: 2]; аерым бер урынчылыкка, телгә хас кеше исемнәренең җыелмасы; кеше исемнәренең килеп чыгышын, структурасын, семантикасын, таралыш ареалын өйрәнә торган ононмастиканың бер бүлеге. Шулай ук антропонимика – тирә-юньдәге чынбарлык белән кешенең бәйләнеш-мөнәсәбәтләрен өйрәнә торган мөһим фән тармагы да [ЭССЛТИП, 2008: 25] Антропоним (грек. antropos – «кеше», «onyma» – «исем, атама») – исем, фамилия, отчество, кушамат, тәхәллүс (псевдоним). Әдәби әсәрләрдә, фольклорда, мифологиядә кулланылган антропонимнар антропонимиканың өйрәнү объектын тәшкил итәләр. Теге яки бу телнең антропонимнар тупламын антропонимия дип атыйлар. Соңгы елларда, бу термин белән бергә, антропонимикон термины да кулланыла. Билгеле бер дәүләттәге иҗтимагый кануннар яки милли традицияләр нигезендә кабул ителгән граждан-

нарны исемләү ысулы, сүз яки сүзтезмә шәкелендәге кеше исемнәре антропонимиконны тәшкил итәләр [ЭССЛТИП, 2008: 20].

Әлеге хезмәт тел тарихы, халык авыз иҗаты, этнография, диалектология өлкәләрендәге казанышларны исәпкә алып, шушы һәм башка фәннәр кисешендә барлыкка килгән этнос, тел, мәдәният бәйләнеше яссылыгында татар исемнәрен өйрәнүне максат итеп язылды. Глобальләшү шартларында гомуми тел белемендә тел берәмлекләрен аерым анализлау түгел, ә этномәдәният кысаларында тел моделе буларак карау, фәннәр кисешендә барлыкка килгән юнәлештә этнос, тел һәм мәдәни мәсьәләләрне системалы-бәйләнешле рәвештә өйрәнү бүген яңа фәнни нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Хезмәтебез, әнә шул максатлардан чыгып, дисциплинаара бәйләнештә телнең этномәдәни тирәлегендә антропонимик берәмлекләрнең үсешен башка төрки телләр белән дә чагыштырып өйрәнүне күздә тота. Этномәдәни тирәлек ул, бер яктан, телнең яшәешен булдырган тирәлек булса, икенче яктан, уртак телгә, мәдәнияткә, фольклорга ия булган халыкның мирасы. Татар кеше исемнәре антропонимик системада халкыбызның кардәш һәм кардәш булмаган халыклар белән этномәдәни бәйләнешләренең, төрле экстралингвистик һәм лингвистик факторларның, җәмгыятебездәге объектив процессларның тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килеп, төрле тарихи чорларда формалашкан төп номинатив антропонимик берәмлекләрне тәшкил итәләр. Шуңа күрә аларны махсус өйрәнү, беренчедән, бары тик татар исемнәренә генә хас үзенчәлекләрне, этнолингвистик катламнарны һәм аскатламнарны, бирелү-кушылу мотивларын, ясалыш-төзелеш һәм барлыкка килү мәсьәләләрен, үсеш тенденцияләрен, телдә, шул исәптән антропонимикада камилләшү закончалыкларын, ономастика фәнендә тоткан урыннарын тулырак ачыкларга ярдәм итә. Аерым алганда, татар исемнәренең «стратиграфик катламнарын ачу һәм һәрберсен тарихи-лингвистик яссылыкта җентекләп өйрәнү татар тел белеме фәненең ономастика тармагы алдында торган бурычларның гаять мөһиме һәм актуале булып санала» [Саттаров, 1990: 5]. Шулай ук татар халкының һәм Идел регионындагы башка төрки халыклар тарихын һәм этногенезын ачыклауда, Көнчыгыш Европа халыкларының этник составын, тарихын, мәдәниятен өйрәнүдә дә үзеннән бер өлеш кертә ала.

Экстралингвистик һәм лингвистик факторлар белән турыдан-туры бәйләнештә, татар исемнәренең бирелү-кушылу мотивлары тулы функциональ бер система барлыкка китерәләр. Татар исемнәренең бирелү- кушылу мотивларын өйрәнү халыкның күзаллаулары, тормышка

карашы, гореф-гадәтләре, фикерләү рәвеше турында мәгълүматлар бирә. Лингвистик методлар белән бергә, фольклор, мифологик һәм башка мәдәни контекстта татар антропонимик системасын реконструкцияләү татар халкының дөнья картинасын күрергә мөмкинлек бирә.

Күпчелек фамилияләр һәм отчестволар комоним һәм полисонимнар, гидроним, ойконимнар, этнонимнар һ.б. исемнәргә нигезләнеп ясалалар һәм, алар трансонимизацияләшү (билгеле бер ономастик берәмлекләрнең икенче бер ономастик берәмлекләргә күчүе) процессыннан соң, яңа бер антропонимик, топонимик, космонимик һ.б. берәмлекләрдә яшәешләрен дәвам итәләр. Шуңа күрә татар исемнәрен комплекслы өйрәнү нәтиҗәләре башка ономастик берәмлекләрне тикшерү өлкәсендә беренчел чыганак булып тора ала.

Фамилия, отчество кебек антропонимик берәмлекләр, чагыштырмача соң барлыкка килеп, исемгә өстәмә мәгълүмат бирүче антропонимик категорияне тәшкил итәләр. Фамилия һәм отчестволарда татар ир-ат исемнәренең икенчел яшәеш процессын барлыкка китерәләр. Шулай ук кайбер өстәмә антропонимик категорияләрне формалаштыруда да татар исемнәренең ролен, әһәмиятен билгеләрү зарур. Башка ономастик берәмлекләр татар исемнәре белән тыгыз бәйләнештә торып, аларның барлыкка килү, ясалышында чыганак булалар. Г.Ф. Саттаров «антропотопонимнар арасында ир-ат исемнәренец зур күпчелеге – феодаль җәмгыятьтә ир-атның өстенлеге белән билгеләнүен» күрсәтә [Саттаров, 1990: 43]. Антропонимнарга нигезләнеп ясалган атамалар татар гидронимиясендә дә шактый күп. Алар җәмгыять югары һәм түбән катлау сыйныфларына аерыла башлагач, җиргә хосусый милек вакытында барлыкка киләләр. Хатын-кыз исемнәренә нисбәтле барлыкка килгән гидронимнар исеменә нигезләнгән атамалар шактый аз. Кеше исемнәренә нигезләнгән зур елга атамалары очрамый. Мондый күренеш вак су чыганаклары өчен генә хас [Гарипова, 1998: 76–78]. Шулай ук антропонимнар кабилә исемнәрен ясауда да кулланылалар. Нигездә, кабилә атамасы кабилә башлыгының исеменнән ясала [Зәкиев, 2010: 86]. Шулай итеп, татар исемнәрен аерым алып тикшерү башка ономастик берәмлекләрне өйрәнүдә, һичшиксез, зур фәнни әһәмияткә ия.

Татар кеше исемнәрен махсус өйрәнү тел тарихы, диалектология белән тыгыз бәйләнештә, ул татар антропонимикасының үсеш тенденцияләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Гасыр үзенчәлекләре, төрле иҗтимагый-сәяси шартларда барлыкка килгән яңару тенденциясе кеше исемнәренә беренчеләрдән тәэсир итә һәм алар «теге яисә бу

чорның этик-эстетик нормаларын һәм күзаллауларын чагылдырган иҗтимагый үсеш һәм тарихның продукты булып торалар» [Благова, 1999: 22]. Кайбер антропонимик берәмлекләр кулланылыштан төшеп калып архаиклашалар, алар урынына яңа берәмлекләр барлыкка килә. Архаиклашкан татар кеше исемнәре иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормыш таләбе нигезендә билгеле бер чорда антропонимик системада яңадан кулланылыш алырга да мөмкин. Бу процесс татар кеше исемнәренең динамик халәтенә, антропонимик системаның яңарып торуына этәрә.

Татар халкының рухи һәм матди мәдәнияте антропонимикага турыдан-туры тәэсир итә. Татар кеше исемнәре – аерым бер универсалийлары һәм специфик үзенчәлекләре булган, халыкның рухи һәм матди яшәешен чагылдырган берәмлекләр. Шуңа күрә татар кеше исемнәрен этнолингвистик аспектта өйрәнү лингвистика, тарих, социология, этнография, психология, география кебек фәннәргә дә үзеннән билгеле бер өлеш кертә.

Тел белемендә һәм шул исәптән антропонимикада антропонимик берәмлекләрнең теоретик концепцияләре А.А. Белецкий, А.В. Суперанская, Г.Ф. Благова, М.З.Зәкиев, В.А.Никонов, К.М. Мусаев, В.Д. Бондалетов, Н.В. Подольская, Г.Р. Алеев, Г.Ф. Саттаров һ.б.ның хезмәтләрендә тирәнтен яктыртыла. Ялгызлык исем белән уртаклык исем мөнәсәбәте, төп антропонимик берәмлекләрнең үзлекләре, аларның хосусый һәм универсаль категорияләрен аеру, семантика мәсьәләләре, исемнең классификацион һәм дифференциаль билгеләренең теоретик нигезләре югарыда күрсәтелгән галим-ономастларның хезмәтләрендә шактый тулы ачылалар.

Төрки антропонимикада тикшеренүләргә бай материаллар үзбәкләрдә – Э.А. Бегматов, казакъларда – Т.Ж. Жанузаков, З.Р. Жаненова, Г.И. Кулдеева, кыргызларда – С.М. Абрамзон, Ш. Жапаров, төрекмәннәрдә – Ш.Аннаклычев, башкортларда – З.Г. Ураксин, Т.Х. Кусимова, А. Шәйхулов, Р.З. Шакуров, З.М. Раемгужина, Р.А. Сөләйманова, азәрбайҗаннарда – Г.Р. Алеев, Р.Ф. Халыгова, М.Н. Чобанов, төрекләрдә – А. Эрол, С. Акалын, Н. Кая, И. Шахин хезмәтләрендә урын алган.

Татар антропонимикасы XIX гасырның II яртысыннан ныклап өйрәнелә башлый. Бу өлкәгә В.В. Радлов, В.К. Магницкий, Н.И. Ашмарин, В.В. Вельяминов-Зернов, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г. Әхмәров, Г.Тукай һ.б. үзләреннән зур өлеш кертәләр.

В.В. Вельяминов-Зернов «Исследование о касимовских царях и царевичах» [ч. 1 СПб., 1863; ч. 2. СПб., 18 64; ч. 3. СПб., 1866] һәм

«Источники для изучения тарханства, жалованного башкирам русского государями» [приложение «Запискам Академии наук», СПб., 1864, т. 4. №6] дигән хезмәтләрендә төрки халыкларның (аерым алганда татар һәм башкортларның) гаять бай антропонимик материалларын тәкъдим итә. Ул хезмәтләрендә төрки чыгышлы татар кеше исемнәренең ясалышын, лингвистик үзенчәлекләрен, семантикасын ача. Исемнәрнең кыскарылу күренешенә беренчеләрдән игътибар итә [Вельяминов-Зернов, 1864: 494].

XIX гасырның 70 нче елларында Казан университеты каршында «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» оештырыла. Шул елларда В.В. Радлов җитәкчелегендә туган якны өйрәнүдә ономастика түгәрәге оештырылу Казанда ономастик эзләнүләрне киңәйтүгә китерә [Никонов, 1956: 145]. Бу түгәрәктә Н.И. Золотницкий, Н.Ф. Катанов, Н.И. Ашмарин, И.А. Износков, В.К. Магницкий, татар галимнәреннән Ш.Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Әхмәров эшчәнлекләрен киң җәелдереп җибәрәләр. Шул рәвешле, XIX гасырның 80 нче елларында Казан ономастика мәктәбенә нигез салына.

Ш.Мәрҗанинең 1897 елда дөнья күргән ике томлык «Мөстафадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендә, Болгар һәм Казан тарихыннан тыш, бик күп ономастик һәм антропонимик материаллар китерелә. Бу хезмәтнең икенче кисәгендә Ш.Мәрҗани борынгы антропонимнарны үз эченә алган татар шәҗәрәләрен тәкъдим итә.

К.Насыйриның «Зөя өязе» хезмәтендә бирелгән шәҗәрәләр, эпитафияләр, кулъязмалар тарихи антропонимика өчен кыйммәтле чыганак ролен үти.

1903 елда Г.Әхмәров Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография хәбәрләре» журналының 2 нче санында «Мишәрләр теле һәм халкы» турындагы мәкаләсендә мишәр диалектларында кулланылган кеше исемнәренең кайбер үзенчәлекләрен күрсәтә. Бу мәкалә татар антропонимикасының этнолингвистик үзенчәлекләрен яктыртуда гаять әһәмиятле урын тота.

XIX гасырның уртасында гарәп-фарсы исемнәренең таралышы күзәтелә. Бу төр исемнәр пропаганда максатында төрле кечкенә китапчыкларда һәм циркулярларда теркәлә. Муллалар тарафыннан дөнья күргән «Исме Аллаһе Тәгалә әл-Хәсәни» [1848], «Авраде Фәтхия» [1865] дигән дини эчтәлектәге һәм мөселман исемнәрен пропагандалаган сүзлекчәләрне күрсәтеп китәргә кирәк. Бу сүзлекчәләрдә балаларга мөселман исемнәре бирергә кирәклеге турында басым ясала.

Җыентыкларда Аллаһының эпитетларыннан саналган 99 исемнең мәгънәсе бирелә. XX гасыр башында шундый ук юнәлештә сүзлекчәләр чыгару эше дәвам итә. Ш.Т. Хәмидуллинның «Исемнәрнең бәгъзеләрене дөрес язу» [1899], Ахун Бендуковның «Исем. Балаларга күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафыйк китап» [1899], бертуган Кәримовлар тарафыннан чыгарылган «Унбер Әхмәт исемнәре» [1914] сүзлекләрендә дә төрле исемнәр тәкъдим ителә. Ахун Бендуковның «Исем. Балаларга күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафыйк китап» сүзлегендә автор бары тик исемнәр сүзлеген генә биреп калмый, ә беркадәр лингвистик анализ, классификацияләү алымнарын кулланырга да омтыла. Ул исемнәрне түбәндәгечә классификацияли: 1. Мәгънәсе яхшы, шәригать кануннары нигезендә язылган исемнәр, җиңел исемнәр: *Адәм, Идрис, Әдһәм, Әхмәт, Асат, Ислам, Исмәгыйль, Исхак, Ибраһим, Асаф, Әснәф, Ильяс* һ.б.; 2. Ике кәлимә булып, мәгънә җәһәтеннән изафә җаиз шәригатьчә күркәм исемнәр. Бу исемнәрдә Аллаһының бер исеме шәригатьчә бирелгән: *Габдулла, Габдерахман, Абдулла, Габдерәхим, Габделгани, Габделхәлүк, Габделгалләм, Габделбари* һ.б.; 3. Ике кәлимә булып, дин хафизына изафә белән булган исемнәр, изафәсе мәгънә җәһәтеннән җаиз шаригатькә мөнхи булмаган исемнәр. Моның кебек әүвәл заманда мәдх касты белән олуб истималь улунмуш: *Шәмседин, Нәҗметдин, Сираҗетдин, Җамалетдин, Кемалетдин, Кыяметдин, Садретдин, Зәйнелетдин, Фәхретдин, Әкъмәлетдин, Гарәфетдин* һ.б.; 4. Хәзрәти Мөхәммәт дәверендә булмаган, Иран һәм Туран халкының мөселман булуы белән кулланылган исемнәр: *Әхмәтгәрәй. Әхмәтсадыйк, Мөхәммәтҗан, Хаҗигәрәй, Мөхәммәтфатыйх, Мөхәммәтзәки, Вәлиәхмәт, Зарифҗан, Нурмөхәммәт*; 5. Хәзрәти Адәмнән хәзрәти Мөхәммәдкә кадәр булган исемнәр: *Апуш, Сиамак, Конак, Хам, Сам, Яфис, Ям, Кантур, Лауз, Иран, Әрван* һ.б.; 6. Хәзрәти Мөхәммәдтән соң мәшһүр исемнәр: *Хишан, Һарунрәшит, Мәдхи, Гайбулла, Мәрван* һ.б. Кыз балаларга күркәм исемнәр*: Әминә, Асия, Бакирә, Сания, Салисә, Җәмилә, Хафиза, Хәмидә, Хәмдия, Хәят, Һава, Хәдимә, Рабига, Разия, Рәхимә, Заһидә, Зөһрә, Зәйнәп, Зәйтүнә* һ.б. [Бендуков, 1899: 12].

30–50 нчы елларда татар исемиятен лексикографик юнәлештә өйрәнгән аерым хезмәтләр билгеләнми. Бары тик XX йөзнең 60 нчы елларында гына дөньяда тел белемендә һәм рус теле белемендә ономастикага карата кызыксыну уяна башлый һәм бу күренеш татар антропонимикасын да җанландырып җибәрә. Беренче мәртәбә

1967 елда Ульяновскида «Идел буе ономастикасы» дигән конференция оештырыла. Соңрак бу конференцияләр традициягә әйләнеп, 1969 елда – Горькийда (хәзерге Түбән Новгородта), 1971 елда – Уфада; 1973 елда – Пензада, 1974 елда – Саранскида; 2006 елда – Уфада; 2008 елда – Ижевскида, 2009 елда – Казанда, 2011 елда – Ярославльда, 2014 елда – Тверьда, 2016 елда – Арзамаста оештырыла. Бу конференциянең оештыручылары һәм әйдәп баручыларыннан А.В. Никонов, Р.Ш. Джарылгасинова, В.А. Бондалетов, В.А. Барашков кебек галим-ономастларны атап китәргә була.

60 нчы еллардан башлап татар антропонимикасы аерым тармак булып үсеш ала башлый һәм фәнни яктан тирәнәя. Г.В. Йосыпов, Г.Ф. Саттаров, Р.Х. Субаева, Ф.С. Хәкимҗанов, М.А. Җәләлиева, Г.Р. Галиуллина һ.б.ның хезмәтләрендә хәзерге татар антропонимикасына нигез салына.

Татар ономастик берәмлекләрен, шул исәптән кеше исемнәрен дә туплап, төрле антропонимик юнәлешләрдә тикшерү Казан дәүләт университетында Г.Ф. Саттаров тарафыннан оештырылган Казан ономастика мәктәбендә алып барыла. Татар халкының этногенез мәсьәләләре яссылыгында төрки-татар ономастикасы, диалектлары һәм лексикасын өйрәнү буенча фәнни-тикшерү бу мәктәпнең бер бурычы булып санала. Аеруча региональ антропонимияне – аерым бер төбәккә караган торак пунктларда, шәһәрләрдә, районнарда, авылларда яшәүче халык телендә кулланылышта булган кеше исемнәрен, кушаматлар һәм фамилияләрне өйрәнү-тикшеренү эшләре алып барыла. Бу юнәлештә эшләүче Х.Ч. Алишина, Г.Р. Галиуллина, Ф.Г. Ваһапова, Ф.С. Сәлимҗанова, Г.Ф. Тимканова, Л.Х. Айтбаева, М.З. Вәлиева, Г.С. Хаҗиева кебек галимнәрнең хезмәтләрендә аерым бер регион-урынчылыкка караган антропонимик берәмлекләрне туплап, аларны тарихи-лингвистик аспектта яктырту максаты куела. Тикшеренүләр XX гасыр антропонимик берәмлекләрен анализлау татар антропонимик системасын алга таба җентекле өйрәнүгә гаять әһәмиятле фәнни юл салалар.

Күренекле татар ономасты Г.Ф. Саттаров татар антропонимикасының аерым тармак булып үсешендә, татар ономастика мәктәбенең дәвамчыларын әзерләүдә бәһасез зур роль уйный. Аның хезмәтләрендә татар антропонимикасының фәне, бурыч-максатлары, методлары тулы итеп ачыла. Шулай ук тарихи чыганаклардан тупланган 20000 гә якын антропонимик берәмлек фәнни әйләнешкә кертелә. Г.Ф. Саттаровның 1975 елда язылган «Татарстан АССРның антропотопонимнары» исемле

докторлык диссертациясендә төрки-татар чыгышлы исемнәрдән барлыкка килгән торак пунктларга җентекле анализ ясала. 1990 елда чыккан «Татар антропонимиясе» хезмәтендә галим татар кеше исемнәренә, фамилияләргә, кушаматларга киң планда тарихи-лингвистик анализ ясый, лексик һәм семантик үзенчәлекләрен әтрафлы тикшерә. Бу хезмәт татар антропонимиясенең сукмагын салуда гаять дәрәҗәдә әһәмиятле хезмәтләренең берсе дип санала. Әлбәттә, татар антропонимиконы һәрдаим үсеш-үзгәрештә булып, төрле сәяси-мәдәни шартларда яңарып, үзгәреп тора. Шуңа күрә, татар антропонимиясен аның борынгы катламы белән чагыштырып өйрәнү, кайбер яңа табылган тарихи чыганаклардагы исемнәрне фәнни әйләнешкә кертү, яңа антропонимиконның үзенчәлекләрен ачыклау бүгенге татар антропонимикасының актуаль бурычларыннан санала, һәм аның татар халкы этногенезының ак тапларын ачуда мөһим эш башкаруын да ассызыкларга кирәк.

Шулай ук тарихи антропонимия үсешендә Ф.М. Хисамованың «XVIII гасыр татар эш кәгазьләренең теле» [1981] дигән хезмәте игътибарга лаек. Галимә бу хезмәтендә XVIII гасырга караган тарихи эш кәгазьләрендәге антропонимнарны фәнни әйләнешкә кертә, аларга лингвистик анализ ясый.

М.И. Әхмәтҗанов 1981 елда язылган «Исследование татарских шеджере в историческом и языковедческом аспектах» исемле тарихи антропронимиянең татар шәҗәрләрендә чагылышын яктырткан кандидатлык диссертациясендә күп сандагы антропонимнарны фәнни әйләнешкә кертә. Татар шәҗәрләре бүгенге көндә Ука елгасы буйларыннан алып, Иртыш, Җим, Җаек елгалары буйларына кадәр саклана. Соңрак чыккан хезмәтләрендә автор XIX йөздә сакланып калган генеологик характердагы мирасны чагылдыра [Әхмәтҗанов, 2012; 2014].

Татар исемнәрен башка төрки халыкларныкы белән чагыштырып, монографик планда өйрәнү А. Шәйхулов хезмәтләрендә чагылыш таба [1983, 2000]. Ул үзенең татар һәм башкорт антропонимикасына багышланган күпсанлы хезмәтләрендә исемнәрнең лексик-тематик төркемнәрен билгели, башка төрки телләрдәге антропонимнар белән чагыштырма аспектта анализ ясый. Шулай ук автор борынгы төрки чыгышлы исемнәрне ономасиологик типологиядән чыгып, системалаштырып өйрәнә. Аның исемнәрне гносеологик принцип нигезендә төркемләве фәнни яктан аеруча әһәмияткә ия.

Рус һәм Көнбатыш Европа чыгышлы татар исемнәре катламы М.А. Җәләлиеваның кандидатлык диссертациясендә һәм

мәкаләләрендә өйрәнелә. Аның хезмәтләреннән күренгәнчә, тормышта барган актив процесслар рус һәм Көнбатыш Европа алынма исемнәренә тиз арада тәэсир итәләр. Татар теленең грамматик, фонетик үзенчәлекләренә ярашып, бу төр алынма исемнәр татар антропонимиконының корпусына үтеп керә башлыйлар. М.А. Җәләлиева хезмәтләрендә XX гасырның 80 нче елларына кадәрге татар антропонимиконының үсеш тенденцияләре чагылдырыла. Әмма соңгы чор татар антропонимиконына алынмаларның үтеп керү сәбәпләре һәм татар теленә адаптацияләнү мәсьәләсе ачыкланмаган һәм өйрәнелүне сорый торган өлкә булып кала бирә.

Гомумән алганда, татар антропонимикасында кеше исемнәрен өйрәнүдә, аерым алганда региональ һәм аерым бер чорлар антропонимикасы юнәлешендә галимнәр тарафыннан зур эш башкарылган. Шулай да татар кеше исемнәре монографик планда этнолингвистик аспектларда махсус фәнни тикшерү объекты булмаган дип әйтергә нигез бар әле.

Татар фамилияләрен өйрәнү мәсьәләсе 1986 елда Ф. Мәҗитованың «Историко-лингвистический анализ татарских фамилий» дигән кандидатлык диссертациясендә һәм мәкаләләрендә чагылыш таба. Аның хезмәтендә тарихи чыганаклардагы татар фамилияләрен лингвистик аспекттан чыгып өйрәнүгә җитди игътибар бирелә һәм фамилияләрнең формалашу чорлары тәгаенләнә.

90 нчы еллардан башлап татар антропонимиясе фәненең үсеше яңа үрләргә омтыла. Бу күренеш галимнәрнең күренекле татар ономатологы Г.Ф. Саттаров җитәкчелегендә якланган диссертацияләрендә чагылыш таба. Антропонимияне өйрәнү, аның максат-бурычларын ачыклау, барлау эше берничә юнәлештә бара: 1) диалекталь антропонимияне өйрәнү; 2) XX гасыр антропонимиясен өйрәнү; 3) антропонимияне гендер аспектта өйрәнү; 4) фольклор һәм матур әдәбият кысаларында татар исемнәрен өйрәнү.

Диалекталь антропонимика татар исемиятенең диалектларда үсешен күзәтүгә багышлана. Себер диалектларында татар исемнәрен өйрәнү Х.Ч. Алишинаның 1990 елда якланган «Себер ономастиконын тарихи-лингвистик аспектта өйрәнү» исемле диссертациясендә чагылыш таба. Ул Тубыл-Иртыш татарларында кулланылган ономастиконга тарихи-лингвистик аспектта анализ ясый. Тубыл-Иртыш татарларында табылган тарихи чыганаклар нигезендә татар исемнәрен монографик планда тикшерә.

Себер татарларының антропонимконын өйрәнү эше Л.Х. Айтбаева диссертациясендә дәвам ителә. Ул Түбән Обь һәм Иртыш елгалары арасында яшәүче Себер татарларының исемнәрен, фамилияләрен һәм аларның ата исемнәрен тикшерә һәм аларның шушы регионга хас гомумтатар антропонимик мирас белән тыгыз бәйләнешен исбат итә [Айтбаева, 2002: 3].

XX гасыр Төмән шәһәрендәге исемнәрне тикшерү эше Г.Ф. Тимканова хезмәтендә башкарыла. Ул Төмән татарларының бу җирләрдә урнашу тарихына, алардагы исем үзгәрешләренең диахроник аспектын, статистик мәгълүматларны да исәпкә алып, җентекле анализ ясый [Тимканова, 2005].

XX гасырның икенче яртысындагы Тура елгасының түбәнге агышында урнашкан татарларның антропонимиясен тарихи-лингвистик планда өйрәнеп тикшерену эше дә зур кызыксыну уята [Замалутдинова, 2007: 3].

Ф.Ф. Гыйльфанова «XVIII–XIX гасырга караган Төмән һәм Тубыл татарларының антропонимиясе. Этник-тарих мәсьәләсенә карата» дигән кандидатлык диссертациясендә, Төмән һәм Тубыл татарларының антропонимнары нигезендә, Себер татарларының этногенез мәсьәләләрен ачыкларга тырыша. Хезмәтенең дәвамы булган «Себер татарларының антропонимиясе этнолингвистик аспектта» (рус архивы документлары нигезендә)» дигән докторлык хезмәтендә автор Себер татарларының исем системасын этнолингвистик аспектта тикшерә. Хезмәттә төмән, тар, бараба, тубыл сөйләшләренең казакъ, башкорт, славян халыклары белән этномәдәни бәйләнешләре өйрәнелә.

Ф.Г. Ваһапованың «Түбән Новгород татарларының XX гасыр антропонимиясенә тарихи-лингвистик анализ» исемле кандидатлык диссертациясендә Түбән Новгородта яшәүче мишәр-татарларның XX гасырга караган исемнәренең фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләре тикшерелә.

Ф.С. Сәлимҗанованың «Тау ягы антропонимиясенең тарихи-лингвистик анализы» хезмәтендә тау ягының антропонимиясе үзенчәлекләре өйрәнелә.

90 нчы еллардан башлап, татар антропонимиясенең XX гасыр исемнәрен өйрәнү аерым юнәлеш буларак билгеләнә. 1999 елда Г.Р. Галиуллина Казан шәһәрендә исем бирү традицияләрен, үсешен, динамикасын монографик планда җентекле өйрәнә. Соңрак, 2010 елда авторның татар антропонимиясен лингвомәдәни аспектта өйрәнгән

җитди хезмәте дөнья күрә [Галиуллина, 2010]. «Лингвокультурология контекстында татар антропонимиясе» хезмәтендә татар антропонимикасының төрки-татар һәм ислам контекстында үсеше ассызыклана. Бу хезмәт лингвомәдәни аспектта татар исемнәрен фәнни яктырткан үзенчәлекле хезмәт булып санала.

Тарихи-лингвистик аспектта антропонимиянең башка берәмлекләрен яктырту да күз уңыннан китми. Шулардан С.И. Гасыймованың «Татар кушаматларына тарихи-лингвистик анализ» [2006], З.И. Хөснуллинаның «Казан шәһәренең XX гасыр фамилияләренә тарихи-лингвистик анализ» [2006] дигән кандидатлык диссертацияләрен күрсәтеп китәргә мөмкин.

Татар антропонимнарын гендер үзенчәлекләрен аерып өйрәнү эше 2007 елда башкарыла. Бу юнәлештә Г.С. Хаҗиеваның «Татар ир-ат исемнәренә тарихи-лингвистик анализ» [2007], М.З. Вәлиеваның «Татар хатын-кыз исемнәренә тарихи-лингвистик анализ» [2007] дигән кандидалык диссертацияләре языла. Соңрак бу хезмәтләр тулыландырылып монография буларак, дөнья күрәләр. Г.С. Хаҗиеваның «Татар ир-ат исемнәре» монографиясендә [2008] татар ир-ат исемнәренең лексик-семантик үзенчәлекләре, этнолингвистик катламнары ачыклана, «Ревизская сказка», ЗАГС материалларыннан файдаланып, XIX, XX гасырга караган татар ир-ат исемнәре фәнни әйләнешкә кертелә. М.З. Вәлиеваның «Татар хатын-кыз исемнәре» хезмәтендә татар хатын-кыз исемнәренең үзенчәлекләре ачыла. Фәкать хатын-кыз исемнәренә генә хас булган үзенчәлекләр ассызыклана [2012].

90 нчы елларда татар антропонимик системасын этнолингвистик юнәлештә өйрәнү башлана. Бу җәһәттән, Ф.С. Баязитованың 1998 елда «Этнолингвистические исследования татарских говоров региона юго-восточного Закамья Татарстана» хезмәте игътибарга лаек. Анда татарларның рухи мәдәнияте һәм шул исәптән татар исемнәре этнолингвистик аспектта тикшерелә. Авторның әлеге тикшеренүләрнең дәвамы булган «Халык традициясе лексикасы. Бишек туе» исемле монографиясендә [2012] бала табу, исем кушу, тәрбияләү, үстерү традиция-йолалары һәм аларга нисбәтле лексика тематик төркемнәргә салып тикшерелә. Ул хезмәт татар антропонимиясен этнолингвистик аспектта анализлауның беренче адымы дип саналырга хаклы.

М.З. Зәкиевнең тарихи антропонимика юнәлешендә язылган «Борынгы төрки ономастикасы һәм аның морфонологиясе» [2013] исемле китабында борынгы төрки антропонимиянең берничә чоры билгеләнә:

1) скиф чорына кадәрге борынгы төрки антропонимнар; 2) икенче скиф чорының борынгы антропонимнары; 3) скиф чорыннан соңгы чоры [Закиев, 2013: 279–290]. Академик М.З. Зәкиев бу хезмәтендә татар антропонимиясенең тагы да архаик катламнарын билгели, ул чорларга караган антропонимик берәмлекләрнең этимологиясен бирә.

Төрки халыкларда да татар антропонимиясен өйрәнү үзбәкләрдә – Э.А. Бегматов, казакъларда – Т.Ж. Жанузаков, З.Р. Жаненова, Г.И. Кулдеева, Г.Ниетбайтеги, кыргызларда – С.М. Абрамзон, Ш. Жапаров, төрекмәннәрдә – Ш. Аннаклычев, башкортларда – Кузеев, З.Г. Ураксин, Т.Х. Кусимова, Ф. Хисаметдинова, А. Шайхулов, Р.З. Шакуров, З.М. Раемгужина, Р.А. Сөләйманова, азәрбайҗаннарда – Г.Р. Алеев, Р.Ф. Халыгова, М.Н. Чобанов, төрекләрдә – Б. Аталай, Ш.Үлкүтраш, Ә. Җәфәроглу, С. Сакаоглу, Д. Аксан, А. Эрола, Ш. Акалын, Н. Кая, Али Ш. Бозкаплан һ.б. ның хезмәтләрендә чагылыш таба.

Кеше исемнәре, фамилияләр, кушаматлар һәм башка антропонимик берәмлекләр, аларның мәгънәләре һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Исемнәр мәсьәләсен өйрәнү, булган тәҗрибәгә таянып, аны яңа фәнни юнәлешләр кысаларында тикшереп чишү һәрвакыт актуаль санала. Ни өчен андый исем кушканнар, ул исемнең мәгънәсе нидән гыйбарәт, аның язмышка тәэсире нинди – бу һәм башка шундыйрак сораулар, уйланулар кешелекне инде борынгы чорлардан ук кызыксындырган, борчыган. Исем ул – халык хәтере, халык мирасы, халык тамгасы. Нәсел җепләрен бәйли торган тирән мәгънәгә ия сүз дә ул исем.

## Беренче бүлек

# ТАТАР КЕШЕ ИСЕМНӘРЕНЕҢ ЭТНОЛИНГВИСТИК КАТЛАМНАРЫ

Татар халкының гасырлар дәвамында кардәш һәм кардәш булмаган халыклар белән сәяси-иҗтимагый-мәдәни багланышлары антропонимик системаның тулылануына, аерым бер катлам исемнәрнең барлыкка килүенә һәм үсешенә китерә. Шуңа күрә билгеле бер тарихи-лингвистик һәм географик алшартларда, төрле кавемхалыкларның үзара коммуникатив арадашлыгы процессында формалашкан татар исемиятендә этнолингвистик катламнарның төрлелеге исемнәренең тарихи-лингвистик үсешен «катып калган» система эчендә генә түгел, бәлки кеше эшчәнлеге нәтиҗәсе итеп карарга мөмкинлек бирә. Аеруча этногенез, этнография, халык көнкүреше һ.б. турында өстәмә мәгълүматлар бирүдә татар исемнәрен кеше эшчәнлегенең этномәдәни берәмлеге буларак өйрәнүнең гаять дәрәҗәдәге әһәмиятен билгеләргә кирәк.

Татарстан һәм аның белән чиктәш территорияләрдә биш этник дөньяның: борынгы иран кабиләләренең (сармат-аланнарның һ.б.), фин-угыр, төрки, монгол һәм славян халыкларының кисешүе татар антропонимиясендә шактый катлаулы стратиграфик катламнар тудыра һәм аларның бер-берсенә йогынтысын барлыкка китерә. «Бер генә халык та үз эченә бикләнеп яши алмый. Әүвәл башка кабиләләр белән, соңга таба төрле халыклар, дәүләтләр белән аралашу нәтиҗәсендә татар теленә теге яки бу телдән алынмалар килеп керә. Алынмаларның иҗтимагый-тарихи җирлеге төрле була. Бер халыктан, матди байлык элиментлары алышканда, теге яки бу сүзләр керсә, икенче халыктан сәясәткә, мәдәнияткә, әдәбиятка, дингә, сәүдәгә һәм башка мөнәсәбәтләргә бәйле алынмалар килеп керү» [Сафиуллина, 1999: 66] процессы татар антропонимик системасын читләтеп үтми. Шул рәвешле, гасырлар дәвамында татар халкының башка халыклар белән тыгыз мөнәсәбәттә булуы татар антропонимик системасының тулылануына һәм аерым бер катлам исемнәрнең үсешенә китерә. Әмма татар антро-

понимик системасы статик халәттә, аерым бер калыпларга салынган закончалыкларга гына буйсынып яшәми. «Төрки телле пласт», «иран телле пласт»лар аерым гына түгел [Никонов, 1974: 93], алар белән бергә иҗтимагый үсеш, иҗади мөмкинлекләренең нәтиҗәсе саналырга хаклы катлаулы кушылмалар (гибрид исемнәр), ономавариатларның да антропонимик системада урын алуын билгеләп үтәргә кирәк. Татар антропонимикасында чыгышы ягыннан төрле булган компонентлар кушылмасыннан ясалган исемнәр (гибрид кушылмалар) шактый күп. «Кеше исемнәре язма һәм сөйләмә телдә озак яшиләр» [Саттаров, 1982: 23], чөнки кайбер төрки антропонимик материал яңа исемнәрдә яңару процессы кичерә. Димәк, татар исемнәре системасы һәрдаим үзгәреш кичереп, шул ук вакытта борынгы антропонимик берәмлекләрне югалтмыйча, аларны яңартып, тулыландырып яши. Шуңа күрә татар исемнәре системасын стратиграфияләү антропонимик киңлекне күзалларга, тикшерү аспектларының үткәнен генә түгел, ә киләчәген дә белергә мөмкинлек бирә. К.М. Мусаев, «төрки антропонимнарын системалы рәвештә анализлау өчен бердәм классификация үткәрергә кирәк» [Мусаев, 1984: 206], дип саный. Г.Ф. Саттаров исемнәрнең этнолингвистик катламнарга бүленешендә «исемнәрнең беренчел мәгънәләрен ачу, лексик номинацияләрен ачыклау һәм морфологик структурасын, фонетик деформацияләрен билгеләү, татар теленең сүзлек составы турында өстәмә мәгълүматлар бирү» әһәмиятен билгеләп, түбәндәге этнолингвистик катламнарны аерып күрсәтә:

1. Гомуми алтай катламы исемнәре;
2. Борынгы төрки катлам исемнәре;
3. Иске татар катламы исемнәре;
4. Гарәби чыгышлы катлам исемнәре;
5. Фарсы чыгышлы катлам исемнәре;
6. Рус һәм аның аша кергән Көнбатыш Европа катламы исемнәре;
7. Яңа татар исемнәре катламы исемнәре;
8. Ясалма исемнәр [Саттаров, 1982: 23–28].

Шушы этнолингвистик классификация нигезендә һәм татар әдәби теле тарихы һәм аны дәверләргә бүлүдән чыгып, татар антропонимик системасы формалашуының һәм үсеш тенденцияләренең шартлы рәвештә берничә үсеш этабын аерырга мөмкин. Һәрбер чор тарихи вакыйгаларга, тарихи шартларга нисбәтле этапларга бүленә, шул ук вакытта чорлар арасында конкрет чикләр куелмый:

1. Татар антропонимик системасы формалашуында алтай чоры;

2. Татар антропонимик системасы формалашуында борынгы төрки чор;

3. Татар антропонимик системасы формалашуында иске татар чоры (X гасыр – XV гасыр).

5. Яңа татар чоры антропонимик системасы (XVI гасыр – XX гасыр башы);

6. Хәзерге чор татар исемияте (XX гасырның 20 нчы еллары – XXI гасыр башы).

Димәк, татар халкы тарихы һәм мәдәниятендә тирән эз калдырган кабилә һәм халыкларның йогынтысы, аларның дөньяви карашлары, милли этник күзаллаулары татар халкының милли антропонимик системасын формалаштыруда, һичшиксез, билгеле бер роль уйный. Татар исемнәрен, аларда сакланып калган борынгы элементларны этнолингвистик аспектта системалы тикшерү татар халкының аерым бер халык яисә кабиләләр белән генетик уртаклыкларын, этномәдәни бәйләнешләрен ачыкларга ярдәм итә.

## § 1. Татар кеше исемнәренең алтай катламы

Алтай чоры төрки, монгол, тунгус-маньчжур телләре үсешендә мөһим булган уртак тел белән характерлана. Әлеге телдә грамматик, фонетик, лексик закончалыкларның уртаклыгы төрки, монгол, тунгус-маньчжур телләренең генетик кардәшлеге турында сөйли [Баскаков, 1981: 155]. Төрки, монгол һәм тунгус-маньчжур телләренең уртак сүзләрендә алтай чорының борынгы лексик элементлары гомуми алтай катламына караган антропокомпонентларда билгеләнәләр [Саттаров, 1982: 24]. Халыкның гасырлар буена тупланган алтай катламы татар исемнәре сан ягыннан күп түгел, шулай да төрки, тунгус-маньчжур, монгол телләре гомумилеген исбатлауда мөһим чыганак булып торалар. Бу чорга караган исемнәрне ир-ат һәм хатын-кыз исемнәренә аеру да күзәтелми һәм бу үзенчәлек исемнәрнең структураларында да, семантикаларында да чагылыш тапмый. Татар телендәге *алтын* компоненты нигезендә ясалган исемнәр алтай чорына карый. Мәсәлән: *Алтын, Алтынбай, Алтынай, Алтынбулат, Алтынгали, Алтынгол, Алтынгәрәй*, *Алтыннур* кебек татар ир-ат исемнәрен билгеләргә мөмкин. Алтын антропокомпоненты «Борынгы төрки сүзлектә» – *алтун* [ДТС, 1969, 40], «Тунгус-маньчжур телләренең чагыштырмалы сүзлеге»ндә маньчжур телендә – *алтахату*, нанай телендә *алта* [ССТМЯ, 1975: 33] булып билгеләнә. Татар телендәге

*алтын* сүзе монгол телендә – *алтан*, бурят телендә – *алт(н),* калмыкларда – *алтн* буларак кулланыла. Татар телендә – *Алтын, Алтынбай, Алтынбәк, Алтынчура*; бурятларда – *Алтан, Алтан Шагай, Алтан Хайша;* борынгы төрки телдә – *Altun gayan, Altun gara, Altun taj sarjun, Altun tamyan* [ДТС, 1969: 40] кебек исемнәрне билгеләргә мөмкин. Татар телендә *бай* компоненты кулланылса, монгол телендә – *баян,* бурятларда – *баян* «бай» мәгънәсендә килсә, тунгус-маньчжур телләрендә – *bayan*, якут телендә – *бай* [ССТМЯ, 1975: 65], борынгы төрки телдә – *baj* [ДТС, 1969: 79] сүзләре исем компоненты булып кулланылалар. Мәсәлән, татар ир-ат исемнәре – *Байчура, Байбүре, Байбарс, Байбулат, Байкотлы, Байбуга, Байарслан, Байтимер, Байтирәк*; бурят исемнәре – *Баян, Баяндай* [ДТС, 1969: 79]. Татар телендә *арслан* кулланылса, монгол телендә – *арслан(г),* бурят телендә – *арсалан*, маньчжур – *арсалан* [ССТМЯ, 1975: 52], борынгы төрки телдә *arslan* [ДТС, 1969: 51] кулланыла. Мәсәлән, *Арслан, Арсланбай, Арсланбәк* – татар ир-ат исемнәре; *Арсалан, Арсалан-Жап* – бурят ир-ат исемнәре; *Arslan balban, Arslan tegin* – борынгы төрки ир-ат исемнәре. Борынгы төрки телдә кулланылган Буга «үгез» татар теле диалектларында «көчле, батыр» дигән мәгънәдә дә очрый [ДТС, 1969: 116], бурят телендә – *буха* «үгез», монгол телендә – *бух* «үгез», якут телендә – *бука* «үгез» мәгънәсендә килә [ССТМЯ, 1975: 104]. Чаг. *Буга, Бугаарслан, Акбуга, Исәнбуга, Алабуга, Байбуга, Тайбуга* – татар ир-ат исемнәре; *Буха, Буханай* – бурят ир-ат исемнәре; *Ara buga Esan buga* – борынгы төрки ир-ат исемнәре [ДТС, 1969: 116]. *Батыр, Батырбай, Батырша, Батыршан, Батырбәк* кебек ир-ат исемнәрендәге *батыр* антропокомпоненты борынгы төрки телдә *batur* формасында «герой, батыр» [ДТС, 1969: 89] мәгънәсендә кулланылган. Шулай ук *batur* компоненты башка төрки халыкларда да билгеләнә. Шул ук мәгънәдә, үзгәрешсез рәвештә, *батыр* буларак татар, казакъ, кырым татарларында, *батир* – үзбәкләрдә, *batur* [Эрол, 1992: 52] төрекләрдә кулланылыш тапкан. Тунгус-манчжур телләреннән эвенк телендәге *багади* [ССТМЯ, 1975: 61] формасы «көчле; батыр» дигәнне аңлата; маньчжур телендә *батору/батуру* «герой; пәһләван» мәгънәләрендә кулланылган [ССТМЯ, 1975: 61–62]. *Сай-саин* антропокомпоненты монгол телендә, «матур, яхшы» дигән мәгънә белән бергә, титул атамасын («министр, сановник») да белдереп килә; бурят телендә *наин* «яхшы» мәгънәсенә кулланыла [ССТМЯ, 1977: 55] Татар антропонимиконында *Саин, Сайкай, Ирсай, Сайман, Сайхан, Сайган* кебек исемнәр составында

очрый. Төрекләрдә *Сайым* исеме теркәлгән [Эрол, 1992: 58]. Монгол телендә *Сайшал, Сайхан* кебек ир-ат исемнәре бар [МРС, 1957: 344]. Япон телендә *Сайси, Сай, Сайка, Сайдзи* исемнәре теркәлүе [СЯИФ, 1958: 1110] сай компонетлы ир-ат исемнәрнең бик борынгы чорлардан ук килүен раслаучы факт булып тора. *Чан-чоно* антропокомпоненты монгол телендә «бүре» дигәнне аңлата [Саттаров, 1998: 280] һәм ир-ат исемнәре ясауда катнаша. Бу компонент татар телендә *Чангол, Чанчура, Чанчык, Чаныш* [Саттаров, 1998: 280] кебек ир-ат исемнәрендә чагылыш таба. *Балтай, Балтабай, Балтабәк* кебек ир-ат исемнәрендә кулланылган балта антропокомпоненты алтай катламына керә, чөнки борынгы төрки телдәге *балту* [ДТС, 1969: 45] формасы «балта» сүзен аңлатса, алтай, якут, тува, хакас телләрендә *балту/балду* формасында [ССТМЯ, 1975 65]; венгр телендә *balta/baltu* «балта», монгол телендә *бата* «чүкеч» [МРС, 1957: 52] буларак кулланыла.

*Баһадир* антропокомпонентын да алтай катламына кертеп карарга кирәк дип саныйбыз, чөнки *батыр/баатыр/батур/ботир// багатур* формасы күп кенә төрки халыкларда очрый һәм *баһадур/ баһадир* сүзләре батур формасыннан шактый соң барлыкка килгән [Кульдеева, 2001: 47]. *Баһадир*, *баһадур* сүзе фарсы-чагатай телендә «батыр, пәһләван» дигәнне аңлата. Бу сүз монгол телендә «баатур, багатур» формасында «бик йөрәкле кеше, юлбашчы, ир-егет» дигән мәгънәгә ия булып тора [Әхмәтьянов, 2001: 37] Төс белдерүче *ала*, *кара* сүзләреннән ясалган ир-ат исемнәре дә бу катламга керәләр. *Ала* сүзе эвенк телендә *ала-алай* шәкелендә килсә, нанай телендә – *сиих,* маньчжур телендә – *алха*, монгол телендә – *алаг* сүзләре «пестрый, пятнистый» мәгънәсен [ССТМЯ, 1975: 27] белдереп киләләр. *Алаҗан, Алабәк, Алабай, Алата*й кебек ир-ат исемнәрен мисалга китерергә мөмкин. *Кара*, борынгы төрки телдән тыш [ДТС, 1969: 423], эвенк телендә «сивый, темносерый» мәгънәсендә килсә, маньчжур, монгол, якут, нанай телләрендә «черный, темный» мәгънәләрен аңлата [ССТМЯ, 1975: 379]. Татар антропонимикасында *Карабай, Каракай, Карагол, Каракаш* кебек ир-ат исемнәрендә бу компонент сакланып калган, бүгенге көндә фамилияләр составында очрый. Димәк, алтай катламы ир-ат исемнәре, борынгы алтай чорында ук формалашып, төрки, монгол, тунгус-маньчжур телләренең исем системаларында да сакланганнар. Татар антропонимиконында *арслан, алтын, саин-сай, батыр* кебек антропокомпонентлар бүгенге татар ир-ат исемнәренең компонентлары булып киләләр.

## § 2. Татар кеше исемнәренең борынгы төрки чор катламы

Татар теле үзенең үсешендә озын һәм катлаулы юл үткән. Бу мәсьәлә төрки халыкларның үсеше белән тыгыз карала. Төркиләрнең безнең эрага кадәр III–II меңьеллыкта яшәгәнлекләре билгеле. Аларның үзләренә генә хас теле, мәдәнияте, яшәү рәвеше булуы да мәгълүм. Төркиләр күккә, кояшка, айга табынып яшәгәннәр. Аларның бердәнбер Алласы – Тәңре булган. Борынгы төркиләр тәңречелек культына буйсынганнар. Борынгы төркиләрнең тирә-юнь чынбарлыгына булган күзаллаулары, табигый ки аларның антропонимик системаларына тәэсир итми калмый. Борынгы төрки исемнәр катламы формалашканда, һәм телнең тарихи үсеш үзенчәлекләрен төрле субстрат, адстрат элементларның бәйләнешен үз эченә туплап, төрки халыкларының дәүләтчелекләрен барлыкка китергән һәм аларның үсеш этапларын да чагылдырган катлаулы бер системасын булдырган. Борынгы төрки катлам исемнәре төрле дәрәҗәләрдәге, бердәм комплекстагы төрки этник төркемнәрнең (болгар, кыпчак, угыз, карлук, уйгыр-угыз, кыргыз-кыпчак) үзара бәйләнеше белән үзенчәлекле. Татар антропонимикасының төрки катламы төрки телләр үсеше чорларында (Борынгы төрки чорда, ягъни (V–X гасырлар), Урта төрки чорда (X–XV гасырлар), Яңа төрки чорда (XV–XX гасырлар) формалашкан һәм, шул нигездә, халыкның рухи һәм матди мәдәниятен тулы итеп чагылдырган. Төрки халыкларда антропонимнарның беренче үрнәкләре орхон-енисей, уйгыр язмаларында билгеләнә. Исем үрнәкләре Орхон-Енисей язмалары лингвистик комментарийлар белән бирелгән хезмәтләргә нигезләнеп тикшерелде (Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969; Е. Малов. Енисейские памятники древних тюрков. М.. 1959; M.Ergin Orhun Abideleri. İstanbul, 1992, T.Tekin. Orhun Yazıtları. Ankara, 1988; Eski Uygur Türkçesi Sözlüğü. İstanbul, 1968).

Безнең эрага кадәр VIII–VI гасырларда Үзәк Азияне, Төньяк Кытай, Монголия, Себер, Казакъстан, өлешчә Иран җирләрен үз эченә алган Төрки каганлык – төрки халыкларның дәүләте төзелә. Төрки каганлык чоры – гомумтөрки мәдәниятнең оешып бетеп, үзенә күрә бер борынгы классик үсешкә ирешкән вакыты. Шул чорда тәмам оешып җиткән тәңречелек төрки халыкларда ислам дине кабул иткелгәнче гамәлдә була [Дәүләтшин, 1999: 429]. Борынгы төрки дин, манихей, зороастризм, православие, ислам, буддизм кебек үк, дөньяви күзаллауларның концепциясен тәшкил итә [Безертдинов, 2001: 51]. Татар исемнәренең борынгы төрки катламы тәңречелек концепциясендә

кеше һәм табигать стихиясе бәйләнешен характерлый. Кеше һәм табигать бәйләнеше турыдан-туры Күк-тәңре атрибутларыннан саналган кояш, ай, йолдызлар культы атамаларыннан ясалган борынгы төрки ир-ат исемнәрендә чагыла. Мәсәлән, бүгенге көндә дә татарларда, башкортларда [Шайхулов, 1983: 11-–12], төрекләрдә [Эрол, 1992 28], үзбәкләрдә [Бегматов, 1965], казакъларда [Кульдеева, 2001: 207] ай, *күк-гөк, офык, көн, таң* кебек антропокомпонентлардан ясалган ир-ат исемнәре борынгы төрки катлам ир-ат исемнәренә карыйлар. Шулай ук космонимия, төрле табигать күренешләре атамалары нигезендә ясалган ир-ат исемнәре борынгы катлам исемнәрен тәшкил итәләр. Тәңре – төрки халыкларда синкретик күренеш. Ул, фәлсәфи субстанция буларак, һәрнәрсә һәм һәрнәрсәне барлыкка китерүнең сәбәбе булып тора (Бер Тәңре!) һәм, теистик субстанция буларак, нәсел башы, яхшылык һәм яманлык чыганагыда (Тәңребиргән!). Руник язмаларда чынбарлык Тәңре тарафыннан яратылган дип языла. Тәңре – борынгы төрки дөньяның югары хакимлеккә ия көче. Төркиләр аны Күк-тәңре дип тә атаганнар. Космосның бер өлеше, Тәңре буларак, руник текстларада *kök tenri* дип аталган һәм борынгы төрки чыганакларда төрле формада чагылыш таба, *kök (kök qalyq, qalyq «hава»);* шуңа күрә аның тагы бер мәгънәсе якын күк йөзе, кошларга якын күк йөзе белән дә бәйләнешле аңлатыла [Кляшторный, 1981: 121]. Борынгы төрки дини күзаллаулар буенча Тәңре ул, беренче чиратта, Күк тәңресе. Тәңре дөньядагы һәрнәрсә белән, кеше язмышлары белән идарә итә. Борынгы кеше галәмне яраткан Күк-тәңрегә буйсына [Исхаков, 2007: 39; Дәүләтшин, 1999: 79]. Билге каганнның кече улының исеме Күк-тәңрегә бәйле – Тәңре каган (734–741 еллар). Борынгы кеше галәм, хаос, җиһанны тудырган күк алласына буйсына, Тәңре кулында яши. Илаһи көчнең атамасы булган Тәңре сүзе [Гумилев, 1994: 340; Дәүләтшин, 1999: 58–59] татар исемнәрендә (Тәңребиргән, Тәңребирде, Тәңрегол) һ.б. да кулланылган һәм казакъ [Кульдеева, 2001, 117], үзбәк [Бегматов, 1965], кыргыз [Жапаров, 1992: 132], төрек [Эрол, 1992: 61] һәм башка төрки халыкларның уртак хәзинәсен тәшкил иткән. Р. Әхмәтьянов чыңгыз исеменең этимологиясен *тәңре* атамасына бәйле карый. Аның фикеренчә, *чынгыз* < *тыцыр* < *таңыр* рәвешле фонетик үзгәрешләр кичереп, «күк алласы» дигән мәгънәне белдерә [Әхмәтьянов, 2001: 196]. Н.Л. Жуковская Чынгызхан антропонимы монгол империясе башлыгының титулына бәйле дип саный. Ике компоненттан торган бу титулның *чыңгыз* компоненты төрки-монгол телендә *tenggis* «океан»,

«бөек», «чиксез зур» кебек мәгънә аңлатуын күрсәтә [Жуковская, 1980: 9]. Безнең карашыбызча, Чыңгыз исеме монгол телендәге *чин* «твердый, непоколебимый» [МРС, 1957: 636] һәм *гийх* «радоваться» [МРС, 1957: 117] компонентларының кушылуыннан ясалган булырга мөмкин. Бу чорга караган антропонимик берәмлекләр Күлтәгиннең Зур һәм Кече язмаларында (732 ел), Билге каганга (Могыйлән ханга) (735), Төньюкукка (712–716), Кол Чурага (759), Енисей язмалары чыганакларындагы ядкәрләрдә сакланып калган. Бу язмаларда, антропонимик системадан тыш, борынгы төркиләрнең яшәгән урыннары, беренче төрки дәүләтләр, ил башлыклары, аларның сәясәте, ул вакытларда яшәгән халыклар турында да мәгълүматлар бирелә. Рун һәм Енисей язмалары татар антропонимик системасының үсешен чагылдырган әһәмиятле язма чыганак булып тора, чөнки бу ташъязмаларда төгәл язылу датасы күрсәтелә.

Орхон-Енисей язмаларында сакланып калган антропонимнар составында титуллар билгеләнә. Борынгы төркиләр бала тугач, аңа башта кендек исеме кушсалар, үсә төшкәч, «үсмер исеме» биргәннәр, гаскәр булгач исә егет «гаскәр исемен» ала, батырлык күрсәткәннән соң янә исеме үзгәрә. Бу күренеш Енисей язмаларында түбәндәгечә яктыртылган*: oɣlan atïm čubuč ïnal ärtä ätïm kümül ögä* «минем үсмер исемем – Чабуч-инал, гаскәри исемем – Огя кюмлей».

Антропонимнарның семантик составы лексик компонентларның төрлелеге, шул исәптән, титулатур лексиканың кулланылуы белән билгеләнә. Орхон язмаларында, нигездә, югары катлауга караган исемнәр теркәләләр. Шуңа күрә титулатур лексиканың исем составында кулланылуы табигый. Титулатура бары тик аерым бер иҗтимагый катлауны гына белдереп калмый, ә шул ук вакытта фамилия функциясен дә үти. Шулай ук фамилия функциясен кешенең этник кабиләсен белдергән атамалар да башкара. Семантик мәгънәсеннән чыгып, борынгы төрки ташъязмалардагы исемнәрнең берничә төрен билгеләргә мөмкин: Титулатура нигезендә ясалаган борынгы төрки кеше исемнәре Орхон-Енисей, уйгур чыганакларында теркәлгәннәр: *Билге Каган, Кюл Тегин, Кюл Ич Чор, Кутлуг Шад, Бойла Бага Таркан* һ.б.

Борынгы төрки телдә һәм исемнәр составында түбәндәге төрки чыгышлы титулатура атамалары очрый: *kağan* «каган», *beg* «бәк», *buyruk, šad, katun, kan, tigin, tarkan, urungu, boyla, bilge, tamgan, inançu, oğlan; saŋgun, çigşi* һ.б.

Кайбер титулатура атамаларының исем составындагы кулланылышлары түбәндәгечә билгеләнә: *Buyruk / Buyuruk* атамасы бөтен титул атамаларын гомумиләштерә *Kutluğ Bağa Tarkan Öğe Buyruku ben* (Мин – Кутлуг Бага Таракан Оге Буйрук); *Beg* «бәк», «князь»: *Bilge Beg, Beg Arslan, Beg Bars, Beg Boga, beg Çur, Beg Timur, Beg Turmuş, Ürüng Beg*; *Çur/Çor* «югары дәрәҗәгә ирешкәнче бирелә торган титул»: *Tegin, Beg Çur, Kül Çur, Küli Çor, Oglan Çur, Yegen Çur; Kagan* «каган»: *Ay Kagan, Altun Kağan, Baz Kağan, Bilge Kağan, İltiriş Kağan, Kül Bilge Kağan, Kapgan Kağan, Oğuz Kagan; Boyla: Boyla Bağa Tarkan, Boya Kutltuğ Yargan*; *Kan/Han* «хан, дәүләт башлыгы»: *Kan Elçi, kan Oğul, Kan Toyin, bars Kan Sangun, Böğü Kan, Kara Kan* һ.б.

Таркан титулы төрки каганлыкларның югары гаскәри-административ иерархиясен билгели [Кляшторный, 1981: 136]. Орхон-Енисей язмаларында таркан компоненты нигезендә ясалган исемнәр: *Ayluç Tarkan, Altun Tamgan Tarkan, Kegilinç Tarkan, Oğul Tarkan, İşbara Tarkan* һ.б.

*Tigin / Tegin / Tekin* атамасы хан гаиләсенең түбән катлау әгъзаларында [ДТС, 1969: 547] чагылыш таба. Түбәндәге исемнәр билгеләнәләр: *Alp Tegin, Esen Tegin, Yaruk Tigin, Kül Tigin, Kümüş Tigin, Kutlug Tigin, Oğul Tigin, Özmış Tigin* һ.б.

*Tutuk* компоненты М. Кашгари сүзлегендә кеше исеме буларак билгеләнә. Борынгы төрки язмаларда *тутук* компоненты икенче компонент буларак кулланыла. Бу сүз «баш командир» мәгънәсендә йөри: *Tutuk, Adak Tutuk, Alp Tutuk, Budak Tutuk, Buzaç Tutuk, El Togan Tutuk, Yabaş Tutuk, Yağmış Tutuk, Kök Amaş Tutuk, Künç Tutuk, Öz apa Tutuk, Soyan Tutuk, Tay Bilge Tutuk Şad* «феодал»: *Mogilyan Şad, Kutlug Şad, Bögü Şad* һ.б.

*Čigsi/čiksi*: *Bağatur Çigsi, Çik Bilge Çiksi, Kül Çigsi, Kadır Çigsi, Kutlug Çiğsi, Urungu Tudun Çigsi Uruŋu* «гаскәри ранг» [Кормушин, 2008: 303]: *Urungu Sangun, urungu Tudun Çigsi, Alp Urungu Tutuk, İnal Urungu, Kül apa Urungu* һ.б.

*Er* «ир кеше» [ДТС, 1969: 175]: *Er Börü, Er Boga, Er Sançmış, Er Togmuş, Er Tonga, Er Ansak Tösek, Alp Er Tonga* һ.б.

*Yabgu* титулы каганнан соң бирелә торган титулны аңлата. *İki oğlıma yabgu, şad atı birtim* «Ике улыма да ябгу титулын бирдем». Түбәндәге кеше исемнәре составында кулланыла: *Dip Yabgu, Ağım Yavkuy, Kurs Yavkuy, Kay Yabğu Han, Ulamdur Yavkuy Han* һ.б.

Борынгы төрки телдә хатын-кыз исемнәре аз очрый. Хатын-кыз исемнәре *katun* компоненты нигезендә ясалалар: *İlbige Katun,*

*Oğlağu Katun, Terken Katun, Kuma Katun, Kut Tengri Katun, Turuş Katun* һ.б.

Димәк, алдагы мисаллардан күренгәнчә, исем һәм титул арасында чик булмый. Титул исем урынында да, аның составында да йөри. Төрки антропонимиянең үсеше процессында титуллар исем функциясен үти башлыйлар.

Орхон-Енисей язмаларында чагылыш тапкан исемнәрдә кешенең физиологик һәм рухи үзенчәлекләрен яктырткан исемнәр дә билгеләнәләр. Югары катлау вәкилләрен характерлаган эпитетлар кеше исемнәре составында кулланылган: *bilgä* «акыллы» [ДТС, 1969: 99], *alp* «укчы, герой, батыр» [ДТС, 1969: 36], *külüg* «танылган» [ДТС, 1969: 329], *küçlig* «көчле, куәтле» [ДТС, 1969: 323]. Хан, каганнарның исеменә акыл, көч, кодрәт кебек үзенчәлекләрне яктырткан сүзләр өстәлү дә очрый. Борынгы төркиләр кешегә хас үзенчәлекләрнең һәм бу кешеләрнең үзләрен дә Тәңре тарафыннан бирелүенә ышанганнар. Орхон-Енисей язмаларында болай дип языла: *Tengride bolmuş, Tengri teg kut bulmuş, Tengri kötürmüş, Tengride kut bulmuş.*

*Bilgä* «акыллы» [ДТС, 1969: 99]: *Bilgä Kağan, Bilgä Işbara Tamğan Tarkan, Bilgä Köngül Sangun, Bilgä Küli Çur, Bilgä sangun, Bilgä Tonyukuk, İnanöu Bilgä, Çik Bilgä Çiksi* һ.б.

*Külüg* «нинди дә булса характерга, үзенчәлеккә ия» [ДТС, 1969: 444]: *Külüg Çigsi, Külüg Çur, Külüg İnan Çaça Sengün, Külüg Şangun, Külüg Tirig, Külüg Tutuk, Külüg Urungu* һ.б.

*Kutluğ* «тормыш көченә ия; бәхетле, бәхет бирүче» [ДТС, 1969: 473]: *Kutluğ, Kutlug Bağa Tarkan, Kutluğ Bayutmış, Kuyluğ Bört, Kutluğ Oğul, Kutluğ Kağan Temir* һ.б.

*Küç* «көч»: *Küç Barlığ, Küç Kül Tutuk, Küç Tegin, Küç Temir, Kılıç Küç Kara, Küç Kıyagan* һ.б.

*Esan* «сәламәт, нык» [ДТС, 1969: 183]: *Esen, Esan Buka, Esen Kaya, Esen Tegin Esen Timur, Esen Tutuk* һ.б.

*Ulug* «зур, көчле» [ДТС, 1969: 610]: *Ulug ordu Beg, Ulug Türük* һ.б.

Борынгы төрки телдә хайван һәм кош атамалары да исемнәр ясауда зур роль уйный. Ир-ат исемнәрендә ерткыч хайван атамалары кулланылса, хатын-кыз исемнәрендә матур хайван атамалары кулланыла: Bars «тигр» [ДТС, 1969: 84]: *Bars Beğ, Bars Kan Sangun, Bars Urungu, Kutadmış Bars, Küç Barslığ, Bars Boğa, Tüz Bay Bars, Kara Bars, Oğul Bars; Arslan* «лев» [ДТС, 1969: 55]: *Arslan Tegin, Arslan Balban, Arslan Çik Toğrıl, Çiğil Arslan; Toğrul* «ерткыч кош» [ДТС, 1969: 571]: *Adam*

*Toğrul, Alp Toğrul, Basa Toğrıl, Ozmış Toğrul, Kutan Toğrıl; Altun* «алтын» [ДТС, 1969: 40]: *Altun Kağan, Altun Kara, Altun Tay Sangun, Altun Tamgan Temür; Temir* «железо» [ДТС, 1969: 551]: *Beğ Temir, Temir Buğa, Esen Temir, Temir Elçi, Tölek Temir, Otunç Temir, El Temir* һ.б.

Билгеле булганча, борынгы төркиләрдә исем алыштыру йоласы була. Л.Н. Гумилёв болай яза: «Төрки халык, европалылар кебек, туганнан бирле бер үк исемне йөртмиләр. Төрки кешенең исеме аның иҗтимагый тормышта тоткан урынын күрсәтеп торган: бала вакытта ул – кушамат йөртә, үсмер вакытта – чин, ир булгач – титул, әгәр ул хан булса, аның исеме чин баскычы нигезендә үзгәреш кичерә» [Гумилев, 1967: 82]. Борынгы төрки һәм башка төрле тарихи чыганаклардан мәгълүм булганча, Орхон-Енисей язмалары адресат тарафыннан языла. Шуңа күрә ташъязмаларда кешенең вазифасы, тоткан урыны турында гына түгел, исеме турында да мәгълүмат бирелә.

Татар антропонимиясендә *ай* антропокомпоненты борынгы төркиләрнең уртак хәзинәсе булып тора [ДТС, 1969: 25]: *Ay Kağan, Ay, Ay Ölütüçü, Ay Toldu, Ay Silig, Ay Çeçek, Ay Han* һ.б. Шунысы үзенчәлекле: төрки халыкларда *ай* культы табыну объекты булмый, ә ай календаре традицияләренә бәйләнешле килә [Безертдинов, 2001: 51]. Димәк, *ай* компонентлы исемнәрдә ел, ай календаренә бәйле традицияләр чагылыш таба. *Айтуды, Айбарс, Айкилде, Айтуган, Айбулат* кебек ир-ат исемнәре, татарлардан тыш, казакъларда [Кульдеева, 2001: 207], башкортларда [Шайхулов, 1983: 11], төрекмәннәрдә, үзбәкләрдә [Бегматов, 1965], төрекләрдә дә [Эрол, 1992: 68] кулланыла. Мәсәлән, төрекләрдә *Айбарс, Айтимер, Айхан, Гөкай, Аканай, Бирай* [Эрол, 1992: 68], казакъларда *Айтуган, Айдан, Айбас* [Кульдеева, 2001: 207], башкортларда Айбәк, Айкилде [Шайхулов, 1983: 11], кыргызларда *Айзат, Айнурзат* [Жапаров, 1992: 139] кебек ир-ат исемнәре актив кулланылып, борынгы төрки катлам ир-ат исемнәрен билгелиләр. Татар антропонимиясенә гарәп теленнән «ай» мәгънәсенә ия булган *Камәр һәм Бәдер (Бәдри),* фарсы теленнән *Маһи* исемнәре белән исем компонетлары алынганнар. Үзара мәгънәдәш булган әлеге антропокомпонентлар бер үк кушымча яисә исем компоненты ялганып кушма төзелешле синоним исемнәр ясала: *Маһия – Камәрия – Бәдрия; Айбикә, Маһибикә, Камәрбикә; Айбанат, Шәмсебанат – Маһибанат, Айгөл –Маһигөл – Камәргөл, Айнур – Бәдринур – Маһинур – Камәрнур; Айҗамал-Бәдриҗамал-Маһикамал; Айниса-Маһиниса-Бәдриниса, Айсылу–Бәдерсылу-Камәрсылу; Аймаһи-Шәмсемаһи-Бәдермаһи* һ.б.

Күзәтүләребезгә караганда, бүгенге ай антропокомпонентлы *Айзат, Айсаф, Айнур* кебек ир-ат исемнәрендә «ай» исемнәрнең компоненты буларак кына кабул ителә, ул билгеле бер ышану-йолаларга бәйле түгел. А.Шәйхулов борынгы *Яркәй* исемененең ике компоненттан торуын (Ярк-әй), соңгы компонентының иркәләү-кечерәйтү кушымчасы булмавын, *ай* компонентының нечкә варианты икәнлеген күрсәтә [Шайхулов, 1983: 12]. Беренче компонентта килгән *ярк* сүзе борынгы төрки телдә «кояш» дигәнне аңлата [ДТС, 1969: 24]. *Яркәй* ир-ат исеме бүгенге көндә Яркәев фамилиясенең нигезен тәшкил итә. Борынгы төрки сүзлектә *kün* сүзенең 1) кояш, 2) көн, 3) көн саен кебек мәгънәләр белдерүе күрсәтелгән [ДТС, 1969: 79]. Орхон-Енисей язмаларында *Kün, Kün Bermiş Sengün, Kün Doğdu* кебек исемнәрнең кулланылышы күзәтелә. Әлеге антропокомпонент нигезендә *Көнбай, Көнбак, Көнтимер, Көнбирде, Көнтумыш, Көнсылу* кебек исемнәр ясалганнар. «Көн – яктылык, матурлык, ирек символына нигезләнеп ясалган ир-ат исемнәре төрки халыкларда, шул исәптән болгар-татарларда кулланылышта актив йөргәннәр» [Саттаров, 1990 63]. Бу компонент нигезендә ясалган ир-ат исемнәре, матурлык, яктылык символы булып килү белән бергә, баланың туу вакытын да билгели булса кирәк.

Татар антропонимиясендә *таң* антропокомпонентлы исемнәрдән *Таңатар, Таңкилде, Таңбулат, Таңгатар, Таңгөл, Таңсылу, Таңсу* кебек исемнәр ясалган. *Таңйолдыз, Таңчулпан* исемнәре ясалу нәтиҗәсендә хәзерге татар антропонимиясендә бу исемнең *Чулпан – Зөһрә – Таңйолдыз – Таңчулпан* синонимик чылбыры билгеләнә. *Таң* компонентлы исемнәр татарларның гына түгел, башка төрки халыкларның исемнәре составында да сакланган. Мәсәлән, төрек телендә бу антропокомпонент нигезендә ясалган ир-ат исемнәре шактый күп кулланыла. Мисал итеп, төрекләрдә *Танай* «таң ае», *Танатылмыш* «таң аткан», *Танайдын* «якты ай», *Тандоан* «таңда туган» [Эрол, 1992: 61]; казакъларда исә *Танбиргән* «таң биргән, таңда туган» [Кульдеева, 2001: 215], башкортларда *Таңатар, Таңбулат* [Шайхулов, 1983: 22] кебек ир-ат исемнәрен билгеләргә мөмкин. Борынгы төрки телдә *ир-ер* антропокомпонентлы *er büri, er buya, eг toymis* [ДТС, 1969: 175] кебек ир-ат исемнәре теркәлгән. *Ер* компоненты исемнәрнең борынгы формаларында ауслаутта – (*Тоңа Алп эр*) һәм инлаутта – (*Алп эр Тоңа*) («ир; гаилә башлыгы») мәгънәсенә «көчле; курыкмас» кебек мәгънәләр дә өстәлергә мөмкин. Башка төрки халыкларда да әлеге компонент шактый киң кулланыла. Мәсәлән, төрекләрдә *Ердоан* исеме «ир кеше, егет

булып туган» [Эрол, 1992: 45] мәгънәсен белдереп килә. Казакъларда *Ергали, Ерден, Ерназар, Ерболат, Ерсултан, Ертай, Ерман* [Кульдеева, 2001: 209], кыргызларда *Ертабылды, Ербото, Ермамат* [Жапаров, 1992: 18], башкортларда *Ират, Ирзат, Ирсай, Иратгол* [Шайхулов, 1983: 13] кебек ир-ат исемнәрнең нигезендә борынгы төрки *ер-ир* антропокомпоненты килә. Төрки халыкларның рухи мәдәнияте хайван, кош-кортка бәйле төрле ышану-йолаларның төрлелеге һәм күплеге белән аерылып тора. А.Г. Шәйхулов фикеренә караганда, «башкортларда хайван һәм кош-корт культы кабилә ыруларның исем-атамаларында, геральдик билгеләрендә сакланган. Шулай ук төрле тыюларда (табуларда), халык медицинасында, ышану-йолаларда, халык авыз иҗатында, топонимиядә, антропонимиядә, зоонимиядә һ.б. да чагылыш тапкан» [Шайхулов, 1983: 16]. Башкортлардан тыш, хайван, кош-корт атамаларына нигезләнеп ясалган татар ир-ат исемнәре төрекләрдә, кыргызларда, казакъларда һәм башка төрки халыклар антропонимиясендә дә кулланылалар. Татар антропонимиясендә борынгы төрки катламны тәшкил итүче бер төркем ир-ат исемнәре хайван, кош-корт культы белән бәйле атамалар нигезендә ясалганнар һәм ир-ат исемнәренең спецификасын тәшкил итәләр. Хайван, кош-корт культы татар хатын-кыз исемнәрендә аз чагылуы белән характерлана.

Гомумтөрки бүре культы бик борынгы заманнардан килә. Төркиләр һәм монголларда бүре уртак тотем хайван саналып, аңа табыну борынгы ата-бабаларга хөрмәт белән карау итеп билгеләнгән [Безертдинов, 2001: 52]. Шулай ук күчмә, мал асраучылык белән шөгыльләнгән халыклар тормышында бүре зур роль уйнаган дип әйтә алабыз. Борынгы Кытай чыганакларына караганда, төрки атлы гаскәрләренең иң яхшыларын «бүреләр» дип йөрткәннәр, борынгы төрки язмаларда «аларга күк көч биргәнгә күрә, минем атам каганның гаскәре бүре кебек» диелә. «*Бүре* сүзе борынгы төркиләрдә кеше исемнәре ясалышында да киң кулланыла. Моны аеруча затлы нәселдән чыккан кеше исемнәрендә күреп була» [Дәүләтшин, 1999, 65]. Болгар-татарларда *бүре* сүзен изге, илаһи сүз санап кешегә исем итеп бирү йоласы барлыкка килә. Бүре сүзе борынгы төрки телдә *бөрө, борүг* формасында килеп, аның синонимы булган *кашкар, кашкур, корт* сүзләрен, монгол телендәге *ашан* һәм *чаны* сүзләрен ир балаларга исем итеп кушканнар [Саттаров, 1990: 16]. Р. Әхмәтьянов *бүре* сүзенең борынгы ирани телләрдән алынуын һәм мари телендә *пириге, пирагу,* мукшыда *виргас* сүзләренең кулланылуын искәртеп китә [Әхмәтьянов,

2001: 56]. Татарларда бүре антропокомпоненты *Бүребай, Бүрекәй, Бүриш, Бүрехан, Башбүре* һ.б. ир-ат исемнәрендә кулланылган. Болгар җирендә табылган һәм борынгы генеологик риваятьне чагылдырган сыннарда гомумтөрки тотем – бүре болгар тотемы – барска алыштырыла [Дәүләтшин, 1999: 98]. Татар антропонимиясендә барс культы ир-ат исемнәрендә чагылыш тапкан. Г.Ф. Саттаров болгар-татарларда изге барс тотемына нисбәтле рәвештә ир бала барс кебек көчле, кодрәтле булып үссен дигән теләктән чыгып та һәм борынгы төрки календарь буенча барс елында туган ир балага барс исемен кушу йоласы булуын билгели [Саттаров, 1990: 17]. *Барс* компоненты нигезендә *Барсбай, Барсби, Барсбуга, Барсбәк, Барсхан* кебек ир-ат исемнәре ясалган. Борынгыдан килгән ышануларга караганда, төрки халыкларда җанварлар арасында арыслан көч, гайрәт һәм затлылык символы булып санала. Татарларда, шул исәптән, башка төрки халыкларда да *Арслан-Арыслан-Аслан* исеме кушыла торган булган. Галимнәр бүгенге көндә ир балалар арасында еш кушылучы исемнәрнең берсе *Руслан* исемен *Арслан* исеменең славянлашкан формасы дип карыйлар [Саттаров, 1990: 24; Суперанская, 2005: 220]. Төрки халыкларда кайбер металл атамаларыннан ясалган ир-ат исемнәре борынгы төрки катламны тәшкил итәләр. Төрки халыкларда корал кою өчен кирәкле металл – тимер җансыз предметларны олылау, изгеләштерү стихиясен чагылдырган. Тимер төрки халыкларның килеп чыгышы белән бәйле күп кенә легенда-риваятьләрдә дә телгә алына, «һуннар римлыларда «Марс кылычы» булып саналган тимергә табынганнар, кесәләрендә бөти урынында йөргән тимер пычакны үзләре белән йөрткәннәр. Төрки империясенең чикләрендә Византия илчеләренә дини тантаналы кичәләр барышында тимер бүләк иткәннәр. Милли исемнәрдән саналган Тимер, Тимерташ, һичшиксез, дини эчтәлеккә ия ир-ат исемнәре булырга тиеш», дип билгели Л. Гумилев [Гумилев, 1963: 123]. Борынгы төрки сүзлектә *temür tuya, baj temür, eltemür, esân temür* кебек ир-ат исемнәре теркәлгән [ДТС, 1969: 533]. Бу антропокомпонент бары тик ир-ат исемнәренең үзенчәлекле компоненты булып килә. Мисал итеп *тимер* антропокомпонентлы *Тимербай, Тимерәй, Тимәш, Тимеркәй* кебек ир-ат исемнәрен күрсәтергә мөмкин. *Тимер* исеме төрки халыклардан русларга үтеп кереп фонетик үзгәреш кичергән хәлдә, XX гасыр урталарында татар антропонимикасына *Тимур* формасында кире әйләнеп кайта. Статистик тикшеренүләргә караганда, 2000–2005 елларда *Тимур* исеменең Казан шәһәре буенча өченче

урында торуы ачыкланды. Шулай ук, татарларда *Тимерхан* «тимер+хан», *Тимерлан* «тимер+олан» (бор.тат. [о > у] оглан > углан), «асылзат егет, гвардия солдаты», *Минтимер* «миң+тимер», *Тимербулат* «тимер+булат» кебек исемнәр кулланылышка керә башлады.

Димәк, тимернең ныклыгына ышану мотивы бүгенге көн татар ир-ат исемнәрендә дә сакланган дип әйтергә нигез бар. Борынгы төрки сүзлектә *таш – tas* компонентының 1) таш; 2) күренеш; тышкы күренеш (55, 539 битләрдә) кебек мәгънәләре күрсәтелгән. Татар ир-ат исемнәрендә әлеге компонент таш мәгънәсен белдерә. Бу антропокомпонентта борынгыларның ир баланы таш, тимер кебек нык булсын, дип теләү мотивы сакланган. Борынгыдан яшәп килгән җансыз предметларга табыну, аларны изгеләштерү *Ташбакты, Ташкай, Ташкабан* кебек исемнәрдә чагылган. *Иш* антропокомпонентлы татар ир-ат исемнәре аеруча киң таралышка һәм кулланылышка ия. *Иш* борынгы төрки телдә җөп, пар, ишле, иптәш, юлдаш, дус, тиң, тиңдәш һ.б. мәгънәләрне белдерә [ДТС, 1969: 139]. Мондый исем компоненты ир балаларга, гаиләнең беренче ир балалары дөньяда тормаганга куелган. *Иш* – өстәү, өстәмә, ягъни беренче бала түгел, дигән мәгънәне белдергән. Әлеге компонентка кушымчалар өстәү нигезендә ясалган *Ишем, Ишкәй, Ишәй* кебек антропонимнарны күрсәтергә мөмкин. Г.Ф. Саттаров, *Ишем-Ишим* антропонимы *иш* («бала», «гаилә») сүзенә беренче зат тартым кушымчасы -ем/-ым ялганып ясалган исемнәренең берсе булып килгән, дип саный [Саттаров, 1998: 119]. Иш антропокомпонентына *-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган ир-ат исеме Ишкәй исеме Ишәйгә әверелеп, хәзерге көндә Ишәев, Ишеев фамилияләренең нигезен тәшкил итә. *Тиң* антропокомпоненты *иш* антропокомпонентының синонимы булып тора. Бу антропокомпонент борынгы төрки исемнәрен ясауда, шулай ук, актив кулланылышта булган: мәсәлән, *Тиңбай, Тиңкәй, Тиңсубай, Тиңчура* һ.б. *Иш* антропокомпоненты препозитив, постпозитив кулланылса, *тиң* антропокомпонентын исә препозитив кулланылышта гына очраттык. *Тиң* антропокомпонентлы исемнәрдә теләк мотивы булган ир-ат исемнәре дә очрыйлар. Мәсәлән: *Тиңбарс* – ир баланың юлбарыска тиң булуын теләп кушылган йола исеме; *Тиңбулат* – ир баланың булатка тиң булуын теләп кушылган [Саттаров, 1998: 237].

*Толым* антропокомпонентының килеп чыгышын һәм лексик мәгънәсен өч чыганакка бәйле карарга мөмкин. Беренчедән, хәзерге татар телендә *толым* сүзе «чәч толымы» мәгънәсендә кулланыла.

*Толымбай* исеменең беренче компоненты шушы сүздән алынган булса, ул «чәче (толымы) калын һәм озын булган бай» дигән мәгънәне аңлата. Икенчедән, борынгы төрки сүзлектә *tolum* сүзенең «оружие», «снаряжение» мәгънәсендә кулланылуы күрсәтелгән [ДТС, 1969, 573]. Толымбай исеменең компоненты шул сүз белән мөнәсәбәтле дип санасак, бу исем «Коралбай» мәгънәсен белдерә. Өченчедән, *толым* компонентының борынгы төрки телдәге: 1) тулы 2) тулысынча, тулысы белән 3) бөтенләй 4) тулган ай мәгънәләрен белдергән *тулы* сүзенең тартым кушымчасы (*-ны*) кабул иткән формасы булуы да мөмкин [ДТС, 1969: 573]. Ул чагында, бу исем Толы(м), Тулы(м) бай мәгънәсен бирә. *Толымбай* исеменең мәгънәсе тулы (ягъни бөтен әгъзасы җитеш, исән-имин) бай яки бөтен яктан да бай мәгънәсенә ия дип әйтә алабыз. Шулай итеп, борынгы төрки чыгышлы ир-ат исемнәре төрле ышану-йолалар, карашлар системасына нигезләнсәләр, бүгенге көн исемнәрендә борынгы төрки катламга караган компонентларның йолаларга бәйле булмавы күзәтелә. Татар ир-ат исемнәрендәге бер төркем антропокомпонентларның башка төрки халыкларның да ир-ат исемнәрендә килүе борынгы төрки телнең тарихи үсешендә әһәмияте булуын раслый.

Иске татар катлам исемнәрнең формалашуы Урта Төрки чорның ахырына (XV гасыр) һәм Яңа Төрки чорга (XV–XIX гасырлар) туры килеп, иске татар теленең нигезе булган болгар, кыпчак, өлешчә угыз телләренең лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләрен үзендә чагылдыруы белән дә аерылалар. Галимнәрнең Идел буе татарларының болгар, кыпчак, угыз һәм башка этник төркемнәр белән тарихи бәйләнешләре турындагы фикерләрен [Хаков, 1972: 26; Халиков, 1974: 55; Закиев, 1977; Саттаров, 1982: 24] әлеге телләрнең элементларын саклап килгән ир-ат исемнәре дәлилли. В. Хаков фикеренә караганда, «Идел буе, үзенә генә хас бер регион буларак, төрки кабилә телләренең, шивәләренең бер үзәге булып китә. Бу хәл монда тарих барышында берничә төрки төркемнең кабиләләр һәм халыкларның (төрки агымнарының) урнашып калуына һәм күп гасырлар дәвамында Идел буе төрки телләр оешуына китерә. Идел буе төрки (әдәби) теленең нигезе шушы тарихи җирлеккә корыла. Борынгы һәм иске татар теле шул туфракта үсеп чыга» [Хаков, 2003: 37]. Шуңа күрә, өйрәнү объектыбыз булган татар ир-ат исемнәренең иске татар катламын болгар, кыпчак, угыз аскатламнарына бүлеп, әлеге телләрнең йогынтысын, иске татар исемнәре катламын формалаштырудагы әһәмиятен

ачыкларга тырыштык. Болгар аскатламы ир-ат исемнәре болгар һәм татар халыклары икътисады, мәдәнияте, теле һәм антропонимикасының күчемлелеге турында сөйли һәм, үз нәүбәтендә, беренчедән, татар теле сүзлек составын килеп чыгышы ягыннан өйрәнүдә «әле моңа кадәр үзенең чишелешен көтеп яткан актуаль проблемаларыннан берсе саналган болгар теленнән килә торган лексик берәмлекләрен ачыклау» [Зәкиев, 1998] мөһим бер башлангыч һәм чыганакны тәшкил итсә, икенчедән, татарларның этник тарихын өйрәнү һәм аларның болгарлар белән канкардәшлеген дәлилләү өчен, һичшиксез, зур фәнни әһәмияткә ия булып тора. Хезмәтебездә болгар аскатламы исемнәрен ачыклауда Х. Мөслиминең «Тәварихы Болгария» [Мөслими, 1286] әсәренә, Г. Йосыпов [Юсупов, 1960], Ф. Хәкимҗанов [Хакимзянов, 1987], Г. Саттаров [Саттаров, 1989] хезмәтләренә таянып эш иттек. Болгар эпитафик язмаларында, ислам диненең көчле тәэсиренә карамастан, болгар ир-ат исемнәре антропонимик системада озак вакытлар әйләнештә йөри. XIII–XVII гасырларда болгар чыгышлы мәҗүси исемнәрне, югары катлау даирәсендә генә түгел, түбән катлауларның да исемнәрендә очратырга мөмкин. Мәсәлән, *Тотай, Балкое, Инук, Бркай, Балтук, Ихидэ, Исук, Бураш, Булартай, Блумшан, Армаш, Акбак, Биктимер, Тимрадж, Исик, Иахам* һ.б. исемнәрне мисалга китерә алабыз» [Юсупов, 1960: 106]. XVI гасыр язучысы Х. Мөслиминең «Тәварихы Болгария» хезмәтендә дә [Мөслими, 1286] болгар катламы исемнәрен мисалга китерә, аларның исемлеге рус графикасында А.Б. Булатов тарафыннан шәрехләнеп бирелә [Булатов, 1971: 80]. Г. Йосыпов борынгы болгар теле үзенчәлекләренең бүгенге татар исемнәрендә дә чагылуын билгели [Юсупов, 1960: 11]. Болгар төркеменә түбәндәге ир-ат исемнәрен кертеп карыйбыз: *Аккам* – ике компонентлы бу исем болгар телендә *ак* – «төс»не, *кам* – «шаман» дигәнне белдерә. *Алып, Алыпарслан, Алыптай* исемнәренең *алып* компоненты «зур гәүдәле, баһадир» дип аңлатыла. *Алып* компонентлы ир-ат исемнәре Идел болгарлары кабер ташларында бар [Саттаров, 1998: 45]. Татарларда XV – X1X йөзләрдә *Алыпарслан, Алыпбай, Алыпкол, Алпар, Алапай* исемнәре кулланыла. Боларның кайберләре татар авыллары исемнәрендә яки фамилияләрендә чагыла. Татарстанның Әлки районында Иске Алпар һәм Яңа Алпар дигән татар авыллары бар. Әлеге комонимнар *Алпар* дигән кеше исеменә нигезләнеп ясалганнар. М. Зәкиев: «болгар патшасы Алмушның исемен галимнәр гарәп хәрефләре белән язылган Ал.м.с ны төрлечә укыганнар: *Алмас, Алмуш,*

*Алмус, Алмс* һ.б. Патша кешенең исеме гадәттә халык арасында тиз тарала, чөнки балага патша кешенең исемен кушу гадәте була. Безнең халыкта *Алмас* исеме гасырлар буена сакланып калган, ә *Алуш, Алмыш, Алмус* исемнәре юк», – дип билгели [Зәкиев, 1998: 332]. Татар антропонимиконында бер төркем ир-ат исемнәре үсемлек дөньясы апеллятивларыннан ясалганнар. Болгар төркеменә караган ир-ат исемнәреннән «имән» антропокомпоненты нигезендә ясалган *Имән, Имәнгол, Имәнкилде, Имәнкискә* [Саттаров, 1990: 114] кебек ир-ат исемнәрен мисал итеп китерергә мөмкин. А. Шәйхулов әлеге ир-ат исемнәренең башкорт телендә дә чагылыш табуын [Шәйхулов, 1983: 19] искәртә. Төрекмән халыкларында үсемлек дөньясына бәйле исемнәрне бирүдә билгеле бер теләк мотивы булуын ир балага кыргый агачлар һәм үсемлекләр исемен бирү күренешенең киң таралу мисалында күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, «төрекмәннәрдә ир балага мондый исем бирелсә, ул нык, сәламәт, озын гомерле һәм күп балалар үстерер дигән ышану яшәвен» билгелиләр [Аннакылычев, 1970: 201]. Болгар чыгышлы *Чутай* исеме чувашларның *Чутай*, карачай-балкарларның *Чотай, Чоту* ир-ат исемнәре чуваш телендәге «нур», «яктылык» мәгънәсендә килгән *Çuta* сүзенә барып тоташа. Карачай-балкарларда *Чотай, Чоту* исемнәре хәзер дә кулланылышта йөри. Казан татарларында *Чутай* ир-ат исеме *Чутай, Чутей, Четай, Чутин* фамилияләрендә саклана [Саттаров, 1989: 21]. Чутай исеме болгар кабер таш язмаларында билгеләнә [Хакимзянов, 1987: 189]. *Тутай* болгар чыгышлы ир-ат исеме «иң олы ир туган» [Саттаров, 1998: 244] дигәнне белдерә. Әлеге исем һәм аның апеллятивы болгар теле аша төрле сөйләшләрдә дә сакланып калган. Тик апеллятивлар, мәгънә дифференциациясенә очрап, беренчел мәгънәләреннән шактый ераклашканнар. Мәсәлән, татар теленең Нократ сөйләшендә *тутай* сүзе «чәчәк» мәгънәсен белдерә [ТТДС, 1993: 309]. *Чулым* татарлар телендә ир һәм кыз туганнар булса, Кырым татарларында «дөя баласы, бота» дигәнне аңлата. *Чалбай, Чултый* кебек исемнәр болгар телендә «таш» мәгънәсен аңлаткан чул-чал компоненты [Саттаров, 1998: 282] нигезендә ясалганнар. Идел-Кама болгарлары телендәге үзара синоним *чал* һәм *таш* сүзләре төрки телләрдә кушма төзелешле кеше исемнәрен ясауда актив кулланыла. Аның *бай, бәк, булат, бакты, Мөхәммәт* һ.б. исем компонентлары белән кушылуы нигезендә болгар-татарларда *Чалбай-Ташбай, Чалбәк-Ташбәк, Чалбулат-Ташбулат, Чаллы-Ташлы, Чалмөхәммәт-Ташмөхәммәт* кебек мәгънәдәш

исемнәр килеп чыккан. «Таштугай» мәгънәсенә ия булган *Чалтуган* исеме исә болгар бабаларыбыз күчмә тормыш белән яшәгәндә, ташлы тугайда туган ир балаларга кушыла [Саттаров, 1990: 40]. *Канак* исеменең болгар теленнән булуын М. Кашгариның сүзлеге раслый (XI гасыр). Болгар телендә бу ир-ат исеме *qanaq* апеллятивыннан алынып, «каймак» дигәнне аңлата [Саттаров, 1982: 25]. Болгар чыгышлы ир-ат исемнәренең татар антропонимиконында урын алуы гарәби-фарсы чыгышлы ир-ат исемнәренең үзгәрешенә китерә. Мәсәлән, Г.В. Йосыпов дини эчтәлекле исемнәрнең «халык массалары тарафыннан болгар әйтелешенә яраклаштыру» күренешенең киң таралыш алуын билгели [Юсупов, 1960: 106]. Мәсәлән, *Абдулла-Апуш, Зәйнулла-Зәйнуш, Ярулла-Яртук* кебек исемнәрнең вариантлары татар антропонимик системасында стилистик бизәкләрдән азат исем формасына бөтенләй күчеп бетә. Кыпчак аскатламына караган Кыпчак теле күп кенә төрки халыкларның тел үсешендә һәм формалашуында зур роль уйнаган. Галим В.Х. Хаков, бүгенге татар теленең барлыкка килүендә Идел һәм Кама буенда киң таралган кыпчак теле диалектының тәэсире зур булган дип саный [Хаков, 2003]. Аның нигезендә караим, кумык, каракалпак, казакъ, татар, башкорт һ.б. телләр үсеш ала. Татар телендә кыпчак ир-ат исемнәрен аеру шактый катлаулы мәсьәлә булып тора. Т.М. Гарипов башкорт антропонимиясендә кыпчак катламы антропонимнарын «исконные, самобытные наименования людей, понятные без перевода как для самих башкир, так и для представителей других близкородственных тюркских народов» дип билгели [Гарипов, 1973: 52–54]. Аның фикеренчә, борынгы субстрат алынмалардан аермалы буларак, кыпчак антропонимнарының структур яктан саф булуы, морфемаларга бүленешендә структур ачыклыгы төп үзенчәлек булып тора [Гарипов, 1973: 52–54]. Шуңа күрә моңа кадәр язылган хезмәтләргә таянып [Курышжанов, 1970; Закиев, 1977; Закиев, 1998; Саттаров, 1982], хезмәтебездә бер төркем кыпчак чыгышлы ир-ат исемнәрен барладык. А.К. Курышжанов «Исследование по лексике старокыпчакского письменного памятника XIII в. – “Тюрко-арабский словарь”» хезмәтендә [Курышжанов, 1970] бер төркем кыпчак исемнәренә туктала. Мисал итеп, *Сүбашы* «войско+глава»; *Санчар* «закалывающий», *Йуваш* «короткий», *Кичүкине* «маленький, малюсенький», *Катыйалу* «твердый, имеющий твердую гриву», *Көшербай* «кочующий бай», *Сонкорча* «похожий на сункара, подобие сункара» кебек ир-ат исемнәрен китерә. *Аппак* кыпчак телендә «ак йөзле» ди-

гәнне аңлата. *Ардак* исеме – кыпчак телендә «кадерле, хөрмәтле; наз» [Саттаров, 1998: 46] дигән мәгънәгә ия ир-ат исеме. *Кайчура, Кайхан, Кайпач* кебек ир-ат исемнәренең нигезен кыпчак телендәге апеллятив лексикадан алынган *кай* сүзе «көчле; сәламәт» [Саттаров, 1998: 128] дигәнне аңлата. *Тумаш, Туматай, Тумак* кебек исемнәрнең нигезен кыпчак телендәге *тума* компоненты билгели. Г.Ф. Саттаров «Отглагольные антропонимы в татарском языке» мәкаләсендә [Саттаров, 1973: 41–48] иске татар катламын тәшкил итүче төрле фигыль формаларыннан ясалган исемнәргә тулы анализ бирә һәм «башка төрки халыклар белән чагыштырганда, фигыль компонентлы исемнәрнең аз санда кулланылуы, бүгенге көндә бу исемнәрнең архаиклашкан антропонимик берәмлекләргә күчүен» [Саттаров, 1973: 48] билгели. ЗАГСлардагы тикшеренүләр барышында, фигыль компонентлы татар ир-ат исемнәренең кулланылышка кире керү тенденциясен ачыкладык (мәсәлән, *Бикбулсын* – 0,06%, *Аллахбирде* – 0,06%). Димәк, болгар аскатламы ир-ат исемнәренең «яңадан торгызылу» процессы башланды дип әйтергә җирлек бар.

Татар исемиятендә боерык фигыль компонентлары нигезендә ясалган ир-ат исемнәре күпчелек исемнәрне тәшкил итеп, атаананың төрле теләкләрен, боеру-кушу, уй-фикерләрен чагылдыралар (*Ирбулсын, Ишбулсын, Котлыбир, Сатыпал, Торбай, Байкара* һ.б.). Шулай ук хикәя фигыльнең төрле заманнары нигезендә ясалган ир-ат исемнәреннән *Ирбула, Янкилә, Таңата, Уразбага, Иштота* кебек исемнәр дә иске татар катламы ир-ат исемнәрен билгелиләр. Н.К. Дмитриев фикеренә караганда, угыз теле элементлары татар теленә XIV–XV гасырда Урта Азиядән керә [Дмитриев, 1948: 125], бу исә татар теленең формалашу вакытына туры килә. Әлеге аскатламга караган *Аслан* исеме кыпчак формасында *Арслан* буларак кулланыла; *Курт, Куртай, Курташ* кебек ир-ат исемнәрендә *курт* сүзе угыз телендә «бүре» дигәнне аңлата. Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең *-мыш/-меш* формасыннан ясалган татар ир-ат исемнәре дә бу аскатламга керә, чөнки «әлеге форма угыз телләре өчен характерлы, кыпчак телләрендә киң таралмаган» [Кононов, 1956; Алиев, 1989: 7; Гаджиева,1971: 216; Юсупов, 2004: 114; Нигъматуллов, 2006: 155], шуңа да «төрки телләр дифференциациясе чорында типик көньяк төрки кушымчасы булып кала» [Дмитриев, 1948: 181]. Кулланылышы чикле булуга карамастан, *-мыш/-меш* формасын барлык диалектларда да очратырга мөмкин [Юсупов, 2004: 272]. Г.В. Йосыпов

XVIII гасырга караган болгар-татар каберташ язмаларында [Юсупов, 1960: 11] *Суламыш, Туктамыш, Еламыш, Кармыш, Аталмыш, Сатылмыш, Туктамыш, Чынмыш* кебек *-мыш/-меш* формалы ир-ат исемнәре булуын билгеләп уза. Шунысы үзенчәлекле: *-мыш/-меш* формалы татар ир- ат исемнәре *-ган/-гән* синонимик пары белән ясалган ир-ат исемнәрендә дә параллель кулланылганнар: *Карамыш// Караган, Бикләмеш // Бикләгән // Иртумыш // Иртуган, Җантумыш // Җантуган* һ.б. Бүгенге ономастиконда *-мыш/-меш* угыз формасы, трансонимизацияләшеп, комонимнарга күчкән атамаларда очрый. Мисал өчен, Мамадыш районында Катмыш, Саба һәм Биектау районнарында Туктамыш авыллары атамаларын билгеләп үтәргә мөмкин. Татарстан Республикасы Питрәч районы Янсывар, Мөслим районы Хансывар авылларының атамалары *Янсывар, Хансывар* ир-ат исемнәренә бәйле каралалар. Н.И. Ашмарин инде болгарларда ук кулланылышта йөргән *Сәвар* исеменең фигыль нигезле исем булуын һәм «сөеләә торган» мәгънә белдерүен билгеләгән [Ашмарин, 1898: 160]. *Сәвар/сывар* антропокомпоненты *Янсывар, Хансывар, Колсывар* кебек ир-ат исемнәре составында урын алган. Безнеңчә, *sevmek* «ярату» (бүгенге төрек, азәрбайҗан телләрендә дә «ярату» мәгънәсендә килә) сүзе угыз телләренең үзенчәлеге булып тора, димәк, әлеге компонент нигезендә ясалган исемнәрне угыз аскатламына кертергә нигез бар. Татар антропонимикасында *Куандык, Сагындык, Сөендек, Табылдык* һ.б. ир-ат исемнәрендә «*-дык* формасы угыз телләренең специфик үзенчәлеге һәм, ул кыпчак теленең -ган формасына туры килә» [Юсупов, 2004: 116]. Әлеге форма бүгенге төрки телләрдән төрек, гагауз, азәрбайжан телләрендә барлык формада актив булса, төрекмән телендә юклык формасында гына кулланыла. Г.Ф. Саттаров *-дык* формасы нигезендә ясалган исемнәрне категорик үткән заманның субстантивациясе дип карый [Саттаров, 1976: 44]. А. Рәхимова төрек телендә үткән заман сыйфат фигыленең бу формасында билгелелек төсмере чагылуын күрсәтә [Рәхимова, 2002: 146]. Шуңа күрә билгелелек төсмере *-дык* формасының ир-ат исемнәрендә кулланалашының сәбәбе булып тора дип әйтергә нигез бирә. *Чук, Чукан, Чукай* кебек ир-ат исемнәре угыз телләрендә чагылыш тапкан *Çok* сүзенә барып тоташа. Бу сүз төрекмәннәрдә, азәрбайҗаннарда, төрекләрдә «күп» мәгънәсен белдерә. Әлеге сүзнең семантикасы киңәюе, *чук* сүзенең монгол телендә *чуог-уй* «бергә җыелу» дигәнне анлатуында күзәтелә [Әхмәтьянов, 2001: 238]. Чук бәйрәмнең аерым чагылышлары керәшен татарларында, чувашларда,

удмуртларда сакланып калган. Керәшен татарларында кешеләр бу бәйрәм көнне урамга чыгып, бер-берсенә су сибешкәннәр, кырга чыгып, ботка пешереп ашаганнар, яңгыр чакырганнар. Казан артындагы татар авылларында Чуков фамилиясен йөртүчеләр очрый. Шулай ук бүгенге төрек, азәрбайжан телләрендә «кул» мәгънәсендә кулланылган *әл* сүзенә I зат берлек сандагы тартым кушымчасы *-ем* кушылу юлы белән ясалган *Әлем* антропокомпоненты нигезендә *Әлембай, Әлемгол, Әлемкәй* кебек ир-ат исемнәре ясалган. Күчерелмә мәгънәдә бу исем «таянычым, ярдәмчем, ышанычым» дигәнне аңлата. Әлем компоненты авыл атамаларында да очрый. Димәк, татар ир-ат исемнәренең иске татар катламы татар халкының этногенезын ачыклауда, татар халкының халык буларак формалашуында зур роль уйнаган халык һәм кабиләләр белән этник бәйләнешләрен барлауда зур әһәмияткә ия.

Октябрь инкыйлабыннын соң илдә барган үзгәрешләр тел үсешенә дә билгеле бер йогынты ясаган. Җәмгыять тәртипләренә, иске иҗтимагый мөнәсәбәтләргә, сәясәткә караган кайбер сүзләр бөтенләй төшеп кала яисә пассив лексикага күчә [ТТАС, 2005: 147]. Телнең лексик составындагы үзгәрешләр лексиканың бөтен катламнарына, шул исәптән, антропонимикага да үтеп керәләр. Татар ир-атларына кушыла торган яңа исемнәрнең антропонимик системада барлыкка килү вакыты социаль факторлар белән билгеләнгән XX йөз башына туры килә. Гасыр башы шаукымы тәэсирендә татар антропонимикасында гасырлар дәвамында сакланып килгән күчемлелек, дәвамчанлык традицияләренә тугры булып, аерым бер йола-гадәтләр кысаларында гына яшәп килгән исем составында үзгәреш күзгә ташлана башлый. Халыкка авыр аңлашыла торган гарәби чыгышлы, кушма төзелешле һәм шулай ук, иске татар катламын тәшкил итүче исемнәргә җиңел әйтелешле, мәгънәви яктан аңлаешлы фонетик яктан зәвыклы саналган исемнәр алмашка килә. Аңа мисал итеп, *Идел, Сарман, Ирек, Ялкын, Дулкын, Ташкын, Очкын, Тырыш, Таймас, Алмас, Үсәр, Өлгер* кебек исемнәрне күрсәтә алабыз. Мәсәлән, 1930–1939 елларда Казан шәһәрендә *Ирек* исеме 5 ир балага (0,34%), Мамадыш шәһәрендә 6 ир балага (2,87%) кушылган. Моны ЗАГС бүлегеннән алынган статистик мәгълүматлар раслый. Гасыр башында татар антропонимик системасының яңарыш тенденцияләре кайбер антропоформант һәм антропокомпонентларның исем составында кулланылыш алуы да күзәтелә. XX гасыр башы мәгълүматлары буенча, еш кулланылучы исемнәрдә нәкъ ил антропоформанты урын алган. Мәсәлән, Казан

шәһәре буенча 1930–1939 елларда Илдус исеме 84 ир балага (5,74%), Мамадыш шәһәре буенча 7 ир балага (3,34%) кушылган. Мисал өчен, *ил* (т.) антропоформанты нигезендә шактый санда ир-ат исемнәре ясалалар: *Илсаф* (т.-г.), *Илнур* (т.-г.), *Илсин* (т.), *Илсөяр* (т.), *Илтаң* (т.), *Илтөзәр* (т.) һ.б. Постпозициядә килгән *наз* (ф.) антропоформанты нигезендә дә исемнәрнең яңа төрләре барлыкка килә. *Илназ* (т.-ф.), *Ирназ* (т.-ф.), *Фирназ* (ф.), *Айназ* (т.-ф.), *Сафназ* (г.-ф.) кебек исемнәрне мисалга китерергә мөмкин. Уңай семантик мәгънәгә ия апеллятив лексикадан ясалган бер составлы исемнәр дә татар исемиятенә кулланылышка кереп китәләр: *Ялкын, Дулкын, Ташкын* һ.б. Шулай ук борынгы чорларда фигыль формаларының татар ир-ат исемнәрендә кулланылышы процессы да яңа гасыр антропонимик системасында торгызыла. ЗАГС бүлеге материалларында билгеле киләчәк заман сыйфат фигыленнән ясалган бер төркем ир-ат исемнәренә тап булырга туры килде. Мәсәлән, *Өлгер, Елгыр, Үсәр, Алмас* һ.б. Шул рәвешле, ир-ат исемнәренең яңа татар катламы, илдә барган сәяси-иҗтимагый үсешнең нәтиҗәсе буларак, кушма төзелешле теофор исемнәрдән соң, татар теленең үз мөмкинлекләрен яңача кулланып, антропонимик системаны тулыландыруда әһәмиятле этап булып торалар.

## § 3. Татар кеше исемнәренең гарәп катламы

Халкыбызның гарәп сәүдәгәрләре, сәясәтчеләре, галимнәре белән тыгыз элемтәдә торуы Х гасырга кадәр үк гарәби чыгышлы сүзләрнең лексикабызга үтеп керүенә китерә. 922 елда Багдад хәлифе Җафар әл Мөктәдир Аббассит хәлифлеге белән эшлекле элемтә урнашкач, Идел буе болгарларының ханы Алмышка үзенең илчесен җибәрә. Идел буена сәяхәт болгарларның ислам динен кабул итүләре белән тәмамлана. Урта Азиядән болгарларга гарәп теле һәм дин нигезләренә өйрәтү максатында, күп санда факыйхлар (юристлар) һәм мөгаллимнәр җибәрелә. Ислам дине кабул ителгәч, телебезгә бик күп санда гарәби чыгышлы сүзләр үтеп керә башлый. Р.Г. Әхмәтьянов «Х гасырдан ХХ гасыр башына кадәр, мең ел дәвамында, татар мәктәп-мәдрәсәләрендә гарәп телен өйрәтү халык массалары тарафыннан гарәп сүзләренең үзләштерелә башлавын һәм мөселман дини өйрәтмәсе аша гарәби чыгышлы сүзләрнең күп санда телебезгә үтеп керүенә китерә,» – дип билгели [Ахметьянов, 1969: 295]. Ислам дине тәэсире лексика һәм, шул исәптән, антропонимика үсешендә, аларның тулылануында мөһим роль уйный. Алтын Урда мәдәни учакларында иҗат итүче галимнәр,

шагыйрьләр һәм язучыларның гарәпчә укып кайтуы төрки телгә күп санда гарәп сүзләренең үтеп керүенә китерә. Уртак сүзләр белән берәттән, төрки телдә гарәби чыгышлы ир-ат исемнәре дә кулланыла башлый һәм гарәби чыгышлы уртаклык компонентлары төрки исемнәргә ялганалар. Шунысы билгеле: XIV гасырда Алтын Урда һәм Мисырда фарсы теленнән тәрҗемәләр ясала. Ә фарсы теле, үз чиратында, татар теленең сүзлек составын баетуда мөһим роль уйный. Р.А. Әхмәтьянов билгеләвенә караганда, «күп кенә гарәп сүзләре татар теленә инде билгеле бер дәрәҗәдә, «гарәпләшкән» фарсы-таҗик теле арадашлыгы аша үтеп керәләр» [Ахметьянов, 1969: 296]. Татар антропонимиконына гарәби чыгышлы исемнәрнең үтеп керүендә әлеге экстралингвистик сәбәпләр сизелерлек йогынты ясаган дип әйтергә мөмкин. Г.Ф. Саттаров билгеләвенчә, [Саттаров, 1990: 190] болгар-татарларда гарәп исемнәре Болгар дәүләтендә 922 елда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгәннән соң кулланыла башласалар да, XIX йөз башларына кадәр халыкта киң таралмаганнар. XIX йөзгә кадәр татарларда борынгы төрки-татар кеше исемнәре күбрәк кушылган. Төрле тарихи чыганаклардагы, болгар-татар каберташларында, нәсел шәҗәрәләрендә, сан алу кенәгәләрендәге татар кеше исемнәре нәкъ шуны раслыйлар. XIX йөздә исә бу хәл бик нык үзгәрә, «Бохара мәдрәсәләрендә белем алучы муллалар татар халкы арасында гына түгел, башка төрки халыкларда да көчле дини пропоганда алып баралар һәм бу, үз чиратында, татар исемиятенең «гарәпләшүенә» китерә» [Юсупов, 1969: 108]. Шулай да мәгънәләре халыкка аңлаешлы булган гарәби исемнәр генә телдә сакланып кала. Мәсәлән, шундыйлардан, *Вәли* («хуҗа, саклаучы»), *Кадыйр* («кодрәтле, көчле»), *Гали* («бөек, өлкән»), *Хәсән* («яхшы, матур»), *Әхмәт* («иң данлыклы, күренекле») кебек ир-ат исемнәрен күрсәтеп китәргә мөмкин. «XIX гасыр урталары XX гасыр башында гарәби чыгышлы сүзләрнең татар телендә актив кулланылуы» [Сиразиев, 2002: 19] татар антропонимиконында да сизелә башлый. Татар халкы исемиятендә гарәби исемнәр интенсив рәвештә тарала башлагач, Г.Тукай саф дини мәгънә аңлата торган һәм катлаулы төзелештәге гарәпчә кеше исемнәрен куллануны тәнкыйтьләп чыга [Тукай, 1975: 96]. Шулай да XX йөзнең 20 нче елларына кадәр, гарәби чыгышлы ир-ат исемнәренең кулланылуы дәвам итә. XX гасыр башларында гарәби чыгышлы антропонимнар кеше исемнәренең 98,1% ын алып торган [Галиуллина, 1999: 11]. Төрки антропонимиядә гарәби чыгышлы исемнәрнең таралышын К.М. Мусаев:

«...степень арабизации тюркской антропонимии не одинаково у разных народов. Обильное проникновение арабских личных имен обнаруживается у тех народов, которые сильно подверглись исламизации, – у турок, азербайджанцев, узбеков, татар, менее заметно исламское влияние киргизов, казакъов, башкир, каракалпаков и др.» [Мусаев, 1984: 210], дип билгели. Язылган хезмәтләргә таянып, кыргыз, казак, башкорт, каракалпак халыкларның антропонимик системасында алтай, борынгы төрки катлам, төрки халыкларының уртак лексикасыннан ясалган ир-ат исемнәренең саны күбрәк булуын билгеләргә мөмкин. Гарәби чыгышлы ир-ат исемнәрен нигезендә ислам дине төшенчәләре һәм көнкүреш лексикасына бәйле сүзләр яткан ир-ат исемнәренә бүлдек. Дини лексикага бәйле төшенчәләрне аңлаткан ир-ат исемнәре *Рахман, Рәхим, Хәмид, Гани, Нур, Мөхәммәт, Һади, Ислам, Мәхмүт, Әхмәт* кебек антропокомпонентлардан һәм *габдел-габде-габди-габд, -етдин, алла-улла* кебек антропоформантлардан ясалалар. Дин – саф гарәби чыгышлы сүз, «ышану, инану, дин» дигәнне аңлата. Әлеге антропокомпонент нигезендә постпозициядә дә, препозициядә дә ир-ат исемнәре ясалганнар. Мәсәлән, *Бәдретдин* «диннең тулган ае», *Кираметдин* «диннең юмарт, эчкерсез кешесе», *Миргаязетди*н «дингә ярдәм итүче, булышучы әмир», *Сәрвәретдин* «дин башлыгы, җитәкчесе», *Сәхибетдин* «диннең дусты, юлдашы», *Фәтхетдин* «диннең яулавы, җиңүе», *Фәһиметдин* «диннең аңлысы, зирәге, үткене» кебек ир-ат исемнәре постпозициядә кулланылганнар. Татар ир-ат исемнәрендә *дин* антропокомпоненты препозициядә дә исемнәр ясый. Мәсәлән, *Динислам* «ышанып буйсыну», *Динмөхәммәт* «Мөхәммәт динендәге кеше», *Динулла* «Аллаһ дине», *Диншәех* «дин шәехе, рухани, дин башлыгы» һ.б. *Алла/-улла* саф гарәби антропоформанты ир-ат исемнәрендә постпозициядә һәм препозициядә кулланыла. Мәсәлән, *Габидулла* «Аллаһыга табынучы», *Зәкиулла* «Аллаһының зирәк, сәләтле кешесе», *Зәйнулла* «Аллаһ бизәге», *Сәйфулла* «Аллаһының кылычы», *Мотыйгулла* «Аллаһыга буйсынучы» һ.б. ир-ат исемнәре *-алла/-улла* компоненты нигезендә ясалганнар. *Ислам* антропокомпоненты «Аллаһыга буйсыну, күндәмлек» дигәнне аңлата. Әлеге исем компоненты препозициядә дә, постпозициядә дә кулланыла. Препозициядә *Исламбакый, Исламбәк, Исламгир, Исламнур, Исламха*н һ.б. исемнәрдә чагылыш тапкан. Постпозициядә исә *Шәйхелислам, Нурислам, Газиислам, Динислам* һ.б. исемнәрендә кулланыла. *Иман* антропокомпоненты «иман, ышану, инану» дигән мәгъ-

нәгә ия. Бу компонент нигезендә татар антропонимикасында *Иманай, Иманбәк, Имангали, Имангол-Иманкол, Иманкай* кебек ир-ат исемнәре ясалган. Аллаһы Тәгаләнең 99 күркәм исемен үз эченә алган исемнәр арасында да ир-ат исемнәрен ясауда катнашучы актив антропокомпонентлар чагыла. 99 исемнең барысы да ир-ат исемнәре. Бу исемнәр Аллаһының илаһи сыйфатларын, атрибутларын белдерүче эпитетлардан гыйбарәт. Мәсәлән, *Азамат* «бөек, шөһрәт, дан», *Басыйр* «барсын да күреп торучы», *Барый* «бар итүче, яктыртучы, тудыручы, иҗат итүче», *Вахит* «бердәнбер», *Ваһап* «тереклек итүче», *Вәли* «хакимлек итүче», Газиз «кодрәтле, көчле; кадерле», *Газим* «бөек, югары дәрәҗәле», *Гали* «һәрнәрсәдән өстен һәм бөек», *Гаффа*р «гөнаһ-хаталарны гафу итүче, кичерүче, ярлыкаучы», *Кави* «көчле, куәтле, киң кодрәтле» [Исме Әгъзам, 2005] һ.б. Аллаһының изге эпитетларыннан саналган *габд-габде-габди-габдел* («кол, алла колы») антропоформанты ир-ат исемнәрен ясауда актив катнаша. Мәсәлән, *Габдрахман, Габделкәрим, Габделрәхим, Габделкәбир, Габдерәшит* кебек ир-ат исемнәре шушы антропоформант нигезендә ясалганнар. *Мөхәммәт* антропокомпоненты «макталган, мактаулы, данлыклы» мәгънәсендә килә. «Мөселманнар Аллаһының илчесе Мөхәммәт пәйгамбәрнең исемен яисә аның исеме белән бәйле эпитетларны исемнәре составына керткәннәр» [Махпиров, 1990: 11]. Препозициядә *Мөхәммәтбакир, Мөхәммәтбасыйр, Мөхәммәтгали, Мөхәммәтгата, Мөхәммәтгаян, Мөхәммәтвәли* кебек ир-ат исемнәре ясалганнар. Постпозициядә исә *Ханмөхәммәт, Динмөхәммәт, Нурмөхәммәт* һ.б. ир-ат исемнәре киң кулланылалар. Мөхәммәт пәйгамбәрнең эпитетларыннан *Рәсүл, Нәби, Әмин, Рәхмәт, Сафи* һ.б. исемнәрнең кайберләре, шулай ук, исем компонентлары булып йөриләр. Мәсәлән, *Рәсүл* антропокомпоненты нигезендә *Рәсүлулла* «Аллаһының илчесе», *Рәсүләхмәт* «илче, хәбәр китерүче илче» һ.б. ир-ат исемнәре ясалган. *Нәби* компоненты нигезендә *Нәбирахман, Нәбихан, Нәбиәхмәт, Нәбияр, Нәбиулла* кебек ир-ат исемнәре киң кулланылалар. Телдән сөйләгән хәдисләрдә ислам пәйгамбәре үзен *Мөхәммәд, Әхмәт, Мәхмүд, Хәмит* дип атый [Хайдар, 2002: 63]. Бу исемнәрнең барысы да «дан, мактау» төшенчәсен белдерә торган бер үк *хмд* тамырына кайтып кала. Бу хәл гарәп грамматикасының үзенчәлеге һәм лексикасының синоним сүзләргә бай булуы белән аңлатыла [Саттаров, 1990: 194]. *Әхмәт* («иң данлы, иң мактаулы») исеме *Әхмәтбакый, Әхмәтбарый, Әхмәтвафа, Вәлиәхмәт, Муллаәхмәт* һ.б. ир-ат исемнәрендә очрый. *Мәхмүт*

(«макталган, мактаулы») компоненты нигезендә *Мәхмүтгәрәй, Мәхмүтвәли, Мәхмүтсолтан, Мәхмүтхан, Мәхмүтҗан* кебек кушма төзелешле ир-ат исемнәре барлыкка килгән. *Хәмит* («мактаулы, мактауга лаек») компоненты нигезендә *Хәмитхан, Нурхәмит, Хәмитвәли, Хәмитҗан* һ.б. ир-ат исемнәре кулланылышта йөри. Татар антропонимиясенә яһүди чыгышлы пәйгамбәр исемнәре мөселманнарның исемнәрен билгелиләр. *Адәм* «кеше, зат» дигәнне аңлата, дини тәгълимат һәм риваятьләр буенча беренче кеше һәм беренче пәйгамбәр. Борынгы яһүд теленнән тәрҗемәдә исә «кызыл балчыктан» [Суперанская, 2005: 36] дигәнне белдерә, *Давыт* гарәп теленнән «сөекле, үзенә җәлеп итүче» дигәнне аңлатса, яһүд теленнән тәрҗемәдә «яраткан» [Суперанская, 2005: 95] дигәнне белдерә; *Йосыф* гарәп теленнән «Алла тарафыннан арттырылган, өстәлгән гүзәллек» дигән мәгънәдә килсә, яһүд телендә «арттыру, керем» [Суперанская, 2005: 131] дигән мәгънә белдерә. Татар антропонимиясендә, бу исемнәрдән тыш, *Исхак* «ул көлде» [Суперанская, 2005: 134], *Идрис* «өйрәнүче, укучы» [Суперанская, 2005: 134], *Муса* «бала» [Суперанская, 2005: 178], *Сөләйман* «исән-имин яшәүче, тыныч» [Суперанская, 2005: 227], *Әюп* «тәүбә итүче» [Суперанская, 2005: 323] һ.б. ир-ат исемнәре борынгы яһүдләрнең Тәүратына барып тоташа. Яһүд пәйгамбәрләренең исемнәре телебезгә гарәп теленнән дини китаплар, дин таратучылар аша үтеп кергән. Бу төр исемнәр бүген дә кулланылалар, чөнки алар структур яктан гадилеге һәм сөйләм агышында авырлыклар тудырмавы белән билгеләнәләр. Ислам дине титулларыннан ясалган кеше исемнәре дини төшенчәләргә бәйле исемнәрнең аерым бер төркемен тәшкил итә [Саттаров, 1990: 197].

Саф гарәби чыгышлы *имам* антропокомпонентының берничә мәгънәсе бар: 1) алда торучы; 2) өлкән мулла; 3) җитәкче, баш кеше [ГТРАС, 1993: 45]. *Имам* компоненты нигезендә *Имамгәрәй* (г.-т.) «имам+гәрәй», *Имамбәк* (г.-т). «имам+бәк», *Имамгали* (г.) «имам +гали», *Имаметдин* (г.) «дин имамы» һ.б. ир-ат исемнәре ясалган.

*Мулла* компоненты гарәпчәдән *мәлла* сүзеннән алынган; мулла – укымышлы кеше, өйрәтүче, укытучы; дингә өйрәтүче, өндәүче; рухани дәрәҗә дигәнне аңлата [186]. Әлеге компонент нигезендә *Муллабай* (г.-т.) «укымышлы бай», *Муллагәрәй* (г.-т.) «мулла+гәрәй», *Муллагол* (г.-т) «мулла+кол», постпозициядә *Бикмулла* (т.-г.) «бик укымышлы», *Галимулла* (г.) «укымышлы мулла», *Баймулла* (т.-г.) «бай мулла» һ.б. ир-ат исемнәре ясалган. *Шәех-шәйхе* компоненты берничә вариантта ир-ат

исемнәрендә чагылыш таба. Гарәп телендәге *шәех* компоненты карт, аксакал, башлык, җитәкче; дин башлыгы, иман, рухи ата [ГТРАС, 1993: 25] дип тәрҗемә ителә. Әлеге компонент нигезендә *Шәехбулат* (г.-т.) «шәех+булат», *Шәехзадә* (г.-ф.) «шәех улы», *Шәеххуҗа* (г.-ф.) «шәех+ хуҗа», *Шәехтимер* (г.-т.) «нык шәех», *Шәехгали* (г.) «укымышлы шәех» һ.б. ир-ат исемнәре ясалган. Исем алдына яки ахырына элементлар ялгану гарәп антропонимикасына хас. Исем алдына кушылучы элементлар «кунья» һәм «нисаб» дип аталса, исем ахырына ялганучы элементларны «насаб», «нисба» дип атыйлар. Гарәп антропонимикасында исем алдыннан куелучы «кунья» элементы *әб-әбү* префиксы ярдәмендә ир-атның атасын белдерә. «Конечно, этот исм не означает, что обладатель соответствующей кунии обязательно в действительности имел сына с таким именем» [Илизаров, 1970: 291]. Татар антропонимикасында исә *әб-әбу-әбел* префиксы икенче компонентка яраклашып, мәгънәсеннән шактый ераклашкан. Гарәп телендә «ата, эти, әткәй, бала атасы; төп иясе, нәкъ иясе» мәгънәләрен белдереп килгән *әб* сүзе, *әба, әби, әбү* формаларын ала. Әлеге префикслар ярдәмендә *Әбелгази, Әбелгазим, Әбелгәрәй, Әбелгаяз, Әбелкадыйр, Әбелгәрәй, Әбелмәлик* һ.б. ир-ат исемнәре ясалган. Исем алдына ялганучы элементлардан *ибн-ибне* префиксы «улы» мәгънәсендә «нисба» булып килә. Татар антропонимиясендә *ибн-ибне* компоненты ата исемен күрсәтү вазифасыннан ераклашкан, әлеге компонент бары тик ир-ат исеме булып кына калган. Бу префикс ярдәмендә *Ибнегаббас* (г.) «Габбас улы», *Ибнегомәр* (г.) «Гомәр улы», *Ибнеислам* (г.) «Ислам улы», *Ибнехөсәен* (г.) «Хөсәен улы», Ибнесәет (г.) «Сәет улы», *Ибнеәмин* (г.) «Әмин улы» кебек ир-ат исемнәре ясалган. Дини тематикадан азат, халыкның яшәешен яктыркан ир-ат исемнәре дә аерым урын алып торалар. «Мотивлашкан исемнең эчтәлеге нигезне тәшкил иткән уртаклык исеменең беренчел мәгънәсе белән билгеләнә. Кешенең матди һәм рухи тормышы, аның шәхесе турында мәгълүмат тупланган сүзләрне аерып, семантик төркемнәрен билгеләү сүзнең беренчел мәгънәсен ача алырга мөмкин» [Молчанова, 1970: 190]. Халыкның матди дөньясы белән бәйле апеллятив лексикадан ясалган ир-ат исемнәренең тематик яктан бүленеше О.Т. Молчанова классификациясенә нигезләнде.

1. Кешенең матди тормышы, көнкүреше турында мәгълүмат бирүче ир-ат исемнәре:

а) көнкүреш, хуҗалык әйберләре белән бәйле ир-ат исемнәре: *Кәндил* «яктыртучы, лампа, шәм», *Сираҗ* «яктырткыч, шәм,

лампа», *Мифтах* «ачкыч», *Мисбах* «яктылык чыганагы, шәмдәл, лампа» һ.б.

ә) өс-киеме, бизәнү кирәк-яракларына нисбәтле ир-ат исемнәре: *Зөннар* «билбау, кушак», *Зиннәт* «бизәк, затлы әйбер» һ.б.

б) хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы белән бәйле кеше ир-ат исемнәре: *Бәкер* «дөнья баласы», *Зәбиб* «йөзем, йөзем бөртеге», *Ногман* «лалә чәчәгенең бер төре» һ.б.

в) төрле һөнәр белдерүче ир-ат исемнәре: *Гамил* «эшләүче, хезмәт итүче, гамәл кылучы», *Хаҗип* «хезмәтче, швейцар», *Сәүбән* «карап, тәрбияләп торучы», *Харис* «игенче, сабанчы, сукачы» һ.б.

г) иҗтимагый мөнәсәбәтләргә бәйле ир-ат исемнәре: *Вәкил* «ышанып җибәрелгән кеше, вәкил», *Рәис* «башлык, җитәкче», *Рәсүл* «илче, хәбәр китерүче», *Галәм* «кол, малай» һ.б.

д) культ бәйрәмнәре белән бәйле ир-ат исемнәре: *Бәйрәм, Корбан* һ.б.

2. Абстракт апеллятив лексика нигезендә ясалган халыкның рухи дөньясы белән бәйле ир-ат исемнәрен түбәндәге семантик ояларга тупладык:

Семантик оя «акыл, белем»

Гыйлем: *Гыйлембай, Гыйлемдар, Гыйлемхан, Гыйлембәк, Гыйлемхан, Гыйлемьяр, Гыйлмехәят, Гыйльминаз, Гыйльмиҗамал, Гыйльимиҗиһан* һ.б.

Гали: *Галиарслан, Галибай, Гализадә, Галикәй, Галиислам* һ.б.

Галим: *Галимбай, Галимби, Галимбул, Галимбәк, Галимнур, Галимә, Бибигалимә, Галимәбану, Нургалимә* һ.б.

Фазыл: *Фазылбәк, Фазылгәрәй, Фазылжан, Фазылхан, Фазылъяр; Фазилә, Бибифазилә, Миңлефазилә, Өммефазыйлә* һ.б.

Фән: *Фәннур, Фәнгиз, Фәндар, Фәндүс, Фәнзаман, Фәнзил, Фәнгизә, Фәнзирәк, Фәнилә, Фәния, Фәннура* һ.б.

Хәбир: *Хәбирулла, Хәбирҗан, Хәбирхан* һ.б.

Семантик оя «бәхет, шатлык, байлык, муллык»

Фәез*: Фәезбай, Фәезбәк, Фәезвәли, Фәезгали, Фәезкәрим* һ.б.

Сәгыйд*: Сәгыйдулла, Сәгытьҗан, Сәгыйтьнур* һ.б.

Шат: *Шатгали, Шатморат, Шатморза; Гөлшат, Шатгөл, Гәүһәршат, Чәчкәшат* һ.б.

Семантик оя «яраткан, сөекле, матур, күркәм»

Әҗме: *Әҗмесәлим, Әҗмулла, Әҗмемөхәммәт, Әҗмебикә* һ.б.; Хәбиб: *Хәбибгали, Хәбибелислам, Хәбибелхак, Хәбибелхан, Хәбиб-*

*задә* һ.б.; Хуш: *Хушбулат, Хушдәүләт, Хушман, Хушнәваз, Хуштаймас* һ.б.; Хөббе/Хөбби/Хөббел: *Хөббевәли, Хөббегали, Хөббизадә, Хөббихан* һ.б.; Зариф («ягымлы, нәзәкатьле, чибәр»): *Зариф, Зарифетдин, Зарифхан, Зарифҗан; Зарифа, Миңлезарифа* һ.б.; Җамал («матурлык, чибәрлек; йөз матурлыгы, гүзәллек, күркәмлек»): *Җамал, Җамалетдин, Җамали, Җамай, Җамалия, Айҗамал, Гөлҗамал, Мәһиҗамал, Миңлеҗамал, Нурҗамал* һ.б.; Вәсим («бик чибәр, сөйкемле, гүзәл»): *Вәсим, Вәсимхан, Вәсимхан; Вәсимә, Миңлевәсимә, Бибивәсимә, Өммевәсимә* һ.б.; Җәмил («матур, гүзәл, чибәр»): *Җәмил, Габделҗәмил, Мөхәммәтҗәмил; Җәмилә, Җәмиләбану, Җәмиләбикә* һ.б.

Семантик оя «данлыклы, хөрмәтле»

Шәрәф: *Шәрәфгали, Шәрәфи, Шәрәфле, Шәрәфулла* һ.б.; Шәһир: *Шәһирзар, Шәһретдин, Шәһрислам, Шәһрияр* һ.б.; Әхмәт: *Әхмәтбай, Әхмәтбакир, Әхмәтбарый, Әхмәтбакый* һ.б.

Татар антропонимиясендә 1990–1999 елларда Казан шәһәрендә яратылып кушыла торган ир-ат исемнәреннән *Камил* исеменең (1,13%) этимологиясе шактый гына кызыклы чыганакларга барып тоташа. Рус галимнәре *Камил* исеменең килеп чыгышын [Бондалетов, 1986: 133] латин телендәге camillus сүзе «молодой человек из знатной семьи, обязанный присутствовать при определенного рода жертвоприношениях» [Петровский, 2000: 158], «юноша безупречного происхождения» [Суперанская, 2005: 137] белән бәйле карыйлар. Исемнәрдә омонимия күренешен Н.А. Петровский болай дип аңлата: «трудно сказать, происходит ли образование нового имени независимо от старого или мы имеем дело с переосмыслением старого имени в наше время, но тем не менее в языке оказывается два одинаково звучащих имени разного происхождения» [Петровский, 2000: 17]. *Камил* исеме нигезендә ясалган *Камилла* исеме дә бу чыганакка карый. Татар антропонимикасында чагылыш тапкан *Камил* исеме исә гарәпчәдән «тулы, бөтен, мөкәммәл булган, һәрьяктан җитешле» дип аңлатыла [Саттаров, 1998: 130]. XII гасырда Мисыр һәм Сүрия илләрендә *камил* компоненты титулатура составында кулланыла [Гафуров, 1971: 90]. Әлеге исем нигезендә хатын-кыз исеме Камилә дә нәкъ шул чыганак белән бәйле. Димәк, *Камилла-Камилл, Камилә-Камил* исемнәрен омоним исемнәр дип әйтә алабыз. Шулай ук бу аскатламга *мал* антропокомпоненты нигезендә ясалган татар ир-ат исемнәрен дә кертергә кирәк (*Малтабар, Малҗан, Малкилде, Малбәк* һ.б). Әлеге исемнәрдәге мал антропокомпоненты татар теленнән тыш, казакъ [Кульдеева, 2001: 45],

каракалпак, кыргыз [Жапаров, 1992: 20], башкорт [Шайхулов, 1983: 18], тунгус-маньчжур [ССТМЯ,1975: 45] монгол телләре [МРС] лексикасында күзәтелә. Р.Әхмәтьянов аны түбәндәгечә билгели: «*Мал* «скот; имущество; богатство»; *товар* – чув. *мол, мул* – хантый, *мол* – монг., фарсы., гар., *мал* «мал, терек; байлык» – киң таралган сүз. Чаг.: бор. кытай, монгол теленең диалектларында *мар* «ат, мал» дигәнне аңлата» [Әхмәтьянов, 2001: 140]. Бүгенге көндә төрек, үзбәк телләрендә *мал* сүзе «товар, чимал» мәгънәсен дә аңлатуы, бу сүзнең семантикасы киңәю күзәтелә.

Гарәп чыгышлы исемнәр төрлелеге, байлыгы белән аерылып торалар. Шуңа күрә, гарәп чыгышлы татар исемнәренең антропонимиконыбызга күп санда үтеп керүендә ислам диненең әһәмияте зур булган дип билгели алабыз.

## § 4. Татар кеше исемнәренең фарсы катламы

Фарсы чыгышлы исемнәр халкыбызның иҗади мөмкинлекләрен чагылдырып, татар исемиятен тулыландырып, үзгә бер урын тоталар. Алар сан ягыннан барлык татар ир-ат исемнәренең 7% ын тәшкил итәләр. Фарсы теле – дөньяда иң бай язма традицияләре булган борынгы телләрнең берсе булып санала. К.М. Мусаев гарәп теленең – фарсы теленә, үз чиратында, фарсы әдәби теленең – бөтен төрки халыкларның язма әдәби теленә, сөйләмә фарсы теленең күрше территорияләрдә яшәгән төрки телле халыкларның, кабиләләрнең телләренә йогынты ясавын, һәм төрек, үзбәк, азәрбайҗан, кырым-татар әдәби телләренә дә фарсы теленең тәэсире зур булуын билгели [Мусаев, 1989: 27]. X–XV гасырларда фарсы телендә бай әдәбият формалаша, поэзия чәчәк ата. Азәрбайҗаннар, әфганнар, Урта Азиянең күп кенә төрки халыклары фарсы телендә иҗат итәләр. Рудаки, Фирдәүси, Хәйям, Низами, Гаттар, Сәгъди, Хафиз һ.б.ның әсәрләрен тәрҗемә итү, әдәби байлыклар белән алмашу нәтиҗәсендә фарсы сүзләре һәм антропонимнары татар теленә дә үтеп керә башлый. Шулай ук Р.Г. Әхмәтьянов: «...заимствования из персидского языка проникли в татарский литературный язык не только через старый литературный язык, через турецко-азербайджанскую и «чагатайскую» (староузбекскую) литературу, но и «снизу» – из различных диалектов татарского языка, а также, возможно, из древнебулгарского. Персидское влияние успело глубоко проникнуть в Среднее Поволжье задолго до сформирования среднего диалекта татарского языка. Народы Поволжья

с древнейших времен имели самые интенсивные контакты с народами Средней Азии» [Ахметьянов, 1969: 300], – дип, фарсы чыгышлы сүзләрнең телебезгә үтеп керүендә татар теленең диалектлары һәм борынгы болгар теленең әһәмиятен ассызыклый. Бөек Болгар дәүләтенең уңай географик урынчылыгы икътисади һәм сәяси бәйләнешләрне нығытуда мөһим роль уйный. Көнчыгыш белән Көнбатышны бәйләп торучы Идел-Чулман елгалары су юлы аша икътисади, сәяси, мәдәни багланышларны тагы да ныгытырга мөмкинлек бирә. Урта Азия һәм Якын Көнчыгыш илләре белән икътисади, сәяси, мәдәни бәйләнешләрнең нәтиҗәсе булып, Идел–Урал буйларында гарәп-фарсы телләрен өйрәнү, ул телләрдә язылган китапларны, күчерү киң колач ала, һәм бу традиция XX йөз башларына кадәр дәвам итә. Бөек Болгар дәүләтенең мөселман мәдәнияте белән киң кырлы бәйләнеше матди һәм рухи мәдәниятнең үсешенә китерә. Болгар-татарлар сәләтле егетләрне һәм кызларны Көнчыгышның фәнни үзәкләренә (Хорезм, Ширван, Дагстан һ.б.га) җибәрәләр [Ганиева, 1988: 50]. Шулай ук фарсы сүзләре һәм антропонимнарының төрки-татар теленә үтеп керүенә коммуникатив арадашлыкның сизелерлек йогынтысы булган дияргә нигез бар. Димәк, дәүләтләр арасында борынгы заманнардан ук башланган дәвамлы сәүдә һәм мәдәни багланышлар аркылы болгар-татар теленә, ә соңыннан исә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында татар теленә байтак кына фарсы сүзләре һәм кеше исемнәре үтеп керә [Хангильдин, 1971: 175; Саттаров, 1990: 19]. Татар антропонимиконында *хуҗа, шан/ша, задә, морза/мирза, шир, мир, яр, дил, шат, яздан, дус, шәй/шәех, наз, җиһан* кебек антропокомпонентлар һәм антропоформантларны аерып күрсәтергә мөмкин. Беренче төр фарсы чыгышлы антропонимнарның нигезен кешенең үзенчәлекле сыйфатларын тасвирлаган сүзләр тәшкил итәләр, чөнки «фарсы чыгышлы алынмаларның күпчелеге халыкның эстетик һәм этик идеалларын, матурлык һәм олылык төшенчәләрен белдерәләр» [Махрипов, 1990: 15]. Татар ир-ат исемнәрендә батырлык, көч, куәт кебек ир-атларга хас асыл сыйфатлар *җан, дил, яр, хуш, мин, рушан/раушан* кебек антропоформант һәм антропокомпонентларда ассызыкланалар. *Хуш* сүзе фарсы телендә «күңелгә ятышлы, яхшы» мәгънәсеннән тыш, «күңелле» дигән мәгънәгә дә ия [ПРС, 1970: 234]. Бу антропоформант нигезендә препозициядә *Хушдил* (ф.) «яхшы күңелле», *Хушяр* (ф.) «яхшы күңелле дус», *Хушаман* (ф.) «гүзәллек, күркәмлек, бәхет иясе», *Хушнам* (ф.) «данлы, атаклы», *Хушнаваз* (ф.)

«яхшылык, юмартлык, игелек» кебек ир-ат исемнәре ясалган. *Хуш* антропокомпонентына *бирде, килде* төрки-татар чыгышлы категорик үткән заман хикәя фигыль кушылып ясалган ир-ат исемнәрен очратырга мөмкин (*Хушкилде, Хушбирде*). *Миһ* антропоформанты фарсы телендә берничә мәгънәле: 1) олы, күренекле; 2) туган җир, туган туфрак [ПРС, 1970: 234]. Бу антропоформант нигезендә *Миһман* (ф.) «туган туфрак иясе», *Миһран* «олы, күренекле зат», *Миһзадә* (ф.) «олы, күренекле егет», *Миһдин* (ф.-г.) «зур ышану» кебек исемнәр ясалган. *Җан* антропоформанты Урта Азиядә XVI гасырда киң тарала башлый [Гафуров, 1971: 39]. XVI гасырга кадәр бу антропоформант бары тик пәйгамбәр исемнәре һәм аларның эпитетлары белән генә кулланыла. В.Хангилдин татарлар арасында *җан* антропоформантының төрки чыгышлы исемнәргә ялгану тарихын «дәүләтнең Урта Азия белән бәйләнеше көчәю барышында шундагы кайбер илләргә, шәһәрләргә, башлыча Бохарага барган татар сәүдәгәрләре, укырга барган татар шәкертләре, дамеллалар аннан «җан» сүзе өстәлгән исемнәр алып кайтулары»на бәйләп аңлата [Хангилдин, 1971: 176]. Татар исемиятендә фарсы чыгышлы *җан* антропоформанты исемнәр ясауда актив катнаша. ЗАГС материалларына караганда, бүгенге көндә дә бу антропоформантның исемнәргә ялгану тенденциясе күзәтелә. Мәсәлән, Казан шәһәре буенча, *otçan* антропоформанты 2000–2005 елларда *Гомәрҗан* (1–0,06%), *Әминәҗан* (1–0,06%), 1990–1999 елларда *Равилҗан* (1–0,03%), *Әхмәтҗан* (1–0,03%) кебек исемнәрдә кулланылган. *Яр* антропокомпоненты фарсы телендә «дус, иптәш; сөйгән кыз яки сөйгән егет» мәгънәсендә килә [ПРС, 1970: 543]. Г.Ф. Саттаров төзегән татар теленең тулы исемнәр сүзлегендәге ир-ат исемнәренең бу антропокомпонеты препозициядә 23 (*Ярулла* (ф.-г.) «яр+алла», *Ярбирде* (ф.-т.) «иптәш бирде», *Ярбулат* (ф.) «яр+булат» һ.б.), ә постпозициядә 18 (*Аллаяр* (г.-ф.) «алла+яр», *Хөснияр* (г.-ф.) «күркәм дус», *Хәсәньяр* (г.-ф.) «яхшы яр») ир-ат исеме ясалган. *Шир* фарсы телендә «арслан» дигәнне аңлата [ПРС; 1970: 456]. Татар антропонимиконында *Ширарслан* дигән исем теркәлгән. Фарсы сүзе *шир* төрки чыгышлы *арыслан* сүзе белән конкретлаша төшә. Бу компонент *Ширгали* (ф.-г.) «арыслан+акыллы», *Ширхан* (ф.-т.) «шир+хан», *Ширдил* (ф.) «арыслан йөрәкле», *Ширзадә* (ф.) «арыслан баласы» кебек исемнәрдә кулланыла. *Маһ* антропоформанты фарсы телендә ай (елга мөнәсәбәтле) һәм ай (луна) мәгънәсендә килә [ПРС, 1970: 78]. Көнчыгыш әдәбиятындагы традицион ай образы *Маһия*н (ф.) «айга мөнәсәбәтле», *Маһиҗан (*ф.)

«ай+җан», *Маһияр* (ф.) «айга тиң яр» кебек ир-ат исемнәрендә чагылган. *Яздан* антропоформанты фарсы телендә ике мәгънәне белдерә: 1) Алла, Тәңре; 2) яхшылык итүче [ПРС, 1970: 78]. *Яздан* исеме *Шарияздан* (ф.) «Тәңре арсланы», *Нурлыяздан* «Тәңре нуры» кебек ир-ат исемнәренең кыскартылган варианты буларак та кулланыла. Татар антропонимиясендә *яздан* антропоформанты постпозициядә генә килә: *Шәяздан* (г.-ф.) «яхшылык итүче шәех», *Шанияздан* (ф.) «яхшылык итүче шаһ», *Хөснеляздан* (г.-ф.) «Аллаһының күркәмлеге» һ.б. *Дил* антропоформанты фарсы телендә «күңел, йөрәк, акыл» дигән мәгънәләрдә [ПРС, 1970: 655] йөри. (Көнчыгыш традицияләреннән килгән күңел образы ир-ат исемнәрендә дә чагыла). Аның, «йөрәк, акыл, күңел» мәгънәсеннән тыш, фарсы телендәге «батырлык, кыюлык» кебек мәгънәләре дә бар [ПРС, 1970: 655]. Бу антропоформант нигезендә татар антропонимиконында *Дилавәр* (ф.) «батыр, йөрәкле, курку белмәс», *Дилваз* (ф.) «гашыйк, яратучы, сөюче» *Дилдар* (ф.) «сөекле; кыю, батыр», *Дилроб* (ф.) «искиткеч; кыланчык»; кебек постпозициядәге ир-ат исемнәре теркәлгән.

*Мәрдан/мәрди* антропокомпонентлары фарсы телендә берничә мәгънәгә ия: 1) ирләр өчен; 2) батыр, кыю, тәвәккәл; 3) намуслы, вөҗданлы; нәзакәтле [ПРС, 1970: 655]. *Мәрди* антропокомпоненты *мэрдан* антропокомпонентының диалекталь варианты булып тора. *Мәрдан/мәрди* антропокомпонентлары постпозициядә дә, препозициядә дә килә алалар. Мәсәлән, *Мәрданшаһ-Шаһимәрдән* һ.б. Фарсы телендә *-дар* антропоформанты кушма төзелешле сүзләрнең беренче компоненты булганда, билгелелек артикле белән бергә, «өй, тору урыны» мәгънәсендә килә. Кушма төзелешле исемнәрнең икенче компоненты булган очракта, нинди дә булса сыйфатның предмет яки объект үзенчәлеге булуын белдерә [ПРС, 1970: 599]. Антропонимнарда исә *дар* антропоформанты күбесенчә икенче компонентта килеп, предмет яисә объектның нинди дә булса сыйфатка ия булуын күрсәтә. *Җиһандар* «дөньяны биләүче», *Дилдар* «күңелне тоткын итүче» кебек ир-ат исемнәрен мисал итеп китерергә була. Ир-ат исемнәре составында актив кулланылучы *шат* антропоформанты «күңелле, кәефле, шат» мәгънәләрен аңлата. *Шат* антропоформантының ир-ат исемнәрендә беренче компонент булып килүе чикле (*Шатгали, Шатморат, Шатморза* һ.б). Нигездә ир-ат исемнәрендә икенче компонентта кулланыла (*Илшат, Иршат, Айшат, Дилшат* һ.б.). *Нар* антропоформанты фарсы телендә «анар җимеше, гранат» мәгънәсе белән беррәттән,

«бәхетле» дигән күчерелмә мәгънәгә дә ия [Саттаров, 1990: 189]. Бу антропоформант ир-ат исемнәрендә, нигездә, постпозициядә кулланыла (*Илнар, Айнар*). А. Гафуров *-нар* антропокомпонентының *миң* мәгънәсен бирүен дә искәртеп китә: «ир балаларда анар җимешен хәтерләткән миңе булса, *-нар* компонентлы исемнәр биргәннәр. Мондый миңне бәхеткә юрап, исемдә чагылдырырга тырышканнар» [Гафуров, 1971: 110]. *Наз* антропоформанты ир-ат исемнәрендә аз кулланыла. Бу антропоформант ярдәмендә, нигездә, хатын-кыз исемнәре ясала. Фарсы телендә *наз* антропоформанты 1) кыланчыклык, чытлыклылык; 2) хозурлык, тынычлык; 3) рияллыык; 4) кирелек, үзсүзлелек; 5) ягымлылык, мөлаемлылеык; 6) нәфислек, гүзәллек, зифалык [ПРС, 1970: 606] кебек мәгънәләрне белдерә. *Наз* антропоформанты ир-ат исемнәрендә бары тик постпозициядә генә очрый. Әмма соңгы еллар тикшеренүләрендә Казан шәһәрендә бер ир балага Назлы исеме кушу очрагы теркәлде. Хатын-кыз исемнәрендә исә препозициядә һәм постпозициядә дә чагылыш таба (*Назлыгөл, Назгөл, Назинә, Назлы* һ.б.). Препозициядә *наз* антропоформанты хатын-кызларга хас матурлык, гүзәллек төшенчәләрен тагы да ассызыклый. *Наз* антропоформанты XX гасырда иҗат ителгән ир-ат исемнәрендә кулланыла башлый. Мәсәлән, татар антропонимиконында *Илназ* (т.-ф.) «ил назы», *Айназ* (т.-ф.) «ай матурлыгы», *Дилназ* (ф.) «күнел гүзәллеге», *Сафназ* (г.-ф.) «сафлык назы» кебек ир-ат исемнәре бар. Ир-ат исемнәрендә *наз* антропоформант ролен үти, чөнки бары тик ауслаутта очрый һәм аерым гына исем булып кулланылмый. Бу формант ярдәмендә ясалган ир-ат исемнәре гадилеге, җыйнаклыгы белән аерылып, төрки-татар чыгышлы компонентларга кушылып та исем ясый.

Икенче төр антропокомпонентлар Көнчыгышта киң таралган титул исемнәрен тәшкил итәләр (*мирза/морза, мир, шаһ/ша/шә, задә*). Галим Алим Гафуров фарсы чыгышлы исемнәрдә титул компоненты исемнән соң ялгану үзенчәлегенең төрки-татар исемнәренә дә хас булуын билгели [Гафуров, 1971: 148]. Титул компонентының исем алдында килүе гарәп антропонимик системасының төп үзенчәлеге булып тора. Антропонимнар нигезендә килгән титулатур антропокомпонентларның күпчелеге титул мәгънәсеннән ераклашып, зат мәгънәсен генә аңлаталар. *Шаһ* сүзе фарсы телендә «хан, патша, хуҗа» мәгънәсендә кулланыла. Исемнәрдә беренче антропокомпонентта килгән очракта «иң яхшы» кебек мәгънәдә килә. *Шаһ* антропокомпоненты татар әйтелешенә, фонетикасына яраклаштырылып, *шәй*

формасына әйләнгән. Икенче компонентта кыскарып, *ша* формасын ала һәм беркадәр кимсетү төсмерен бирә [Саттаров, 1998: 286]. *Шаһ* антропокомпонентының кыскаруы постпозициядә күзәтелә. Мәсәлән, *Гыйлемшан-Гыйлемша, Мөхәммәтшаһ, Мөхәммәтша, Әхмәтшан-Әхмәтша* кебек ир-ат исемнәрендә [һ] авазы бөтенләй төшеп кала. Кайбер очракларда *шан* компоненты белән бергә *-и* формаль күрсәткече атрибутив мөнәсәбәтне күрсәтеп, *Шаһигәрәй, Шаһимәрдән, Шаһинур* кебек ир-ат исемнәрендә кулланыла. *Мирза/морза* антропокомпонентлары фарсы телендә берничә мәгънәдә килә: 1) писарь, сәркатип; 2) шаһ династиясенең титулы. Бу мәгънәләрдән тыш, *мирза* сүзе Көнчыгышта ялгызлык исемнәренең алдында килеп, укый-яза белүче кешене аңлаткан [ПРС, 1970: 453]. Аның нигезендә *Мирзабәк, Мирзабай, Мирзагали, Морзабак, Морзаби, Шәйморза* һ.б. исемнәр ясалган. *Мир* антропоформанты «хәрби башлык, хөкемдар, ил белән идарә итүче түрә, әфәнде; әмир» мәгънәләрен [ПРС, 1970: 161] белдерә. Бу сүз нигезендә *Мирвәли* (ф.-г) «изге әмир», *Мирбәшир* (ф.-г.) «сөенеч китерүче әмир», *Миргази* (ф.-г.) «изге юлда көрәшүче әмир», *Миргазиз* (ф.-г.) «кадерле, затлы, зыялы әмир», *Миргазим* (ф.-г.) «бөек, зур әмир» кебек ир-ат исемнәре ясалган. *Задә* антропоформанты фарсы телендә «бала, нәселне дәвам итүче; туган» кебек мәгънәләрдә [ПРС, 1970: 234] килә. Бу антропоформант ярдәмендә ясалган ир-ат исеме атасының титулына ия улны (малайны) тәгъбир итә. Фарсы телендә задә мөстәкыйль лексик берәмлек булып килсә, татар телендә кушымча буларак кына кулланыла [Ганиев, 1974: 145]. *Задә* антропоформанты *Шаһзадә* (ф.) «шаһ баласы», *Ханзадә* (т.-ф.) «хан баласы» кебек исемнәрдә аерым затның дәрәҗәсен, титулын белдерсә, *Илзадә* (т.-ф.) «ил баласы», *Асылзадә* (г.-ф.) «асыл бала» кебек исемнәрдә титул атамасына бәйле түгел, ә затны белдереп килә. *Задә* антропоформанты бары тик постпозициядә генә кулланыла. Галимнәр билгеләвенчә, «ике телнең фонетик системасындагы аермалар булу сәбәпле, фарсы чыгышлы исемнәр телебездә авыр үзләштерелгәннәр» [Гарипова, 1973: 82]. Гарәби исемнәр нейтраль булулары белән билгеләнсәләр, фарсы чыгышлы исемнәрдә эстетик функциягә ия үзенчәлекнең укымышлы кешеләргә карата кулланылучы белән аерыла. Исемнәрнең семантикасында билгеле бер объектка мөнәсәбәте үзенчәлек булып тора. Мисал өчен, *рушан/раушан* антропокомпонентларының фарсы варианты – *роушан*. Татар антропонимиконында *раушанның* кыска варианты *рушан* компоненты да киң кулланыла.

*Роушан* фарсы телендә, «якты, ачык; чиста, үтә күренмәле» кебек мәгънәләрдән тыш, «якын торучы, аңлашыла торган, ачык, тыныч; анык, төгәл» кебек мәгънәләрне дә белдерә [ПРС, 1970: 452]. Г.Ф. Саттаров күрсәтүенчә, *Рушан/Раушан* исеме «нур сибүче, нур иясе; нур чәчеп торучы, якты» мәгънәсендә килә [Саттаров, 1998: 200]. Татар антропонимиконында *Рөстәм* фарсы чыгышлы ир-ат исеменең этимологиясе кызыклы. Г.Ф. Саттаров *Рөстәм* «бик зур алып гәүдәле, борынгы иран фольклорында легендар, каһарман, пәһлеван» дигән мәгънәгә ия дип билгели [Саттаров, 1998: 206].

*Фирнад* исеме «җиңелмәс; тиз төшенүчән» дигәнне аңлата [Саттаров, 1998: 261]. Аның диалекталь варианты – *Фәрхәт*. *Булат* исеме «яхшы корыч» дигәнне аңлата. Булат болгар-татарларда корычның аерым бер төрен белдереп килгән. Әлеге корычны Шам (Дамаск) шәһәрендә ясаганнар. *Булат* сүзе исә фарсы телендә *пулат* формасында кулланыла. Димәк, фарсы чыгышлы Булат исеме болгар-татарларга гарәп теле аша кергән дип уйларга нигез бар. Шул рәвешле, татар антропонимиясендә фарсы чыгышлы ир-ат исемнәренең үсеш тарихы, телебезгә үтеп керү сәбәпләренә, үзләренә генә хас үзенчәлекләренә бәйле. Алар, төрки һәм гарәби чыгышлы компонентларга кушылып, татар антропонимиконын тулыландыруда мөһим роль уйныйлар.

## § 5. Татар кеше исемнәренең Көнбатыш Европа һәм рус катламы

Антропонимик киңлек күләме һәм составы ягыннан диахрониядә үсеш-үзгәреш кичергән антропонимик берәмлекләрдән тора. Халыкның тарих иязмышы белән бәйләнешле телара һәм мәдәни багланышлар нәтиҗәсендә антропонимик киңлектә үсеш-үзгәреш процессы барлыкка килә. Бер халык та изоляциядә яши алмый, шуңа күрә һәрбер халыкның антропонимик киңлегендә алынма элементлар табылалар. Гомумән, чит телләрдән кеше исемнәре алыну экстралингвистик факторларга гына бәйле түгел, бу процесска яшәешебезнең башка бик күп өлкәләре, шулай ук лингвистик факторларның да йогынтысы зур. Рус теле һәм аның аша үтеп кергән Көнбатыш Европа алынма исемнәрнең телебездә популярлашуында этнолингвистик факторларның тәэсире аеруча көчле. Татар теленең традицион исемнәренә охшаш булуы (*Ирек-Эрик-Ирик*), татар теле авазлары системасында үзенчәлекле авазларның исемнәрдә кулланылышы (*Эдик, Эдвард, Энгел*), сонор авазларның күплеге (*Ленар, Марат, Ренат*)

кебек линвистик факторлар әлеге ир-ат исемнәренең антропонимик системабызда күпләп кулланылышына китерә.

Рус һәм Көнбатыш Европа телләре аша кергән исемнәр тел белемендә В.А. Никонов, М.А. Җәләлиева, Г.Ф. Саттаров, Р.Г. Әхмәтьянов, Г.Р. Галиуллина, М.З. Вәлиева, Г.С. Хаҗиева һ.б. тарафыннан өйрәнелгән. М.А. Җәләлиеваның бу темага язылган кандидатлык диссертациясе бар [Залядиева, 1985: 297]. Соңгы елларда рус теле һәм аның аша кергән Европа алынмалары күп санда татар антропонимиконына үтеп керде. Бу үз чиратында мәдәният, икътисад, сәясәт өлкәсендәге халыкара тыгыз элемтәләргә бәйле рәвештә аңлатыла. Татар теленә рус алынмаларының үтеп керүе инде Казан ханлыгы Россиягә буйсындырылуга кадәрге чорга карый [Ахунҗанов, 1968]. Октябрь инкыйлабыннан соң, рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән кергән исемнәр татар антропонимиконына һәм, шул исәптән, башка төрки телләргә дә, интенсив рәвештә үтеп керә башлыйлар [Залялиева, 1989: 50]. «Традицион исемнәргә караганда, бу исемнәрнең популярлыгы зур була» [Галиуллина, 2000: 23], чөнки әлеге исемнәрне балага кушканда, ата-ана иң беренче исемнең үзенчәлекле яңгырашына игътибар итә. 2000–2006 елларда да татар антропонимиконында рус һәм Көнбатыш Европа чыгышлы ир-ат исемнәренең кулланылышы кимеми. Рус теленнән алынган исемнәр арасында апеллятив сүзләрдән (*Рим, Артем*), исем-аббревиатуралардан (*Ким, Ренас, Ленар*), шулай ук, семантик юл белән ясалган ир-ат исемнәре бар (*Идея, Искра, Май, Гений* һ.б). Татар ир-ат исемнәре арасында чын рус антропонимнары сирәк очрый, алар фәкать катнаш гаиләләрдә генә күзәтелә. Апеллятив сүзләргә төрле кушымчалар өстәлеп (*Радик, Октябрин*), аббревиатур исемнәргә төрле компонентлар ялганып (*Вилнур, Вилдан*), апеллятив лексиканы кыскартып (*Рем* – революция мировая, *Рикс* – рабочих и крестьян союз, *Ревмир* – революция мировая) ясалган исемнәр шактый. Рус чыгышлы *Радик* исеме, галимнәр фикеренә караганда, *радий* латин чыгышлы уртаклык исеменә *-ик* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган ир-ат исеме [Петровский, 2000: 236; Саттаров, 1990: 199; Галиуллина, 2000: 85]. Безнең уйлавыбызча, *Радик* исеме радость тамырына бәйле кушылган. *Радость* сүзе нигезендә рус антропонимикасында *Рада* хатын-кыз исеме ясалган. *Рада* исеменә *-ик* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы өстәлеп, *Радик* исеме кулланылышка кергән. Бу исем ата-ананың хис-кичерешләрен тасвирлаган исемнәр рәтендә карала. Роман-герман төркеменә керүче немец, испан, инглиз, итальян телләре

грек яисә латин теленнән үсеш алганнар. *Риман* (лат.-т.) «рим+ан», *Рубин* «кызыл якут», *Флорис* «чәчәк ату, данлы булу; көчле булу», *Флорид* «чәчәк атучы», *Фидел* «тугрылыклы, ышанычлы», *Ренат* «яктыртылган, яңадан туган», *Рикс* «патша» кебек ир-ат исемнәре латин аскатламын тәшкил итәләр. Латин чыгышлы *Ренат* исеме *renascor* сүзеннән алынып, «яңадан туган, яңадан торгызылган, тормышка яңадан кайткан» дигән мәгънәгә ия [Саттаров, 1990: 201; Галиуллина, 2000: 86; Петровский, 2000; Суперанская, 2005: 216]. *Ренат* омоним исемнәр рәтендә карала, чөнки бу исемнең килеп чыгышын ике нигезгә бәйле карарга мөмкин. Икенче бер мәгънәсе «революция, наука и труд»тан кыскартылып ясалган ир-ат исеме [Саттаров, 1998: 201]. Казан шәһәре буенча алынган статистик мәгълүматларга караганда, *Ренат* исеме 1920–1930 еллардан алып шактый активлашып, 1990–1999 елларга кадәр кулланылуын дәвам итә [Галиуллина, 2000: 56]. *Әмил* исеме немец теленнән инглиз теленә алынган, чыгышы белән латин теленә бәйле дип аңлатыла. *Aemilius (Эмилий)* кабилә исеме б.э к. III–I гасырга карый, *aemulus* – «тырыш, дәртле, ихласлы» дигәнне аңлата. Казан шәһәре буенча 2000–2014 елгы статистик мәгълүматларга караганда бу исем алтынчы урында тора. *Рикс* исеме латин телендәге *rex* – патша дигән сүзгә барып тоташа [Суперанская, 2005: 216]. Бу ир-ат исеме – омоним исем. Икенче бер мәгънәсе «рабочих и крестьян союз» сүзләреннән кыскартылып ясалган. Латин чыгышлы *Рем* исеменең латин телендә ике мәгънәсе бар: 1. *Remus* – Ромулның абыйсы; 2. *Remus* – ишкәк. *Рим, Риман* исә латин телендәге rom – Рим шәһәре исеменә бәйле карала [Петровский, 2000: 56]. Татар антропонимикасында бер төркем ир-ат исемнәре грек теленнән алынганнар. *Флүн* исеме – грекча philön «кадерле җан, сөя торган нәрсә» [Саттаров, 1998: 256] дигән мәгънәгә ия. 1990–1999 елларда Казан шәһәрендә *Рамил* исеме – 66, 2000–2014 елларда – 15 ир балага кушылган. Бу исемнең килеп чыгышы төрле чыганакларда төрлечә күрсәтелә. Кайбер галимнәр бу ир-ат исемен гарәби чыгышлы дип карасалар [Саттаров, 1998: 199; Галиуллина, 2000: 85], икенчеләре исә бу исемне грек теленнән алынган дип күрсәтәләр [Петровский, 2000: 241]. Гарәпчә *рамл* сүзе «комда багу, юрау» төшенчәсен белдерә. Көнчыгышта комга ясалган нокта һәм сызыклар буенча багу юрауның киң таралган төрләреннән санала, шуңа күрә бу исемне юрау, багуга бәйле «юрау; тылсымчы» дип тәрҗемә итәләр. *Рамил* исемен чыганак телгә бәйләнешле грек чыгышлы Рамил – Рим шәһәренә нигез салучы легендар *Romulus* исе-

менә, грек телендә rhome «көч» дигән мәгънәдә дә карыйлар. Димәк, бу исем ике чыганакка бәйләнешле омоним исем булып санала. Шулай ук грек чыгышлы *Арсен* [Саттаров, 1998: 46] «көчле, батыр» мәгънәсенә [Суперанская, 2005: 54] туры килгән arşen сүзеннән барлыкка килгән дип аңлатыла. Соңгы елларда популярлашып киткән *Данил* исеме (Казан шәһәрендә 2000–2014 елларда ул 113 ир балага бирелгән), борынгы яһүд теленә барып тоташа. *Dânfel* («Алла минем судьям») исеменең фонетик варианты дип карала, [шунда ук: 96]. *Исмәгыйль* исеме *lismâ'el* («Аллаһ ишетә») [шунда ук: 128] сүзенә бәйле карала. Борынгы яһүд теленнән алынган ир-ат исемнәре яһүдиләрнең дине, борынгы дини китаплары аша телебезгә үтеп кергән. Инглиз чыгышлы *Роберт* исеме *Hrodebert, Hruodperht* исемнәренә барып тоташа. *Hrot, hruod* «дан, дәрәҗә» дигәнне аңлатса, *beraht* «менә дигән, бик яхшы» [шунда ук: 217] дигән мәгънәгә ия. Инглиз телендә *Alfred – Альфред* ике компонетлы: *alf* – «эльф», *raed* – «киңәш, яхшы киңәшче» дигәнне белдерә. *Оскар* исеме инглиз телендәге os «алла» һәм gar «сөңге» сүзләреннән гыйбарәт, шулай ук инглиз теленнән алынган ир-ат исеме итеп карала [Рыбакин, 2000: 157]. Соңгы елларда «модалы исемнәр»дән саналган *Артур* исеме инглиз телендәге *Arthur* сүзенә нигезләнә. Казан шәһәре буенча бу исем икенче урында тора. «Урта гасыр әдәбиятында *Артур* турында риваятьләр халык аңына ныклап урнаша. Британия корольләренең улларына *Артур* дигән исем кушулары бу исемнең күпләп кулланыла башлавына китерә» [Новикова, 2006: 85]. *Arthur* сүзе кельт нигезенә барып тоташа, arth «аю» дигәнне аңлата [Рыбакин, 2000: 41]. Бу исем, шулай ук, грек телендәге arktos «аю» нигезендә ясалган Волопас-Арктур йолдыз исеме белән дә тәңгәл. Димәк, бу исемнең нигезе грек теленнән алынып, инглиз телендә киң кулланыла башлаган булырга тиеш. Француз чыгышлы ир-ат исемнәренең рус теленә интенсив рәвештә үтеп керә башлавы Петр I заманына туры килә. Э.Х. Хәбибуллина сүзләрнең француз теленнән үтеп керү сәбәпләрен өйрәнеп, түбәндәге фикергә килә: «возможность усвоения иноязычного словарного состава в новой языковой системе свидетельствует о гибкости языка, о его оперативности в удовлетворении коммуникативных потребностей носителей языка. В основном это вызвано появлением новых понятий, явлений, свойств, состояний, действий, для номинаций которых русский язык не располагал лексическими и словообразовательными ресурсами» [Хабибуллина, 2001: 4] Антропонимнарга килсәк, аларның телебезгә үтеп

керүе әдәбият аша бара. Тарихта эз калдырган шәхесләр, француз язучыларының әсәрләре популярлашуы һәм әсәр геройларының исемнәре татар антропонимиконына француз исемнәренең үтеп керүендә сизелерлек роль уйнаган дип әйтә алабыз. Шулай ук фонопсихологик факторны да билгеләргә кирәк. Сонор тартыкларның ир-ат исемнәрендә чагылуы ата-аналарның теге яисә бу исемне сайлауга психологик яктан якын килүеннән дә бәйле. Исем кушуда фонопсихологик факторның йогынтысы турында диссертациябезнең икенче бүлегендә киңрәк тукталырбыз. Француз ир-ат исемнәре чыгышы белән, инглиз һәм немец исемнәре кебек, латин, грек теленә барып тоташа. Француз чыгышлы *Альянс* исеме «ризалык, берләшмә» дип тәрҗемә ителә; *Арсенал* хәрби терминологиядән алынган сүздән «сугыш кирәк-яраклары склады» дигәнне аңлата; *Идеал* француз теленнән алынган сүз, «камил» дигән мәгънәгә ия; *Рафинад* французчадан «кечкенә шикәр кисәкчекләре» дип тәрҗемә ителә; татарларда исем буларак таралган *Ркаил* француз телендәге Рокайль исеменә нисбәтле ир-ат исеме. *Рокайль* француз телендә «кабырчык, энҗе кабырчык» дигән мәгънәгә ия. Француз чыгышлы ир-ат исемнәренең күбесе билгеле бер предмет, күренешләрне белдергән апеллятивлардан ясалганнар. Нигездә бу исемнәрнең фонетик яңгырашы исем сайлауда мотив булган дип әйтә алабыз. Немец алынмаларыннан *Маркс* һәм *Энгельс* (әлеге исемнәрнең вариантлары: *Энгель, Ингель, Марк* һ.б.) белән бәйле ир-ат исемнәре дә татар антропонимиконында урын ала. Татарларда сирәк очрый торган *Маузер* исеме немецларда корал уйлап табучы *Маузер* фамилиясеннән ясалган; *Риф* немец телендәге «су асты кыялары» дигән мәгънәдә килә. *Форель* немец апеллятив лексикасында балык төренең атамасы нигезендә ясалган; *Фрид* ир-ат исеме немец телендәге *Frida* – «тынычлык, тынлык» [Суперанская, 2005: 263] дигәнне белдерә. Борынгы алман телендә *Эдвард – Эдуард* исеме *ead* «милек», *weard* «сакчы» кебек нигезләргә бәйле [Суперанская, 2005: 270] аңлатыла. Димәк, әлеге исемнең мәгънәсе «милек сакчысы»н аңлата. Киң кулланылышка ия *Арнольд* исеме *Arnold – Arimvald* борынгы герман телендә ике компонетттан тора: *am – аго* «бөркет» булса, *waltan* «хөкем сөрү, хакимлек итү» [шунда ук: 54] мәгънәсендә килә. Борынгы немец мифологиясендә *бөркет* сугыш символы булып тора. Шуңа күрә немец телендә күп кенә ир-ат исемнәре *arn – аю* «бөркет» компонентыннан ясалалар. *Зефил* исеменең мәгънәсе «тыйнак, төгәл» дигәнне аңлата. *Эдгар* немец телендәге *Edgar* «ed милек +

gar сөңге», «сөңге белән саклаучы» [Суперанская, 2005: 270] дип тәрҗемә ителә. *Фридрих* исеме борынгы герман телендә ике компоненттан ясалган ир-ат исеме *fridy* – «тынычлык» булса, *ric* – «бай, шөһрәтле; саклаучы, юлбашчы» мәгънәсенә [шунда ук: 263] ия. *Эрнест* исеме немец теленә грек теленнән кергән. «Җитди; ышанган, инанган» [шунда ук: 273; Рыбакин, 2000: 82] дигәнне аңлата. Әлеге исем Германиянең сәяси эшлеклексе *Эрнест Тельман* исеменә бәйле карала. Бу исемнең татар телендә дә берничә варианты бар: *Эрнес, Эрнис, Ирнис. Фердинанд* исеменең татар телендә *Фернан, Фирнат, Фернад* кебек вариантлары кулланыла. *Ferdinand* – «кыю, батыр сакчы» [Суперанская, 2005: 256] дигәнне аңлата. Башлыча, итальян теленнән татар теленә рус теле аша музыка терминологиясенә бәйле алынмалар үтеп кергән: *тенор, бас, виолончель, флейта* һ.б. Шулай ук сәнгатькә бәйле түбәндәге сүзләрне дә очрата алабыз: театр белән бәйле – балерина, браво, ложе һ.б; рәсем сәнгатенә караган – *акварель, палитра*; архитектурага бәйле – *балкон, коридор* һ.б. А.В. Суперанская билгеләвенчә, «имена итальянского происхождения исторически восходят к католическим святцам» [шунда ук: 93]. Итальян исемнәренең дә төп нигезе латин-грек телләренә бәйле карала. Татарларда киң кулланылышка ия исемнәрдән итальян чыгышлы *Рафаэль* исеме грек теленнән латин теленә *Rhaphael* буларак, борынгы яһүд теленә латин теленнән *Repha'el* «дәвалаучы, сихәт бирүче алла» [шунда ук: 215] мәгънәсендә килеп керә. Бүгенге көндә бу исем татар теленә яраклаштырылып Рафаил вариантында да киң кулланыла. М. Җәләлиева «антропонимик системаның күпчелек берәмлекләре исемиятнең миллилеген чагылдырып, татар теленең үз мөмкинлекләреннән ясалсалар да, рус теле һәм аның аша кергән алынма исемнәр татар тел исемнәренең репертуарын тулыландырып, киңәйтеп, баетып торалар» дип билгели [Залялиева, 1985: 17]. Рус һәм Европа телләре аша кергән исемнәрнең семантик мәгънәләре бу исемнәрнең билгеле бер предмет, күренешләр белән бәйле апеллятивлардан ясалып, ата-ананың хисләрен, теләкләрен чагылдыралар. Рус теленнән алынган исемнәрнең күпчелеге аббревиатур исемнәр һәм, нигездә алар билгеле бер тарихи затка, вакыйгаларга багышланган исемнәр булып саналалар.

## Икенче бүлек

# ТАТАР КЕШЕ ИСЕМНӘРЕНЕҢ ҮСЕШ-ҮЗГӘРЕШ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

## § 6. XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башы татар антропонимик системасы

Тарихи антропонимиканы өйрәнүдә писцовый кенәгәләр мөһим чыганакларның берсе саналалар. XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башында Россия империясендә рус булмаган халыкларга карата куелган тарихи-мәдәни шартлар писцовая кенәгәләрдә сакланып калган исемнәрдә дә чагылыш таба. Писцовый кенәгәләрдәге лексик материалны аерым тикшерү С.А. Мартьянова хезмәтләрендә чагыла. Ул Казан шәһәренең XVI–XVII гасырга караган писцовый кенәгәләрендәге лексиканы өйрәнеп, рус антропонимик берәмлекләрен җентекләп анализлый [Мартьянова, 1952]. Аның фикеренә караганда, писцовый кенәгәләр Россиядә эш документларының сүзлек составы, аерым сүзләрнең тарихы, аларның эчтәлек һәм форма үзгәрешләрен өйрәнүдә бәһасез чыганак саналырга хаклы [Мартьянова, 1952: 109]. Шулай да чыганактагы татар кеше исемнәрен тикшерү бүгенгәчә тарихи антропонимиканың актуаль мәсьәләләренең берсе булып кала бирә. Әлбәттә, бу мәсьәләгә Г.Ф. Саттаров хезмәтләрендә күзәтү рәвешендә анализ ясала, шуңа карамастан, бу чорга караган исемнәр диахроник аспектта өйрәнелүне таләп итәләр дип саныйбыз. Ономастик эзләнүләребезнең төп чыганагын 1979 елда Казанда И.П. Ермолаев, М.Г. Госманов фәнни редакциясендә нәшер ителгән басмаларда Казан өязенең 1602–1603 елларга һәм 1647–1656 елларга караган писцовый кенәгәләрендә теркәлгән кешеләр исемлеге тәшкил итә.

Тарихи чыганакларда сакланып калган исемнәр, аерым алганда, писцовый кенәгәләрдә теркәлгән исемнәр, тарих, чыганак белеме фәне белән беррәттән, тарихи антропонимика өчен дә мөһим. А.В. Суперанская билгеләвенчә, елъязмалар, писцовый кенәгәләр, борынгы һәм хәзерге тарихны өйрәнү дә генә түгел, ономастик

эзләнүләр өчен дә мөһим документ булып санала [Суперанская, 2007: 15]. Ономастик берәмлекләрнең барысының да диярлек нигезчыганагын тәшкил иткән, тарихи үсеш комбинатор-позицион үзгәреш процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән писцовый кенәгәләрдәге татар исемнәре зур кызыксыну уята.

XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башы – татар халкы тарихында гаять каршылыклы чор. Идел буенда яшәүче рус булмаган халыкларга карата руслаштыру сәясәтенең чагылышы булган христианлаштыру патша самодержавиесе сәясәтенең төп юнәлеше санала. Писцовый кенәгәләрнең материаллары турыдан-туры христианлаштыруны күрсәтүне максат итмәсәләр дә, аның нәтиҗәләренең һәм чагылышының кайбер моментларын яктырталар. Алар бигрәк тә татар халкының антропонимик системасында түбәндәгечә чагылыш таба: 1. Милли исемнәрне тулысынча христиан исемнәренә алыштыру; 2. Милли исемнәрнең рус теле тәэсирендә фонетик һәм грамматик үзгәрешләргә дучар ителүе.

Беренче юнәлеш – милли исемнәрне христиан исемнәренә алыштыру – формаль һәм формаль булмаган шәкелдә бара. Рус булмаган милләтләр, рәсми рәвештә христиан исемнәре белән бергә, көнкүрештә милли исемнәрне дә кулланалар; христиан динен тулысынча үз дине дип кабул иткәннәре милли исемнәрен кулланыштан тулысынча төшереп калдыралар. XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башында Россия империясендә дәүләт хезмәте яки хәрби хезмәт үтәүче йомышлы татарлар патша хөкүмәтенең төрле хокукларын алу гаратиясе буларак христианлаша. Шул рәвешле, йомышлы татарларның христиан диненә карата булган мөнәсәбәтләрен исемнәрдә күрергә мөмкин. Мәсәлән, *Якуш Иванов, Туктар Иванов.* Христиан динен кабул иткән йомышлы татарлар арасында *Московко* исеменең еш кулланылышын билгеләргә кирәк: *Тойгилдин Московко, Уразлин Московко, Собатаев Московко*. Рус исемнәрен алу яки татар исемнәрен рус теленең фонетик яки грамматик закончалыкларына буйсындыру берьяклы гына бармый. Мәсәлән, писцовый кенәгәләрдә кайбер рус исемнәре дә татар әйтелеше закончалыкларына буйсындырыла, ягъни рус исемнәре татар теленең фонетик-грамматик структурасына яраклаштырыла: *Ибый – Иван, Учый – Осип, Урый – Ирина, Инук – Иннокентий, Микуш – Михаил, Митуш – Дмитрий* һ.б.

XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башы писцовый кенәгәләрендә 268 төрки чыгышлы исем һәм исем варианты теркәлгән. Кенәгәләрдә

күпчелек исемнәр үзгәрешкә дучар ителгәннәр, исемнәрне транслитерацияләүдә хаталар, кимчелекләр күзәтелә. Исемнәрнең рус фонетик һәм грамматик үзенчәлекләренә яраклаштырылуы сәбәпле, күп кенә исемнәрнең фонетик йөзе югалган. Мәсәлән ауслаутта [и] авазы [ей] дифтонгы белән бирелә: *Байгелдей-Байкилде, Тавгелдей-Таукилде, Теребердей-Теребирде*. Иркәләү-кечерәйтү кушымчасы «-кай» рус исемнәренә хас булган «-ко» суффиксы белән транслитерацияләнә: *Айко-Айкай, Акко-Аккай, Ишейко-Ишкәй*. 1647–1656 елгы писцовый кенәгәләр белән чагыштырганда, 1602–1603 елларга караган писцовый кенәгәләрдәге исемнәрдә фонетик һәм морфологик үзгәрешләр азрак чагылыш таба.

Писцовый кенәгәләр материалларын анализлау барышында төрки чыгышлы исемнәрнең саны күбрәк булуы билгеләнде. Исем ясауда төрки чыгышлы антропокомпонентлар һәм антропоформантлар иң продуктив саналалар. Аерым алганда, фигыль антропоформантлар исем ясауда мөһим урын тоталар: *Аллабирде, Айтуган, Исәнгилде, Кайбул, Уразбакты, Алман, Исәнгилде, Алмай* һ.б. Бу исемнәр төрле фигыль формаларында субстантивлашып, писцовый кенәгәләрдә төрле язылышта чагылыш тапканнар.

Фигыль антропоформантлы исемнәрдә нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль, яки үткән заман сыйфат фигыль формаларындагы исемнәр еш күзәтелә: *Туктамыш; Кармыш-Карамыш*.

Шулай ук *иш* антропоформанты (АФ) еш кулланыла, бу АФ кушып ясалган исемнәр «ата-анага ярдәмче, дус булсын» дигән теләк-исем ролен үти: *Үтиш, Туиш* (бүгенге антропонимик системада бу исем Туишев фамилиясендә сакланган); *Агиш*; препозициядә *Иштуган, Ишмәмәт, Ишәй*. *Иш* антропомормантлы исемнәр бөтен төрки халыкларда, шулай ук кайбер фин-угор халыкларында (мари, удмурдларда) да билгеләнәләр. Татар антропонимикасында *иш* АФ – *тиң* синонимы. *Иш* препозициядә һәм постпозициядә кулланылса, *тиң* бары тик препозициядә генә очрый.

Шулай ук бу чор писцовый кенәгәләрендә борынгы төрки халыкларның яшәү фәлсәфәсе чагылышы булган төс белдерүче антропоформантлар билгеләнәләр. Мисал итеп түбәндәге исемнәрне күрсәтергә мөмкин: *Акморза, Аксубай, Алабай, Алакай, Карабай, Кызылбай, Карай, Күкеш* һ.б. Төс белдерүче антроформантлар М. Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендә дә теркәлгән.

Лексик-семантик яктан караганда, писцовый кенәгәләрдә баланың физик үзенчәлекләрен чагылдырган тасвирлама исемнәр аерым

бер төркем тәшкил итәләр: *Кучук* (11 исем), *Кәтук, Тулыбай, Кукеш, Сытыш* һ.б. Мәсәлән, *Кукеш, Сытыш* кебек исемнәр баланың җитлекмичә тууына ишәрәлиләр. Бу писцовый кенәгәләрдә дә шулай күрсәтелә.

Әгәр XVI гасыр ахырында исем системасы исем һәм фамилиядән торса, XVII гасыр башындагы писцовый кенәгәләрдә ата исеме дә теркәлә башлый: *Янбашин Булат Янбаев, Янбашин Сары Янбаев сын*.

Шулай ук писцовый кенәгәләрдә кыпчакларның исем бирү традицияләренә бәйләнешле *Көчек, Көбәк* «зур эт», *Барак* «эт» кебек исемнәр билгеләнә. Кыпчакларның ата-бабаларын олылау атрибуты саналган бүре яки этне олылау, бу исемне йөртүче кабилә башлыгының бүре яки эткә әйләнүенә ышану белән бәйләнешле килә. Шулай ук кыпчакларда ант итүдә этне корбанга китерү традициясе хакында мәгълүматлар бар. *Көбәк* сүзе төрле үзгәрешләргә дучар ителеп, *köbäk – köbek – köpek* формалары алган. Бу сүз күп кенә төрки телләрдә мәгънә дифференциациясе белән аерылып тора. Мәсәлән, кыпчак төркеменә караган телләрдә *кобәк* «кечкенә эт» мәгънәсендә килсә, угыз телләрендә «зур эт» мәгънәсен белдерә. Барак апеллятив сүзеннән ясалган *Барак* исеме М. Кашгарый сүзлегендә «йонлач, елгыр, җитез ау эте» дип аңлатыла. *Барак* исеме төрекмән халыкларында аеруча киң таралган, ул шулай ук, Бохара хөкемдары Нәүрүз Әхмәт ханның кушаматы да була. Марко Полоның тарихи язмаларында могол бәге һәм 1269–1270 елларда Төрекмәнстанны яулап алучы чагатай хөкемдарының исеме *Барак* дип күрсәтелә.

Төрки халыкларда *Барак* исеме антропонимнар гына түгел, топонимнар һәм этнонимнар буларак та билгеләнәләр. Шулай ук *барак* сүзе хәзерге төрек теленең кайбер диалектларында да күзәтелә.

Югарыда күрсәтелгән исемнәрдән ясалган *Кибәков, Кучугов, Бараков* кебек фамилияләр дә писцовый кенәгәләрдә теркәлгән.

Шулай ук писцовый кенәгәләрдә еш очрый торган кайбер исемнәрнең мәгънәләренә тукталып китик. Мәсәлән, *Кудаш* исемен борынгы төрки телдә *quda – qudaša* «кодача» сүзенең этимологиясе *qundaš* сүзенә бәйләп карарга кирәк: *qun+ daš*, ягъни «*кан-кардәш*». Писцовый кенәгәләрдә теркәлгән *Кардаш* исеме: *qardaš – qardeš – qardas – qaryndas – qaryndaš* «кардәш, абый» дигәнне аңлата һәм бу сүз бүгенге төрки телләрнең барысында да очрый.

Писцовый кенәгәләрдә *Чулпан* исеме ир-ат исеме буларак теркәлгән: *Чулпан Тепкеев, Чулпанко Айтуганов* һ.б. Билгеле булганча,

хәзерге татар антропонимиконында бу исем хатын-кыз исеме буларак та кулланыла.

XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башы антропонимик системасында гарәп һәм фарсы исемнәренең азрак кулланыла башлавы күзәтелә. Писцовый кенәгәләрдәге материалларга караганда, XVI гасыр белән чагыштырганда, XVII гасыр уртасына таба гарәп һәм фарсы исемнәренең антропонимик системада кулланылышы 10% ка арта.

Нигездә бу чор писцовый кенәгәләрендә ике компонентлы исемнең ике антропокомпоненты да яки антропоформанты да гарәп-фарсы чыгышлы булуы сирәк очрый. Еш кына ике компоненттан торган исемнәрнең берсе – төрки чыгышлы, икенчесе – гарәп яки фарсы чыгышлы. Шулай ук писцовый кенәгәләрдә гарәп яки фарсы антропокомпонентлы яки антропоформантлы исемнәрнең бер үк вакытта төрки чыгышлы эквивалентларының кулланылышы да билгеләнде: *Уразкилде – Бәхткилде*; яки фарсы чыгышлы антропоформант яки антропокомпонент гарәп һәм фарсы вариантларының да кулланылышы теркәлде: *Ходайбирде, Аллабирде.* Безнең фикеребезчә, XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башларында татар антропонимик системасында гарәп һәм фарсы исемнәре тулысынча кулланылышка кереп бетми. Гарәп һәм фарсы чыгышлы исемнәр халык арасында XVII гасыр урталарында кулланыла башлый.

Шул рәвешле, писцовый кенәгәләрдәге антропонимик материални диахрониядә өйрәнү татар халкы тарихын гына түгел, ә халыкның мәдәниятен, көнкүрешен тәшкил иткән исем бирү традицияләрен, исем системасын күз алдына китерү өчен дә мөһим.

XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башы – татар халкы тарихының иң авыр этабы. Без моны исем системасындагы үзгәрешләр мисалында да күрә алабыз. Тарихчыларның сүзләре белән әйтсәк, «халыкның милли һәм социаль составын үзгәртү процессы аны Россия империясендә барган сәяси процесс шартларына әзерли». Исем системасындагы үзгәрешләрнең берсе – исемнәрне христианлаштыру, ягъни милли исемнәрне христиан исемнәренә алыштыру, милли исемнәрнең рус теле тәэсиренә дучар ителүе әлеге чорда антропонимик системасында барган үзгәрешләр буларак билгеләнә. Писцовый кенәгәләрдәге исемнәрнең 96% ы төрки чыгышлы, шул рәвешле, исем бирүдә дә төрки традицияләрнең көчле йогынтысы булуы ассызыклана. Татар исемнәрен телнең аерым бер системасы буларак билгеле бер чорларга нисбәтле, җәмгыятьнең үсеш тарихы белән

бергә өйрәнү антропонимиканың төп эволюцион тенденцияләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

## § 7. XVIII гасыр татар исемнәре

Тарихи антропонимиканы өйрәнүдә «Ревизская сказка» материаллары гаять дәрәҗәдә әһәмиятле чыганак булып торалар. Моңа кадәр «Ревизская сказка» материаллары лингвистик аспектта, аерым алганда татар антропонимнарын өйрәнү эшендә аерым тикшерү объекты булмый. XVIII гасырда географ И.К. Кириллов тарафыннан статистик тасвирлама бирү максатында гына «Ревизская сказка» материалларына игътибар ителә. Шулай ук аларның аерым өлешләре туган як тарихын өйрәнүдә кулланылалар. Шуңа күрә «Ревизская сказка» материаллары татар антропонимиясен өйрәнүне, аларга тарихи-лингвистик анализ ясауны таләп итәләр. 1763 елгы III ревизиянең Арча юлындагы авылларның, Малмыж өязенең халык санын алу материалларыннан барлыгы 2367 антропонимик берәмлек анализланды. Шуның 1852 се ир-ат исеме булса, 515е – хатын-кыз исеме.

XVIII гасырның икенче яртысы татар халкының рухи үсеше белән характерлана. Мәчетләр ачылу, мәктәп-мәдрәсәләр төзелү, шул рәвешле халык арасында мөселман диненең төрле катлам арасында нык җәелүе күзәтелә. Татар халкы диндә ныгып, аның максатчан нигезе көчәя. XVIII гасырга караган исемнәр XVII гасырга караган исемнәрдән нык аерыла, чөнки антропонимик системаның нигезен төрки чыгышлы исемнәр тәшкил итсә, перифириясе мөселман исемнәреннән гыйбарәт була.

«Ревизская сказка» материалларында, төрки чыгышлы исемнәр белән чагыштырганда, гарәп-фарсы чыгышлы исемнәр зур күпчелекне тәшкил итәләр. Гарәп-фарсы чыгышлы антропокомпонентларның еш очрый торганнары: *Назсолтан, Яшьсолтан, Биксолтан, Хәлилсолтан* һ.б.

Төрки чыгышлы антропокомпонентлардан: *Батыр, Тимер, Тимербәк, Биктимер, Миңтимер* һ.б.; *Исәнбирде, Исәнгол* һ.б.; *Яшьбулды, Яшьалды* һ.б., *Котлыяр, Ишморат* һ.б.; *Байтимер, Акбай, Байбахты, Байбулат* һ.б.

Фигыль формалары нигезендә ясалган исемнәр постпозициядә дә, препозициядә дә очрыйлар: *Исәнкилде, Яшьбулды, Яшьалды, Алдыбай, Тангелди, Килдебай, Байбахты, Гөлбахты*. «Туды» мәгънәсендә килгән *бакты, килде, бирде* антропоформантлары нигезендә ясалган

исемнәр дә билгеләнә. Фигыль формалары ауслаутта булган очраклар да бар: *Алдыбай, Килдебай* һ.б.; инлаутта исә: *Байбахты, Гөлбахты*.

Угыз формасында фигыльләр нигезендә ясалган *Сөендек, Туктамыш, Катмыш* кебек архаик исемнәр берәр тапкыр теркәлә. Бу исемнәр *-дык, -мыш* кебек угыз формасындагы архаик фигыльләргә кушылып ясалганнар. «Ревизская сказка» материалларында *Үлмәс, Үтәгән, Бакты* кебек фигыльдән ясалган исемнәр чагылыш таба. Исем һәм язмышның тыгыз мөнәсәбәтен чагылдырган *Үлмәс* хатын-кыз исеме 10 тапкыр теркәлгән. Бу исемнең кушылуы сүзнең магик көченә ышану нигездә барлыкка килгән йолага барып тоташа.

Структур-төзелеш ягыннан иркәләү-кечерәйтү семантикасына ия төрки чыгышлы актив сүзьясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалган исемнәрне аерым күрсәтергә мөмкин: -кай/-кәй: *Ишкәй, Нуркай*; -ай/-әй: *Карманай, Солтанай, Ибрай, Юанай, Балтай*; -юк: *Абдюк, Нурюк* һ.б. Бу архаик иркәләү-кечерәйтү кушымчалары белән ясалган исемнәр бүгенге көндә дә Түбән Новгородта яшәүче мишәрләрдә киң таралган.

«Ревизская сказка» материалларында исем кушамат белән бергә кулланыла: *Карабаш Гали, Сабай Ишкенә* һ.б. Әлеге исемнәрдә *Карабаш, Сабай* патроним функциясен үти.

«Ревизская сказка» да татар исемнәре рус теленә яраклаштырылып, рус теленең фонетик-грамматик үзенчәлекләренә адаптацияләнгән була. Исемнәрне транслитерицияләүдә түбәндәге үзенчәлекләр билгеләнә: ауслаутта [и] авазы русчада [ей] белән бирелә: *Гали – Галей, Тимери-Тимерей*. Күп исемнәргә патронимик суффикс *-ко* кушыла Юзейко, Амирко, Назирко, Булатко һ.б. А. Суперанская *-ко/-ка* патронимик суффиксының түбәнсетү мәгънәсен бирүен искәртә [Суперанская, 1973: 135]. Билгеле булганча, русларда *Ивашка, Петрушка* кебек исем төрләре XVIII гасырның рәсми стилендә кулланылыш алган һәм сословиегә туры килмәгән исемләү моделендә очрыйлар.

Халык исәбенең һәм составының тулылыгы өчен, III ревизиядән башлап, хатын-кызның җан исәбен дә алу максаты куела. Хатын-кыз турындагы мәгълүматларга иренең исеме, атасының исеме, яше, элеккеге яшәү урыны, милләте, социаль статусы керә: *Монасыпа жена Салиха Хасанова 35 летов взята Казанского уезда из деревни Тынсар, Татаринов дочь; Габделхаяра жена Салима; Муслима Мусалимова 20 лет взята Казанского уезда из деревни Нового Кызылъяр, Татаринов дочь; У него жена Заяра Юсупова 30 летъ взята из деревни Терячи крестьяников дочь; У него жена вдова Гулия Нариманова*

*19 лет взята Казанской губернии, крешинова* [РС Малмыж., 1763, ф. 3, о. 2, д. 438].

Хатын-кыз исемнәренең күпчелеген гарәп-фарсы чыгышлы исемнәр тәшкил итә: *Гөлгыйзар* (ф.-г.) «гөл яңаклы»; *Ясмия* (ф.) «ясмин гөле»; *Халисә* (г.) «ихлас, саф, пакъ килеш; ирекле»; *Фатыйма* (г.) «үскән кыз; Мөхәммәт пәйгамбәрнең кызы»; *Сәхибә* (г.) «дус, юлдаш, иптәш, сердәш»; *Халидә* (г.) «мәңге яшәр. үлемсез»; *Гөлбия* (ф.-т.) «матур кыз»; *Мөслимә* (г.) «мөселман кызы»; *Гамбәр* (г.) «1) җофар, 2) хушбуй, ислемай»; *Гөлназ* (ф.) «назлы гөл»; *Назсолтан* (ф.) «назлы солтан»; *Рәбига* (г.) 1) «дүртенче гаиләдә дүртенче кыз бала, 2) яз фасылы, 3) умырзая чәчәге»; *Рәхимә* (г.) «мәрхәмәтле, рәхим-шәфкатьле, рәхимле»; *Гөлбакты* (ф.-т.) «гөл кебек»; *Сәлимә* (г.) «сау-сәламәт»; *Галимә* (г.) «акыллы, галим»; *Мәдинә* (г.) «шәһәр, Согуд Гарәбстанындагы шәһәр»; *Зәбидә* (г.) «сайлап алынган асыл зат»; *Мөнәзәрә* (г.) «алдан хәбәр бирүче; сак булырга кушучы»; *Рәхимә* (г.) мәрхәмәтле, рәхим-шәфкатьле, рәхимле; *Габидә* (г.) «гыйбадәт кылучы» һ.б. Хатын-кызга кушыла торган *Сандугач, Үлмәс* – еш кулланыла торган исемнәр.

XVIII гасыр антропонимик системасы үзгәреш чорын кичерә. Исем кушуда төрки традицияләрнең мөселман традицияләре белән алышынуы XVIII гасыр исемиятендә сизелерлек урын ала. Бу – татар халкының тарихи-мәдәни алшартлары йогынтысында милли яңарышның бердәнбер чарасы булган ислам диненә таянуны аңлата. Әлеге алшартлар антропонимик системада да үзләренең тулы чагылышын табалар. Төрки чыгышлы исемнәрнең, кысрыкланып, традициялелеген югалтуы гарәп-фарсы чыгышлы исемнәрнең күпләп кулланылуына китерә, ул – исем реестрының 98% ын тәшкил итә. Шулай итеп, «Ревизская сказка» исем бирү тенденцияләрен чагылдырган, исемнәренең тарихи формалашуын күрсәткән тарихи чыганак ролен үти.

## § 8. XIX гасыр татар исемнәре

XIX йөз – татар әдәби теле һәм матур әдәбият стиле тарихында яңару һәм үзгәрешләргә бай, гаять үзенчәлекле, катлаулы чорларның берсе [Хаков, 1993: 209]. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр, милли күтәрелеш һәм җәмгыятьтәге тарихи вакыйгалар, балага исем кушуның тулысы белән муллалар кулына күчүе бу чорда теофор ир-ат исемнәренең артуына китерә. Дин әһелләре бу өлкәдә махсус китапчыклар бас-

тыру эшен дә киң җәелдерәләр. 1848 елда Казанда – «Исме Аллаһе Тәгалә әл-хәсәни», 1865 елда – «Авради Фәтхия», 1899-1900 елларда Ахун Бендуковның «Исем. Балага күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафикъ китап» [Бендуков, 1899] һ.б. китаплар киң катлау укучыга тәкъдим ителә. Шуны билгеләргә кирәк, XIX гасыр гарәби-фарсы чыгышлы исемнәрнең күп санда кулланылуы белән билгеләнсә, Ф.М. Хисамова XVIII гасырга караган татар эш язуларының үзенчәлекләрен анализлап, «документларда очраган 500 исемнән 200 гә якыны гарәп-фарсы чыгышлы булса, калганнары телнең үз лексикасы нигезендә ясалуын» [Хисамова, 1981: 54] искәртә. Димәк, татар антропонимикасына гарәби-фарсы чыгышлы ир-ат исемнәренең интенсив рәвештә үтеп керүе XIX гасырга карый. Хезмәтебездә XIX гасыр башы һәм XIX гасыр ахыры татар исемнәре статистик һәм социаль үзгәреш үзенчәлекләре, исем составы «Ревизская сказка» чыганакларына нигезләнеп анализланды. Әлеге зур чорны анализлау өчен билгеле бер территориягә бәйле төрле синхрон вакыт аралыгына караган антропонимик берәмлекләрне күзәтү, кенәгәләрдә билгеле бер вакыт аралыгын яктырткан мәгълүматлары булган, халык составы ягыннан, географик урынчылыгы ягыннан, мәдәни үсеше ягыннан билгеле бер идеалга якын территорияләрне тикшерү һәм аларны чагыштыру кызыклы гына мәгълүмат бирә дип саныйбыз. Казан шәһәре буенча XIX гасыр башы һәм ахырының антропонимик системасын күзәтү өчен 1816–1825 һәм 1870–1879 елгы «Ревизская сказка» кенәгәләреннән барлыгы 2078 антропонимик берәмлек сайлап алынды. 1870–1879 елгы «Ревизская сказка» кенәгәләреннән Мамадыш өязе буенча 534 татар ир-ат исеме теркәлде. 1816–1825 елларда Казан шәһәрендә 1302 ир-ат исеме кушылса, исем репертуары 225 исем тәшкил итә. Исем йөртүчеләрнең санын (1302) исем репертуары санына (225) бүлеп, бер үк исемдәгеләрнең уртача коэффициент санын билгелибез. Бу сан якынча 6 кешегә туры килә. Әгәр исем 6 һәм аннан да күбрәк ир балага кушылса, ул еш кулланыл торган исем булып исәпләнә. Казан шәһәрендә 1816–1820 елларда еш кулланылучы 56 ир-ат исеме 997 ир балага кушылган. Әлеге ир-ат исемнәре түбәндәге чагыштырмада (беренчесе – күрсәтелгән исемне йөртүче балалар саны, икенчесе – вакланмалысы – процент күләме) бирелә: *Ибраһим* 61-4,68; *Хәсән* 59-4,53; *Муса* 52-3,99; *Хөсәен* 48-3,68; *Йосыф* 42-3,22; *Мостафа* 41-3,14; *Исхак* 32-2,45; *Мөхәммәтгали* 29-2,22; *Мортаза* 28-2,15; *Хәбибулла* 27-2,07;

*Әхмәт* 25-1,92; *Мөхәммәт* 25-1,92; *Якуп* 25-1,92; *Мөхәммәтҗан* 23-1,76; *Исмәгыйль* 19- 1,45*; Габделатыйф* 18-1,38; *Габдерәшит* 18-1,38; *Габдулла* 17-1,30; *Салих* 17-1,30; *Сөләйман* 17-1,30; *Мөхәммәтрәхим* 16-1,22; *Хәмит* 16-1,22; *Шаһигәрәй* 16-1,22; *Габделвәли* 15-1,15; *Мөхәммәтсадыйк* 15-1,15; *Җәмил* 14-1,07; *Фәйзулла* 3-0,99; *Халит* 13-0,99; *Габидулла* 12-0,92; *Мөхәммәтвәли* 12-0,92; *Фәхретдин* 12-0,92; *Бикбай* 11-0,84; *Мәхмүт* 10-0,76; *Хисаметдин* 10-0,76; *Шәмсетдин* 10-0,76; *Габделгаффар* 9-0,69; *Давыт* 9-0,69; *Әхмәтҗан* 9-0,69; М*өхәммәтшәриф* 9-0,69; *Тимербулат* 9-0,69; *Гали* 8-0,61*; Әмир* 8-0,61; *Миңлебай* 8-0,61; *Нигъмәтулла* 8-0,61; *Рәхмәтулла* 8-0,61; *Сәйфулл*а 8-0,61; *Фәтхулла* 8-0,61; *Габделкәрим* 7-0,53; *Габделмәҗи*т 7-0,53; *Габит* 7-0,53; *Сәгыйть* 7-0,53; *Баязит* 6-0,46; *Габдерәхим* 6-0,46; *Гобәйдулла* 6-0,46; *Сәйфелмөлек* 6-0,46; *Таҗетдин* 6-0,46. Казан шәһәрендә гасырның ике чирегендә дә кушылган ир-ат исемнәре түбәндәгеләр: *Баһаветдин, Баязит, Бәдретдин, Бәшир, Бикбай, Биккенә, Биктимер, Габделатыйф, Габделваһап, Габделвәли, Габделвахит, Габделгаффар, Габделкәрим, Габделмәҗит, Габделнасыйр, Габдерәхим, Габдулла, Гайнулла, Гали, Галиәкбәр, Галимҗан, Гобәйдулла, Гомәр, Госман, Давыт, Әмир, Әхмәт, Әхмәтҗан, Исхак, Йосыф, Мәхмүт, Миңлебай, Мортаза, Мостафа, Мөхәммәт, Мөхәммәтвәли, Мөхәммәтгали, Мөхәммәтҗан, Мөхәммәтйосыф, Мөхәммәткәрим, Мөхәммәтлатыйф, Мөхәммәтрәхим, Мөхәммәтсадыйк, Мөхәммәтша, Мөхәммәтшәриф, Муса, Нигъмәтҗан, Нигъмәтулла, Нурмөхәммәт, Рәхмәтулла, Садыйк, Салих, Сәгыйть, Сәйфетдин, Сәйфулла, Сираҗетдин, Сөләйман, Тимербулат, Фәйзулла, Фәтхулла, Фәхретдин, Хәйбулла* һ.б. Казан шәһәрендә XIX гасырның ике чирегендә дә күпчелек очракта ике составлы ир-ат исемнәре кулланыла. Бер составлы ир-ат исемнәре ике составлы исемнәрнең компонентлары булып киләләр. Гасырның ике чирегендә дә *Мөхәммәт* антропокомпоненты нигезендә ясалган ир-ат исемнәре сан ягыннан зур күпчелекне тәшкил итәләр. Бу антропокомпонент нигезендә гасырның беренче чирегендә 26 төрле ир-ат исеме 300 балага бирелгән. Бу барлык ир-ат исемнәренең 23,04% ын тәшкил итә. Гасырның икенче яртысында исә *Мөхәммәт* антропокомпоненты 144 ир балада, 17 төрле ир-ат исемендә очрый. Бу барлык ир-ат исемнәренең 21,7% ын тәшкил итә. Димәк, гасыр ахырына таба, *Мөхәммәт* антропокомпонентлы татар ир-ат исемнәренең 1,34% ка кимүе күзәтелә. Казан шәһәрендә

гасыр башында кулланылган *Батыр, Биккол, Бикмирсәгыйтъ, Бикчәнтәй, Вәлит, Габбас, Габделбакир, Габделбашар, Габделгалим, Габделкәфил, Габделмәннәф, Габдесаттар, Габдесәлим, Габдрахман, Әсфәндияр, Гобәй, Галәветдин, Җаббар, Җаббаркол, Сәфәр, Сәфәргали, Солтанис, Ярми, Ногъман, Туктар, Төхвәтулла* кебек ир-ат исемнәренең гасыр ахырында кулланылуы күзәтелми. Әмма бу ир-ат исемнәре тулысы белән төшеп калган дип тә әйтеп булмый, чөнки XX гасыр башында әлеге ир-ат исемнәренең антропокомпонентлары яки антропоформантлары билгеле бер исем составында очрый. Мәсәлән, *Батыргали, Сәфәргали, Солтан* һ.б.

Казан шәһәрендә гасыр башында *габд-габде-габдел* антропоформантларыннан 35 ир-ат исеме ясалган һәм алар 146 ир балага кушылган. Бу барлык ир-ат исемнәренең 11,2% ын тәшкил итә. Гасыр ахырына таба *габд-габде-габдел* антропоформантлары исем составында кыскаруга яисә бөтенләй төшеп калуга таба бара. Гасырның икенче яртысында бу антропоформантлы 16 ир-ат исеме 29 ир балага кушылган. Бу барлык ир-ат исемнәренең 4,2% ын тәшкил итә. *Габд-габде-габдел* антропоформантлы татар ир-ат исемнәренең гасыр ахырына таба 7% ка кимүе күзәтелә. Алда әйтелгәнчә, *Мөхәммәт* компонентының ир-ат исемнәрендә кулланылышының кимүен дә исәпкә алсак, XIX гасырның ахырларына таба татар антропонимиконында «гадиләшү» тенденциясен билгеләргә мөмкин. Мамадыш өязе буенча алынган 1870–1874 елгы мәгълүматларга караганда, 534 ир балага 162 ир-ат исеме бирелгән. Бер үк исем йөртүчеләрнең уртача коэффициенты 3,2 гә туры килә. Еш кулланылучы ун ир-ат исемнәре түбәндәгеләр: *Мөхәммәтвәли* 17-3,18; *Әхмәтҗан* 14-2,62; *Мостафа* 14-2,62; *Мөхәммәтгали* 14-2,62; *Мөхәммәтзариф* 14-2,62; *Мөхәммәткәрим* 13- 2,43; *Мөхәммәтша* 13-2,43; *Мөхәммәтшакир* 13-2,43; *Мөхәммәтҗан* 12-2,24; *Мөхәммәтрәхим* 12-2,24. Әлеге ир-ат исемнәреннән күренгәнчә, еш кулланылучы ун ир-ат исеменең сигезе *Мөхәммәт* антропокомпоненты нигезендә ясалган. Бу антропокомпонент барлыгы 24 ир-ат исеме составында кулланылган һәм 164 ир балада очрый, һәм барлык ир-ат исемнәренең 30,7% ын тәшкил итә. Казан шәһәре белән чагыштырып караганда, XIX гасырның икенче яртысында Мамадыш өязендә *Мөхәммәт* антропокомпоненты нигезендә кушылган ир-ат исемнәре 9% ка күбрәк дип әйтергә мөмкин. Мамадыш өязендә *габд-габде-габдел* антропоформанты 24 ир-ат исемендә чагылган. Бу антропоформантлы ир-ат исеме 52 ир ба-

лага бирелгән. Бу барлык ир-ат исемнәренең 9,7% ын тәшкил итә. Казан шәһәре белән чагыштырсак, бу антропоформантлы ир-ат исемнәре Мамадыш өязендә 5,5% ка күбрәк ир балага кушылган. Әйтелгәннәрдән чыгып, халык азсанлы территорияләрдә дини идеологиянең, ышану-традицияләрнең йогынтысын исемнәрдә дә белгеләргә кирәк.

Мамадыш өязендә XIX гасыр ир-ат исемнәренең зур күпчелеге генетик яктан гарәп-фарсы исемнәрен тәшкил итәләр. Шулай да, аз санда булса да, төрки-татар ир-ат исемнәрен яисә исемнәрдә төрки-татар антропокомпонентларын очратырга мөмкин: *Аблак, Таишәрдан, Котлымөхәммәт, Тимергали, Тимербулат, Биккенә, Биктимер, Килмәмәт* һ.б. Мамадыш өязендә XIX гасыр исемнәренең 98,1% ы гарәп-фарсы чыгышлы булуы ачыкланды. Казан шәһәре мәгълүматлары буенча, 15 төрки-татар ир-ат исеме һәм компоненты кулланылышы билгеләнде. Димәк, Казан шәһәре исемиятенең 99,3% ы гарәби-фарсы чыгышлы. Мамадыш өязе белән чагыштырганда, Казан шәһәрендә гарәби-фарсы чыгышлы ир-ат исемнәренең 1,2% ка күбрәк булуы ачыкланды. XIX гасырның икенче чирегенең структур-ясалыш үзгәрешләрен тулырак ачу максаты белән түбәндәге таблицаны тәкъдим итәбез.

1 нче таблица

| Ир-ат исемнәре составы (% ларда) | 1870–1874 еллар |
|---|---|
| Казан шәһәре буенча | Мамадыш өязе буенча |
| 27 | 23 |
| 73 | 77 |

Димәк, таблицадан күренгәнчә, Мамадыш өязендә ике составлы ир-ат исемнәре барлык ир-ат исемнәренең 77% ын тәшкил итәләр һәм, Казан шәһәре белән чагыштырганда, 4% ка күбрәк кушылганнар. Ягъни, Мамадыш өязендә XIX гасыр ахырына таба традицион ике компонентлы исемнәр калыбы тотрыклы рәвештә саклана.

Күзәтүләребезгә караганда, халык саны белән аерылып торган территорияләрдә яшәүчеләрнең (Казан шәһәре һәм Мамадыш өязе мисалында) исем составында да аерымлыклар күзәтелә. Бу, беренче

чиратта, иҗтимагый- сәяси, дини шартларның әлеге территорияләрдә үзгә булуыннан һәм халык саны аз булган шәһәрләрдә, авылларда консерватив фикерләүнең исем кушуда чагылыш табуыннан бәйле. Икенче чиратта, халкы азсанлы территорияләрдә гореф-гадәтләрнең, йола-традицияләрнең нигезле сакланып килүе исем системасының тотрыклылыгын тәэмин итүдә чагыла.

## § 9. XX гасыр татар исемнәренең үсеш тенденцияләре

XX гасыр – төрле сәяси-иҗтимагый, мәдәни вакыйгаларга бай чор. Бу үз чиратында, татар антропонимик системасының үзенчәлекле формалашуына, үсеш-үзгәрешләренә тәэсир итә. XX гасыр татар антропонимикасы Казан шәһәре исемнәр системасы галимә Г.Р. Галиуллина хезмәтләрендә урын алган, системалы итеп синхроник-диахроник аспектта тикшерелгән [Галиуллина, 2000: 38]. Г.Р. Галиуллина XX гасыр татар ир-ат исемнәренең динамика һәм статикасын тикшереп, 99 ел эчендә (монда XX гасыр күз алдында тотыла) Казан шәһәрендә татар ир-ат исемнәренең чагыштырмача үзгәрешләр кичерүен, әгәр гасыр башында ике составлы дини эчтәлекле гарәп-фарсы чыгышлы исемнәр чагылыш тапса, туксанынчы еллар ахырына исә, исемнәрнең европалашуы күзәтелүен билгели [Галиуллина, 2000: 71]. Казан шәһәре ЗАГС бүлеге материаллары нигезендә ике хронологик вакыт аралыгы анализланды. 1930–1939 еллар буенча 1312 ир баланың тууы турындагы акт язулары тикшерелде. Ир балаларга барлыгы 310 төрле исем бирүе ачыкланды. 1990–1999 еллар дәвамында 1378 ир баланың тууы турындагы акт язулары анализланды. Бу вакыт аралыгында ир балаларга 223 төрле исем бирелүе билгеләнде. Димәк, гасыр ахырына таба татар ир-ат исемнәре репертуар ягыннан кимүгә таба бара. Мамадыш районы ЗАГС бүлегеннән алынган ике хронологик вакыт аралыгы күзәтелде. 1930–1939 еллар буенча 723 ир баланың тууы турындагы актлар язуы анализланды. Бу еллар аралыгында 127 төрле ир-ат исеме кушылган. 1990–1999 елларда 812 ир балаларның тууы турындагы актлар язуы анализланды. Бу елларда 128 төрле ир-ат исеме бирелгәнлеге ачыкланды. Әлеге территорияләрдә яшәүчеләрнең исем зәвыкларын чагыштырып карау максатыннан, еш кулланылучы унбиш татар ир-ат исемнәрен чагылдырган 2 нче таблицаны тәкъдим итәбез.

2 нче таблица

| 1930–1939 | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Казан шәһәре буенча | | | Мамадыш шәһәре буенча | | |
| Илдус | 84 | 5,74 | Рафаил | 12 | 5,74 |
| Рәшит | 60 | 4,10 | Илдус | 7 | 3,34 |
| Равил | 57 | 3,89 | Азат | 6 | 2,87 |
| Рәфкать | 50 | 3,41 | Ирек | 6 | 2,87 |
| Мансур | 49 | 3,35 | Илгиз | 6 | 2,87 |
| Рафаил | 49 | 3,35 | Наил | 5 | 2,39 |
| Әнвәр | 47 | 3,21 | Мансур | 5 | 2,39 |
| Наил | 44 | 3,00 | Рәфкать | 5 | 2,3 |
| Илдар | 41 | 2,80 | Марат | 4 | 1,91 |
| Шамил | 37 | 2,53 | Рәшит | 4 | 1,91 |
| Фәрит | 35 | 2,39 | Марсель | 4 | 1,91 |
| Илгизәр | 34 | 2,32 | Роберт | 4 | 1,91 |
| Камил | 28 | 1,91 | Марс | 4 | 1,91 |
| Мәхмүт | 27 | 1,84 | Рәүф | 4 | 1,91 |
| Фоат | 27 | 1,84 | Альберт | 3 | 1,43 |
| Габдулла | 20 | 1,36 | Равил | 3 | 1,43 |
| Гомәр | 20 | 1,36 | Алмаз | 2 | 0,95 |
| Ренат | 18 | 1,23 | Габдулла | 2 | 0,95 |

Әлеге таблица буенча Мамадыш шәһәре ир-ат исемнәре системасында рус һәм Көнбатыш Европа алынмаларының, Казан шәһәре белән чагыштырганда, күбрәк булуын күзәтә алабыз. Казан шәһәрендә еш кулланылучы 15 исемнән икесе рус теле һәм Көнбатыш Европа телләреннән алынган. Бу – исемнәрнең 13% ын тәшкил итә. Мамадыш шәһәрендә, таблицадан күренгәнчә, алты исем рус теле һәм Көнбатыш Европа телләреннән кергән. Бу – исемнәрнең 40% ын тәшкил итә. Димәк, Мамадыш шәһәрендә «европалашу» тенденциясе 27% ка

югарырак булуы ачыкланды. 1990–1999 елларда ир-ат исемнәрен Казан шәһәре мәгълүматлары белән Мамадыш шәһәрен чагыштырып анализлау өчен 3 нче таблицаны тәкъдим итәбез:

3 нче таблица

| 1990–1999 еллар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Казан шәһәренең Киров районы буенча | | | Мамадыш шәһәре буенча | | |
| Артур | 216 | 8,13 | Айрат | 20 | 2,91 |
| Руслан | 184 | 6,93 | Илнур | 18 | 2,62 |
| Тимур | 170 | 6,40 | Рамил | 17 | 2,48 |
| Адел | 144 | 5,42 | Габдулла | 17 | 2,48 |
| Булат | 99 | 3,73 | Адел | 16 | 2,33 |
| Айрат | 90 | 3,39 | Айдар | 16 | 2,33 |
| Марат | 70 | 2,63 | Марат | 16 | 2,33 |
| Алмаз | 70 | 2,63 | Айнур | 15 | 2,18 |
| Рамил | 66 | 2,48 | Ришат | 15 | 2,18 |
| Айдар | 64 | 2,41 | Артур | 14 | 2,04 |
| Ренат | 59 | 2,22 | Рәмис | 14 | 2,0 |
| Динар | 59 | 2,22 | Раил | 12 | 1,75 |
| Әмил | 57 | 2,14 | Илшат | 12 | 1,75 |
| Эдуард | 57 | 2,14 | Альберт | 12 | 1,75 |
| Данил | 56 | 2,11 | Рөстәм | 11 | 1,6 |
| Альберт | 54 | 2,03 | Дамир | 11 | 1,6 |

Шәһәр ир-ат исемнәре исем репертуары ягыннан төрлелеге белән аерыла. Кечкенә шәһәрнең исемнщр репертуары төрлелек ягыннан чикле. Бу күренешне зур шәһәрләрдә төрле этнокультураларның тыгыз бәйләнештә торулары һәм аларның татар мөхитенә тәэсире белән аңлатырга кирәк. Бигрәк тә соңгы елларда халкыбызның Көнчыгыш һәм Кавказ илләре белән сәяси-икътисади, сәүдә элемтәләре, туризм-

ның үсеше антропонимик системабызга татар ир-ат исемнәренең яңа дулкыны килүенә сәбәп булып тора. Татар антропонимиконында 1990–1999 елларда *Азаман, Анар, Аршак, Айзек, Алишер* кебек ир-ат исемнәренең артуы Көнчыгыш һәм Кавказ илләре белән тыгыз бәйләнешләр нәтиҗәсе дип әйтә алабыз. XX гасыр ахырларына татар ир-ат исемнәр системасында ясалма ир-ат исемнәре арта. Ата-аналарның иҗаты нәтиҗәсендә барлыкка килеп, зур тизлек белән таралу алган ясалма ир-ат исемнәре традицион исемнәрнең фонетик ономавариантлары булып киләләр. Бу исемнәрне балага кушуда фоносимволик мотив төп мотив итеп карала. Мәсәлән, *Реназ* исеме (Казан шәһәре буенча 0,11%) *Ренас* («революция», «наука», «союз» сүзләренең аббревиатурасы) сүзенең фонетик варианты дип уйлыйбыз. Бу очракта Реназ исеменең соңгы компонентын милли җирлеккә күчереп әйтү, исемне миллиләштерү тенденциясе күзәтелә. Әйтергә кирәк, XX гасырда татар ир-ат исемиятендә сизелерлек үзгәрешләр тенденциясе ассызыклана. Ясалма ир-ат исемнәренең саны арту, рус теле һәм Көнбатыш Европа исемнәренә охшаш исемнәр ясалу тенденцияләре, ата-аналарның уңай семантик мәгънәгә ия исемнәргә игътибар итмәве милли антропонимик реестрның традицион үсешенә тискәре йогынты ясый. XIX гасыр ир-ат исемнәреннән аермалы буларак, XX гасыр антропонимик системасының «гадиләшү» тенденциясе ике компонентлы ир-ат исемнәренең аз санда кулланылуы белән билгеләнә.

## § 10. XXI гасыр башы татар исемнәренең үсеш тенденцияләре

2000–2005 елларда Казан шәһәрендә 1429 ир баланың тууы турындагы акт язулары анализланды. 211 төрле ир-ат исеме бирелгәнлеге мәгълүм булды. Мамадыш шәһәре буенча 603 ир баланың тууы турындагы актлар язуы тикшерелде. Барлыгы 149 ир-ат исеме бирелгәнлеге ачыкланды. XXI гасыр татар мәдәниятендә торгынлык чоры белән билгеләнә. Бу, үз чиратында, татар ир-ат исемнәре системасында да чагыла. Халыкның милли үзаңы кимүе татар ир-ат исемнәренең «чуарлануына» китерә. Бу тенденция аеруча зур шәһәрдә чагыла. Төрле милләтләрнең бер территориядә тупланып яшәве, аларның үзара сәяси-икътисади, сәүдә, мәдәни элемтәдә булулары һәм туризмның алгарышы катнаш никахларның артуына һәм шулай ук татар антропонимикасының ассимиляциясенә зур йогынты ясый. Соңгы еллар материалларына караганда, татар антропонимиконы, Көнбатыш белән бергә,

Көнчыгыш тәэсирен дә кичерә башлады, ягъни «европалашу» һәм «азияләшү» тенденцияләре татар антропонимик системасының билгеле бер дәрәҗәдә үсешен билгели башладылар. «Европалашу» тенденциясе татар милли ир-ат исемнәрен үзгәртеп куллану юлын алса (*Илдар – Эльдар, Илнар – Эльнар, Илназ – Эльнас* һ.б.) антропонимиконыбызга яңа төр ир-ат исемнәре (*Азамат, Кәмран, Анар, Аршак, Эрхан* һ.б.) кулланыла башлавы «азияләшү» тенденциясе белән билгеләнә. Бу күренешләр, материалларга караганда, зур шәһәрләр өчен хас. Халык демографиясен тикшеренүләр, авыл, район халкының балаларын татар традицияләрендә тәрбияләргә теләүләрен күрсәтәләр. «Шәһәрдә ата-аналарның 25,9% ы балаларын милли мәдәният традицияләрендә тәрбияләргә теләсәләр, авылда исә 64,1% ата-ана милли үзаң культурасын бирергә тели» [Язык и этнос..., 2002: 64]. Әйтергә кирәк, саннарның социаль аермасы татар ир-ат исемнәрендә дә күзәтелә. Шуңа күрә, ата-аналарның балага милли исем бирү тенденциясе, йола-традицияләрнең сакланып килүе авыл үзәкләрендә күпкә югарырак дип әйтә алабыз. Мәсәлән, балага озын исем бирү традициясе, балага озын гомер теләү мотивы белән билгеләнә. Әйтергә кирәк, әлеге традиция бүгенге көндә дә авыл җирлегенә яшәвен дәвам итә. Татар исемнәренең XXI гасыр баншндагы торышын тулырак күз алдына китерү өчен, тупланган антропонимик берәмлекләр нигезендә еш кулланылучы егерме татар ир-ат исемнәре исемлеген, зур һәм кечкенә шәһәрләр мисалында чагыштырып, 4 нче таблицада тәкъдим итәбез:

*4 нче таблица*

| 2000–2005 еллар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Казан шәһәре буенча | | | Мамадыш шәһәре буенча | | |
| Данил | 113 | 7,90 | Булат | 36 | 5,97 |
| Артур | 81 | 5,66 | Алмаз | 35 | 5,80 |
| Тимур | 79 | 5,52 | Илназ | 23 | 3,81 |
| Руслан | 68 | 4,75 | Адел | 21 | 3,48 |
| Булат | 67 | 4,68 | Инсаф | 19 | 3,15 |
| Әмил | 61 | 4,26 | Руслан | 18 | 2,98 |
| Әмир | 43 | 3,00 | Ислам | 17 | 2,81 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Камил | 37 | 2,58 | Илдар | 16 | 2,65 |
| Айрат | 35 | 2,44 | Ильяс | 16 | 2,65 |
| Марсель | 28 | 1,95 | Нияз | 15 | 2,48 |
| Азат | 26 | 1,81 | Илнур | 12 | 1,99 |
| Алмаз | 26 | 1,81 | Рөстәм | 12 | 1,99 |
| Дамир | 26 | 1,81 | Рамил | 10 | 1,65 |
| Айдар | 24 | 1,67 | Дамир | 10 | 1,65 |
| Рөстәм | 22 | 1,53 | Әмир | 10 | 1,65 |
| Динар | 20 | 1,39 | Айдар | 9 | 1,49 |

XXI гасыр башы татар антропонимиясе баю, яңару процессы түбәндәге юллар белән бара:

1. Чыгышлары белән гореф-гадәтләргә, мәҗүси йолаларга бәйләнешле татар ир-ат исемнәрен куллану ерак гасырлардан ук күзәтелә. Ә менә XXI гасыр башында кушылган *Тимер, Тимерхан, Булат, Арслан, Алмаз, Илбарис* кебек ир-ат исемнәре исә сүзнең магик көченә ышану мотивына нигезләнгән.

2. XXI гасыр башы теологик мотивка бәйле татар ир-ат исемнәренең исемияттә яңадан модага кереп китүе белән билгеләнде. Бигрәк тә, теопрефикслы, ике составлы ир-ат исемнәренең 9,3% ка артуын күререргә мөмкин. Казан шәһәре буенча алынган материаллардан күренгәнчә, *Кәрим* (1,04%), *Ислам* (0,90%), *Мөхәммә*т (0,1%), *Мөхәммәткадыйр* (0,06%), *Габделгазиз* (0,06%), *Сәйфулла* (0,06%), *Нурмөхәммәтгали* (0,06%), *Габдрахман* (0,06%) *Габдулла* (0,06%), *Аллаһбирде* (0,06%), *Рамазан* (0,55%), *Ибраһим* (0,20%), *Габделваһап* (0,60%) кебек ир-ат исемнәренең кулланылыш ешлыгы арта төшкән.

Мамадыш шәһәре антропонимиконында теофор исемнәрнең кулланылыш проценты югары: *Ильяс* (2,65%), *Салават* (1,32%), *Габдулла* (0,66%), *Рамазан (*0,49%), *Ибраһим* (0,33%), *Мөхәммәт* (0,33%), *Динислам* (0,33%), *Йосыф* (0,16%), *Кәри*м (0,16%).

3. Төрки чыгышлы «ил», «ир», «идел», «ай», «ал» компонентлары һәм антропоформантлары нигезендә ясалган ир-ат исемнәре гасыр башында яңа эчтәлек алалар (*Илдан, Иршат, Иделман, Айзат, Айшат, Алнур, Язнур*);

4. Татар антропонимикасында традицион ир-ат исемнәрендә татар антропонимикасына хас булмаган авазларның кулланылуын билгеләргә мөмкин. Мәсәлән, *Илдар* исемен *Эльдар* дип, *Илнар* исемен *Эльнар* һ.б. дип үзгәртү күренешләре күзәтелә. Шулай ук *Эльтимур, Эльнур, Эльвин, Эльвар* кебек ир-ат исемнәре дә очрый. Казан шәһәре материалларына караганда ике составлы ир-ат исемнәре кулланылышы арта. XX гасырда киң кулланылган традицион татар ир-ат исемнәреннән (*Илнур, Иршат, Вилдан* һ.б) тыш, чор өчен яңа дип табылган татар ир-ат исемнәре кулланылышка килеп керәләр (*Әмирхан, Габделваһап, Әмиртимур, Бикбулсын, Әбүрәхил, Аллаһбирде, Әбрарбәк, Әмирбәк, Сәетбәк, Габделгазиз, Нурмөхәммәтгали, Әмиргазиз, Сабиржан, Гомәрҗан, Таһирҗан*). XX гасырда кулланылыштан төшеп барган *әмир, бәк, җан* кебек антропокомпонентларның гасыр башында «кире торгызылу» процессы бара.

Мамадыш шәһәре материаллары Казан шәһәре материалларының киресен күрсәтә: монда, нигездә, XX гасырда кулланылган традицион татар ир-ат исемнәре генә кушылган, чор яңалыклары күзәтелми. Димәк, халкы азсанлы җирлекләрдә экстралингвистик факторларның тәэсире азрак чагылыш таба. Татар ир-ат исемнәре, башка антропонимик берәмлекләр кебек үк, аерым бер функция башкаралар. Хезмәтебездә XIX–XX гасырлар һәм XXI гасыр башы антропонимик берәмлекләрен тикшерүдә бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булган ир-ат исемнәренең ике төр функцияләре билгеләнде. Бу чорларда татар ир-ат исемнәрендә иҗтимагый аеру функциясе ассызыклана. Шәхесне аеру, «легальләштерү» белән бергә, җәмгыятьнең социаль структурасында кешенең урыны да билгеләнә. Шәхесне аеру ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре өчен дә универсаль функция вазифасын үти. Ә социаль «легальләштерү» исә, нигездә, ир-ат исемнәренә хас хосусый функция буларак билгеләнә. Мәсәлән, төрле сословие титулларының, кәсеп-һөнәр атамаларының, кешенең социаль статусын чагылдырган компонентларның ир-ат исемнәре (*бай, ярлы* антропокомпонентлары) составында килүе иҗтимагый аеру функциясе ролен үти. Шуңа күрә бу төр ир-ат исемнәрен хосусый функция итеп карарга кирәк. XIX гасыр антропонимиконында югары катлау кешеләрен түбән катлаудан аеруда хезмәт итүче *хан, бай, мирза/морза, мулла* кебек компонентлар шулай ук исемнәрдә иҗтимагый аеру функциясе вазифасын үтәгән. Традиция, йола-гадәтләргә, модага, шәхси зәвыкка туры килә торган универсаль функция әйтеп үткән һәр гасырда, субъектив факторлар

белән билгеләнеп, рациональ рәвештә чагылыш таба. Әйтергә кирәк, исем кушу, исем сайлау традиция-йолалары, үзләренең формацияләрен үзгәртеп, бүгенге көнгәчә яшиләр. Мәсәлән, *ай* компонентлы ир-ат исемен кушуда мәҗүси традицияләр бала ай кебек матур булсын, яки айлы кичтә туган балага исем бирү традицияләре белән алыштырылалар. XX–XXI гасыр башында *ай* компонентлы ир-ат исемнәре ай культына бәйле кушылмый, бу исемнәрдә теләк мотивы билгеләнә. Исемнең саклау үзенчәлегенә, язмышка тәэсир итүенә ышану кебек универсаль харизматик функцияләр бүгенге көндә дә яшәп киләләр. Мәсәлән, «миң» компонентлы ир-ат исемнәрендә, *Булат, Тимер, Тимерхан* кебек ир-ат исемнәренең нигезендә дә сүзнең магик көченә ышану ята. Теологик функцияне аерып карарга кирәк дип уйлыйбыз, чөнки ислам диненә бәйле кушылган ир-ат исемнәре татар антропонимикасында бүгенге көнгәчә яратып кушылалар. Билгеле бер көчкә ышану нигез булганга, соңгы ике функцияне берләштереп, шартлы рәвештә теохаризматик функция дип атадык. Күрсәтелгән функцияләр конкрет тарихи чорларның үзгәреше процессында ир-ат исемнәр системасы үсешендә төп хәрәкәткә китерүче көч булып саналалар. Гарәп-фарсы чыгышлы ислам һәм аның атрибутлары чагылган исемнәр ир балаларга кушылган. XX гасыр урталарына таба татар ир-ат исемнәре составы үзгәреш кичерә. Өч һәм аннан да күбрәк иҗекле татар ир-ат исемнәре кимүгә таба бара. Әлеге ир-ат исемнәре урынына татар теленең үз сүзләре нигезендә яңа татар ир-ат исемнәре ясалу процессы башлана. Бу процесс белән бергә, рус теленнән һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән байтак кына ир-ат исемнәре кулланылышта йөри башлый. Тик традицион татар ир-ат исемнәре тотрыклы рәвештә калалар. 1930–1939 елларда еш кулланылучы ир-ат исемнәрендә теләк мотивлары чагылыш таба. XX гасыр ахырына таба татар ир-ат исемнәрендә сизелерлек үзгәрешләр күзәтелә. Рус һәм рус теле аша кергән ир-ат исемнәре сан ягыннан беренчелекне алалар. Милли исемнәр кимүгә таба бара, теофор мотив чагылган ир-ат исемнәре дә, аз санда булсалар да, кулланылышка керә башлыйлар, ягъни теофор ир-ат исемнәренең «торгызылу» тенденциясе сизелә. Өч гасырда да киң кулланылышка ия 20 татар ир-ат исеме арасында бу өч дәверне тоташтырып торган бер генә татар ир-ат исеме дә күзәтелмәде.

Мамадыш шәһәре буенча җыелган материаллардан бераз үзгәрәк картина күрәбез. XIX гасырда еш кулланылучы 20 татар ир-ат исемнәрен Казан шәһәре белән чагыштырып карасак, ике составлы

ир-ат исемнәре аз булуын күрәбез. Еш кулланылучы ир-ат исемнәре исемлеген пәйгамбәрләр исемнәре алып тора. Димәк, халык саны аз булган территорияләрдә дини ышану-йолалар буыннан-буынга саклапып килеп, халык аңында яшәүләрен дәвам итәләр. XX гасыр урталарына таба татар ир-ат исемнәрендә кискен борылыш чоры күзәтелә: рус һәм рус теле аша кергән ир-ат исемнәре беренчелекне алып торучы ир-ат исемнәре составында күзәтеләләр. Татар ир-ат исемнәре составы «чуарлану» чоры кичерә башлый. Ике составлы теофор ир-ат исемнәренең саны бермә-бер азая төшә. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар ир-ат исемнәре составында аерма күзәтелми. Тик авыл ир-ат исемнәре системасы белән шәһәр ир-ат исемнәре системасында бер үзенчәлекне күзәтеп була: авыл антропонимик системасында «европалашу» тенденциясе чагылмый. Авыл ир-ат исемнәре системасы үзенең миллилеген югалтмаган, традицион татар ир-ат исемнәре еш кулланылучы ир-ат исемнәре исемлеген билгеләп торалар. Традицион татар ир-ат исемнәрен татар теленә хас булмаган авазлар белән үзгәртеп куллану очрамый. Шулай итеп, исемнәрне җәмгыять тарихы, аның хокукый институтларының тәэсире, икътисади хәлнең үзгәреше нигезендә үсеш кичереп формалашкан универсаль берәмлекләр дип билгеләргә мөмкин. Татар исемнәренең үсеш тенденцияләрен ачыклау халкыбызның милли үзаңны дәрәҗәсен, гореф-гадәтләрнең, традицияләрнең халык көнкүрешендә яшәешенең торышын, шулай ук тел мәсьәләләрен ачыклауда да мөһим урын били.

Соңгы елларда татар антропонимик системасы төрле этномәдәни процесслар нәтиҗәсендә үзгәреп, экстралингвистик факторларга таяпып үсеш кичерә. Аерым алганда, татар теленең антропонимик системасын, борынгы традицияләр һәм йолалар нигезендә формалашкан исем кушу мотивларын борынгы күзаллауларны традиция нигезендә саклап килгән, төрле этномәдәни процессларның тәэсире нәтиҗәсендә үсеш алган парадигма дип атарга мөмкин.

Казан шәһәренең Үзәк ЗАГСы каршындагы архивта сакланган барлыгы 10567 кешенең туу турындагы кенәгәләреннән саф татар гаиләләрендә туган балалар исемнәренең үсеш-үзгәреше, статистикасы тикшерелде.

Татар исемнәренең түбәндәге үсеш-үзгәреш тенденцияләрен билгеләдек:

1. Статистик исәпләүләргә караганда, XXI гасыр башында исем репертуарының кимүе күзәтелә. 2005–2010 еллар аралыгында татар

ир-ат исемнәре репертуарында 220 исем исәпләнсә, 2010–2015 елларда бу күрсәткеч 147 исемнән гыйбарәт. 1995–1999 елларда 223 исем билгеләнсә, 1935–1939 елларда 310 исем кушылганлыгы ачыкланды. 1820–1825 елларда исә исемнәр составы һәм саны ягыннан шактый нык аерыла, исемнәр репертуары 225 исем тәшкил итә. Хатын-кыз исемнәренә килсәк, 2005–2010 елларда исем репертуары 197 исемне тәшкил итсә, 2010–2014 елларда 138 исем билгеләнә; 1995–1999 елларда 201 исем билгеләнсә, 1935–1939 елларда 280 исем бирелүе күзәтелә; 1816–1825 елларда исем репертуары 204 исемне тәшкил итә. Димәк, хатын-кыз һәм ир-ат исемнәрендә исемнәр төрлелегенең күплеге 1935–39 елларга туры килә. Исем төрлелегенең азаюы 2010–2014 елларда күзәтелә.

2. Соңгы бишьеллыкка (2010–2015 еллар) караган материалларда еш кулланыла торган ун исемне *Әмир* (133), *Кәрим* (128), *Булат* (125), *Данияр* (120), *Арслан* (113), *Йосыф* (110), *Рәхим* (109), *Рамазан* (107), *Рөстәм* (105), *Ризван* (102); хатын-кыз исемнәреннән *Ясминә* (141), *Әмирә* (140), *Камилә* (137), *Наилә* (132), *Сафина* (130), *Суфия* (128), *Мәликә* (125), *Сабина* (123), *Исламия* (120), *Айсылу* (113) тәшкил итә.

Материалларда сирәк очраган исемнәрдән: *Гәбдерәүф, Гәбдерахман, Камал, Надирбәк, Рамаз, Сәяр, Хәсәнбәй, Хәмзә, Ринар, Расил;* хатын-кыз исемнәреннән: *Айза, Айа, Айда, Риана, Лея, Амелия, Райана, Айли, Эльзара, Разана, Арина.*

3. Исем составына килгәндә, бүгенге көндә ата-аналар исем кушканда, аны, төрле экстралингвистик факторларга нигезләнеп, исемнең эчке һәм тышкы формасына игътибар биреп сайлыйлар. Исемнең тышкы формасы – исемнең фамилия, отчество белән ярашуы булса, аның эчке формасы – экстралингвистик факторларга һәм шартларга мөнәсәбәтле барлыкка килгән гаилә традицияләре, исемнең яңалыгын ассызыклап модага кергән, мөселман традицияләре һ.б. Соңгы ун елда исемнәргә мода, нигездә, традицион исемнәрдә сакланса, икенче яктан караганда, Көнбатышка йөз тоткан, медиа чараларында кулланылыш алган модалы исемнәрнең дә репертуарга үтеп керүе сиземләнә.

4. XVIII гасыр «Ревизская сказка» материалларындагы түбәндәге исемнәр антропонимик системага үтеп кергән: *Габдерахман, Габдулла, Галимҗан, Габдерәуф* (г. «рәхимленең, кызганучының (Аллаһының) колы»), *Исхак* (г. «пәйгамбәр исеме»), *Ихсан* (г. «игелек, яхшылык, ярдәм; булышлык; шәфкатьлек эшләү»), *Каюм* (г. «мәңге яшәр; бер дә үзгәрмәүчән, тотрыклы»), *Мостафа* (г. «сайлап алынган,

иң саф, башкалардан өстен, иң яхшы»), *Мөхәммәтәмин* (г. «тугры, ышанычлы Мөхәммәт»), *Мөхәммәтгали* (г. Мөхәммәт + Гали), Мөхәммәтсалих (г. Мөхәммәт + Салих), *Сәлахетдин* (г. 1) «дин игелеге, яхшылыгы; 2) дин солтаны»), *Солтан* (г. «патша, хөкемдар, дәүләт хуҗасы, монарх, император») һ.б.; хатын-кыз исемнәрендә исә бу тенденция азрак күзәтелә: *Латыйфа* (г. «шәфкатьле, мөлаем, гүзәл, нәфис»), *Фатыйма* (г. «үскән кыз»), *Сәлимә* (г. «сау, сәламәт, төзекләүче»), *Сәгыйдә* (г. «бәхетле, рәхәт яшәүче»), *Хәят* (г. «тереклек, яшәеш, тормыш»), *Гайшә* һ.б. Бу исемнәр, нигездә, ике компоненттан торган гарәп алынмалары. XVIII–XIX гасырларда кулланылган *Газизә-Газиз, Ислам-Исламия* исемнәренең дә яңа гасыр репертуарында активлашуын билгеләргә мөмкин.

5. Традицион төрки нигезле компонентларга төрле исем компонентларының кушылуы нигезендә барлыкка килгән исемнәр дә репертуарда билгеләнәләр: *Айбулат, Айгиз, Айдан, Айден, Айдар, Айзат, Айназ, Айнур, Арслан, Батырлан, Илназ, Илнар, Илнур; Тимерлан*; хатын-кыз исемнәреннән *Айбикә, Айсылу, Айзилә, Иделия, Айда, Айгөл, Язгөлем, Гүзәл, Сылу* һ.б. Исемнәрдән күренгәнчә, традицион төрки нигезле компонентлардан *ай* компонентының активлыгын күрергә мөмкин. *Ай* компоненты хәзерге заман исемнәрендә борынгы мәҗүси традицияләрдәге ай культына бәйләнешле түгел, ә бала ай кебек матур, чибәр булсын дигән теләк белән бәйләнешле исемнәрдә чагылыш таба.

6. Исем ясалышында ата-ананың исем бирүдә төрле иҗат мөмкинлекләрен куллануын билгеләргә мөмкин. Мәсәлән, 2005 елларда яңадан антропонимик реестрда барлыкка килгән *Солтан* исеменең, *Солтания* варианты белән бергә, *Солтана* хатын-кыз исеменең дә ясалышын күзәтергә мөмкин. Бу исем әлегә сирәк исемнәр рәтендә, ЗАГС материалларында бары тик 4 тапкыр теркәлгән. Шулай ук, татар исемиятендә татар халык җырларында чагылыш тапкан *Рәйхан* исеменең активлашуы күренә. Татарларда урта гасырларда һәм XVIII–XIX йөзләрдә «Ревизская сказка» материалларында билгеләнгән *Рәйхан* – киң таралган исемнәрнең берсе. Гарәп теленнән кергән бу исемнең «зәңгәр чәчәкле хуш исле гөл, рәйхан гөле (базилик)» һәм «рәхәтлек», «ләззәт» мәгънәләре бар. Татар исемиятендә бу исемнең *Рәйхана* варианты да кулланылышка керүен билгеләргә кирәк. Хатын-кыз исемнәрен ясаучы *-а/-ә* кушымчасы нигезендә Рәйхан исеменең *Рәйхана* варианты да барлыкка килгән. Еш очрый торган *Ясминә* (фар-

сы теленнән алынган) исеменең хатын-кыз исемнәрендә *Ясмин* варианты да бар.

7. Татар исемиятендә «Ревизская сказка», писцовый кенәгәләрдә, сүзлекләрдә һәм башка чыганакларда очрамаган *Айден, Арысхан, Вилдар, Рамаз*; хатын-кыз исемнәреннән *Зәйнура, Эльзара, Риана, Райана, Лея, Нурхәят* кебек исемнәрне билгеләргә мөмкин.

8. Татар гаиләләрендә игезәк балаларга исем бирүдә, нигездә, ике исемнең дә рифмалашуыннан чыгып эш итәләр. Мәсәлән, бер гаилә балаларына *Хөсәен* белән *Хәсән* исеме куша. Игез балаларга кушылган бу исемнәр XIX гасырда «Ревизская сказка» материалларында да еш очрый. Ахыргы иҗекләрнең рифмалашуы нигезендә *Әмир-Самир, Булат-Салават* кебек исемнәр кушылса, шулай ук бер үк авазга башланган *Рамил-Рөстәм* кебек исемнәр игезәк балаларга кушылган.

9. Татар исемиятендә Көнбатыш тәэсиренең күбрәк хатын кыз исемнәрендә очравын күрсәтергә кирәк. Татар ир-ат исемнәренең тотрыклы традицион үсеше билгеләнә. Хатын-кыз исемнәрендә Көнбатыш исемнәре яисә Көнбатыш илләр теленә тартым исемнәрнең кулланылышы ачык сиземләнә: *Кира* грек. *Кирей*дан «хакимлек, көч»; *Милана* 1) бор. рус. «милый» сүзеннән. 2) Италия шәһәре, Илона-Елена исеменең маҗар варианты; *Алиса* фр. *Алис* – «затлы»; *Фернанда* fern «абага»; Регина лат. «патшабикә». Татар ир-ат исемнәрендә *Рафаэль* бор. яһүд. «Тәңре дәвалаган»; *Эрик* бор. алман *era* «намус» + *richi* «хөкемдар», *Эдуард* бор. инглиз теленнән *ead* «милек» + *weard* «терәк, таяныч»; *Эмиль – aemilus* – «тырыш» кебек исемнәр теркәлгән.

Көнбатыш телләре тәэсирендә барлыкка килгән яки Көнбатыш илләр телләреннән алынган исемнәрдә кайбер фонетик үзенчәлекләр һәм исемнең этимологик мәгънәләре югалуы күзәтелә. Исемнәрдә сонор авазларының билгеләнүе (*Ринар*), исемнәрнең [е] авазына башлануы (*Эльдар, Эмиль, Эмир, Эрик*), тартык авазлар алдыннан [р] яки [л] авазларының килүе «экзотик» исемнәр санала.

Иң актив сүзьясалышы формантлары булып *-а/-ә/ -ия* форманты билгеләнә. Бу формант ярдәмендә хатын-кыз исемнәреннән хатын-кыз исемнәре дә яисә ир-ат исемнәреннән хатын-кыз исемнәре дә ясалалар: *Данияр – Данияра, Әмир – Әмирә, Мәлик – Мәликә, Идел – Иделә (Иделия), Камил– Камилә, Нәфис – Нәфисә, Руслан – Руслана, Самир – Самирә, Ренат – Рената, Эльнар –Эльнара, Ранэль– Ранэлия, Рәйхан – Рәйхана, Мөслим – Мөслимә, Солтан – Солтана, Җәмил –*

*Җәмилә, Рушан – Рушана – Рушания, Райнур – Райнура, Руслан – Руслана* һ.б.

## Кыскача нәтиҗәләр

Татар халкының милли-сәнәгать, рухи үзәге булган Казан антропонимик системасын, авыл культурасының йогынтысын кичергән Мамадыш шәһәре антропонимик системасын төрле тарихи чорларга нисбәтле чагыштыру татар исемнәр системасының социаль дифференциациясен билгеләргә мөмкинлек бирде. Апеллятив лексика кебек үк, антропонимик лексика да вакытлар узу белән үзгәреш кичерә, ул, бер яктан, антропонимиконны яңа исемнәр белән тулыландырса, икенче яктан, еш кулланылучы исемнәрнең традицион характер алуына китерә. Антропонимиконда барган әлеге «антропонимик процесс» нәтиҗәсендә, татар исемнәре яңара, уңышсыз табылган исемнәр төшеп кала. Бу процесс унъеллык антропонимик аралыкларны чагыштыру нәтиҗәсендә ачыкланды. XIX гасыр исемнәре XX исемнәреннән бермә-бер аерыла. Әмма XX гасыр һәм XXI гасыр башы ир-ат исемнәре составында аерым үзгәрешләр булуына карамастан, бу ике гасырда еш кулланылучы исемнәр составы һәм күләме тотрыклы рәвештә саклана. XX гасыр XXI гасыр башы исемнәрендә региональ үзенчәлекләр Мамадыш шәһәрендә традицион исемнәрнең саклануында чагыла. Бу – авыл культурасында традицияләрнең, милли үзаңның антропонимик системага тәэсире белән билгеләнә. Казан шәһәренең антропонимиконы, социаль-икътисади, мәдәни үзгәрешләр тәэсирендә, яңа исемнәр белән тулылана.

## Өченче бүлек
## ТАТАР ИСЕМНӘРЕН БИРҮ ЙОЛА-МОТИВЛАРЫ

### § 11. Татар телендә исем кушу лексикасы һәм йолалары (диалекталь һәм этнографик текстлар контекстында)

Бүгенге тел белеме төрле катлаулы һәм каршылыклы процесслар нигезендә үсеш ала, шулар арасында этнолингвистик проблемаларга аерым урын билгеләнә. Балага исем кушу процессы төрле ритуалларга нигезләнгән һәм кеше җанының тулы бер концептуаль чагылышын яктырткан, архаик лексиканы үз эченә алган борынгы йола-гадәтләрнең тупламын тәшкил итә. Исем кушуның йола-традицияләренә булган һәм аның ритуалларын яктырткан лексикага карата зур кызыксыну татар халкының милли рухи культурасын аңларга һәм аның мәдәни-тарихи контекст эчендәге ролен һәм урынын аңларга ярдәм итә. Билгеле булганча, «традицияләренә нигезләнмәгән культура үзенең милли үзенчәлеген югалта бара. Әгәр милли культура үзенчәлекләре югала икән, ул халык үзе дә бетә» [Давлетшин, 2004: 6]. Балага исем кушуга бәйләнешле фәнни тикшеренүләр аерым аспектлар буенча алып барылган [мәс., тарихи-этнографик аспектта. Кара: К. Насыйри 1974; Я.Д. Коблов, 1908; Р.К. Уразманова, 1984: 106–131; лингвистик аспектта. Кара: Г.Ф. Саттаров, 1973; А.Г. Шайхулов, 1973; Ф.С. Баязитова, 2012; Г.С. Хазиева-Демирбаш, 2006; 2008]. Билгеле булганча, фольклор һәм этнографик текстларда татар телчеләре һәм этнографлары тарафыннан әлегә кадәр аз өйрәнелгән, яисә бөтенләй этнолингвистик аспектта өйрәнү объекты булмаган ономастик материал урын алган. Бу текстлардагы ономастик материал халыкның рухи традицияләрен барлау өчен генә түгел, ә, гомумән, халык тарихы, этногенезы мәсьәләләрен яктыртуда һәм ачыклауда да мөһим булып торалар. Исем бирү йолалары кеше исеменең аның җаны белән тыгыз мөнәсәбәтен чагылдырган һәм шул рәвешле инсаниятнең әхлакый идеаллары ассызыкланган ритуаллар белән бергә үреп алып барыла. Төрки халыкларның дөнья картинасында исем бирү йола-гадәтләре киң кырлылыгы һәм төрлелеге

белән аерылып тора, шул ук вакытта ул бер-берсенә тыгыз бәйләнештә торган элементлардан гыйбарәт. Исем бирү йола-гадәтләренең нигезе кешенең җаны, язмышны билгеләгән тамга буларак күзалланган төрки халыкларның ышану һәм күзаллауларыннан тора. Енисей һәм руник ядкәрләрдә исем бирү һәм исем алыштыру йола-гадәтләре чагылыш тапкан. Тарихи чыганакларда исем бирү йола-гадәтләре берничә этаптан тора: бала тууга исем бирү, бала туып бераз вакыттан соң исем бирү, яшүсмер чакта, яшьлектә, картайгач. Тугач та бирелгән исем – *ада атым, оглан атым*, туып бераз вакыттан соң бирелгән исем *эр атым* дип аталган. Соңгы исем *айаг атым* дип билгеләнгән: *Эр атым Йула, яни эргенлик атым. Эр атым Озгут Оглу.* Кешенең титулы үзгәрү, югары дәрәҗәгә ирешү исем алыштыруга сәбәп булган. Нигездә төп исем үзгәрмәгән, бары тик өстенлекле титул гына үзгәргән. Бу титул да төп исем составында килеп, исем вазифасын үтәгән. Төп исем үзгәреш кичерми, бары тик титул үзгәрә. Димәк, төрки халыкларда исем титул, статус, җәмгыяттәге эшләргә карап үзгәреш кичерә, шулай ук исем саклау (мәсәлән, миңле балаларның миңнәре үсүен туктату өчен миң компонентлы исемнәр бирү), дәвалау һәм өлкәннәрне олылау функциясен дә үтәгән.

Халыкның традицион рухи культурасында исем социаль, идентификацияләү һәм табигать белән кеше арасындагы мөнәсәбәтләрне, галәм һәм гайре табигый дөньяны җайга салу функциясен үти. Исем диалекталь-фольклор һәм этнографик текстларда, гомумтелдән аермалы, үзенчәлекле семантикага ия, шул ук вакытта денотат белән үзенчәлекле бәйләнештә тора.

Татар гаиләләрендә исем кушу йола-гадәтләре үз эченә ислам традицияләрен һәм җирле культурага хас үзенчәлекләрне туплый. Исем бирү йолалары үзләренең архаиклыгы һәм күпкырлылыгы белән аерылып тора һәм йола лексикасын тәшкил итә. Татар әдәби телендә исем кушу терминының берничә төре бар: *исем кушу, исем бирү, ат бирү*. Татар диалектларында исә исем кушу атамасы төрлелеге белән аерылып тора: *ат атау* (төм.), *пәпә атату* (тобол. ), *ат кушу* (урт. д.; мишәр. д.; себ. д.), *ат кушма* (баст.), *ат кушу* (кас.), *атын атату, ат кычкырту* (әстерх.; хвл.), *ат кыцкырту* (чст.), *ат кычкыру* (лмб.), *ат салу, исем салу, исем кистерү* (нокр. ); *исем атау, исем кушу* (перм., лмб., серг.); *исем кушу* (глз., минз., төм.); *азанлашу, азан әйтү* (кр.-уф.). Шул рәвешле, исем кушуның йола лексикасы татар теле диалектларында күптөрлелеге белән аерылып тора.

Исем кушу йоласы, иң беренче чиратта, кендек әбисенә бәйләнешле үтә. Билгеле булганча, элек бала тудыру йортлары булмаган чорларда, авылларда баланы кендек әбиләре ярдәмендә тудырганнар. Кендек әбиләре авылның иң мөхтәрәм һәм им-том сәләтенә ия кешеләр булганнар. Халык арасында кендек әбиләренә бәйле төрле им-томнар яшәп килә. Һәр авылда андый кендек әбисе берничә булган. Алар бала табучы хатыннарга бала тудыруда гына ярдәм итмәгәннәр, ә биш көн буе баланы тәрбияләргә, мунчада юындырырга өйрәткәннәр. Татар әдәби телендә бала тудырырга ярдәм итүче хатынны «кендек әбисе» дип атаганнар. Татар диалектларында кендек әбисенең берничә төрле атамасы яшәп килә**:** *әби* (урт. д.; миш. д.), *әби булучы* (т.я.-нрл; тя. к.т.), *бала түрәтүче әби* (мишәр. д), *бәбәй әбисе* (чст., дрож.), *инәкә әби, кендекче әби, кендегәе, мама, мамай, инәкә мама* (әстерх.), *инәлек әби, мама, мамай* (себ. д.), *олан әбисе* (тя. крш.), *түти әби, бабка* (кас.), *әби тәтә* (т.я.-трх.), *әбилек, кендергәц, кенддергәч, кендергәч карчык* (том.), *кендек әби* (к.-уф.; хвл.; влгг.; брб.; минз.), *кендек абасы, кендек мамам, бахсы* (әстерх.); *кендек инә, кендекәй* (к.-уф.), *кентек инә, кендекче, кентекче, инәлекче* (брб.), *аппай корткайак, инәлек корткайак, инәкә* (төм.), *оста корткайак, колака, колакам, колагинәм, инәлек нәнә* (тбл.) һ.б. Исем бирү йоласында да иң беренче булып мулла түгел, ә кендек әбисе катнаша. Ул, иң беренчеләрдән булып, балага вакытлыча гына бер исем биреп тора, аны икенче төрле «кендек аты» дип әйтәләр. «*Бала туа, исемсез тормасын, кендек аты кушалар. Мулла китерәләр дә йакшы ат кушалар. Мулла кушкан исем белән гомер итәләр. Бусы кендек исеме, ә бала йакшыргач, азанчы китереп исем бирә. Ике исем бирәләр*» [Баязитова, 2012]. Баланы исемсез калдырырга ярамаган, чөнки ышануларага караганда, яман көчләрнең балага зыян китерү ихтималы булган. Мәсәлән, нократ сөйләшендә баланы мифик зат булып саналган әби (аны йорт әбисе дип атаганнар) алыштырырга мөмкин дигән ышану яшәгән. «*Бала тугач зак тотасы дегел, әби алыштыра аны. Ат саласы тизерәк. Өч көндән артык тотасы дегел*» [шунда ук]. Билгеле булганча, хәтта үле туган баланы да исем кушып күмү традициясе яшәп килгән. Әгәр бала исемсез күмелсә, ышануларга караганда, бу бала шунда ук явыз мифик затка әверелә. Бу мифик зат *Атсыз* дип атала. Борынгы заманда ир балага *Атсыз* исеме аны явыз көчләрнең эзләп тапмавын теләп, яман көчләрне алдау, эз яздыру өчен, исемнең магик көченә ышанып кушылган. *Атсыз* исеме югары катлау, хәтта хан, патша балаларына да бирелгән.

Хәзерге татар мәдәниятендә мулла һәм башка кадерле кунакларны өйгә чакырып исем кушу, исем бирү дини йоласын үткәрәләр. Исем кушу йоласы татар әдәби телендә *аш, бәби ашы* дип атала. Татар диалектларында бу йола атамасы төрле вариантларда очрый: *аткушар, аткушар туй, аткушар мәҗле*с (әстерх.), *исем ашы* (том.д.). Шулай итеп, кунакларның санына карап, әстерхан сөйләшендә исем бирү йоласы ике төргә аерыла: *кече аткушар, зур аткушар*. Кече аткушар – бары тик якын туганнар гына катнаша торган йола. «*Балага бөтен затларын китереп, туганнарын чакыртып азан чакырттык*». Зур аткушар – күп кунаклар чакырылып ясала торган йола: «*Зур аткушар йасадык соңында. Ирләр, ирләрдән соң катыннар чакырдык. Урамага кийемнәр китерәләр, кодагый киләде, килененең анасы. Ул китергән кийемнәрне күрсәтәйәк булдылар»* [Баязитова, 2012]. Балага исемне туганнан соң берничә көн үткәч бирәләр. Мәсәлән, Әстерхан, Нократ татарларында исемне өч көн үткәч кушалар. Волгорад өлкәсе Ләмбрә һәм Рузаев районнарында исемне җиде көн үтәч бирәләр: «*Бәбә тугач, исем бирәләр бер йомадан (атна) сун*» [шунда ук]. Баланы бер атнадан артык исемсез калдыру куркыныч санала, чөнки шайтан исем бирергә мөмкин дигән ышану бар һәм ул очракта бала авырып китәргә мөмкин. Әстерхан татарарында балага озак вакыт исем бирмәсәң, бала лаек була, тынычсыз була дигән ышану яшәп килә: *«Мулланы чакыртып, ат кычкыртып алабыс. Атсыз йатса, бала йылый диләр*» [шунда ук]. Исем кушу йоласында муллага баланы мендәрдә китерәләр. Әстерхан татарларында исә баланың йөзен кулъяулык белән каплый торган гадәт тә бар*: «Баланың битен йабып мендәргә салып китерә»*. Мулла баланың аякларын кыйбла (Мәккә) тарафына юнәлдерә. Баланың иң беренче ишеткән сүзе «Алла» сүзе булсын диеп, шайтаннар бу сүздән курыкканга күрә, баш очына басып азан әйтә. Соңыннан сулга таба борылып, кулларын ике якка куеп камәт әйтә. Камәт – намазга кадәр сөйләнгән сүзләр. Әйтергә кирәк, иң яхшы исемнәрдән *габд, амәт* сүзләре кушылган исемнәр саналалар. «Бер хәдистә пәйгамбәрләр һәм фәрештә исемнәрен сайлау яхшы икәнлеге билгеләнә. Мөхәммәд пәйгамбәрнең исеме тагы да яхшырак булып исәпләнелә. Мөхәммәд пәйгамбәр: – Минем исемемне кушыгыз балаларыгызга, – дигән. Шуңа күрә Мөхәммәд исеме бөтен дөньяда иң яратылып кушыла торган исемнәрнең берсенә әверелгән» [Мусульманские..., 2007: 4]. Исем бирү йоласында мулла сабыйның колагына исемен әйтә. Минзәлә татарларында исем кушуда шундый теләк сүзләре әй-

теләː *«Аллаһы Тәгаләгә кол булсын, Пәйгамбәребезгә өммәт булсын»* [Баязитова, 2012 ]. Әгәр баланың тәнендә төрле тимгелләр, миңнәр булса, исем кушу процессында морҗадан кашык төшергәннәр. Балага *миң* компонентлы исемнәр биргәннәр: *Миңнегөл, Миңнебай, Миңнекамал* һ.б. *«Баланың миңе булса, җүшкәдән кашык төшереп исем кушалар ыйы. Миңнегөл, Миңнебай, Миңнекамал исемнәре кушалар ыйы баланың миңе булса»* [шунда ук].

Исем кушуда төрле ритуаллар яшәп килә. Мәсәлән, Екатеринбург өлкәсендә яшәүче татарларда исем качмасын дип, шайтаннар өйгә кермәсен дип, өйдәге бөтен тишек-тошыкларны – морҗаны, ишекләрне, тәрәзәләрне һ.б. ны ябып куялар: «*Исеме сыгып китмәссен, шайтаннар-нимәләр кермәсен дип бөтен нимәне йаба торганнар ыйы, мөрҗә-йүшкәләрне, капка-ишекләрне йабалар ыйы*» [шунда ук].

Күп кенә халыкларның тарихында һәм этнографиясендә мич, тау куышына охшаш булуы сәбәпле, саклау урыны, культ ролен үти. Моннан тыш, морҗа кеше һәм галәмне бәйләү функциясен дә үти.

Пермь татарларында мулла исем кушканнан соң, муллага көмеш акча бүләк итәләр. Бу гадәт баланың көмеш кебек ныклы, сәламәт булуын теләүгә тиң була: *«Көмеш тәңкә кушкан «көмеш кебек нык булсын», – дип»* [шунда ук]. Исем кушканда, бала елмайса, төрле тавышлар чыгара башласа, йола беткәч йоклап та китсә, бу очракта, исем балага килеште дип әйтәләр**.**

Исем кушу йоласы кунакларны сыйлау белән тәмамлана, аны *аш* дип атыйлар. Башта кунакларны бал һәм майдан авыз иттерәләр. Соңыннан килгән кунаклар балага бүләкләр бирәләр. Аш дога уку белән тәмамлана. XX гасыр башында ук исем кушу йоласын тасвирлаган этнографик хезмәтендә К. Фукс болай дип яза: «Өч көннән соң, дүртенче көнгә мулланы чакыралар. Ул баланы кулларына тотып аның уң колагына кычкырып азан әйтә, соңыннан сул колагына баланың исемен әйтә. Муллага һәркем үзенең мөмкинлегенә карап түли, һәм бик яхшы итеп кунак итәләр. Кунак ашына бөтен таныш ир-атлар чакырыла. Берничә көн дәвамында балалы хатын янына таныш хатыннар бүләк алып килә, нәкъ руслардагы кебек. Яңа туган балага күлмәкләр, байлар – ефәк, хәерчеләр – ситсы, күбесе юрган, түбәтәй бүләк итә. Яңа бәби тудырган хатынга шулкадәр күп итеп бүләк бирәләр, ул үзенең сандыгын тутыра» [Фукс, 1844: 45]. XX гасырның этнографик тасвирламасында Я.Д. Коблов болай дип яза: «Дини бәйрәмдә кунакларны бик каты сыйлыйлар. Исем бирү йоласы зур гаилә

бәйрәме санала һәм моңа ата-ана сый-нигъмәтләрне кызганмый, төрледән-төрле ризыклар әзерлиләр. Көндезгә токмачлы аш, бәлеш, компот тәкъдим ителә» [Коблов 1908: 7–8].

Исем, җанның чагылышы буларак, магик көчкә, үзен йөртүченең эшләгән эшләрен, уй-тойгыларын контрольдә тоту мөмкинлегенә ия. Кешенең исеме – җанның бер өлеше, дигән фикергә бәйләнешле исем алыштыру һәм исем кушуның төрледән-төрле ырымнары яшәп килә. Исем алыштыру табу күренеше белән тыгыз бәйләнештә тора [Толстая, 2008: 375]. Татар әдәби телендә бу йола *исем алыштыру* дип аталса, татар диалектларында *исем аwыштыру, исем алыштыру, исем бозу* (урт. диалект; перм. тат.) дип атала. Әгәр бала бик нык авырса, яисә балага миң чыкса, исем алыштыралар. Баланың кинәт кенә авыруы дөрес сайланмаган яисә «бозылган» исем белән аңлатыла. Шуңа күрә, төрки традицияләрдә исем алыштыру халык медицинасы белән тыгыз бәйләнгән. Мәсәлән, Казан арты татарларында, әгәр бала авырып китсә, тары боткасы пешерәләр һәм аны мичкә куялар. Морҗадан кашык төшереп, әфсен укыйлар: *«Исемен алыштырам, Миннегол булсын. Кашык төшердем, саулыгын бирсен, дип»* [Баязитова, 2012]. Соңыннан тары боткасын кошларга бирәләр. Билгеле булганча, морҗа начар рухларның өйгә керү юлы булып санала. Шуңа күрә, кешенең морҗага мөрәҗәгать итүе начар көчләргә мөрәҗәгать итү булып аңлатыла. Бу йолага балага миң чыккан очракта да мөрәҗәгать ителә. Әгәр баланың тәненә миңнәр чыкса, балага *миң, кал* компонентлы исемнәр бирелә. Бу йоланы «миң боздыру» дип атыйлар. Билгеле булганча, миң төрки халыкларда бәхет символы, бәхетле язмыш күрсәткече. Миң боздыру йоласында Казан арты татарларында морҗадан тары боткасына кашык төшергәннәр. Нократ татарларында баланың яңа исемен морҗадан кычкырганнар. Кендек әбисенә яңа кашык бүләк иткәннәр [Баязитова, 2006: 103]. Бу йоланы кар эреп бетмәгәндә яисә җәй җиткәнче үткәргәннәр. *Миң* компонентлы исемнәр биргәннәр: *Миңсылу, Миңнәхмәт* һ.б. Себер татарларында мич саклау ролен үтәгән. Авыру баланы яисә миңле баланы мичкә куйганна һәм морҗадан яңа исем кычкырганнар.

Пермь татарларында бала бик елак булганда исем алыштырганнар: *«Сыктак булса, әйтәләр, исеме килешми микән, диләр, исемен алыштырыйк диләр»* [Баязитова, 2012]. Нократ татарларында да исем алыштыру йоласы бар: *«Йылак, олан булса, исемен алыштыралар. Минем малаем Шәйхулла, исемен алыштырып кашык төшерделәр*

*морйадан Минкәт итеп. Гөлзәмингә Миңзифа дип исем салдырдым»* [Баязитова, 2012].

Себер татарларында *миң* компоненты белән бергә *кал* компонентлы исемнәр кушылалар: *Калыстан, Калпикә, Калы, Миңкалыш* һ.б. Миң өстенә яңа гына суелган мал канын сөртү йоласы да яшәп килә. Себер авылларында яңа суелан әтәч канын сөртү йоласы була: *«Калы цыккан балага курасны суйып, аның канын сөрткәле кәрәг икән»* [шунда ук]. Мал-туар каны саклау, көч чарасы була, шул ук вакытта җанлы һәм җансыз дөньяны бәйләүче булып тора. Кан, шулай ук, җанны алмаштыручы ролен үтәү, ә исем – үлгәннәрнең җаның яктыртучы булып тора.

Сүзнең магик көченә нигезләнгән, баланы саклау максатында кушылган исемнәр дә бар. Себер татарларында бала көчле, нык булсын дигән максат белән «тимер», «таш» компонентлы исемнәр бирелә: *Тимергали, Тимербай, Тимерхан, Тимербәк; Таштимер, Ташпулат* һ.б. Керәшен һәм Минзәлә татарларында *тимер* компоненты балага озын гомер теләү мотивы белән бирелә: *Тимергали, Тимершәех, Минтимер, Тимерүк* һ.б.

Ономастик магия исем кушу, исем сайлау референтның үзенчәлекләре белән түгел, ә антропонимның «семантикасы», мифопоэтик коннотацияләре белән билгеләнә [Толстая, 2008: 275]. Бу тип исемнәргә туктатучы исемнәрне кертергә мөмкин. Себер татарларында *тукта* компоненты нигезендә ясалган исемнәр бар: *Туктар, Туктарбикә, Туктасын*. Әгәр гаиләдә бер-бер артлы балалар үлеп торса, яңа туган кызга да малайда *Калсын, Үлмәс, Үлмәскол, Яшәр, Торсынбай, Торсынай* һ.б.ш. исемнәр кушалар. Әстерхан татарларында мондый очракларда*: Сатыбал, Сөйөндөк, Куwандык, Туктар, Сатыбалды, Туктамыш, Тимерулат, Туктагол, Балтабай* һ.б. исемнәр, ә Рязань өлкәсе татарлары гарәп чыгышлы *Бакый, Бакыйа* исеме биргәннәр.

Әгәр гаиләдә балалар еш үлсә, бала сату йоласы үткәргәннәр. Бу йола яман көчләрне ялганлау, бутау өчен ясалган, *сату* компонентлы *Сатукай, Сатый, Сатыпал* кебек исемнәр кушылган. Бу архаик йола керәшен татарларыда да билгеләнә. Өч тапкыр тәрәзәдән бала сату турында хәбәр бирелгән. Бу бала бик очсызга сатыла, дип әйтелгән. Бала саткан гаиләдә калса да, сатып алучыларның баласы дип йөртелгән. Бу йоланың мәгънәсе баланы сатуга барып тоташкан. Ата-ана фикеренчә, сатылган бала инде хәзер чит бала һәм ата-анага ачуланган яман көчләрне инде бу бала кызыксындырмый.

Тәрәзәнең сакраль чигендә сатып алу оештырыла. Кендек әбисе сатучы ролендә, сатып алучылар нигездә күршеләр. Сатучы һәм сатып алучы арасында символик диалог корыла:

– *Сатам, аламсыз?*

– *Алабыз. Хакы ничә сум?*

– *Биш сумнан сорыйбыз, күп сорамыйбыз* [Баязитова, 2012].

Тәрәзәдән чыгару яңа тормышка, яңалыклар процессына таба баруны аңлата, йола мәгънәсен ала. Шул рәвешле сакраль тәрәзәдән чыгарылган бала явыз көчләргә каршы тора ала торган балага әверелә.

Балаларга яхшы семантикага ия исемнәр кушу, этимологик магия дип атала. Әгәр гаиләдә озак вакыт балалар булмаса, ул очракта, әти-әнисенең төрле хис-тойгыларын яктырткан, фигыль сүз төркеменнән ясалган исемнәр кушыла: *Куандык, Сагындык, Сөендек, Юаныч, Табылдык* һ.б. [Саттаров 1973: 44].

Себер һәм Әстерхан татарларында балага *әби, бабай, әни, әтигә* багышланган исем биргән очракта, аны исем белән атап йөртмәгәннәр, ә туганлык терминнары белән атаганнар. Татар гаиләләрендә хатын ирне, ирнең туганнарын үз исеме белән әйтмәгән, ирен *мәсәлән аталары / әтиләре/ әтисе/ атасы* дип атап йөрткән [Рамазанова 2014: 47]. Г.Ф. Благова фикеренә караганда, төрки халыкларның традицион-патриархаль үзаңына зур тармаклы туганлык системасы хас, шул рәвешле, туганлык системасы терминнарының күплеге, шуның белән бергә, төрки антропонимик системасында да гасырлар дәвамында беркетелгән туганлык терминнары белән билгеләнә [Благова 1998: 183]. Әстерхан татарларында әнисенең исеме кушылса, баланы *Аккыз* дип йөртәләр, әгәр әтисе исеме бирелгән булса, баланы *Акбала* дип йөртәләр. Тубыл татарларында бу очракта баланы *Атамаң, Аташ* дип исемлилиләр. Әгәр бала әбисенә багышланган исем йөртсә, аны *Инә, Инәкә, Инәч, Өннәкә, Өннәш,* әгәр бабайга багышланган исем йөртсә, *Олота* дип атыйлар. Бу күренеш кабилә бердәмлегенең, зур буынга хөрмәтне чагылдырган традиционпатриархаль үзаң белән аңлатыла.

Баланың туу вакыйгаларын, вакытын, урынын чагылдырган исемнәр семантик исем кушу дип аталалар. Мәсәлән, Бараба татарларында бала кайсы айда туса, шул атама белән исем бирү, беренче күргән хайван исемен балага кушу йоласы яшәп килә: *Торна, Карга, Чыпчык, Бүре, Саескан, Эт* һ.б. *«Тышка чыгып ни күрсә, аны атап куйганнар элгәре. Торна китеп барамы, карга очып барамы. Карга*

*күрсә – Карга, чыпчык күрсә – Чыпчык, бүре күрсә – Бүре, эт күрсә – Эт*» [Баязитова, 2012].

Әгәр гаиләдә балалар үлсә, хайван исемен балага бирү йоласы яшәгән, бу исем баланы саклаучы ролен үти: *Аю, Бүре, Караэт, Каракөчек*. Хайван исемнәрендә этномәдәни архаика үзенчәлекләре чагылыш тапкан. Хәзерге көн шартларында бу төр исемнәр мифологик актуальлелекләрен югалтып, кайбер исемнәр исә метофоризация кичереп, нәтиҗәдә теләк исемнәргә әйләнәләр [Благова, 1998: 182], мәсәлән, яңа туган бала көчле, үткен, батыр булсын өчен *Арслан* исеме кушыла. Татар һәм башкортларда нигезендә эт атамасы булган исемнәр кулланылыш ала: *Этул, Эткөчек, Этҗигәр* һ.б. Ономатолог А.Г. Шәйхулов фикеренчә, билгеле бер хайваннар тулы бер дини күзаллауларны чагылдырырга мөмкин [Шайхулов, 1983: 13]. Этнографиядә күп кенә халыкларда эт магик йолаларның атрибуты санала. Нигездә, эт яңа туган баланы үлемнән коткара.

Татар антропонимиясе мөселман мәдәниятенең көчле йогынтысын кичергән. Бу, беренче чиратта, исем составында чагылыш таба, шулай да мәҗүси мифопоэтик традицияләргә хас үзенчәлекләр, исемгә, исем кушуга һәм исем алыштыруга бәйле йолалар бүгенгәчә сакланып калган.

Шул рәвешле, традицион татар мәдәниятендә исем ата-ананың, олы буынның теләкләрен яктыртып, бу дөньяны, табигать белән тиңләштереп (туган көнгә, урынга нисбәте исемнәр бирү), борынгыларның рухларына табыну ысулларын ачып, дөньядагы уңай әйберләрне күбәйтеп, үлемне алдау, язмышны яхшырту функциясен үти. Гомумиләштереп шуны әйтергә кирәк: татар халкының рухи-мәдәни мирасы чагылыш тапкан, җирле үзенчәлекләр белән аерылып торган уртак этномәдәни бәйләнешләр төрле территорияләрдә яшәүче татарларның исем бирү йолаларында сакланып калган. Кешенең тормыштагы табигый барышын чагылдырган лексика һәм төрле бәла-казалардан, авыру-сырхаулардан котылырга ярдәм иткән антропонимнар, куркыту һәм культ семантикасына ия саклау исемнәр ата-ананың, өлкән буынның теләкләрен яктырта. Бала туугa бәйле йолалар этномәдәни мирасның трансмиссиясендә чагылыш тапкан халыкның үсешендә тотрыклылык булдыралар.

## § 12. Антропонимиядә исемнәрнең лексик-семантик төрләрен өйрәнү торышы

Антропонимик системаны тикшеренүчеләрнең иң киң кулланыла торган лингвистик ысул – аны лексик-семантик төркемнәргә бүлеп өйрәнү. Шулай да «исемнәрне лексик-семантик яктан төркемләү «антропонимиядә катлаулы мәсьәләләренең берсен тәшкил итә» [Махрипов, 1990: 130; Жапаров, 1989: 81] һәм тюрколог-ономастлар арасында бу мәсьәләдә фикер уртаклыгы булмау һәрбер халыкның исем бирү мотивларында үзенә генә хас милли колоритының, иҗтимагый зәвыгының, «кешеләрнең күзаллаулары, аларның иҗтимагый мөнәсәбәтләре, идеологиясе һәм, ниһаять, традицияләре чагылышы»-ның [Суперанская, 2005: 242] төрлелеге белән аңлатыла. Венгр антропонимисты Л.Рашоньи 1953 елда исемнәрне лексик-семантик яктан төркемләүдә аларның семантик билгеләренә нигезләнгән классификация тәкъдим итә [Rasonyi, 1953]. Л.Рашоньи барлык исемнәрне җиде төркемгә бүлеп, аларны 1) тотем исемнәр, 2) билге исемнәр, 3) очраклы исемнәр, 4) теофор исемнәр, 5) ата-ананың хисләрен аңлаткан исемнәр, 6) мода исемнәре, 7) титул исемнәре кебек төркемчәләргә аерып карый. Төрек антропонимисты А. Эрол да Л. Рашоньи классификациясенә нигезләнә [Эрол, 1992: 23]. В.А. Никонов төрки антропонимик системаны лексик-семантик төркемнәргә бүленешендә Л.Рашоньи классификациясен тагы да тулыландыра, камилләштерә. Аның классификациясен В.У. Махпиров, А.Г. Шәйхулов, Г.Р. Галиуллина, Г.И. Кульдеева һ.б. өлге-схема итәләр. В.А. Никонов лексик-семантик классификациясендә номинация мотивын төп принцип итеп, нигезне тәшкил иткән апеллятив мәгънәсеннән исемнең мәгънәсен аерып карый: «семантика имен – совсем не значения тех слов, от которых имена образованы, а отношение в сознании называющих между называемым (носителем имени) и тем понятием, которое выражено словом-основой» [Никонов, 1974: 95]. Аның фикерләре белән килешеп, исемнең мәгънәсе апеллятив мәгънәсеннән шактый киң һәм исем кушучы тарафыннан аның мәгънәви семантик вазифасы конкрет эчтәлек алуын билгеләргә мөмкин. Әлеге үзенчәлек исемнең телдән тыш һәм телара йөкләмәсен тулысынча чагылдырырга ярдәм итә дияргә нигез бар. Антропонимикада лексик-семантик яктан Т. Жанузаков («Лично-собственные имена в казахском языке») – 10, Г.Х. Кусимова («Древнебашкирские антропонимы») 20 төркемчәне аерып чыгара. Исемнәрне лексик-семантик төркемнәр буенча классифи-

кацияләү О.Т. Молчанова, В.А. Никонов, Г.Ф. Саттаров, А.Шәйхулов, В.У. Махпиров һ.б.ның хезмәтләрендә дә бирелә.

Г.Ф. Саттаров татар антропонимиясендә болгар-татар исемнәрен борынгы ышануларга, йолаларга һәм традицияләргә нисбәтле ике төркемгә аерып карый:

1) баланың ата-анасының, туган-кардәшләренең нәсел-ыруының теләге, хис-кичерешләре, бу бала шундый сыйфатка, холыкка ия булсын иде дигән ниятләр яткан ышанулар, йолалар һәм традицияләргә нисбәтле исемнәр;

2) асылларында баланың үзенә нисбәтле төрле ышанулар, йолалар, гадәт-традицияләргә нисбәтле исемнәр [Саттаров, 1990: 12–13]. Галим күрсәтелгән төркемнәрне үз эчендә дә кечкенә төркемчәләргә бүлә. Әлеге төркемчәләрдә болгар-татарларның исем бирү мотивлары тагы да тулырак ачыла.

Э.Бегматов үзбәк исемнәренең лексик-семантик төрләргә бүленешен исемнәрнең номинатив мәгънәсеннән чыгып анализлый. Үзбәк исемнәрен семантик яктан өч төркемгә бүлә: 1) конкрет затның исем мәгънәсе икенче бер затның исем мәгънәсендә белдерелә алуы. Мәсәлән, таныш кешенең исемен әйткәндә, аның исеме белән бергә, бу кешенең характер үзенчәлекләре төс-кыяфәте турында күзаллау барлыкка килә; 2) исемнең килеп чыгышы, сәбәпләре. Исемнең килеп чыгышы – халыкның икътисади хәле, мәдәнияте, культ һәм тотемнары, төрле дини мифологик күзаллаулар белән бәйле күренеш; 3) исемнең лексик мәгънәсе. Исем сайлауда уртаклык исемнән ясалган кеше исеменең лексик мәгънәсе зур әһәмияткә ия [Бегматов, 1965: 16–18].

Ш.Жапаров кыргыз антропонимик системасында балага исем бирүдә сүз һәм аны ачыклаган күренеш яисә предмет, шулай ук кеше исеме һәм аны йөртүче арасындагы бәйләнешнең мөһимлеген билгели [Жапаров, 1992: 70–71]. Исем бирү традицияләренә, апеллятив нигезләрнең семантикасына нигезләнеп, кыргыз антропонимнарын тотем, дезидератив, дескриптив антропонимнарга, этнографик характеристика бирүче антропонимнарга бүлеп карый. 90 нчы елларда антропонимиядә исемнәрне лексик-семантик яктан төркемләүдә яңадан-яңа юнәлешләр туа, ләкин, нигездә, номинация төп принцип итеп алына. Галимнәр билгеле бер вакыт аралыгына караган антропонимнарны лексик-семантик яктан төркемләүне төп өйрәнү объекты итеп алалар. Соңгы елларда телне, шул исәптән антропонимиканы прагматик юнәлештә өйрәнү киң колач алды. Бу юнәлештә эшләүче Анна

Вежбицкая «семантика имен – это потенциально важная область исследований не только с лингвистической точки зрения, но и в психологическом, антропологическом, социальном и культурно-историческом отношении. И в особенности важна с точки зрения межкультурных сопоставлений, как в теоретическом, так и в прикладном аспектах», дип билгели [Вежбицкая, 1997: 198]. Антропонимнарның прагматик мәгънәсе, эмоциональ концептларның коммуникация процессындагы торышын ачыклап, исемне, лингвистик берәмлектән бигрәк, социаль берәмлек буларак чагылдыра. Шулай ук, ул исемнәрнең телдә номинатив функциясеннән тыш, объект идентификациясе, шәхесне социаль легализацияләү функцияләрен дә аерырга мөмкинлек бирә. Хезмәтебездә, Л. Рашоньи һәм В.А. Никонов классификациясе нигезендә, исемнәрне өч төркемгә бүлеп өйрәндек:

1.Тасвирлама исемнәр (дескриптивлар).

2. Теләк исемнәр (дезидеративлар).

3. Багышлау исемнәр (меморативлар).

Тасвирлама исемнәргә а) баланың физик үзенчәлекләрен тасвирлаган исемнәр, ә) баланың туу урыны, көне, ае белән бәйле исемнәр, б) ата-ана хисләре белән бәйле исемнәр, в) бала туганда төрле вакыйгаларга бәйле булган исемнәр, г) гаиләдә баланың ничәнче булып туууына бәйле исемнәр кебек төркемчәләрне кертергә мөмкин.

Теләк исемнәр ата-ананың балага булган иң изге теләкләрен яктырталар. Бу төркемгә түбәндәге төркемчәләрне кертергә була: а) бәхет, байлык теләү исемнәре, ә) тазалык-саулык теләү исемнәре, б) матурлык, гүзәллек теләү исемнәре, в) озын гомер теләү исемнәре. Багышлау исемнәренә төрле тотемистик ышануларга, тарихи шәхесләргә, халык геройлары, танылган кешеләр, якыннарының истәлегенә бәйле исемнәрне кертеп карыйлар. В.А. Гречко сөйләүче тарафыннан индивидуаль һәм субъектив кабул ителгән исемнең эчке һәм тышкы формасы беренче планга чыгуын һәм шул субъективлыкның исем сайлауда төп критерий булуын билгели [Гречко, 2003: 242]. Димәк, балага исем сайлауда исемнең эчке, тышкы формасы аның бирелү мотивларын билгеләүдә әһәмиятле. Шулай ук исем сайлауда аның эчке формасын – «безнең яңа эчтәлекнең аңыбызга ничек, ни рәвешле үтеп керүен, ягъни яңа кушылган исемнең мәгънәсен» [Гречко, 2003: 243] ачыклау мөһим. Антропонимның эчке формасы төрле шартлар һәм факторлар нәтиҗәсендә туган билгеләрне, күзаллауларны (дини, тарихи традицияләр йогынтысы, моданың тәэсире, гаилә традицияләре) үз эченә

ала. Болар барысы да дескриптив (тасвирлама), дезидератив (теләк), меморатив (багышлау) исемнәрдә чагылалар. Исемнең тышкы формасын яңгырашы һәм төрле ассоциацияләр билгели. Бу, үз чиратында, күпчелек ир-ат исемнәребезнең алынма булуы һәм әлеге алынма ир-ат исемнәренең этимологиясе таныш булмавы белән дә аңлатыла. Димәк, исемнәрнең эчке һәм тышкы формаларында лингвистик һәм экстралингвистик параметрлары ачыла. Лингвистик параметрлар ир-ат исемнәренең фонетик ягын, структур һәм лексик яктан мотивлашкан булуын билгеләсәләр, экстралингвистик параметрлар исә исемнең милли үзенчәлеген, традицияләргә бәйле кулланылышын, исем белән туган төрле ассоциацияләрне, билгеле бер тел коллективына караганлыгын, аның бу коллективта танылу дәрәҗәсен билгелиләр.

## § 13. Дескриптив (тасвирлама) татар исемнәре

Бу исемнәр, номинатив универсальлектән тыш, үзләренең эчтәлек үзенчәлекләре белән дә аерылалар. Исемдә конкретлаштыру белән коннотация функцияләренең синтезы исемнең мәгълүмати һәм үзенчәлекле билгеләренең нигезе булган шәхси һәм иҗтимагый үзенчәлеген тасвирлауны барлыкка китерә. Исемнең мәгълүмати, шәхси, иҗтимагый кыры – «шәхеснең физик, рухи-интеллектуаль, психик, биологик, әхлакый характеристикасы, шулай ук аның билгеле бер милли, социаль, территориаль бәйлелеге» [Суперанская, 1973: 245] дескриптив ир-ат исемнәрендә тулы чагылыш таба. Борынгы чорда кушылган дескриптив исемнәр кушаматны хәтерләтәләр, «чөнки төрки-монгол халыкларының эпик әсәрләрендә сугыш кырында, төрле яуларда кыюлык күрсәткәч кенә, егет үзен ир-егет итеп санау һәм чын ирләргә хас исем алу хокукына ия була» [Гумилев, 1960: 243]. Шуңа күрә дескриптив исемнәрнең кайберләре кушаматтан аерылып җитмәгән берәмлекләрне тәшкил итәләр. Нигездә дескриптив (тасвирлама) татар ир-ат исемнәре татар халкының борынгы чорлардан ук килгән йола-гадәтләрен чагылдыралар, көнкүреш традицияләренә нисбәтле кулланылалар.

### *Баланың физик үзенчәлекләрен тасвирлый торган исемнәр*

Борынгы халыклар төсләрнең магик көченә ышанганнар. Ак төс – сафлык, пакьлек, яктылык, яхшы теләк, ышаныч кебек төшенчәләрнең символы булса, кара төс җир символы булып саналган. Борынгы төрки халыкларда сары төс «затлы» мәгънәсен аңлаткан. Төсләрнең символик үзенчәлекләре халыкның тормышы, көнкүреше, гореф-гадәтләре белән бәйле якларын да ача. Рус фразеологик

әйтелмәләрендә кызыл төс матурлык, шатлык, бәйрәм мәгънәләрен белдерсә, татар телендә кешегә хас үзенчәлекләрне ачуда чагыла. Мәсәлән, *кызыл авыз* кешенең булдыксызлыгын белдерсә, *кызыл тел* гыйбарәсендә кешенең зиһен үткенлеге кебек сыйфаты ачыла. В. Шерцль белдергәнчә, «Кеше үзенең тәэсирләрен һәм күзаллауларын төсләргә символик һәм метафорик мәгънә салу аша да белдерә ала» [Шерцль, 1884: 60], ул татар антропонимиясендә *кара, ак, ал, кызыл, сары күк, буз-бүз* кебек антропокомпонент һәм антропоформантлар нигезендә ясалган ир-ат исемнәрендә билгеләнә. *Кара* сүзе борынгы төрки телдә, төс мәгънәсеннән тыш, «дәһшәтле, көчле, куәтле; күп, мул, бай; баш, бөек; җир; күр, бак» кебек мәгънәләрне дә белдерә [ДТС, 1969: 423]. Татар исемиятендә кара антропоформанты белән ясалган ир-ат исемнәре шактый кулланылалар, аларда, төс мәгънәсе белән бергә, теләк төсмере дә билгеләнә. Мәсәлән, *Караарслан* исеме ир баланың арыслан кебек көчле булуын теләп кушылган булса (дезидератив исем), *Караби* исеме исә көчле, куәтле би мәгънәсендә килә (дескриптив исем). Төрки халыклардан *кара* компонентлы ир-ат исемнәре кыргызларда (*Карабәк*) [Жапаров, 1992: 21], төрекләрдә (*Караарслан* «кара+арслан», *Каракуш* «кара+кош», *Чоккара* «бик кара») [Эрол, 2000: 28], казакъларда (*Карабай* «кара+бай», *Карасай* «кара+матур», *Караман* «кара+ман») [Кульдеева, 2000: 211], башкортларда (*Карагужа* «кара+хужа») [Шайхулов, 1983: 15] кулланылалар.

В.В. Радлов төрки телләрдә *ак* антропокомпонентының 1) ак, 2) чиста, саф, киң күңелле мәгънәләрен күрсәтә [Радлов, 1963: 67]. Татар антропонимиконында *ак* антропокомпоненты *Акбит, Акбуга, Акбулат, Аккылыч, Акчура* кебек исемнәрдә килә. А.Гафуров *ак* компонентлы ир-ат исемнәрендә теләк мотивы ассызыклана дип саный. «Компонент *ак* часто встречается и в мужских именах: *Акбай, Акбулат, Акмухаммад, Акмирза, Актимур.* Конечно, не за белизну лица и не из желания видеть сыновей светлокожими называли мальчиков этими именами. В антропонимии компонент ак означает не белый, а долгожитель, счастливый, благословенный, хотя в некоторых именах, таких как *Аксуннур* белый кречет, сохраняется и буквальное значение» [Гафуров, 1987: 23]. Димәк, төрки халыкларда ир-ат исемнәре составында килгән *ак* антропокомпонентының мәгънәсе бик киң. Татар теленнән тыш, *ак* компонентлы ир-ат исемнәре казакъларда *Акҗегет* (ак+егет), *Акдәүләт* (ак+дәүләт), *Актау* (ак+тау) [Кульдеева, 2000: 207], башкортларда *Акбулат* (т.-ф.) (ак+булат), *Аккужа* (т.-ф.)

(ак+хуҗа) [Шайхулов, 1983: 7], төрекләрдә *Акбыек* (ак+мыек), *Акбай* (ак+бай), *Акгеик* (ак+киек) [Эрол, 1992: 27] исемнәрендә актив компонент булып килә. Галим Г.Ф. Саттаров *ак, кара* компонентлары нигезендә ясалган топонимнар, антропотопонимнарны тикшереп, кеше исемнәрен ике төркемгә бүлә [Саттаров, 1998: 134]. Беренче төркем исемнәрдә төс белдерүче компонентлар төп мәгънәсендә, төс белдереп, кешенең үз-үзен, гәүдәсен, тән өлешләрен таныту вазифасын үтәсә, икенче төркем исемнәрдә төс белдерүче компонентлар символик мәгънәгә ия булалар дип күрсәтә. *Коба* антропокомпоненты белән татар телендә өч ир-ат исеме ясалган. Коба – аксыл, сыек көрән төсне аңлата [ТТАС, 1979: 124]. Бу төс хайван төсе буларак кына кулланыла. Шуңа күрә бу компонент нигезендә ясалган ир-ат исемнәре кушамат белән исем аерылып каралмаган чорда ук ясалган дип әйтә алабыз. Татар антропонимиконында *Кобаев-Кабаев* фамилиясенең нигезен *коба* компоненты тәшкил итә. Борынгы төрки сүзлектә *сары* антропокомпоненты нигезендә ясалган *sarij cir saraj saman, sarij tojin, iktu sarij bas* кебек ир-ат исемнәре теркәлгән [ДТС, 1969: 488]. Ир-ат исемнәре составында *сары* антропокомпонентының, төс мәгънәсеннән тыш, «аксакал» мәгънәсе дә бар. «Компонент *сары* в именах преобретает значение «старый», «умудренный жизнью». Имя *Сарымбет*, встречается у казахов и каракалпаков – это не «желтый Мухаммад, а долгожитель Мухаммад», хотя и нередко этим именем называют светловолосого ребенка» [Гафуров, 1987: 23]. Борынгы заманнарда *Сарыбала, Сарыбаш, Сарыбулат, Сарыбәк, Сарыарслан* кебек *сары* антропокомпонентлы ир-ат исемнәрендә күбрәк тасвирлау функциясе өстен килә. *Сары* антропокомпоненты препозициядә дә, постпозициядә дә кулланыла. Мәсәлән, *Байсары, Тайсар, Туксар* кебек ир-ат исемнәре һәм алар нигезендә ясалган авыл атамаларын әйтергә мөмкин. Төрки халыклардан кыргызларда *сары* компонентлы ир-ат исемнәре (*Сарыгул* (сары+огул, ул») [Жапаров, 1992: 77], төрекләрдә (*Ерсары* «ир+сары», *Сарыбуа* «сары+үгез», *Сарухан* «сары+хан») [Эрол, 1999: 28] исемнәре теркәлгән. Борынгы төрки телдә *кук* антропокомпонентының, руслардагы «голубой, сизый, синий» мәгънәсеннән тыш, «небо», «свободный, вольный» кебек мәгънәләре дә кулланыла. *Күккүз, Күктай, Күктимер* кебек исемнәр кушуда ир баланың йөзе, берәр әгъзасының төсе мотив булган дип әйтә алабыз. Борынгы төрки телдә *кук* компонентлы kök amas, tutuq köklü [ДТС, 1969: 115] кебек ир-ат исемнәре теркәлгән. Төрекләрдә *Гэкалп* «күк+алып»,

*Гөкай* «күк+ай», *Гөкхан* «күк+хан» [Эрол, 1999: 28] кебек күк компонентлы ир-ат исемнәре бүгенге көнгәчә актив кулланылышта йөриләр.

Татар антропонимиконында сирәк очрый торган *бүз* антропокомпонентының беренче мәгънәсе «соргылт; аксыл» булса, икенче мәгънәсе «үсмер егет» дигәнне аңлата [ТТАС, 1977: 219]. *Бүз* компоненты борынгы төрки телдә «соры» мәгънәсен белдерә [ДТС, 1969: 115]. *Бүзъегет, Бүзтанай, Бүзтимер, Бүзтирәк, Бүзәк* кебек ир-ат исемнәре шушы антропокомпонент нигезендә ясалган.

Төс белдерүче *ал* компоненты нигезендә бары тик *Алтаң, Алнур* кебек исемнәр ясалган. Ә төс белдерүче *коңгырт* антропокомпоненты нигезендә ясалган ике ир-ат исеме теркәлгән (*Коңгырт, Коңгыртбай*). Галим Г.Ф. Саттаров фикеренә караганда, бу исемнәр коңгырт күзле, яки коңгырт чәчле ир балага кушылган. Казан татарларында *Коңгыров, Кунгуров* фамилияләрендә сакланган [Саттаров, 1998: 128].

Татар антропонимиконында *кызыл* антропокомпоненты бары тик ике ир-ат исемендә (*Кызылбаш, Кызылбай*) аларның балачактагы төс-кыяфәтенең үзенчәлекләрен күрсәтү өчен кулланылган. *Кызыл* антропокомпоненты ир-ат исемнәрен ясауда аз катнаша, ул, нигездә, тән әгъзалары төзелеше үзенчәлекләрен күрсәтүне максат итә (*Кызылкүз*). Төрек телендә *Кызыларслан, Кызылбай, Кызылхан* кебек ир-ат исемнәре теркәлгән [Эрол, 1999: 28]. Шулай итеп, татар телендә борынгы төрки исемнәрнең нигезен тәшкил иткән төс белдерүче компонентлар төсләр палитрасын барлыкка китерәләр. Төс белдерүче антропокомпонентлар борынгы төрки ир-ат исемнәренең нигезендә сакланып, бер яктан, халыкның этник үзенчәлекләрен билгеләүдә әһәмиятле булсалар, икенче яктан, бу исемнәрдә халыкның мифологик күзаллаулары, дөньяга карашы чагыла. Шулай ук, төс белдерүче антропокомпонентлардан тыш, татар антропонимиконында «миң» компонентлы ир-ат исемнәрен дә тасвирлама исемнәр төркеменә кертергә мөмкин. «Миң» компонентлы ир-ат исемнәренең бирелү мотивлары түбәндәгеләр:

1) төрки халыкларда миң уңышка ирешү, бәхет символы булып тора;

2) баланың тәнендә миң табылуга бәйләнешле рәвештә исемнәргә кушылып бирелә;

3) «миң» компонентлы исемне күз тимәсен өчен кую очраклары да бар;

4) нинди дә булса авырудан котылу чарасы булып та «миң» компонентлы исемнәр куелалар.

Халык ышануларына караганда, әгәр авыру озакка сузылса, кешегә «миң» компонентлы исем бирәләр яисә исемне бөтенләй алыштыралар. Әлеге ышану-йола беренче мен кабиләсендә кулланылган. «Бу ышанауга караганда, исем алыштыруның магик көче явыз чирләрне җиңәргә тиеш булган. Соңрак бу ышану төркиләрнең уртак традициясенә әйләнә» [Юсупов, 1970: 249]. *Миң, миңле* сүзе «матурлык, чибәрлек, күркәмлек» төшенчәсен белдерү өчен дә хезмәт иткән [Саттаров, 1998: 165]. Ләкин безнең фикеребезгә караганда, *миң* антропокомпонентының бу мотивы хатын-кыз исемнәрендә чагыла, ир-ат исемнәренә исә *миң* антропокомпоненты югарыда санап үтелгән мотивларга нигезләнеп куела. Казакъларда «миң» компонентлы исемнәрдә теләк төсмере дә өстәлә, чөнки *миң* бәхет, уңышлылык символы булып тора. Бу исемнәрдә ата-ананың балага уңыш, бәхет теләү мотивлары ята [Кульдеева, 2001: 10]. Татар антропонимикасында да *миң* антропокомпонентлы исемнәрдә теләк төсмере чагыла. Мәсәлән, *Миңлехуҗа, Миңлехан* кебек исемнәрдә «миң» компоненты бәхет символы, бәхет теләү мотивы белән билгеләнә. С.М. Абрамзон билгеләвенчә, кыргызларда миң белән туган баланы бәхетле киләчәк көтә дип фаразлаганнар. Әгәр ир бала кара миң белән туса, ул балага *Калбай, Калдыбәк* исеме биргәннәр, кызыл миң белән туса, *Анарбай* исеме бирелгән [Абрамзон, 1962: 15]. Айдил Эрол *миң* антропоформантлы исемнәрнең төрек антропонимиясендә киң кулланылуын билгели [Эрол, 1999: 46]. Төрек телендә *миң* компоненты *һал-бен* вариантларында килә. Төрек антропонимиясендә *нал* компоненты (*һаллы, һалдар*) *бен* антропокомпоненты (*Бенли, Бенлиоглу*) белән бергә ялгана. *Кал* варианты таҗикларда һәм фарсыларда «миң» мәгънәсендә килә. Димәк, *миң* антропокомпонентлы исемнәр төрле вариантларда килеп (*миң, мен, кал, нал*), баланың тәнендә булган миңне тасвирлау вазифасыннан тыш, бәхет, уңыш теләү төсмерен дә чагылдыралар. *Миң* антропокомпонентлы исемнәр үзбәк, казакъ, төрекмән, башкорт, төрек халыкларында киң кулланыла.

### *Вакыт һәм урынга бәйле татар исемнәре*

Вакыт кеше яшәешенең төп ориентиры булып тора. Шуңа күрә вакыт турында күзаллаулар һәрбер халыкның рухи һәм матди мәдәнияте, шул исәптән, антропонимиясе өчен дә характерлы. Әлеге мәсьәләнең чагылышы вакытка бәйле татар ир-ат исемнәре төркемендә аеруча ачык сизелә. Вакытка бәйле ир-ат исемнәре баланың туу көне,

ае, елы белән бәйле исемнәрне үз эченә алалар. Вакытка бәйле ир-ат исемнәренең үсеше төрле даталар, традиция-йолаларга мөнәсәбәтле «борынгылар календаре, вакыт хисабының үзенчәлеге күчмә, соңрак утрак, игенчелек ихтыяҗлары, башка илләр белән мәдәни-сәүдә бәйланышлары, дин һәм традицияләргә нигезләнә» [Дәүләтшин, 1999: 169]. Вакытка бәйле исем бирү традицияләренең борынгылыгы төрки халыкларда да кулланылуы белән бәйле характерлана.

Ш. Жапаров атна атамалары нигезендә ясалган исемнәрне кыргыз антропонимиясенең үзенчәлеге дип билгели. Мәсәлән, *Жекшембек* < таҗ., якшәмбе, *Дүйшәмбек* < таҗ., дүшәмбе, *Шейшембай* < таҗ., сишәмбе, *Шершеналы* < таҗ., чәршәмбе һ.б. [Жапаров, 1992: 26]. «Ислам кабул ителгәнче, болгар-татарларда җирле көн исемнәре дә кулланылышта була. Алар XIII–XIV йөз болгар кабер ташларында очрый. Дүшәмбе – әрнә башы, чәршәмбе – кан көн, пәнҗешәмбе – кече әрнә көн, җомга – әрнә көн» [Хакимзянов, 1987: 83]. Ислам дине кабул ителгәннән соң, болгарларда атнаны гарәп-фарсы чыгышлы атамалар белән билгели башлыйлар, шул рәвешле, атна атамаларына бәйле *Дүшәмбай, Дүшәмбе, Сишәмбе* кебек ир-ат исемнәре дә тарала башлый. Бүгенге көндә әлеге төр исемнәр ир балаларга кушылмый. Базар – фарсы телендә «бәйрәм көн» дигәнне аңлата. Көнчыгыш илләрендә мөселманнар базар көнне дуслар, туганнары белән очрашканнар. Төрки халыкларда базар көнне туган ир балага *Базар* исемен кушу йола-гадәте булган. Әлеге антропокомпонент нигезендә *Базарбай, Базар* кебек исемнәр ясалганнар.

*Җомга* (г.) анропокомпонентлы ир-ат исемнәре җомга көнне туган ир балаларга бирелгән. Татар антропонимикасында *Җомагол* (г.-т.), *Җомгагали* (г.), *Җомгабай* (г.-т.) һ.б. ир-ат исемнәре теркәлгән. «Җомга» сүзенең диалекталь варианты «йома» сүзе белән ясалган ир-ат исемнәреннән *Йомабай* (г.-т.), *Йомагали* (г.-г.), *Йомагол* (г.-т.), *Йомахуҗа* (г.-ф.) кебек исемнәрне мисал буларак китерергә мөмкин. Төрек антропонимиясендә *җомга* антропокомпоненты актив кулланыла. Айдил Эрол «төрек дөньясы өчен җомга көнне туган ир балага *Җомга* исемен бирү киң таралган бер гадәт» дип билгели [Эрол, 1999: 41]. Гарәп теле тәэсирендә төрек телендә исемнәрдә Cuma варианты килә. Казакъ антропонимиясендә җомга компонентлы исемнәрдән *Жумабек, Жумабай, Жуман, Байэ/жуман, Жумагали* кебек мисалларны китерергә мөмкин [Кульдеева, 2000: 221]. Казакъ антропонимиясендә дә cuma угыз варианты кулланыла. Җомганың диалекталь варианты

булган «атна көн» ир-ат исемнәрендә дә чагылыш тапкан. Борынгы заманнардан татарларда яхшы, изге көн дип саналган атна (җомга) көнне туган балаларга шул көн исемен кушу йоласы булган. Мишәрләрдә, Чистай керәшеннәрендә җомга атна (ф.) көн термины белән бергә кулланылган [Махмутова, 1978]. *Азнагол* (ф.-т.), *Азнабай* (ф.-т.), *Азнакай* (ф.-т.) кебек ир-ат исемнәре *азна – атна* сүзенә кушылып ясалган исемнәр. *Бәйрәм* (т.) компонентлы ир-ат исемнәре бәйрәм көнне туган ир балаларга кушыла. Әлеге компонент нигезендә *Бәйрәмбай* (т.), *Бәйрәмгали* (т.-г.), *Бәйрәмхан* (т.), *Бәйрәмша* (т.-ф.), *Бәйрәмгол* (т.) кебек ир-ат исемнәре ясалганнар. Татар антропонимиконында теләсә нинди бәйрәмгә бәйле көннәрдә туган ир балага Бәйрәм исеме куелган. «Төрекләрдә дә Рамазан бәйрәмендә туган ир балаларга Бәйрәм исеме бирелә» [Эрол, 1999: 37]. Ислам дине белән бергә болгарларда мөселман ай календаре – ай һиҗрәсе дә кулланылышка керә. Ул ислам диненең төп атрибутына әйләнә. Татар антропонимиконында ай һиҗрәсенә нисбәтле Сәфәр – һиҗри аеның 2 нче ае; Рәҗәп – һиҗринең 7 нче ае; Шәгъбан – һиҗринең 8 нче ае; Шәһретдин – һиҗринең 12 нче ае; Рамазан – һиҗринең 9 нчы ае белән бәйле ир-ат исемнәре кулланылалар. Баланың туу ае белән бәйле ир-ат исемнәреннән *Нәүрүз* (ф.) антропокомпоненты нигезендә ясалган исемнәр төркемен дә аерып күрсәтергә мөмкин. Нәүрүз яңа елның беренче көне (яз бәйрәме), көн белән төннең тигезләнгән вакыты – 21 мартка туры килә. Урта Идел буе халыкларында яңа ел башланган фарсыча соңгы чорларга кадәр «нәүрүз» – яңа көн дип йөртелгән [Дәүләтшин, 1999: 17]. Бу антропокомпонент нигезендә *Нәүрүз* (ф.), *Нәүрүзбай* (ф.-т.), *Нәүрүзбәк* (ф.-т.), *Нәүрүзгали* (ф.-г), *Нәүрүзхан* (ф.-т.) кебек ир-ат исемнәре ясалган. Төрекләрдә язның беренче аенда туган ир бала яхшыга юралган. Бу айда туган ир балага *Нәүрүз* исемен бирү ир балага гомер буе шатлык юлдаш булсын дигән теләк төсмерен дә өсти. Төрек антропонимиконында *Нәүрүзбәхт, Нәүрүзкол* кебек ир-ат исемнәре теркәлгән [Эрол, 1999: 55]. Шулай ук *Нәүрүз* исеме башкортларда [Шәйхулов, 1983: 20], казакъларда [Кульдеева, 2000: 231], кыргызларда [Жапаров, 1992: 23] кулланыла. Корбан аена бәйле исемнәрдән *Корбан* (г.), *Корбанбакый* (г.), *Корбанкилде* (г.-т.), *Корбангази* (г.), *Корбанвәли* (г.), *Корбанкол-Корбангол* (г.-т.) кебек ир-ат исемнәре ясалган. «*Корбан* компонентлы ир-ат исемнәре төрек антропонимиконында да бар» [Эрол, 1999: 45]. Төрекләрдән тыш, башкортларда [Шайхулов, 1983: 15], казакъларда [Кульдеева, 2000: 77], кыргызларда [Жапаров, 1992] да бу компонент

нигезендә ясалган ир-ат исемнәре очрый. Мөселманнарда изге саналган бәйрәмнәрдән берсе булган Гает көнендә туган ир балага *гает* (г.) антропокомпонентлы исемнәр кую гадәте дә яшәп килә. Бу төркемчәне *Гает* (г.), *Гаетбай* (г.-т.), *Гаетхан* (г.-т.), *Гаетхуҗа* (г.-ф.), *Гаетҗан* (г.-ф.) кебек ир-ат исемнәре билгелиләр. Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне булып билгеләнгән Мәүлид кичәсендә туган ир балаларга *мәүлид* антропокомпонентлы ир-ат исемнәре бирелә: *Мәүлид* (г.), *Мәүлидбай* (г.-т.), *Мәүлидгәрәй* (г.-т), *Мәүлиддин* (г.), *Мәүлидҗан* (г.-ф.) һ.б.

Рус календарена бәйле ир-ат исемнәре татар антропонимиясендә дә чагылыш тапкан. Мәсәлән, *Октябрь, Май* кебек ир-ат исемнәре октябрь, май айларында туган ир балага бирелгәннәр. Календарь ай исемнәренә бәйле ир- ат исемнәре казакъ антропонимиясендә киң кулланыла. Мәсәлән, *Шилдебай* («шилде» – июнь), *Мамрай* («мамыр» – май), *Акпапбет* («акпап» – февраль), *Сеипбай* («сеип» – апрель) кебек ир-ат исемнәрен атарга була [Кульдеева, 2000: 65]. Төрек антропонимиконында да Нисан (апрель), Маес (май), Эким (октябрь) кебек ай исемнәренә бәйле ир-ат исемнәре чагылыш тапкан [Эрол, 1999:, 53].

Вакыт аралыгын күрсәткән *таң, көн, төн, кич, сәхәр, ахшам* кебек апеллятивлар нигезендә ясалган ир-ат исемнәре вакытка бәйле исемнәр рәтендә каралды, чөнки алар нигезендә вакыт мәгънәсе ассызыклана, ир баланың туу вакыты билгеләнә. Борынгы төрки сүзлектә kün сүзенең 1) кояш, 2) көн, 3) көн саен кебек мәгънәләр белдерүе күрсәтелгән [ДТС, 1969: 79]. «Көн – яктылык, матурлык, ирек символына нигезләнеп, төрки халыкларда, шул исәптән болгар-татарларда кулланылышта актив йөргәннәр» [Саттаров, 1998: 63]. Хатын-кыз исемнәрендә көн антропокомпоненты матурлык, яктылык символы булып килсә, ир-ат исемнәрендә (*Көнтимер, Көнбирде, Көнбак*) баланың туу вакытын билгели дип уйлыйбыз. Татар антропонимиясендә таң (т.) компонентлы ир-ат исемнәреннән *Таңатар, Таңкилде, Таңбулат, Таңатар* кебек исемнәрне күрсәтергә була. «*Таң* компонентлы исемнәр татарларның гына түгел, башка төрки халыкларның да составында сакланган» [Саттаров, 1998: 54]. Мәсәлән, төрек телендә *таң* антропокомпонентлы ир-ат исемнәре шактый күп кулланылалар. Мисал итеп, *Танай* «таң+ай», *Таныты́лмыш* «таң +атылган», *Танайдын* «таң+якты» *Тандоан* «таңда туган» [Эрол, 1999: 43] кебек ир-ат исемнәрен күрсәтергә мөмкин. Шулай ук таң компонентлы ир-ат исемнәре башкортларда (*Тангатар, Таңбулат, Таңатар*) [Эрол,

1999: 155, 22], казакъларда (*Таңбиргән*) [Эрол, 1999: 80, 215], кыргызларда (*Таңатар, Аткантаң*) [Эрол, 1999: 60, 77] да билгеләнәләр. Шулай итеп, вакытка һәм урынга бәйле ир-ат исемнәре борынгыларның рухи тормышын, космогоник карашларын чагылдырып киләләр. Ата-ананың төрле хисләрен аңлаткан татар ир-ат исемнәре дә бар. Бу төркем исемнәр антропокомпонентларның төрлелеге белән аерылалар. Әлеге исемнәр, нигездә, кушма төзелешле. Мисал итеп, түбәндәге антропокомпонентлы ир-ат исемнәрен китерергә була:

– *асыл* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Асылгата* (г.), *Асылбай* (г.-т.), *Асылбәк* (г.-т.), *Асылхуҗа* (г.-ф.), *Асылгали* (г.) һ.б.;

– *өмет* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Өметбай* (г.-т.), Өметгәрәй (г.-т.), Өметҗан (г.ф.) һ.б.;

– морат (г.) «теләк, ният, теләгән әйбер» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Моратбай* (г.-т.), *Моратбирде* (г.-т.), *Моратшаһ* (г.-ф.), *Шаһиморат* (ф.-г.) һ.б.;

– *ният* (г.) «теләк, максат, ният» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Ният* (г.), *Ниятбай* (г.-т.), *Ниятшаһ* (г.-ф.) һ.б.;

– *нияз* (г.) «ихтыяҗ; мәрхәмәт, шәфкать; үтенү» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Нияз* (г.), *Ниязгали* (г.), *Ниязсолтан* (г.) һ.б.;

– *хөрмәт* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Хөрмәтулла* (г.), *Хөрмәтгали* (г.), *Хөрмәтбай* (г.-т.), *Хөрмәт* (г.) һ.б.;

– *шат* (ф.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Шатлык* (ф.-т.), *Илшат* (т.-ф.), *Иршат* (т.-ф.), *Айшат* (т.-ф.) һ.б.;

– *ләззәт* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Ләззәтҗан* (г.-ф.), *Ләззәтхан* (ф.-т.), *Ләззәт* (г.) һ.б.;

– *фарих-фәрхе-фәрхи* (г.) «шат, бәхетле» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре*:* *Фәррах* (г.) «шат күңелле, шатлык, сөенеч», *Фәрхетдин* (г.) «дин шатлыгы, сөенече», *Фәрух* (г.) «шат, сөенечле» һ.б.;

– *җан* (ф.) антропоформантлы ир-ат исемнәре: *Газизҗан* (г.-ф.), *Мөбарәкҗан* (г.-ф.), *Җангали* (ф.-г.) һ.б.

*Җан* антропоформантлы ир-ат исемнәре бу төркем эчендә каралды, чөнки әлеге компонент нигезендә исемнәрдә ата-ананың балага булган хисләре чагыла. Халыкта бүгенге көндә дә иң кадерле кешегә «җаным» дип атау традициясе яши. Моннан тыш, татар телендә *җан* – фида ителәчәк иң кадерле әйбер турында «җаным фида» дигән гыйбарә кулланыла. Г.Ф. Саттаров *җан* компонентының исемнәргә «җан кебек якын, кадерле» мәгънәсен бирү өчен кулланылуын күрсәтә [Саттаров, 1998: 327]. А.Гафуров *җан* антропоформантын балага

озын гомер теләү функциясен үтәүче форма дип күрсәтә [Гафуров, 1987: 46, 40]. Бу мәгънәләрдән тыш, *җан* компоненты «зат, кеше, җан» мәгънәсен дә белдереп килә дип саныйбыз. Нигездә, постпозициядә *җан* антропоформанты «җаным» иркәләү-кечерәйтү функциясеннән тыш, затны белдерү өчен хезмәт итә. Мәсәлән, *Галимҗан* исемендә җан антропоформанты «кеше, зат» ягъни «белемле, укымышлы зат» мәгънәсендә килә. Препозициядә килгәндә, озын гомерле мәгънәсен белдерә. Мәсәлән, *Җангали* дигәндә, «озын гомерле; бөек, югары дәрәҗәле» кебек эпитетлар күз алдында тотыла. Бер төркем ир-ат исемнәренең нигезен төрле тәм-том апеллятив лексикасыннан ясалган антропоформантлар тәшкил итәләр:

– бал антропоформантлы ир-ат исемнәре: *Балкай, Баллыбәй, Баллыбәк* һ.б.;

– шикәр антропоформантлы ир-ат исемнәре: *Шикәрҗан, Балшикәр, Шикәр* һ.б.

Бу компонентлар нигезендә ясалган исемнәр ата-ананың балага булган хисләрен чагылдыруның аерым бер шәкеле булып торалар, чөнки татар халкында иркәләп-яратып эндәшү формаларында тәм-том апеллятивыннан ясалган исемнәр дә кулланыла. Бала туганда төрле вакыйгаларга бәйле иҗат ителгән татар ир-ат исемнәре дә аз түгел.

Бала туганда булган вакыйгаларга бәйле иҗат ителгән татар ир-ат исемнәрен үз эчендә ике төркемчәгә бүлеп карадык:

1) кечкенә вакыйгага бәйле кушылган татар исемнәре;

2) зур вакыйгага бәйле кушылган татар исемнәре.

Беренче төркемчәгә авыл, район, шәһәрдә булган кечкенә вакыйгага нисбәтле кушылган ир-ат исемнәрне керттек:

а) зур кунаклар килү вакыйгасына бәйле кушылган татар исемнәре: *Байкилде, Хаҗикилде, Морзакилде* һ.б.;

ә) туй вакыйгасына бәйле кушылган татар исемнәре: *Туйбала, Туйбай, Туйчы, Туйбакты* һ.б.;

б) төрле табигать күренешләренә бәйле иҗат ителгән исемнәре: *Яңгырбай, Аяз, Карлыхан, Салкынбай, Давыл* һ.б.

Табигать күренешләрен ир-ат исемнәрендә чагылдыру төрек, казакъ, төрекмән халыкларында да киң кулланыла. Мәсәлән: төрекләрдә *Томан, Томанҗы* «томан+чы», *Ягмур* «яңгыр», *Карйагды* «кар яуды» [Эрол, 1999: 62], казакъларда *Айборан* «ай+буран», *Боранҗан* «буран+җан», *Жанбырбай* «яңгыр+бай», *Жанбырбәк* «яңгыр+бәк» [Кульдеева, 2001: 80]; төрекмәннәрдә *Гарлы* «кар+лы», *Гайлы*

«давыл+лы» һ.б. [Аннакылычев, 1970: 201]. Табигать күренешләренә бәйле ир-ат исемнәре төрекмән халыкларында да киң кулланылыш алган дип билгели Ш. Аннаклычев: «следует отметить, что имена связанные с планетами, природой и ее явлениями, чаще всего давались мальчикам» [шунда ук]. Димәк, бу төркем ир-ат исемнәренең үзенчәлеге булып санала. Татар антропонимиясендә төрле өй кирәк-яраклары, конкрет предмет төшенчәсен белдергән сүзләр нигезендә ясалган исемнәр дә үзләре бер семантик оя тәшкил итәләр. Төрле йорт кирәк-яраклары, конкрет предмет төшенчәсен белдергән сүзләр нигезендә ясалган ир-ат исемнәрендә халыкның матди тормышы чагыла. Бу төр антропокомпонентлы ир-ат исемнәре бала туганда, ананың нинди дә булса предметны күрүе белән нисбәтле кушыла.

Антропонимикон нигезендә өй кирәк-яраклары нигезен тәшкил иткән исемнәр түбәндәгеләр:

– *кылыч* (т.) антропокомпонентлы исемнәр: *Кылыч* (т.), *Кылычбай* (т.), *Кылычарслан* (т.) һ.б.;

– *балта* (т) антропокомпонентлы исемнәр: *Балтабай* (т.), *Балтай* (т.), *Балтан* һ.б.;

– *сәйф* (гарәпчәдән: кылыч мәгънәсендә килә) антропокомпонентлы исемнәр: *Сәйфи* (г.), *Сәяфетдин* (г.), *Сәйфихан* (г.-т.) һ.б.;

– *көмеш* (т.) антропокомпонентлы исемнәр: *Көмешаһ* (т.), *Көмешбай* (т.), *Көмеш* (т.) һ.б.;

– *алтын* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Алтынай* (т.), *Алтынбай* (т.), *Алтынбәк* (т.) *Алтыннур* (т.-г.), *Алтынгәрәй* (т.), *Алтынгали* (т.- г.) һ.б.;

– *бүләк* (т.) антропокомпонентлы исемнәр: *Бүләкбай* (т.), *Бүләкбирде* (т.), *Бүләккол* (т.) һ.б.

Зур вакыйгага нисбәтле кушылган ир-ат исемнәрендә тарихи һәм иҗтимагый вакыйгалар чагыла. Г.Р. Галиуллина «социаль вакыйгаларның ир- ат исемнәренә тәэсире зур» [Галиуллина, 2000: 72], дип саный. Тарихи һәм иҗтимагый вакыйгаларны чагылдырган ир-ат исемнәре башка төрки халыкларда да кулланылалар. С. Акалын фикеренә караганда, «төрекләрдә тарихи вакыйгаларны исемдә чагылдыру киң таралган күренеш санала» [Акалын, 1998: 13]. Казакъларда сугыш, фронт, мылтык һ.б.ның апеллятивларыннан ясалган ир-ат исемнәре тормыштагы иҗтимагый вакыйгаларга бәйле кушылалар [Кульдеева, 2000: 81]. Татар антропонимиконында *ил* антропокомпоненты нигезендә ясалган *Илтөзәр, Илнар, Илшат, Илсур, Илдан,*

*Илданур, Илнур, Илдар, Илдус, Илсаф* кебек ир-ат исемнәре киң таралышка ия. Шулай ук *Ирек, Азат* кебек ир-ат исемнәре дә бу төркемгә карыйлар. Революция вакыйгаларына нисбәтле *Рево, Октябрь, Ревдар* («революционный дар»), *Ревмир* («революция мировая») [Саттаров, 1990: 201], шулай ук *Иншәр* «инкыйлабый шәрык», *Инкыйлаб* кебек исемнәр дә шушы төркемне билгелиләр.

## *Баланың гаиләдә ничәнче булып туына бәйле исемнәр*

Баланың гаиләдә ничәнче булып туына бәйле татар исемнәре борынгы исемнәр катламын тәшкил итәләр. Бүген бу ир-ат исемнәре гомумән кулланылышта юк. XIX гасырда үткәрелгән җир сәясәте ир балалар туу ихтыяҗын алга чыгара. Шуңа күрә, гаиләләрдә ир баланың туы зур һәм көтелгән шатлыкка әйләнә. Ир-ат исемнәрендә ир баланың беренче, уртанчы, соңгы бала булып туы антропокомпонентларда ассызыклана. *Тәүге, баш, ал* антропокомпонентлары нигезендә ясалган ир-ат исемнәре ир баланың беренче булып туын билгелиләр. *Тәүкилде, Балабаш, Алкилде, Алгай* һ.б. ир-ат исемнәре бүгенге көндә кулланылыштан төшеп калсалар да, кайбер топонимнар, фамилияләр составында сакланалар әле. Сан белән бирелгән *Сигезәк, Өчтәк, Дүртәк, Тугызбай, Игез* кебек ир-ат исемнәре баланың гаиләдә туу тәртибен билгелиләр. Төпчек, яки беренчеләреннән соңрак туган *ахир, азак, хәтем, кече-кечек* антропокомпонентлары кушып ясалган ир-ат исемнәре: *Ахир, Ахияр, Хәтим, Мирхәтим, Кечебай, Кечеккол* һ.б. *Кызтумас, Кызбирмәс* исемнәрендә исә, ир бала тусын иде, дигән теләк ята. Бу төркемгә керә торган исемнәрдән дә бүгенге көндә кулланылышта йөргән *Ранис* исемен Г.Ф. Саттаров «Ранис исеме русчадан «раннист» – баштагы беренче бала сүзеннән ясалган ир-ат исеме дип билгели» [Саттаров, 1998: 164]. Дескриптив татар ир-ат исемнәрендә коннотатив функция өстенлек итә, шуңа күрә бу төркем ир-ат исемнәре кушаматка якын торалар. Шулай да әлеге ир-ат исемнәрендә билгеләнгән мәгълүмати һәм иҗтимагый йөкләмә кеше һәм исем бәйләнешен тагы да ассызыклый. Кешенең физик, психологик үзенчәлекләре, туу вакыты, вакыйгалары белән бәйле барлыкка килгән ир-ат исемнәре бүгенге көн ир-ат исемиятендә аз санда кулланылалар.

## § 14. Дезидератив (теләк) татар исемнәре

Исем асылында балага билгеле бер теләк мотивы яту – дөньядагы барлык халыкларның тарихи антропонимиконына да хас, уртак күренеш. Борынгы җәмгыятьтә сүзнең магик көченә ышану исемнәрдә төрле теләкләрнең чагылыш табуына китерә. Шуңа да исемнәрдә теләк мотивы, борынгыларның сүз көченә ышануы буларак, бүгенге көн антропонимнарында да сакланган. Теләк исемнәрдә ата-анасы, туган-кардәшләренең бу бала шундый сыйфатка ия булсын иде дигән теләге, хис-кичерешләренә нисбәтле мотивлар билгеләнәләр.

### *Ата-ананың балага бәхет теләве төп мотив булган исемнәр*

Бүгенге көндә актив булмаган антропокомпонентлар бу төркемдә зур күпчелекне тәшкил итәләр:

– *ураз* (араз, рыс) (т.) «бәхет, шатлык» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Уразбай* (т.) «бәхетле бай», *Уразбак* (т.) «бәхетле кара», *Уразбәк* (т.) «бәхетле бәк», *Уразай* (т.) «бәхетле+ай ирк.-кечерәйтү кушымчасы», *Уразбакты* (т.) «бәхетле карады» һ.б.

– *кот-котлы* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Котлыби* (т.) «бәхетле бәй», *Котлыдәүләт* (т.) «бәхетле дәүләт», *Котлыморат* (т.-г.) «бәхетле теләк», *Котлыҗан* (т.-ф.) «бәхетле җан»; *Котлымөхәммәт* (т.-г.) «бәхетле +мөхәммәт», *Котлыбарс* (т.)»бәхетле барс», һ.б.

Исемнәрдә бәхет төшенчәсен белдерүче сүзләр белән беррәттән, гарәби чыгышлы бәхет, сәгадәт компонентлары да ир-ат исемнәрен ясауда катнашалар:

– *бәхет* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Бәхетҗан* (г.-ф.) «бәхетле җан», *Бәхетхан* (г.-т.) «бәхетле хан», *Бәхетбай* (г.-т.) «бәхетле бай», *Бәхетгәрәй* (г.-т) «бәхет+гәрәй», *Бәхтегани* (г.) «бәхетле бай», *Бәхтияр* (г.-ф.) «бәхетле дус» һ.б.;

– *сәгадәт* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Сәгадәтша* (г.-ф.) «бәхетле шаһ», *Сәгадәтхан* (г.-т.) «бәхетле хан», *Сәгадәткол* (г.-т.) «бәхетле кол», *Сәгадәтҗан* (г.-ф.) «бәхетле җан», *Сәгадәтулла* (г.) «бәхетле +улла», *Сәгадәтнур* (г.) «бәхетле нур» һ.б.

### *Бала матур, чибәр булсын дигән теләк белән кушылган исемнәр*

Балага матурлык-чибәрлек теләү мотивы хатын-кыз исемнәрендә генә түгел, ир-ат исемнәрендә дә чагылыш таба. Бу төр исемнәр түбәндәге компонентлар нигезендә ясалалар:

– *гүзәл*: *Гүзәлбану* (т.-ф.), *Гүзәлем* (т.), *Гүзәлгөл* (т.-ф.), *Гүзәлия* (т.), *Гүзәлнур* (т.-г.), *Гүзәлҗан* (т.-ф.);

– *сылу* (т.) «гүзәл, сылу; зифа, матур, сынлы»: *Сылубану* (т.-ф.) «сылу кыз», *Сылубиби* (т.-ф.) «сылу кыз», *Сылугөл* (т.-ф.) «сылу гөл», *Сылуйөз* (т.) «сылу йөз» һ.б., *Айсылу* (т.) «ай сылуы» һ.б.;

– *хөсни* (г.): «иң яхшы, иң күркәм, иң гүзәле, иң күркәме»: *Хөснибану* (г.-ф.) гүзәлләрнең гүзәле; *Хөснигөл* (г.-ф.) гөлнең иң күркәме, иң гүзәле, иң матуры; *Хөснизадә* (г.-ф.) баланың иң күркәме, иң матуры; *Хөсния* (г.) иң шәп, иң гүзәл, иң күркәм», *Хөсниҗамал* (г.) чибәрнең иң күркәме, иң гүзәле иң матуры һ.б.;

– *зифа* (ф.): «чибәр, сылу, зифа, күркәм, гүзәл, зиннәтле»: *Зифабану* (ф.), *Зифабикә* (ф.-т.-т.) *Зифагөл* (ф.), *Зифанур* (ф.-г.), *Зифасылу* (ф.-т.) һ.б.

Түбәндәге исемнәрнең нигезендә дә «матурлык, гүзәллек, чибәрлек төшенчәләре ята: *Хәсәния* (г.) «яхшы, чибәр, матур. күркәм», *Хәсәнә* (г.) «чибәр, матур, күркәм», *Рәгыйнә* (ф.) «чибәр, купшы».

### *Балага байлык-муллык теләү төп мотив булган исемнәр*

Балага байлык-муллык теләү мотив булган ир-ат исемнәре төрлелеге белән аерылып торалар. Моны әлеге төркем ир-ат исемнәренә хас бер үзенчәлек дип әйтергә кирәк, чөнки кыз балага байлык, муллык теләү исемнәре, ир балага караганда азрак чагылыш тапкан.

Бу төркемгә кергән исемнәрне, байлыкның мәгънәви дифференциациясеннән чыгып, ике семантик төркемчәгә бүлеп карарга мөмкин.

1. Нигезендә абстракт мәгънәгә ия байлык теләү чагылган ир-ат исемнәре:

– *бай* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Байбулсын* (т.), *Байҗан* (т.-ф.), *Байбул* (т.), *Байбулат* (т.-ф.) һ.б.;

– *дәүләт* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Дәүләтгәрәй* (г.-т),

Дәүләтгали (т.), Дәүләтша (г.-ф.), Дәүләтхан (г.-т.) һ.б.

2. Конкрет мәгънәдәге байлык теләү чагылган ир-ат исемнәре:

– *тай* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Тайморза* (т.-ф.), *Тайхан* (т.), *Тайхуҗа* (т.-ф.) һ.б.;

– *мал* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Малбай* (т.-т.), *Малтабар* (т.) һ.б. Борынгы төрки телдәге *мал* сүзе «терлек» мәгънәсеннән тыш, «байлык» дигәнне дә аңлата. Татар телендә, төрек, үзбәк, азәрбайҗан телләрендә дә *мал* сүзе «байлык, мал-мөлкәт»

мәгънәсендә кулланыла. Әйтергә кирәк, төрки халыкларда байлык мал-туар, кош-корт, терлек саны белән билгеләнгәнгә, балага байлык теләү мотивы *мал, тай* кебек компонентлар нигезендә ясалаган ир-ат исемнәрендә чагылыш тапкан.

### ***Кыюлык, батырлык теләү төп мотив булган исемнәр***

Татар антропонимик системасында хайван, кош-корт исемнәрен белдергән сүзләр нигезендә ясалган исемнәр балага кыюлык, батырлык теләү мотивын билгелиләр. Төрки халыкларның тотем хайван яисә кош исеме нигезендә ясалган ир-ат исемнәре тотемистик исемнәр рәтендә каралды. Түбәндәге антропокомпонентлар нигезендә ясалган исемнәрнең нигезендә ир балага көч, батырлык теләү мотивлары ята:

– *арслан* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Арсланбай, Арсланхан, Арслангали* һ.б. Төрки халыкларда арысланны көч-куәт, гайрәт һәм затлылык символы дип санау бик борынгы заманнарга барып тоташа. Татарларга шул ук мәгънәдәге *Газанфар* (г.) «арыслан», *Ләис* (г.) «арыслан», *Хәйдәр* (г.) «арыслан», *Әсәд* (г.) «арыслан» кебек гарәби чыгышлы, *Шир* «арыслан» фарсы чыгышлы исемнәр дә килеп кергән;

– *шир* (ф.) антропоформантлы ир-ат исемнәре: *Алишер* «гали+ арыслан», *Ширали* «арыслан +гали» һ.б.;

– *хәйдәр* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Хәйдәргали* «арыслан+гали», *Хәйдәрхан* «арыслан+хан», *Хәйдәрҗан* «арыслан+ җан» һ.б.;

– *лачын* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Лачын, Лачынбарс* һ.б.;

– *аю* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Аюхан, Аюбай* һ.б.;

– *буга* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Бугаарслан, Бугруслан* һ.б. Борынгы төрки телдә böğâ «герой, батыр, көчле» дигәнне аңлата [ДТС, 1969: 116].

Бу исемнәрдә, бер яктан, ата-ананың баланы теге яисә бу хайван, кош кебек батыр, кыю булуын теләү чагыла, икенче яктан, татар халкының элек-электән килгән аучылык мәсләгенә һәвәс халык икәнлеген исбатлый. Бу төр ир-ат исемнәре төрки халыклардан төрекләрдә (*Buğra* «ата дөя», *Ertuğrul* «ир+лачын») [Эрол, 1999: 29], казакъларда (*Аюхан* «аю+хан», *Киикбай* «киек+бай», *Буркитбай* «бөркет+бай» [Кульдеева, 2000: 90], башкортларда *Бөркөт* «бөркет», *Кушкар – Кускар* «кучкар») [Шайхулов, 1983: 17] киң кулланылалар.

*Батыр* антропокомпонентлы ир-ат исемнәре балага батырлык, кыюлык теләкләрен чагылдыралар: *Батырхан, Батыргали, Батыргәрәй, Тимербатыр, Илбатыр* һ.б.;

– *мәрдан* (ф.) «батыр ир егетләрдән» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Мәрдән, Мәрдәнша, Мәрдәнҗан* һ.б.;

– *мәрди* (ф.) «батырлык, кыюлык; ирлек» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Мәрди* (ф.), *Мәрдихан* (ф.-т.), *Мәрдиша* (ф.) һ.б.

Түбәндәге гарәби чыгышлы ир-ат исемнәренең нигезендә «көч, куәт» мәгънәсе ята: *Габделҗаббар* «көч, куәт, кодрәт колы; көч-куәткә ия булучы»; *Зөфәр* «җиңүгә ирешүче, үз дигәнен эшли торган, теләгенә ирешүче»; *Кави* «көчле, куәтле»; *Кадыйр* «көчле, бөек көчкә ия булучы; булдыра алучы»; *Мансур* «җиңүче, җиңүен бәйрәм итүче»; *Мозаффар* «җиңүче, өстенлеккә теләгенә ирешүче»; *Сабит* «курку белмәс, батыр»; *Миргазиз* «көч-куәткә ия булучы».

### Бала билгеле бер һөнәр-кәсеп иясе булсын иде, дигән теләк мотив булган татар исемнәре

Кешенең мәсләген, гаиләнең аерым бер социаль катлавын билгеләүче, шулай ук, бала билгеле бер һөнәр-кәсеп иясе булсын иде дигән теләк мотив булган апеллятив атамалардан ясалган исемнәрне семантик яктан ике төркемчәгә бүлеп карадык:

1. Нигезендә төрле һөнәр һәм мәсләк белдерүче сүзләр ятучы ир-ат исемнәре: *Газыйф* «музыкант, башкаручы»; *Рәсим* «рәсем ясаучы»; *Талиб* «укучы, шәкерт, студент»; *Харис* «игенче, сабанчы»; *Вассиф* «врач»; *Гаттар* «хушбуй ясаучы, сатучы»; *Сәях* «сәяхәтче, дөнья гизүче, турист»; *Тәрҗеман* «тәрҗемәче, тылмач».

Татар антропонимиясендә һөнәр һәм мәсләк апеллятив лексикасыннан ясалган ир-ат исемнәре хатын-кыз исемнәре белән бердәй дәрәҗәдә урын ала. Ләкин аларның һәрберсенә хас эш төрләре бар. Мәсәлән, хатын-кызлар өчен дәвалаучы, эрләүче кебек эш-һөнәр төрләре, ә ир-ат өчен сәүдәгәр, хәрби хезмәткәр, сакчы, укчы, балта остасы, сунарчы кебек эш-кәсеп төрләре хас [Саттаров, 1990: 203]. Башка төрки телләрдән «төрек исем гыйлеме мәсләккә бәйле үрнәкләргә бай» [Рашоньи, 1953: 13]. Мәсәлән, *Кятиб* «секретарь», *Мохтар* «авыл старостасы», *Мөбашир* «төрмәдә ярдәмче эшләрен башкаручы хезмәткәр», *Мебус* «депутат» кебек ир-ат исемнәрен мисалга китерергә мөмкин. Һөнәр атамалары фамилияләр составында чагылыш тапкан. Мәсәлән, *Боланчин* (боланчы], *Бакырчин* (бакырчы), *Урманчеев*

(урманчы), *Уракчеев* (уракчы), *Сунарчин* (сунарчы) кебек фамилияләрне мисалга китерергә мөмкин [Мәҗитова, 1995: 12].

2. Икенче төркем исемнәргә ир балага билгеле бер дәрәҗә, матди ireклек теләген чагылдырган төрле сословие титулларын белдерүче антропокомпонентлар нигезендә ясалган татар исемнәрен кертергә мөмкин. Аларны үз эчендә берничә төркемгә бүлеп карарга була:

1) хөкүмәт иерархиясен тәшкил итүче антропокомпонентлар:

– *солтан* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Солтанбай, Солтангази, Солтангали* һ.б.;

– *хан* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Ханзафар, Ханморат, Ханзаман* һ.б.;

– *мирза* (ф.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Мирзавәли, Мирзагали, Мирзанур* һ.б.;

– *морза* (ф.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Морзабәк, Морзабулат, Морзагаян* һ.б.;

– *шәех* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Шәехбулат, Шәехтимер, Шәехгали* һ.б.;

– *әмир* (г.) антрпокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Әмирхан, Әмирҗан, Әмирсани* һ.б.;

– *мир* (ф.) антропоформантлы ир-ат исемнәре: *Мирсафа, Миртимер, Мирхатип* һ.б.;

– *сәед* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Сәетхан, Сәетгали, Сәетрәхим* һ.б.;

– *шан* (ф.) антропоформантлы ир-ат исемнәре: *Шаһбаз, Шаһгәрәй* һ.б.;

– *задә* (ф.) антропоформантлы ир-ат исемнәре: *Шәйхезадә, Әхмәтзадә* һ.б.;

2) хөкүмәт хезмәтен башкаручылар исемнәрен тәшкил итүче антропокомпонентлар:

– *тархан* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Тархан, Тарханбәк, Тархангол* һ.б.;

– *би* (т.) антропоформантлы ир-ат исемнәре: *Биарслан, Бигиш, Бикол* һ.б.;

3) дин әһелләренең титулатурасы нигезендә ясалган ир-ат исемнәре:

– *ахун* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Ахун, Ахунбай, Ахунҗан* һ.б.;

– *ишан* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Ишанбай, Ишангали, Ишангәрәй* һ.б.;

– *мулла* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Муллахан, Муллаәхмәт, Мулланур* һ.б.;

– *хаҗи* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Хаҗивәли, Хаҗигали, Хаҗинур* һ.б.;

– *шәриф* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Шәрифгали, Шәрифулла, Шәрифзадә* һ.б.;

4) хәрби хезмәт башкаручы исемнәрен аңлаткан ир-ат антропоформантлары:

– *әскәр* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Галиәскәр, Динәскәр, Әскәрҗан* һ.б.;

– *солдат* (р.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Солдатбай, Солдатҗан, Солдатулла* һ.б.;

– *мәргән* (т.) «аучы, төз атучы; снайпер» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Җизмәргән, Мәргәншаһ* һ.б.

«Төрки халыкларда сословие титуллары шәхес исемен ачыклау, конкретлаштыру функциясен (ягъни фамилия функциясен) генә башкармаганнар, бәлки байтак кына бер тамырлы яки кушма төзелешле кеше исемнәрен ясауда да катнашканнар» [Саттаров, 1990: 250]. Болгар-татарларда исем+титул моделендәге катлаулы исемнәр халыкның өстен хокуклы (привилегияле), бай тормышлы катлауларында барлыкка килүен төрле тарихи чыганаклар раслый. Болгар-татар байлары әлеге титуллар ярдәмендә үзләрен халыкның ярлырак өлешеннән аерып куярга теләгәннәр. Бу, шулай ук, аларга үзләреннән соң байлыкларын балаларына һәм оныкларына тапшыру өчен дә кирәк булган. Алынма титулларның ир-ат исемнәренә өстәлүе халык саны арту, болгарларның башка халыклар белән элемтәләре киңәю, үзләре арасында аралашуда антропонимик берәмлекләрнең яңа формалары барлыкка килүенә китергән. *Мир, шан, задә* антропоформантлары ир-ат исемнәре составында гына кулланылып, мөстәкыйль булып килүдән читтә торалар. Калган титулатуралар, кушма антропонимнар составыннан тыш, аерым антропонимик берәмлек буларак та кулланыла алалар. Мәсәлән, *Морза-Шәйморза, Мирза-Мирзаәхмәт* кебек ир-ат исемнәрен мисалга китерергә мөмкин. *Хан, мулла, тархан* һ.б антропокомпонентлар аерым ир-ат исемнәре булып килмәсәләр дә, төрле катлау вәкилләре фамилияләрендә чагылыш тапканнар. Мәсәлән, *Каганов* (каган), *Ханов* (хан), *Морзаев*, *Мирзаев* (морза, мир-

за), *Тарханов* (тархан), *Муллин, Муллаев* (мулла) кебек фамилияләр бүгенге көндә дә кулланыла.

### *Баланың белемле, укымышлы булуы төп мотив булган исемнәр*

Татар халкында укымышлы, белемле кешегә карата зур ихтирам, хөрмәт – мәкаль һәм әйтемнәрдә, фразеологик берәмлекләрдә, шулай ук, бала укымышлы, белемле булсын иде, дигән теләк татар исемнәрендә чагыла. Татар антропонимиконында баланың укымышлы, галим булуын теләү мотивы чагылган исемнәр барысы да гарәби чыгышлы:

– *галим* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Галимулла* (г.) «галим+мулла», *Галимхан* (г.-т.) «галим+хан», *Галимҗан* (г.-ф.) «галим+җан», *Галимә, Галимәбану* «галим+бану» һ.б.;

– *гыйлем* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Гыйлемхан* (г.-т.) «гыйлемле хан», *Гыйлемдар* (г.-ф.) «гыйлемле», *Гыйлемша* (г.-ф.) «гыйлемле шаһ» һ.б.;

– *фәһим* (г.) «зиһен, аң, зирәклек» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Фәһим* (г.) «аңлы, зирәк», *Фәһиметдин* (г.) «диннең аңлысы, зирәге», *Фәһимҗан* (г.-ф.) «зирәк, аңлы җан», *Фәһимә* һ.б.;

– *галләм* (г.) «укымышлы, бөтенесен белүче, бөек белгеч, галим» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Галләметдин* (г.) «диннең зур галиме», *Галләмхан* (г.-т.) «галләм+хан», *Галләмша* (г.-ф.) «галләм+шаһ» һ.б.;

– *гариф* (г.) «белүче, танучы, хәбәрдар; укымышлы; акыл иясе» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Гарифхан* (г.-т.) «белүче, укымышлы хан», *Гарифулла* (г.) «Аллаһының укымышлысы», *Гарифҗан* (г-ф.) «белүче, укымышлы җан» һ.б.;

– *фазыл* (г.) «белемле, укымышлы, талант иясе. Галим титулы» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Фазылхан* (г.-т.) «белемле хан», *Фазылҗан* (г.-ф.) «укымышлы җан», *Фазылъяр* (г.-ф.) «укымышлы дус» һ.б.;

– *фән* (г.) «гыйлем, белем, фән» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Фәннур* (г.) «фән нуры», *Фәнният* (г.) «фән ихтыяҗы, фән бүләге», *Фәнзирәк* (г.) «фәнгә, белемгә зирәк» һ.б.;

– *хәким* (т.) «акыл, белем, фикер иясе; хәким «антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Хәкимулла* (г.) «Аллаһ биргән акыл, белем иясе», *Хәкимша* (г.- ф.)»хәким+шаһ», *Хәкимьяр* (г.-ф.) «акыллы, белемле дус» һ.б.;

– *хикмәт* (г.) «хикмәт, белем» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Хикмәт* (г.) «белем», *Хикмәтулла* (г.) «Аллаһының белемлесе» һ.б.;

– *зәки* (г.) «зирәк, үткен, сәләтле» антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Зәкиетдин* (г.) «диннең сәләтле кешесе», *Зәкиҗан* (г.-ф.) «зирәк җан», *Зәкихан* (г.-т.) «зирәк, сәләтле хан» һ.б.

Татар антропонимиконында фарсы чыгышлы *Зирәк* «үткен, акыллы, зирәк» ир-ат исеме дә бу төркемгә карый.

### *Балага озын гомер теләү төп мотив булган татар исемнәре*

Балага озын гомер теләү төп мотив булган исемнәрне ике төркемчәгә бүлеп карадык:

1. Явыз көчләрдән саклап, баланың гомерен озайту нияте белән кушылган исемнәр.

2. Ир балага озын гомер теләү исемнәре. «Тамыры белән борынгы чорларга караган саклау исемнәре» [Акалын, 1998: 13] сүзнең магик көченә ышанып, баланы саклап калу өчен, усал көчләрне куркытып качыру нияте белән кушылганнар [Саттаров, 1990: 90]. Г.Ф. Саттаров *ачи, сарымсак, атсыз, өркү, курку, яман* һ.б компонентлы ир-ат исемнәрен саклау исемнәренә кертә [Саттаров, 1990: 90]. Бу төр исемнәр хәзерге вакытта кулланышта юк, бары тик фамилияләр составында гына сакланганнар.

Саклау исемнәре, төрки халыклардан тыш, башка халыклар антропонимиясендә дә чагылыш тапкан. Мәсәлән, рус халкында исем кешенең икенче «мине» дип кабул ителгән. Борынгылар, исем начар уйлар белән әйтелсә, аның хуҗасы үлә яисә авыруга сабыша, дип уйлаганнар. Шуңа күрә кешенең чын исемен яшергәннәр, аның урынына явыз көчләрне куркыту өчен «ялган исемнәр» уйлап тапканнар. Очсызлы, кешене кызыктырмый торган предмет атамалары (Горшок, Ложка) белән бергә начар семантик мәгънәгә ия сүзләрне (Пьяный, Дурень, Выроd, Неудача, Безум) чын исем урынына кулланганнар. «Балалар бик күп үлгәнгә, борынгы славяннарда явыз көчләр яңа туган баланы сагалап йөри дигән ышану да яшәгән. Шуңа күрә ямьсез эчтәлекле исемнәр кушканнар» [Суперанская, 2005: 21]. Балаларның үлемен туктатуга бәйле кушылган исемнәр казакъларда, төрекмәннәрдә, төрекләрдә, кыргызларда да бар [Жанузаков, 1971: 100]. Төрки халыкларда, балаларның үлемен туктату максатыннан, күзгә ташлан-

ган предмет атамаларын исем итеп кушу ырым-йоласы яшәп килгән [Шәйхулов, 2006: 46]. Моннан тыш, татар һәм башкорт антропонимикасында, Т.Х. Кусимова, А. Шәйхулов тарафыннан билгеләнгән *Этбай, Эталмас, Этул, Эткол* кебек ир-ат исемнәре эт белән бәйле йолага нигезләнеп бирелгәннәр [Шәйхулов, 2006: 15; Кусимова, 1975]. Борынгылар бала тугач, аны эт каршына китергәннәр, әгәр баланы эт, иснәп, китеп барса, явыз көчләр дә бу балага тимәс дип уйлаганнар. Әлеге йолага нисбәтле *эт* компонентлы ир-ат исемнәре барлыкка килгән. Бүгенге башкорт антропонимиконында «иш» компонентлы ир-ат исемнәрен саклау исемнәренә кертеп карыйлар, чөнки гаиләләрдә беренче бала үле туса, икенче балага *Ишбулат, Ишдәүләт, Ишмөхәммәт* кебек исемнәр кушу гадәте күзәтелүе мәгълүм [ОП, 2006 21]. Саклау исемнәре, бер яктан, явыз көчләрне куркыту нияте белән кушылсалар, икенче яктан, табигатьтәге җанлы яисә җансыз предметларның үзенчәлекләрен балага юнәлдерү нияте белән дә биреләләр. Бу төркемгә түбәндәге ир-ат исемнәрен кертеп карыйбыз:

– *тимер* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Тимербай* (т.), *Минтимер* (т.), *Тимербулат* (т.-ф.) һ.б.;

– *булат* (ф.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Булат* (ф.), *Тимербулат* (т.-ф.), *Ханбулат* (т.-ф.), *Айбулат* (т.-ф.) һ.б.;

– *таш* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Ташмөхәммәт* (т.-г.), *Ташбай* (т.), *Акташ* (т.), *Бикташ* (т.), *Ташлыяр* (т.-ф.) һ.б. Ташка, тимергә, булатка хас ныклык үзенчәлеге балага да күчә дигән фикер яшәгән, шуңа күрә бу антропокомпонентлар нигезендә сүзнең магик көченә ышану ята. Икенче төркемчәгә бала озын гомерле булсын, дигән теләк-мотивы белән билгеләнгән ир-ат исемнәрен кертеп карарга мөмкин Әлеге төркем исемнәре «озын гомер» мәгънәсендә килүче абстракт мәгънәле сүзләр (*озак, үлмәс* һ.б) һәм конкрет сан белән белдерелгән компонентлар нигезендә ясалганнар. «Озын гомер» мәгънәсен белдерүче абстракт мәгънәле ир-ат исемнәренә түбәндәгеләр керә:

– *озак* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Байозак, Жанузак, Гомерозак* һ.б.;

– *үлмәс* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Үлмәс, Үлмәсбай, Үлмәсбәй* һ.б.

Нигезендә конкрет саннар чагылган ир-ат исемнәре түбәндәге антропокомпонентлар нигезендә ясалганнар:

– *сиксән* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Сиксәнбай, Сиксәнбәк* һ.б.;

– *туксан* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Туксанбай, Туксанбәк, Таксанбәк* һ.б.;

– *йөз* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Йөзтяшәр, Йөзмөхәммәт, Йөзмәмәт* һ.б.;

– *мең* (т.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәре: *Меңьяшәр, Меңҗитәр* һ.б.

Озын гомер теләү төп мотив булган гарәби чыгышлы ир-ат исемнәре тулы бер семантик оя тәшкил итәләр. *Һәзар* («мең»), *Әлфик* («мең яшәр»), *Гомәр* («гомерле, гомер, яшәүчән»), *Бакый* («мәңгелек, мәңге яшәүче»), *Халит* (мәңге яшәр, үлемсез, даими») һ.б. ир-ат исемнәре, статистик мәгълүматларга караганда, бүген дә актив кулланылалар.

***Баланың ата-анасына таяныч, ярдәмче булуын теләү төп мотив булган татар исемнәре***

Татар антропонимиконында асылларында ир баланың әти-әнисенең таяныч, ярдәмче булуын теләү мотивы яткан кеше исемнәре шул теләкне белдерүче антропоформантлар ярдәмендә ясалганнар. Бу төр исемнәр ир-ат исемнәренең үзенчәлеге булып торалар. Ир бала нигезгә хуҗа булып калучы, нәселне дәвам иттерүче булганга, ата-ана ир балага зур өметләр баглый. «Иске татар телендә мондый лексик-грамматик чаралар булып *йорт, багыш, карамыш, элем, терсәк, терәк, таган* кебек лингвистик берәмлекләр хезмәт итәләр [Саттаров, 1990: 136]. Әлеге антропоформантлар ярдәмендә ясалган ир-ат исемнәре бүгенге көндә кулланылмыйлар. Гарәби чыгышлы ир-ат исемнәреннән *Ансар* «zрдәм итүче, булышчы», *Габдерәуф* «миһербанлы, ярдәмчел», *Фидаил* «яхшы сыйфатлы, ярдәмче», *Мөгыйн* «ярдәмләшүче, ярдәм итүче», *Рәфит* «ярдәм итүче, булышчы» мәгънәсенә ия исемнәр әлеге төркем эчендә карала. Димәк, дезидератив татар ир-ат исемнәрендә ата-аналарның, туганнарның балага булган изге теләкләре чагылыш таба. Ир балага байлык, батырлык, кыюлык, терәк-таяныч, акыл иясе булу семантикасы хас булган исемнәрне кушу дезидератив ир-ат исемнәренең үзенчәлеген билгели.

## § 15. Меморатив (багышлау) татар исемнәре

Билгеле бер идеянең, ышануларга бәйле күренешләрнең кеше исемендә чагылышы, аларның үзара бәйләнеше меморатив (багышлау) антропонимнарны тәшкил итә. Әлеге төркемдә төрле дини ышануларга, космогоник күзаллауларга, табигать чагылышларына, сүзнең ма-

гик көченә, ышану-йолаларга, легенда-риваятьләргә, анимистик һәм тотемистик ышануларга бәйле исемнәр карала [Шайхулов, 1983: 98]. Г.Ф. Саттаров мемратив (багышлау) исемнәрне нинди дә булса уңай, яхшы һәм югары сыйфатка, идеалга, зәвыкка ия булган мифологик, фольклор, әдәби әсәр геройлары һәм тарихи шәхесләр белән бәйле мотив балага исем кушканда төп сәбәпче булган исемнәр дип билгели [Саттаров, 1990: 145].

Мемратив (багышлау) исемнәрне, төркемчәләргә бүленешендә В.А. Никонов классификациясенә нигезләнеп, өч төркемгә бүләргә мөмкин:

1) тотем исемнәр;

2) теофор исемнәр;

3) билгеле бер затка багышланган ир-ат исемнәре.

Татар антропонимиконында югарыдагыларның барысы да чагылыш тапкан.

## *Тотем исемнәр*

Тотем исемнәрнең килеп чыгышы борынгы күзаллауларга барып тоташа. Борынгы кешенең табигать алдында көчсезлеге тотем итеп алынган предметны, җанварны, кош-кортны табыну объекты итә, аларны табу итеп яисә кеше исеме итеп куллану ихтыяҗы туа, тора-бара җанвар, кош-корт атамалары нигезендә ясалган исемнәр ир-атның батырлыгын, кыюлыгын гәүдәләндерүгә хезмәт итә башлыйлар. Хайван культы бик борынгы заманнарда, борынгы кеше әле үзен табигатьтән аерып карамаган, аңа каршы куя алмаган, бар ыруг-кабилә һәм кеше хайваннар белән тиңләштерелгән чорларда барлыкка килгән. Борынгы кеше тирә-юньне үзенә бик якын һәм аңлаешлы ыруг-кабилә мөнәсәбәтләре аша танып белгән һәм аны табигатькә, шул исәптән хайваннар дөньясына күчергән [Дәүләтшин, 1999: 64]. Кешене аерып атау өчен хезмәт иткән исемнәрне дә хайван атамаларыннан алып кушканнар. Бу үзенә күрә билгеле бер хайван белән тиңләшү, аның көчен кешегә күчерү булып саналган. Җанвар һәм кош-корт культы төрки династияләрнең, нәселләрнең геральдик билгеләрендә, фольклор материалларында, антропонимиясендә, халык медицинасында, табуларда сакланган. Тотем хайван исемен яңа туган балага кушу – борынгыдан килгән гадәт. Шуның белән балага тотем көчен бирергә теләгәннәр, аның баланы яклаячагына ышаныч белдергәннәр. Чыгышы белән тотем җанварга бәйле ир-ат исемнәрен балага кушу бары

тик аксөякләр катламына хас булган, ыру тарихын, бабаларын белү җәмгыятьтә сыйнфый баскычлардан үрмәләү өчен һәм үзенең югары сыйнфый баскычта торуын нигезләү өчен кирәк булган. Мондый төр ир-ат исемнәре аеруча төрки ханнарның исемнәрендә очрый: *Арслан, Бури хан, Ил-Арслан, Ирбие, Ышбара. Бури-шад, Поши хан, Болан каган* һ.б. [Дәүләтшин, 1999: 402].

Гомумтөрки бүре культына бәйле кеше исемнәре затлы нәселдән булуны күрсәткән. *Бури хан, Бури шад* кебек ир-ат исемнәренең нигезендә гомумтөрки *bori* «бүре» сүзе ята. *Бүре* сүзенең угыз формасы *курт-корт* аерым тарихи чыганакларда Азов болгарларының атаклы хәкиме *Кубрат* исеме урынында да килә. М. Зәкиев *Кубрат* исеменең этимологиясен Кубар+ат: кубар «очып китәргә тора торган», «ат», «очар ат» кебек сүзләргә бәйле карый [Зәкиев, 1977: 58]. Бу фикер белән тулысынча килешәбез. Шулай ук күчмә, мал асраучы кабиләләрдә, бүре культы белән беррәттән, этне дә изгеләштергәннәр. Ул кайбер генеалогик риваятьләрдә кабилә башлангычы дәрәҗәсенә күтәрелгән. Эт күп кенә кыпчак кабиләләренең тотемы булган. Кыпчак аксөякләре үзләренең эт белән бәйләнешле генеалогияләре белән горурланып, балаларына эткә бәйләнешле исем кушканнар. Мәсәлән, *Кобәк, Кончак, Әнәк, Көчек, Муйнак, Бойнак* кебек күренекле бәкләрнең исеме эт белән бәйләнешле кушылган.

Борынгы исемнәрдә чагылыш тапкан төрле җанвар атамаларын тотем ир-ат исемнәренннән аерып карарга кирәк, чөнки алар төркиләрнең матди мәдәниятен яктыртучы бер өлкә булып торалар. Әлеге төр исемнәрдә татар халкының утрак көнкүреше, терлекчелек белән шөгыльләнүе чагылыш таба.

## *Теофор исемнәр*

Ислам дине кабул ителгәнче, телебездә мәҗүси ышанулар, йолаларга нисбәтле теофор исемнәрнең кулланылышы шактый очрый, чөнки борынгы төркиләр табигатьтәге кояш, ай, йолдызлар, җир-суны илаһи көчләр дип санаганнар һәм аларга табынганнар. Шуңа нисбәтле, татар антропонимиясендә төрле культларга бәйләнешле исемнәр барлыкка килгән.

Хәзергә кадәр сакланып килгән *ай* (т.) антропокомпонентының да кулланылыш тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Бүгенге антропонимиконда мәҗүсилек чорында ук формалашкан *ай* (т.) антропокомпонентлы исемнәрнең, туры мәгънәсеннән тыш, күчерелмә мәгънәләре

дә бар. Мәсәлән, борынгы төрки телдә *ай* сүзе «сылу, чибәр, матур, асыл; акыллы; нурлы» мәгънәләрен белдергәнгә, ир-ат исемнәрендә *ай* көчәрелмә мәгънәдә дә килә ала: *Айбаксын* «ай кебек матур булсын», *Айбакты* «ай кебек чибәр бала бакты (карады, туды)» һ.б. Ислам диненә бәйле теофор исемнәрнең нигезендә дини атрибутикага мөнәсәбәтле сүзләр ята. Теофор исемнәр түбәндәге антропокомпонентлар нигезендә ясалганнар:

– *ислам* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәренең нигезендә ислам динен зурлау, олылау мотивы ачыла: *Ислам, Исламгали, Исламгир, Исламшәриф, Исламхәй, Нурислам* һ.б.;

– *дин* (г.) антропокомпонентлы ир-ат исемнәренең нигезендә динне зурлау мотивы чагыла: *Динислам, Динәхмәт, Динулла, Кираметдин, Шәйхетдин, Сәйфетдин* һ.б.;

– *алла/улла* (г.) антропоформантлы ир-ат исемнәренең нигезендә Алланы хөрмәт итү мотивы ята: *Аллабирде, Аллакуәт, Аллахуҗа* һ.б., *Сәйфулла* «Аллаһ кылычы», *Гайфулла* «Аллаһының мәрхәмәте», *Кәримулла* «Аллаһының хөрмәтле, юмарт, кадерле кешесе» һ.б. Препозициядә *алла* антропоформанты килсә, постпозициядә *улла* антроформанты билгеләнә;

– *ходай* (ф.) антропоформантлы ир-ат исемнәренең нигезендә Алланы хөрмәт итү мотивы ята: *Ходайбирде* «Аллаһ бирде», *Ходайназар* «ходай мәрхәмәте», *Ходайгол* «Аллаһ колы» һ.б.

Коръәндә һәм хәдисләрдә Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларын чагылдырган 99 исем дә ир-ат исеме: *Рахман* (г.) «рәхимле, шәфкатьле», *Рәхим* (г.) «мәрхәмәтле, рәхим-шәфкатьле», *Котдус* (г.) «бик изге, бик кадерле», *Сәлам* (г.) «коткаручы, араландыручы», *Газиз* (г.) «ныгытучы», *Җәббар* (г.) «зур көч-куәт иясе», *Гаффар* (г.) «кичерүче, гафу итүче», *Бари* (г.) «бар кылучы, яратучы», *Халик* (г.) «яратучы, баркылучы», *Кави* (г.) «көчле, куәтле, киң кодрәтле, һәрнәрсәгә көче җитүче», *Гадел* (г.) «тугры, тугрылыклы», *Гафур* (г.) «үтә мәрхәмәтле, гафу итүче», *Хәмид* (г.) «мактаулы, мактауга лаеклы, данлы», *Каюм* (г.) «мәңге яшәр; бер дә үзгәрмәүчән» һ.б.

Пәйгамбәрләр исемен чагылдырган ир-ат исемнәре: *Мөхәммәт, Муса, Ибраһим, Гайсә, Сөләйман* һ.б; Мөхәммәд пәйгамбәрнең эпитетлары: *Мостафа* (г.) «сайлап алынган, иң саф, башкалардан өстен», *Камил* (г.) «тулы, бөтен яктан мөкәммәл» һ.б; Мөхәммәд пәйгамбәрнең якын туганнары белән бәйле ир-ат исемнәре*: Габдулла* – Мөхәммәд пәйгамбәрнең әтисе; *Габбас, Хәмзә* – абыйлары, *Хәсән, Хөсәен* – кызы

Фатыйма белән ике туган энесе Галидән туган оныклары. Статистик мәгълүматларга караганда, соңгы елларда (2000– 2014) теофор исемнәр артуга таба бара. Антропонимик системада яңадан популярлаша башлаган теофор ир-ат исемнәреннән *Ибраһим* (бор. яһ.-г.) «гарәпләрнең һәм яһүдләрнең уртак бабалары *Авраам* (Абрахам) «халыклар атасы» исеме», *Динислам* (г.-г) «дин+ислам», *Ислам* (г.) «ышану», *Ильяс* (бор. яһ.-г.) «Аллаһ куәте, могҗизасы», *Кәрим* (г.) «юмарт, рәхимле, киң күңелле» һ.б. исемнәрне күрсәтеп китәргә мөмкин.

### *Билгеле бер объект яки субъектка багышланган исемнәр*

XIX–XX гасырларда татарларда исем бирүдә билгеле бер кагыйдәләр була. Беренчедән, яңа туган балага әти-әнисенең һәм дүрт буынга кадәр туганнарының исемнәрен бирү тыела. Руслардагы ир балага атасының исемен бирү традициясе татарларда киң таралмаган. Әмма бер төрле детерминантларның берничә буын исемнәре составында кулланылуы еш очрый. Шулай ук бу кагыйдәләр буенча, татарларда вафат булган абый яки апаларының исемен бирү рөхсәт ителә. А. Гафуров исә ата-ана исемен балаларга кушу үткән буынны олылау гына түгел, ә җанның үлемсезлегенә дә ишарә ясауга тиң дип күрсәтә: «вера в то, что с именем предка в ребенка входит его дух, основывается на представлении об имени как о душе человека, которая раз покинув тело умершего, будет потом вселяться второго или иного потомка через имя. Отсюда и все тревоги о продолжении рода и отношении к бездетности как к самому большому несчастью, ибо тогда некому будет передать имя» [Гафуров, 1964: 284]. Төрекләрдә, мәсәлән, кайбер гаиләләрдә яшь буынга дөнья белән хушлашкан ата-бабаның исемнәрен истәлек итеп калдыру гадәте дә яшәп килә. Татарлар арасында да ата-бабасының исемен яңа туган ир балага бирү очраклары бар. Икенче төргә күренекле затларга багышланган исемнәрне кертеп карарга мөмкин. Билгеле бер шәхескә төбәп аталуы бу исемнәрнең төп үзенчәлеген тәшкил итә. 20 нче елларда В.И. Ленинның истәлегенә бәйле ир-ат исемнәре күп санда барлыкка килә [Суслова, 1991: 65]. *Вил* (р.) «Владимир Ильич Ленин», *Вилнур* (р.) «В.И. Ленин нуры», *Ленар* (р.) «ленинская армия», *Владлен* (р.) «Владимир Ленин» кебек ир-ат исемнәрен мисалга китерергә мөмкин. Шулай ук сәясәттә танылган шәхесләргә багышланган *Маркс* (К. Маркска багышланган), *Энгельс* (Ф. Энгельска багышланган), *Эльма (Энгельс,*

*Ленин, Маркс* исемнәреннән), *Марлен (Маркс, Ленин* исемнәреннән), *Кубрат* (Бөек Болгар дәүләте ханы (VII гасыр) исемен күрсәтергә мөмкин. Татар җирлеге белән бәйле милли күренекле затларга багышлау ир-ат исемнәреннән *Мулланур* – Мулланур Вахитовтан), *Минтимер* (Минтимер Шәймиевтән), *Илһам (* Илһам Шакировтан) һ.б. күренекле шәхесләргә багышланган ир-ат исемнәрен билгеләргә мөмкин. Теге яисә бу шәхеснең иҗтимагый тормышта танылуы әлеге шәхес исеменең халык арасында күпләп таралуына китерә. Мәсәлән, Г.Р. Галиуллина «90 нчы елларда Казан шәһәрендә Миңтимер һәм Салават исемнәренең активлыгы кинәт кенә артып китүе күзәтелә» дип билгели [Галиуллина, 2000: 39]. Шулай ук 90 нчы елларда бер төркем ир-ат исемнәре сәнгать, әдәбият, сәясәт әһелләренә нисбәтле киң кулланыла башладылар. Мәсәлән: *Хәйдәр* – җырчы Хәйдәр Бигичев исеме белән бәйле булса, *Гаяз* – исеме әдип Гаяз Исхакый белән бәйле исем; *Илдар* – Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзиев исеменә нисбәтле рәвештә активлашып киткән антропоним. *Марат* – француз буржуаз революциясенең юлбашчыларыннан берсе Жан-Поль Марат (1747–1793) хөрмәтенә татарларда 30 нчы еллардан соң киң таралса, *Спартак* – безнең эрага кадәрге беренче гасырда Римда баш күтәргән гладиаторларның легендар җитәкчесенә багышланган ир-ат исеме итеп билгеләнә. Топонимнар, космонимнар, мифонимнар, этнонимнардан ясалган ир-ат исемнәрендә билгеле бер объектка юнәлгәнлек төп үзенчәлек булып тора. XX гасыр башында татар антропонимик системасында ата-аналарның балаларына исем сайлауда иҗади якын килүе шәһәр, таулар атамаларын ир-ат исеменә күчерү тенденциясен көчәйтә. Мәсәлән, *Идел – Идел* елгасына нисбәтле кушылган ир-ат исеме, *Иделман* «Идел кешесе», *Илбакты* – тугач, Иделгә баккан, караган ир бала; *Урал, Казбек, Алтай* – тауларга нисбәтле бирелгән ир-ат исемнәре; *Марсель* – шәһәрләргә нисбәтле кушылган ир-ат исеме, *Эльба* – елгага нисбәтле кушылган ир-ат исеме һ.б. Г.Ф. Саттаров әлеге күренешнең бик борынгыдан ук килүен ассызыклап, кеше исемнәре (антропонимнар) белән географик атамалар (топонимнар) арасында элек-электән үзара күчешү, тыгыз бәйләнеш яшәгәнлеген (*Килдеураз, Әлмәт* һ.б.) билгели [Саттаров, 1990: 215]. Шулай ук татар антропонимиясендә ир-ат исемнәре мифологик образларның исемнәре нигезендә дә барлыкка киләләр. Ялгызлык исемнәрен өйрәнүдә мифик исемнәрне – мифонимнарны кеше исемнәреннән аерып карарга кирәк [Белецкий, 1978: 94]. Мифонимнар ир-ат исемнәрен ясауда

нигез булып торалар. Мәсәлән, бүгенге көндә дә милли җирлектә иҗат ителгән мифоантропонимнар ерак гасырлар белән тоташтыручы «Йосыф вә Зөләйха», «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн» әсәрләренең геройлары исемнәре белән өзлексез яңартылып торалар. Шулай ук, борынгы Грециянең атаклы полководецы Александр Македонскийга мөнәсәбәтле рәвештә Урта гасырлардан ук билгеле *Искәндәр* («ирләрне яклаучы») һәм *Зөлкәрнәй* («куш мөгезле») исемнәре татар антропонимиконында кулланылалар.

Этноантропонимнар төрки халыкларда киң кулланыла торган төркемне тәшкил итәләр. Калмыкларда, монголларда этноним ир-ат исемнәре гаиләдә балаларның үлүен туктату өчен кушылган. Бүгенге көндә исә бу төр ир-ат исемнәре әнә шул традицияләрнең дәвам ителүе нигезендә сакланып калган. Ш.Жапаров билгеләвенчә, кыргызларда, этноантропонимнар – борынгы күренеш, «обычаи и обряды киргизов, связанные с этноантропонимами, имеют многовековую историю и представляют собой многослойную картину. Это объясняется длительностью самой истории народа и происхождением от этнонимов личных имен, а также различиями этнических традициях, историко-культурных влияниях и множеством народных обрядов, связанных с имянаречением» [Жапаров, 1992: 26]. Татар антропонимиконында *Үзбәк, Башкорт, Типтәр, Чуваш, Чирмеш, Яһүд* кебек этнонимик атамалардан ясалган ир-ат исемнәре һәм алар нигезендә барлыкка килгән фамилияләр чагылыш таба.

Тотемизм, фетишизм чорларыннан ук, антропонимик системага үтеп кереп, бүгенге көнгә кадәр багышлау ир-ат исемнәренең үсеше дәвам ителүен исемнәр банкында тупланган ир-ат антропонимнары раслыйлар. Кулланылыш ешлыгына килсәк, тотем ир-ат исемнәре, теофор һәм билгеле бер шәхескә багышланган ир-ат исемнәре төркеменә кергән антропонимнардан күпкә азрак кулланылалар яисә бөтенләй кулланылмыйлар. Мәсәлән, 2000–2014 елларда билгеләнгән *Арслан* исемендә тотемистик мотив югалып, ир балага арыслан кебек кыю, көчле булу теләге генә өстенлек ала.

## § 16. Ассоциатив мотивлар

XX гасыр ахыры XXI гасыр башында исем кушуда, халыкның гореф-гадәтләргә, традицияләргә нигезләнеп барлыкка килгән исем бирү мотивлары белән бергә, экстраоригиналь исемнәр кушу тенденциясе шартларында, кешенең психик эшчәнлеге нәтиҗәсе булган төр-

ле ассоциатив мотивларның да билгеләнүе күзәтелә. Татар антропонимиконында күпчелек ир-ат исемнәре алынма булганга күрә, исемнәрнең беренчел лексик мәгънәләре игътибарга алынмый, нәтиҗәдә, татар антропонимиконында исем бирү мотивларының ассоциатив төрләре барлыкка килә. «Тел күренеше буларак объектив яши торган сүз, үзенең парадигматик вариантлары һәм синтагматик мөмкинлекләре белән бергә, субъектның, ягъни сөйләүченең иҗади-психик эшчәнлеге нәтиҗәсендә, чынбарлыктагы башка объект-системалар белән реаль ассоциатив бәйләнеш хасил итә» [Бәширова, 2006: 100].

Антропонимик берәмлекләрдә тышкы яңгырашның эчке мәгънә барлыкка китерүе, телнең тарихи үсеше процессында исемнең яңа эчтәлек алуы, авазларның фонетик мәгънәләреннән оешкан ассоциатив бәйләнешләрне тәшкил итүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән сөйләм һәм фикерләүнең эчке бәйләнеш-мөнәсәбәтләре кешенең исем бирү мотивларында чагыла.

*Аваз ассоциацияләре.* Аваз ассоциацияләре, эвфония, какафония факторлары исем сайлау процессында аеруча мөһим . Ир-ат исемнәренең авазлар ассоциациясен билгеләүдә исемнең билгеле бер бердәм музыкаль фраза басымы астында әйтелүе, аның ритмикасы, мелодикасы, пластикасы әһәмиятен күп кенә галимнәр таныйлар [Кусимова, 1975; Митрошкина, 1987; Никонов, 1970: 38; Ивашко, 1988; Журавлев, 1974; Леонтьев, 2005; Алефиренко, 2005: 160]. Башка галимнәрнең хезмәтләрендә, исемнең фонетик яңгырашы югары күтәрелешле авазларның түбән күтәрелешле авазлардан өстен булуы, аерым бер сузык авазларның чагылыш табуы ([а], [о], [е], [и]) [Ивашко, 1988: 87], сонор авазлар килү ([м], [л], [р], [н]) [100, 115] кебек үзенчәлекләр исемнең фонетик яңгырашын билгелиләр. Кайбер галимнәр исә тартык [р], [с], [п], [т] авазларының калынлыгы исемгә аһәңлелек өсти дип саныйлар [Угрюмов, 1962: 45]. Эксперименталь психометрик метод ярдәмендә, аерым бер ялгызлык исемне әйтү процессында барлыкка килгән тискәре яки уңай тәэсир калдыру мөмкинлеге рус теле белемендә А.П. Журавлев тарафыннан раслана [Журавлев, 1974: 117]. Әлеге хезмәттә авазларның символик мәгънәләре өйрәнелеп, фонетик мәгънәнең моделе төзелә, сүзнең фонетик мәгънәсен ачыклауда автомат рәвештә анализ программасы эшләнелә.

И.С. Чурсина, кайбер авазларның ир-ат, хатын-кыз исемнәрендә төрлечә ешлыкта кулланылуына карап, «ир-ат», «хатын-кыз» авазларын аерырга кирәклеген күрсәтә [Чурсина, 2002: 143]. А.П. Журавлев

исә «билгеле бер ир-ат исемнәренең хатын-кыз исемнәренә күчүенә дә фонетик яңгырашның тәэсире зур» [Журавлев, 1974: 139], дип билгели. Авазларның аерым бер символик үзенчәлекләренең фәнни теоретик-практик базасы булып фоносимволизм теориясе тора. «Фоносимволизм – непроизвольная, фонетически мотивированная связь между фонемами слова и полагаемыми в основу номинации незвуковым (неакустическим) признаком денотата (мотивом)» [Языкознание, 2000: 166]. Галимнәрдән В.А. Никонов, А.А. Леонтьев, А.П. Журавлев, В.А. Ивашко, В.Д. Бондалетов, Ю.В. Казарин, татар тел белемендә Х.Х. Сәлимов белән Л.Ф. Осипова фоносимволизм турында фәнни яктан тикшерүләр уздырганнар. В.А. Ивашко фоносимволизм теориясе нигезендә кеше исемнәрендәге аерым авазларның символикасын билгеләргә омтыла. И.С. Чурсина инглиз исемнәрендә авазларның билгеле бер мәгънә бирүләрен исбатлап, фоносимволизм теориясен таный һәм бу теориянең исем бирүдә мотив булып торуын билгеләп үтә [Чурсина, 2002: 143].

Бүген фәннәр кисешендә барлыкка килгән яңа фән тармакларында авазларның фоносимволик мәгънәләрен өйрәнү яңа юнәлешләр тууына китерә. Мәсәлән, бүгенге көндә төрле телләр һәм культураларның авазларына фоносимволик характеристика бирү юнәлешендә этнопсихологиянең яңа тармагы үсеш алды [Леонтьев, 2005: 196]. Шулай да кайбер галимнәр бу теорияне әлегә кадәр исбатланмаган һәм ачыкланмаган дип саныйлар. «Думается, что успех этой концепции в изучении ономастического материала будет достигнут тогда, когда удастся, общеязыковые фоносимволические универсалии сочетать с тонким знанием звуковых ассоциаций национальных языков в конкретный период их развития» [Бондалетов, 1986: 72]. Төрки телләр антропонимикасында антропонимнарда авазларның символик мәгънәләрен ачыклау мәсьәләсе берникадәр читтә торса да, соңгы елларда аның белән кызыксыну артты. Мәсәлән, Х.Х. Сәлимов, Л.Ф. Осипова компьютер программасы нигезендә кайбер исемнәрнең фонетик мәгънәләрен исәпләп чыгаралар [Салимов..., 2006: 334]. Мисал өчен, компьютер исәпләүләре *Фазылҗан* исеменең фонетик мәгънәсенең «зур», «авыр», «көчле», «дәһшәтле», «куркыныч» кебек сыйфатларын күрсәтә. *Әбүзәр* «актив», «көчле», «бөек», «батыр» кебек сыйфатларга ия исем буларак билгеләнә. Татар телендә авазларның фоносимволик мәгънәләрен өйрәнүдә беренче адымнар ясала башлады һәм тик әлегә бу өлкә күп төрле эзләнүләр таләп итә. Соңгы елларда чит ил линг-

вистикасында фоносимволизм өлкәсендә авазларның эмоциональ тәэсире турында тикшеренүләр алып барыла. Әлеге теорияне яклаучылар авазларны әйткәндә, төрле эмоциональ рефлексларның барлыкка килүен исбатлыйлар.

*Тартык авазлар.* Татар ир-ат исемнәрендәге [л], [н], [р], [т], [с], [м] кебек еш кулланылучы тартык авазларны аерып чыгардык. Әлеге тартык авазларга фонетик, фоносимволик характеристика биреп китик. [Л] – ярымйомык тел-теш тартыгы. Акустик аспекттан чыгып карaганда, сонор аваз. Ир-ат исемнәрендә кулланылган [л] сонор тартыгы – эмоциональ яктан, күнелгә ятышлы, пассив, ягымлы аваз. Татар антропонимиясендә *Ленар, Рамил, Рәмзил* кебек ир-ат исемнәрендә төрле позициядә кулланыла. Ләкин бу аваз хатын-кыз исемнәренә хас булганга, аның ир-ат исемнәрендә кулланылышы каршылык уята.

[Р] – калтыраулы тел-аңкау тартыгы. Акустик аспекттан караганда, шулай ук сонор тартык. Әлеге сонор тартык фоносимволизмда активлык, агрессивлык кебек эмоциональ төсмерләрне чагылдырып, ир-атларга хас аваз буларак характерлана.

[Н] – ярымйомык, тел-теш тартыгы. Акустик аспекттан караганда, сонор тартык. Бу аваз пассив, төшенкеэмоциональ хис өсти.

[М] – йомык ирен-ирен тартыгы. Акустик яктан, сонор тартык. Рус теле белемендә бу аваз хатын-кыз авазы буларак билгеләнә. «М – знак материнский и женский; образ действия внешнего, страдательного. Он имеет связь с идеей материнства» [Флоренский, 2004: 468].

[Д] – яңгырау тел-теш тартыгы. Рус телендә бу фонема уңай характеристикага ия. Аны «ачык», «матур» аваз итеп билгелиләр.

Ир-ат исемнәрендә еш чагылыш тапкан [с] авазының эмоциональ мәгънәсе – актив, көчле.

*Сузык авазлар*. Таблицадан күренгәнчә, ир-ат исемнәрендә сузык фонемаларның кулланылыш ешлыгын тикшерү түбәндәге нәтиҗәләр бирде: [и] – 21, [а] – 18, [у] – 7, [ә] – 5. Г.Р. Галиуллина XX гасыр исемнәренең статистикасына җентекле анализ ясап, Казан шәһәренең ир-ат исемнәрендә еш кулланылучы фонемалардан [и] (46), [а] (37), [ә] (33) кебек фонемаларны аерып күрсәтә [Галиуллина, 2000: 62]. Димәк, әлеге фонемаларны ир-ат исемнәрендә еш кулланылучы, үзенчәлекле сузык фонемалар дип атарга мөмкин. Психолингвистлар авазларның вокальлеге, югары тональлеге йомшаклылык, назлылык кебек үзенчәлекләр белән ассоциацияләшә дип саныйлар. Нигездә мондый күзаллаулар хатын-кыз исемнәрендә күзәтелә. Сузык фонемалар

хатын-кыз исемнәренең мелодикасын билгели. Күпчелек очракта сузык авазларга тәмамланган хатын-кыз исемнәренең ритмикасы исемнең вокальлегенә йогынты ясый (*Илнар-Илнара, Эльвыр-Эльвира, Эльмир-Эльмира* һ.б.).

Ир-ат исемнәрендә еш кулланылучы сузык һәм тартык фонемаларны билгеләү теге яисә бу авазның исемнәрдә билгеле бер мәгънә аңлатып, исем бирү идеясен чагылдыруда әһәмиятен ассызыкларга мөмкинлек бирә. Үткәрелгән тикшеренүләр исемдә авазларның очраклы гына кулланылмавын күрсәтәләр. Димәк, ир-ат исемнәренең аваз тышчасы исем сайлауда фоносимволик мотив була ала дияргә нигез бар. Исем йөртүчегә карата туган ассоциацияләр исем кушуда билгеле бер мотив барлыкка китерәләр. В.А. Гречко исемнең мәгънәсен кешенең үзенә бәйләп карый: «для круга людей, знающих определенное лицо, смысл имени изменяется по мере изменения самого человека в зависимости от его возраста, деятельности, взаимоотношения с людьми, близости с ними и др. Во всем обнаруживаются особенности характера человека, его качества, способности и пр., что и находит отражение в конкретном содержании антропонима» [Гречко, 2003: 243]. Кешенең кылган гамәлләре, эшләре аның исемен билгели. Исем шәхеснең матрицасы рәвешендә дә кабул ителергә мөмкин. Исем сайлаганда, билгеле бер кеше, аның кылган гамәлләре күзаллана. Мәсәлән, *Адольф* исеме татарлар һәм руслар арасында популярлашып китә алмады, чөнки бу исем Адольф Гитлер белән туган ассоциацияләр бирә. 2000–2014 елларда *Тамерлан-Тимерлан, Чыңгыз, Чыңгызхан* исемнәре тарихта эз калдырган шәхесләр белән ассоциацияләшә. Бу исемнәрне кушуда ассоциатив мотивлар мөһим роль башкаралар. Гаилә эчендә ассоциацияләр исемнең башка гаилә әгъзалары белән рифмалашып килүендә дә барлыкка килә Төрки халыкларда исемнәр рифмалашу мәсьәләсендә күп кенә тикшеренүләр үткәрелгән [Никонов, 1970: 131–141; Саттаров, 1970: 223; Шакуров, 1980: 43–49; Шатинова, 1980: 39–41; Галиуллина, 1999: 49–51; Эрол, 1999: 14]. З.Г. Ураксин исем бирүдә рифмалашуның әһәмиятен билгеләп болай дип яза: «немаловажное значение при выборе имени имеет и созвучность начальных и конечных частей имени ребенка с именем отца, матери, или старших братьев и сестер. Эта древняя традиция сохраняется поныне и является одним из важных моментов при наречении тем или иным именем» [Ураксин, 1973: 183]. А.Г. Митрошкина гаилә әгъзалары белән рифмалашып килүнең вертикаль һәм горизонталь рифмалашу төрләрен

күрсәтә. Төрле буын арасында рифмалашу вертикаль булса, бер буын арасындагы (абый һәм апа, игезәкләр һ.б.) рифмалашуны ул горизонталь рифмалашу дип атый [Митрошкина, 1987].

Аллитерация – пост позициядә яки препозициядә билгеле бер авазның яисә аваз кушылмасының, формант яки компонентның кабатланып килүе. Препозицион аллитерация нигезендә ясалган ир-ат исемнәре: *Айрат-Айиур-Айвар-Айдар- Айбулат, Илшат-Илнар-Илдар, Рамил-Радик* һ.б. Постпозицион аллитерация нигезендә ясалган ир-ат исемнәре: *Илназ- Айназ; Салихжан-Сәетҗан- Шакиржан; Булат-Марат-Айрат* һ.б.

***Исем фәлсәфәсе***. Дөньяга аваз салганнан алып, фани дөнья белән хушлашканчыга кадәр исем кешенен үзе белән бергә йөри торган юлдашы. Балага матур, мәгънәви һәм яңгыраш ягыннан күңелгә ятышлы исем бирү – һәрбер ата-ананың изге бурычы. Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең бер хәдисендә: «Балаларыгызга матур исемнәр бирегез, – дип, әманәт әйтә. – Беренче тапкыр сорау алырга исемнәрегез белән чакырырлар», – ди. Кеше вафатыннан соң, аның исеме һәм исән вакытта кылган гамәлләре генә хәтер учагында кала. Бүгенге телебездәгә «исем кешенең җисемен билгели», «исемен телгә алу», «исеменә тап төшерү», «аты чыккан», «атказанган», (борынгы төрки телдә *ат* сүзе исем мәгънәсендә йөргән) кебек гыйбарәләрдә, әйтемнәрдә исем кешенең үзе белән бер дәрәҗәгә куела, аның тормышта мөһимлеген тагы бер ассызыклый. Азәрбайҗаннарда «исеме матурның үзе матур», төрекләрдә «исеме тугыз тапкыр телгә алынса, соңыннан инде сигезгә төшмәс», үзбәкләрдә «исеме телләрдә дастан булды» («исеме, гамәлләре белән танылды» мәгънәсендә), калмыкларда «исемгә тап төшергәнче үлем яхшырак» һ.б. төрки халыкларның мәкаль һәм әйтемнәрендә, канатлы тәгъбирләрендә исемгә зур мәгънә бирелә.

Галимнәрнең, психологлар, шагыйрьләрнең, язучыларның, философларның һ.б. акыл ияләренең исем турында әйткән фикерләре исемнәрне тудырган халык һәм кеше гамәлләре белән бәйләнештә бирелә. Исем турында күренекле галим-антропонимист Г.Ф. Саттаров: «Тел, сүз, исем-фамилия милләтнең йөзе, тылсымлы могҗизасы һәм сакчысы, һәркемгә үз исеме иң якын, иң кадерле сүз» дип язуы белән, һичшиксез, хаклы [Саттаров, 1990: 5]. Үзбәкләрнең бөек шагыйре Алишер Нәвои әйткәнчә: «Исеме онытылмаган кеше – иң бәхетле кеше». Элек-электән, исем белән бергә, ата исемен дә сорау гадәте ата-бабаларның кылган гамәлләре, нәселең турында күзалларга

мөмкинлек биргән. Галимнәр фикеренә караганда, кеше үзенең берничә буын бабасының исемен хәтерләргә сәләтле. Шуңа күрә ир-ат исеме икенчел яшәешен ата исеме, фамилияләрдә дәвам итеп, киләчәк буыннарга ата-бабалар, нәсел турында мәгълүмат калдыра. Борынгы заманнардан ук исем кешенең «икенче мин»е буларак кабул ителгән. Исемне начар уйлар белән әйтү исем йөртүчене авыруга дучар итәргә яисә үлеменә китерергә дә мөмкин дигән ышану яшәгән. Шуңа да ике исем йөртү киң таралаган, берсе – «табу» исем, икенчесе явыз көчләрдән «саклау исеме» булган. Борынгы төрки халыкларда яңа туган бала янына усал явыз көчләрне, җен-пәриләрне китермәү, аларны куркыту максатыннан чыгып, аңа «начар» мәгънәле исем бирү йоласы яшәгән [Саттаров, 1990: 90]. Монголларда *Унеэн* «начар сыер» [Алдаров, 1976: 104], кыргызларда *Сасык* «сасы» [60, 73] мәгънәсендәге ир-ат исемнәре кулланылышта йөргән. П.А. Флоренский, А.Ф. Лосев кебек күренекле философлар һәм башка галимнәр, тарихчылар исемнең харизматик теориясен раслыйлар. П.А. Флоренский исемнәрне «аваз – сүз – термин – символ – исем» аша күрсәтеп, «исем кешенең алдагы язмышына тәэсир итә һәм характеры турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә» дип саната [Флоренский, 2004: 437], А.Ф. Лосев исемнәрне шәхеснең йөзе буларак ача, «мәгънәви һәм акыл гармониясендә тереклекнең стихиясе итеп билгели» [Лосев, 1990: 270]. Философларның исем турындагы фәлсәфи уйланулары галимнәрнең фәнни-теоретик фикерләрен үстерүдә бүген дә нигез булып торалар. XXI гасыр башында антропонимика өлкәсендә фәнни яктан расланмаган харизматик теорияләр күпсанлы авторлар тарафыннан тәкъдим ителеп, исемнең кеше язмышына тәэсире турында күп санда популистик фикерләр ташкыны агыла башлады. Г. Квита, В. Миронова, Д. Зима, Н. Зима, Б. Хигир, С. Минцалов, Пьер Руже, А. Хигир тарафыннан язылган популяр сүзлекләрдә теге яисә бу исемне йөртүченең характер үзенчәлекләре, киләчәк тормышына фаразлар бирелә. Б.Хигирның фикерләрен дәвам иткән Ася Хигир «Энциклопедия имен» хезмәт исемнәрнең кеше характерын билгеләвен конкрет исемнәр мисалында исбатлый, һәрбер исемнең характер белән гармоник рәвештә туры килүен, исем бирүдә баланың туу вакытын билгеләп кушарга кирәклеген искәртә [Хигер, 1995: 255]. Исем һәм язмыш мәсьәләсе төрки халыкларның антропонимиясендә чагыла. Мәсәлән, исем алыштыру, исемгә *миң* сүзенең өстәлүе борынгы ышану-йолаларга бәйле күп кенә төрки халыклар-

да яшәвен дәвам итә. Татар халкында озак вакытлар авырган кешенең исемен алыштыру савыгу китерә, исемнәргә *миң* сүзенең өстәлүе чирләрдән арыну, уңышка ирешү символы буларак яши. Бүгенге көндә *нар* сүзе кергән исемнәрне кушу киңәш ителми, чөнки *нар* сүзе фарсычадан « ут, ялкын» дип тәрҗемә ителә. *Илнар, Гөлнара, Айнар* кебек исемнәрне йөртүчеләр тормышта күңел тынычлыгы таба алмыйлар дип фаразлыйлар. Халык арасында бу исемнәрне алыштыру күренеше яшәп килә.

Дөньяны уратып алган һәрбер әйбергә – җанлы һәм җансыз предметларга, тирә-юньгә исем-атама бирелгән, һәркайсына бирелгән исем- атама һәм җисеме арасында диалектик бердәмлек яши. Халык «исеме җисеменә туры килсен» – ди. Шуңа күрә халык кеше исемнәре дөньясында мәгънәви матурлыкка омтылуның классик үрнәкләрен тудырган, үзенең идеалларын һәм тарихын чагылдырган исемнәр хәзинәсен барлыкка китергән. Димәк, татар исемнәрен кушуда түбәндәге ассоциатив мотивлар билгеләнде:

1. Аваз ассоциацияләре;

2. Билгеле бер исемне йөртүче белән туган ассоциацияләр;

3. Исемнең язмышка тәэсире белән бәйле карашларга нигезләнгән ассоциатив мотивлар.

Бүгенге көндә ассоциатив мотивлар кешенең иҗади-психик эшчәнлегенә бәйле рәвештә барлыкка килеп, исем кушуда мөһим урын алып торалар. Шулай да исемнең лексик мәгънәсен игътибарга алмыйча, ассоциатив мотивларга гына нигезләнеп балага исем бирү, исем семантикасын «кимчелекле» итә, милли антропонимик берәмлекләргә зыян китерә.

## Кыскача нәтиҗә

1. Татар антропонимикасы номинатив чыганакларының күп аспектлылыгы, исем бирү традицияләренең байлыгы, мотивларының төрлелеге белән характерлана. Исем бирү мотивлары исемнәрнең эчке һәм тышкы формаларында ачылалар. Исемнәренең эчке формасында исемнең билгеле бер традиция-йолаларга нигезләнүе, ата-ананың балага булган изге теләкләре, тарихи шәхесләргә, милли геройларга, сәнгать әһелләренә багышлау кебек билгеләр төп рольне үти. Исемнең яңгырашы, фамилия, ата исеме белән аваздашлыгы, гаилә әгъзалары белән рифмалашып килүе исемнәрнең тышкы формасын тәшкил итә. Исемнәрнең эчке формасы анық яңа эчтәлеген ача, семантикасын

билгели. Исемнәрнең яңа эчтәлегендә лексик-семантик төркемнәрендә ачылалар.

2. Татарларда балага батырлык, кыюлык, ныклык, тазалык, көчлелек, дәүләт-байлык, акыл иясе булуын теләү семантикасы хас булган исемнәр төп үзенчәлек булып торалар. Сословие титуллары, кыргый һәм йорт хайваннары, корал, металл атамалары ир-ат исемнәренең әлеге лексик-семантик төркемнәрендә кулланылалар.

3. XXI гасырда исем кушуда, халыкның гореф-гадәтләргә, традицияләргә нигезләнеп барлыкка килгән исем бирү мотивлары белән бергә, экстраоригиналь исемнәр кушу тенденциясе шартларында, кешенең психик эшчәнлеге нәтиҗәсе булган төрле ассоциатив мотивларның билгеләнүе күзәтелә. Статистик мәгълүматларга караганда, киң кулланылышка ия ир-ат исемнәрендә аерым бер авазлар исемнең яңгырашын, аһәңлелеген билгелиләр.

## Дүртенче бүлек
## ТАТАР ИСЕМНӘРЕНЕҢ МОРФОНОЛОГИЯСЕ

### § 17. Татар исемнәренең структур үзенчәлекләре

Татар антропонимикасын бай һәм киң колачлы исемнәр системасы һәм аларның мәгънәләре тәшкил итәләр. Антропонимик системаның баюы, телдән тыш факторларның көчле булуы белән беррәттән, тел йогынтысы белән дә билгеләнә, монда бигрәк тә сүз ясалышы мөмкинлекләре роль уйный.

Төрки телләрдә сүз ясалышы Э. Севортян, Н. Баскаков, П.Азимов, А. Голямов, А. Базиев, Л. Харитонов, Т. Гарипов, М. Хабичев, С. Джаффаро в тарафыннан, татар телендә К. Насыйри, Г. Алпаров, Ш. Рамазанов, В. Хангильдин, Ф. Фәсиев, Д. Тумашева, Ф. Ганиев тарафыннан өйрәнелгән. 70 елларда Ф.Ә. Ганиев хезмәтләрендә сүз ясалышы татар теле белеменең аерым фәнни тармагы дәрәҗәсендә үсте. Татар антропонимикасында сүз ясалыш мәсьәләләре Г. Саттаров, Р. Субаева, Ф. Ганиев, Х. Исхакова, Г. Галиуллина, М.Әнвәрова һ.б. хезмәтләрендә, мәкаләләрендә чагылыш таба. Хезмәтебездә исем компонентларын антропокомпонент һәм антропоформант терминын кулланып, сүз ясалыш модельләрен билгеләдек, чөнки хезмәтләрдә төрле терминнарга мөрәҗәгать итү күзәтелә. Мәсәлән, галимнәр хезмәтләрендә компонент [Никонов, 1974; Гафуров, 1971; Саттаров, 1976: 65], терәк компонент [Саттаров, 1976: 65], элемент [Баскаков, 1979], детерминант элемент [Баскаков, 1979], аффикс [Никонов, 1974: 109], кушымча [Гафуров, 1964: 75], антрополексема [Галиуллина, 1999: 13] кебек терминнарны кулланалар. Шулай ук исем компонентларын төп һәм төрләндергеч компонентларга аерып карыйлар. Компонентлар мөстәкыйль, ягъни үзләре генә кулланыла ала торганнарга һәм ярдәмлек компонентларга, шулай ук үзләре генә кулланыла алмый торганнарга бүленәләр [ТТАС, 2005: 833]. Монографиябездә антропокомпонент, кушма төзелешле исемнәрнең детерминантивы буларак, кулланыла торган мөстәкыйль оним итеп билгеләнә. Антропокомпонент

исемнәрнең төрле позицион урыннарда очрый торган актив кисәге булып килә. Мәсәлән, гарәби чыгышлы *нур* антропокомпонент ролен үти, чөнки ул постпозициядә дә (*Газинур, Айнур, Алнур* һ.б.), препозициядә дә урын алган (*Нурҗан, Нурислам, Нургали* һ.б .) һәм, шулай ук, мөстәкыйль исем вазифасын да үти. Антропоформант – бары тик онимнарның ауслаутында яисә анлаутында гына очрый торган һәм мөстәкыйль оним булып кулланылмаган компонент: *габд-габде-габди-габдел* (г.), *-улла/-алла* (г.), *-етдин* (г.), *миң* (т.), *наз* (ф.), *ходай* (ф.) һ.б. Апеллятив лексикадан аермалы буларак, татар исемнәре бер һәм ике составлы исемнәргә бүлеп карау кабул ителгән, чөнки беренче компонент төшереп калдырырга ярамый торган компонент булса, икенче компонент ярдәмчел компонент буларак, сөйләмдә төшереп калдырылган. Татар телендә ир-ат исемнәренең ике структур компоненттан торган җыйнак тибы, тотрыклы төп антропонимик модельне тәшкил итеп, халыкчан традицион милли калыпны барлыкка китергән. Бер составлы татар исемнәре түбәндәге структурада очрыйлар:

1) антропокомпонент (АК): *Гәрәй, Бәйрәм, Рамазан, Нур, Баттал, Баян* һ.б.;

2) АК+ кушымча (К) структурасында: *Нурлы, Балаш* һ.б.;

3) антропоформант (АФ)+кушымча: *Назлы, Миңле, Юлдаш* һ.б. Х.Ф. Исхакова фикеренә караганда, ике составлы татар ир-ат исемнәре бары тик янәшә килү («сopoложение») юлы белән ясала, һәм бу ысул нәтиҗәсендә юкстапозит исемнәр барлыкка килә. Юкстапозит тибындагы сүзләр морфемалар составы ягыннан ирекле сүзтезмәләргә якын тора, әмма аларга уртак бербөтен басым һәм компонентларның ирекле булмаган тәртибе хас [Исхакова, 2000: 6]. Түбәндәге ике составлы исемнәр структурасын аерып карадык:

1) АК+АК: *Тимербулат, Рәхимхан, Мөхәммәтхан, Нурмөхәммәт, Хаҗихан* һ.б.;

2) АК+антропоформант (АФ): *Сәйфулла, Рәфигулла, Гыйсметдин, Мирхәбибулла* һ.б.;

3) АФ+АК: *Габделгазиз, Габденур, Габделхак, Миңлетимер, Ишмөхәммәт* һ.б.

Татар антропонимик системасында бер һәм ике составлы исемнәр морфологик, синтаксик, аббревиация кебек сүз ясалыш ысуллары белән ясалганнар.

## § 18. Морфологик ысул белән ясалган татар исемнәренең модельләре

Сүз ясалышының бу ысулы сүз ясалыш типларына яраклы рәвештә кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясаудан гыйбарәт [Татар грамматикасы, 1998: 208]. Татар антропонимнарының зур күпчелеге төрле кушымчалар (башлыча тамыр яки нигез исемгә төрки-татар яки алынма кушымчалар) ялгану юлы белән ясалалар.

### *Төрки-татар кушымчалары нигезендә ясалган татар исемнәре модельләре*

Антропоформант (АФ) + *-лы/-ле* кушымчасы. Хәзерге татар телендә -лы/-ле кушымчасы исемнәр һәм сыйфатлар ясауда катнаша. Күпчелек галимнәр бу кушымчаны *-лык* кушымчасыннан килеп чыккан дип саныйлар. Кушымчаның семантик һәм кулланылыш үзенчәлекләреннән чыгып караганда, бу фикер белән тулысынча килешергә мөмкин. Татар исемнәрендә бу кушымча *миң* антропоформантына кушылып, билгеле бер үзенчәлекне (монда миңне күз алдына китерәбез) күрсәтә. *Миңле* үзе бер антропокомпонент тәшкил итә. *Миңле* антропокомпоненты нигезендә *Миңлегазиз* (т.-г.), *Миңлегаяз* (т.-г.), *Миңлегалим* (т.-г.), *Миңлегалләм* (т.-г.), *Миңлевәли* (т.-г.), *Миңлебулат* (т.-г.) кебек ир-ат исемнәре ясалган. Ир-ат исемнәреннән *-лы* кушымчасының *Чуклы* (т.), *Татлы* (т.), *Юллы* (т.), *Назлы* (ф.-т.) кебек ир-ат исемнәрендә дә кулланылуын билгеләп үтәргә кирәк.

Антропокомпонент яисә АФ + *-даш* кушымчасы. Бу кушымчаның этимологиясе турында берничә төрле караш бар. Бер төркем тикшеренүчеләр *-даш* кушымчасын ике элементтан: *-да* элементыннан (урын-вакыт килеше күрсәткече) һәм *иш* дигән сүздән торуын күрсәтәләр. Икенчеләре *-да* элементы фигыль ясаучы кушымча, *-ш* элементы юнәлеш ясаучы кушымча тәшкил итә, дип саныйлар. Өченче төркем тикшерүчеләр, *-даш* кушымчасын борынгы *даш* (иптәш) дигән сүзгә барып тоташа, дип раслыйлар [Татар грамматикасы, 1998: 53]. Ф.Ә. Ганиев, соңгы фикер логик яктан дөрес һәм аны кабул итәргә кирәк, дип саный [Ганиев, 2000: 54]. Ир-ат исемнәрендә табылган *-даш* кушымчасы өченче төркем тикшерүчеләрнең фикерләрен расларга да мөмкинлек бирә. Мәсәлән, татар антропонимиконында *Юлдаш* исеме теркәлгән. *Юл* (т.)+*даш* (т.) исеме «юлдагы иптәш» мәгънәсенә туры килә.

Антропокомпонент яисә АФ + *-чык/-чек* кушымчасы. Татар телендә *-чык/-чек* кушымчасы, стилистик кушымча булуы белән бергә, сүз ясагыч функциясен дә үти. Ир-ат исемнәрендә бу кушымчада, безнең фикеребезчә, сүз ясагыч функциясе өстенлек итә, «кечкенә, бәләкәй» дигән мәгънәдәге *чак* сүзенә барып тоташа. Мәсәлән, татар антропонимиясендәге *Исәнчек* исеме «кечкенә генә булып исән туган ир бала» мәгънәсен белдерә.

Антропокомпонент яисә АФ + *-ак/-әк* кушымчасы. Бу кушымча ачыктан-ачык кечерәйтү төсмерен белдерә [Татар грамматикасы, 1998: 67]. Аның нигезендә ясалган ир-ат исемнәрендә дә кечерәйтү төсмере бар. Әйтик, кушымча *Бүзәк, Дусак, Кадерәк, Мәрдәк* һ.б. ир-ат исемнәренең бер мәгънәсе турыдан-туры «кечкенә» сүзе белән бәйле дип саныйбыз.

Антропокомпонент яисә АФ + *-кай/-кәй* кушымчасы. Бу кушымча, иркәләү-кечерәйтү төсмерен биргән стилистик кушымча булу белән бергә, сүз ясагыч кушымча буларак та ир-ат исемнәре ясый. Мәсәлән, *Батыркай, Тимеркәй, Ишкәй* кебек ир-ат исемнәрендә *-кай*/*-кәй* сүзьясагыч кушымча вазифасында килгән.

Антропокомпонент яисә АФ + *-тай* кушымчасы. Монгол телендә *-тай* кушымчасы «батырлык иясе, ир-егет» мәгънәсен белдерә. Бу кушымча нигезендә *Чурамантай, Актай, Салтай, Янтай* кебек ир-ат исемнәре ясалганнар. Мишәр диалектында *-тай* аффиксына мөнәсәбәтле берлек санда, беренче затта килгән *тайым* сүзе балаларга, үзеңнән кечеләргә иркәләп эндәшү формасы буларак та кулланыла [Махмутова,1978: 119]. Димәк, *-тай* аффиксының тай сүзе белән турыдан-туры бәйләнешен диалект һәм сөйләшләрдә сакланган *тай* сүзенә нисбәтле итеп карарый алабыз.

### *Алынма кушымчалар ярдәмендә ясалган исемнәр*

Хәзерге татар теленең ир-ат исемнәре системасында алынма кушымчалар ярдәмендә ясалган берәмлекләр шактый. Гарәп-фарсы теленнән кергән *-задә, -дар/-дәр, -ат/-әт, -сар*, рус чыгышлы *-ик* кушымчасы ир-ат исемнәрен ясауда катнашалар. Алынма кушымчалар ярдәмендә ясалган ир-ат исемнәренең түбәндәге модельләрен аерып чыгардык.

Антропокомпонент + *задә* (ф.) кушымчасы. Антропонимик системада аның функциясе титулга бәйле түгел, затны белдереп, күбрәк хатын-кыз исемнәрен ясауда катнаша. Фарсы телендә әлеге морфема

«туган» мәгънәсендә үткән заман сыйфат фигыль формасында килә: *Асылзадә* (г.-ф.) «асыл туган», *Әмирзадә* (ф.-ф.) «әмир туган» һ.б.

Антропокомпонент яисә антропоформант + *-дар/-дәр* (ф.) кушымчасы. Фарсы чыгышлы *-дар/-дәр* кушымчасы фарсы телендә «бар, булу» мәгънәсендә хәзерге заманны белдереп килә [Ганиев, 2000: 84]. Бу кушымча *Айдар* (т.-ф.) «айлы», *Байдар* (т.-ф.) «байлык иясе», *Занидар* (г.-ф.) «изгелек иясе», *Сәйдә*р (г.-ф.) «затлы; асыл; аксөяк», *Гыйлемдар* (г.-ф.) «гыйлемле», *Илдар* (т.-ф.) «илле», *Сердәр* (т.-ф.) «серле» һ.б.ир-ат исемнәрендә чагылыш таба.

Антропокомпонент + *-гир* (ф.) кушымчасы. Бу кушымча фарсы телендә «яулап алу, тотып алу» мәгънәсен белдергән хәзерге заман формасында килә. Татар антропонимикасында *Җиһангир* (ф.) «илне яулап алучы», *Исламгир* (г.-ф.) «ышаныч яулаучы», *Намгир* (ф.) «исем яулаучы» кебек ир-ат исемнәре теркәлгән.

Антропоформант + -*сар* (ф.) кушымчасы. Теге яки бу предметның, әйбернең булуын яки күплеген -*сар* кушымчасы белдерә. Татар теле сөйләшләрендә бу кушымча белән ясалган сүзләр әле дә сакланган. Фарсы телендә *-сар* кушымчасы *-зар* формасында йөри, шулай ук әйбернең күп була торган урынын белдерә [Татар грамматикасы, 1998: 285]. Күбесенчә бу кушымча үсемлекләр дөньясына караган терминнарны ясау өчен хезмәт итә. Ир-ат исемнәрендә дә чагылыш тапкан. *Айсар* (т.-ф.) «айлар», *Байсар* (т.-ф.) «байлар», *Ансар* (г.-ф.) «ярдәмчеләр, яраннар, юлдашлар» кебек ир-ат исемнәрен мисалга китерергә мөмкин.

Антропоформант + *-ат/-әт/-ят* кушымчасы. Гарәби чыгышлы *-ат/-әт* кушымчасы ярдәмендә *Нәүфәт, Рәфгать, Илфират, Гатият, Зилмәт, Мидхәт, Хәйрәт, Әсфәт, Һадият* һ.б. ир-ат исемнәре ясалган.

Антропоформант + *-ик* кушымчасы. Октябрь революциясе үзгәрешләренең татар антропонимиконының кушымчалар системасына тәэсире *-ик* кушымчасының төрки-татар, гарәби, фарсы, рус һәм Көнбатыш Европа алынмаларына ялгануында чагыла. Рус һәм әрмән телләрендә иркәләү-кечерәйтү функциясен үти торган әлеге кушымча [Суперанская, 1969: 133] татар теленең антропонимик системасында соңгы унъеллыкларда активлаша. Бу кушымча нейтраль мәгънәдә дә кулланыла ала. Ир-ат исемнәрен кыскартып әйтү белән бергә, ул уңай семантикага ия бәя бирү төсмерен дә өсти [Суслова, 1991: 114]. Галимә Г.Р. Галиуллина, рус телендә бары тик стилистик функция

башкара торган *-ик* кушымчасы метрик кенәгәләрдә тулы мәгънәле рәсми исем буларак теркәлгән берәмлекләр составында очрый, дип билгели [Галиуллина, 2000: 198]. Бу исемнәргә *Радик, Лерик, Эдик, Эрик, Рәмзик* һ.б.ир-ат исемнәрен кертергә мөмкин.

Антропокомпонент + *-ман* (ф.) кушымчасы. Бу модель нигезендә *Нуриман* (г.-ф.) «нур иясе», *Нариман* (ф.) «көчле, рухлы, кыю, батырлык иясе», *Сайман* (г.-ф.) «яхшылык, чибәрлек, уңганлык иясе», *Сарман* (м.-ф.) «айлы», *Хушман* (ф.) «гүзәллек, күркәмлек, бәхет иясе», *Чураман* (бор.төр.-ф.) «батыр сугышчы», *Шадман* (ф.) «шатлык иясе», *Иделман* (бор. төр.-ф.) «Идел кешесе» һ.б. ир-ат исемнәре ясалган.

Татар антропонимиконында хатын-кыз исемнәрен ир-ат исемнәреннән аеруда хезмәт итүче, шул ук вакытта ир-ат исемнәреннән хатын-кыз исемнәре ясаучы *-а/-ә* кушымчаларын күрсәтеп китәргә кирәк. Нигездә ир-ат исемнәре тартык авазга бетсә, хатын-кыз исемнәренең грамматик күрсәткечләре булып, исем ахырында сузык авазлар килә. Хатын-кыз исемнәренең ир-ат исемнәреннән ясалышы ир-ат һәм хатын-кызның дөньяга яратылуы турындагы Коръән-Библия сюжетларында да чагыла. Кешелекне дөньяга яраткан *Адәм* белән *Һава* исемнәрендә дә җенес категориясенең күрсәткечләрен билгеләргә мөмкин: *Адәм* тартыкка бетсә, *Һава* исеме сузыкка бетә. Бу кушымчалар гарәби-фарсы чыгышлы исемнәргә ялганып, түбәндәге хатын-кыз исемнәрен ясыйлар: *Камил-Камилә, Наил-Наилә, Равил-Равилә, Фаиз-Фаизә* һ.б. Шулай ук, рус һәм Көнбатыш Европа чыгышлы ир-ат исемнәренә дә әлеге кушымчалар ялганып яңа төр хатын-кыз исемнәрен ясыйлар: *Рим-Римма, Дамир-Дамирә, Ленар-Ленара, Риф-Рифә, Динар-Динара* һ.б.

## § 19. Синтаксик ысул белән ясалган татар исемнәре

Татар телендә кушма сүзләр синтаксик мөнәсәбәтләре юкка чыгып, үзара атрибутив, объект һәм предикатив бәйләнештәге сүзләрнең кушылуыннан барлыкка килә [Ганиев, 2000: 436]. Татар кушма ир-ат исемнәре синтаксик ысул белән ясалалар. Синтаксик ысул белән ясалган ир-ат исемнәре Г.Ф. Саттаров, Ф.Ә. Ганиев, Х.Ф. Исхакова, М.Х. Әнвәрова хезмәтләрендә урын ала. Ф.Ә. Ганиев хезмәтендә предикатив, атрибутив, комплетив сүзтезмәләрнең лексикалашуы юлы белән барлыкка килгән татар кушма ир-ат исемнәренең ясалыш типларын күрсәтә һәм аларга бик күп үрнәкләр китерә [Ганиев, 2000: 104–109]. Х.Ф. Исхакова фикеренчә, татар телендә кушма исемнәр

бары тик янәшә килү («соположение») юлы белән ясалалар. Ул, янәшә килү нәтиҗәсендә юкстапозит исемнәр барлыкка килә, дип саный [Исхакова, 2000: 4]. Үзара ирекле булмаган тәртипкә ия компонентларның бер басым астында әйтелеп, морфемалар составы ягыннан ирекле сүзтезмәләргә тәңгәл сүзләр юкстапозит тибында булалар. Композит сүзләрдә исә компонентлар арасында бәйләнеш юк. Юкстапозит сүзләрдә синтаксик бәйләнеш тулысынча яисә өлешчә саклана [Исхакова, 2000: 9]. Алда язылган хезмәтләргә таянып, татар антропонимик системасындагы исемнәрнең компонентлары арасында түбәндәге бәйләнешләр ачыкланды:

1) атрибутив бәйләнештәге татар ир-ат исемнәре;

2) комплетив бәйләнештәге татар ир-ат исемнәре;

3) предикатив бәйләнештәге татар ир-ат исемнәре.

1. Атрибутив бәйләнештәге ир-ат исемнәре нигездә 1 нче төр изафәгә корылган исем+исем моделенә нигезләнәләр.

Исем + исем моделе: *Юлтаң, Айхан, Айнур, Алламорат, Имамкол, Илнур, Муллагол, Нуриман, Рәхмәтбай, Сәгадәткол, Сәетнур, Ташбулат, Ташморза, Ханбулат, Хакморза, Динислам. Нурислам* һ.б.

Сыйфат + исем моделе: *Акморза, Акморат, Сарыбала, Акмәрдән, Алтаң, Газизҗан, Акбарс, Асылгали, Акбулат, Асылзат, Асылхан, Асылҗан* һ.б.

Рәвеш + исем моделе: *Бикташ, Бикбулат, Биккол, Бикбай, Бикбарс, Тиңкуәт, Тиңхан, Тиңморза* һ.б.

Сан + исем моделе: *Йөзҗан, Йөзмөхәммәт, Бишбүләк, Төмәнбай, Туканбай, Тугызбәк* һ.б.

Сыйфат фигыль + исем моделе: *Үлмәсбай, Сулмасхан, Үтәмешгәрәй, Туганбай, Сөяргол, Туктархан* һ.б.

2. Комплетив бәйләнешкә кергән татар ир-ат исемнәре компонентлары арасында, нигездә, объект һәм хәл бәйләнешләре урнаша. Түбәндәге ир-ат исемнәре модельләрен аерып чыгардык:

а) компонентлары объект мөнәсәбәтендәге ир-ат исемнәре:

исем + билгесез киләчәк заман хикәя фигыль моделе: *Малтабар, Илтөзәр, Хансөяр, Илгизәр* һ.б.;

исем + категорик үткән заман хикәя фигыль: *Бүләкбирде, Дәүләтбакты, Көнбирде, Морзабирде, Солтанбирде, Айбакты, Илбакты, Ташбакты, Теләкбирде, Юлбакты* һ.б.;

категорик үткән заман хикәя фигыль + исем моделе: *Бирдехан, Бирдетәңре, Килдебәк, Килдехуҗа* һ.б.;

сыйфат + категорик үткән заман хикәя фигыль: *Гаделбирде, Татлыкилде, Юашбирде, Яхшыкилде* һ.б.;

исем + нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль: *Көнтуган, Илтуган, Айтуган, Тәңребиргән, Дусбиргән, Дәүләтгизгән* һ.б.;

исем + боерык фигыль моделе*: Айгиз, Җиһангиз, Илүс, Дилүс* һ.б.

ә) компонентлары хәл бәйләнешендәге ир-ат исемнәре:

сыйфат + боерык фигыль: *Исәнкил, Котлыбир, Котлыкил, Байбулсын, Ныкбул* һ.б.;

сыйфат + хикәя фигыль: *Теребирде, Саугилде, Дөрестуган, Актуган, Тиңтуган, Каратуган, Яшьтуган, Тиңбиргән, Каракилде, Юашбирде* һ.б.;

сан + боерык фигыль: *Туксанбак;*

рәвеш + сыйфат: *Бикбатыр, Бикчибәр, Үтәбай* һ.б.;

рәвеш + боерык фигыль: *Төгәлкара, Исәнкил, Исәнтуг* һ.б.;

рәвеш + хикәя фигыль: *Саукилде, Тукбакты, Исәнбулды, Исәнкилде, Яңабирде* һ.б.;

хәл фигыль + хикәя фигыль: *Көтепалдык, Көтепалдым, Сатыпал* һ.б.

3. Галимнәр предикатив бәйләнештәге ир-ат исемнәренең борынгы чорларда ук ясалуларын ассызыклыйлар [Закиев, 1963; Саттаров, 1978: 70]. Әлеге исемнәр түбәндәге модельләрдә чагыла:

исем + боерык фигыль моделе: *Илүс, Айбул, Галимбул, Ишкил, Иштуг* һ.б.;

боерык фигыль + исем моделе: *Килсенбай, Килморза, Килтимер, Килбай, Торсынбай, Торсынгалим, Торбай* һ.б.;

исем + категорик үткән заман хикәя фигыль моделе: *Корбанкилде, Илбакты, Солтанкилде, Ишбулды, Уразбакты, Хангилде, Айбирде, Иштуган, Айтуган, Хакбирде, Ходайбирде* һ.б.;

исем + нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль моделе: *Хакбиргән, Аллабиргән* һ.б.;

исем + билгесез киләчәк заман хикәя фигыль моделе*: Илтабар, Илтуар, Айтуар, Илтазар, Коттаймас* һ.б.;

билгесез киләчәк заман хикәя фигыль + исем моделе: *Сөярбай, Тазарҗан, Сөярбәк, Сөярхуҗа, Таймасбай* һ.б.;

хикәя фигыль + исем моделе: *Килдебәк, Килдеураз, Бирдебәк* һ.б.;

исем + инфинитив моделе (татар ир-ат исемнәрендә инфинитивның борынгы формасы чагылыш таба): *Иркилмәк* һ.б.;

исем + предикатив сүз моделе: *Илбар, Ишбар, Айбар* һ.б.;

исем + сыйфат моделе: *Айтулы, Гомерозак, Илшат, Илгүзәл* һ.б.

Ф.Ә. Ганиев фикеренә караганда, исемнәрдә кире тәртиптә ясалган исем модельләре «телнең борынгы хәлендә хәбәрнең урыны сүзтезмәнең башында булуын, юк дигәндә, мисаллардан күренгәнчә, аның урыны ирекле булуын күрсәтә» [Ганиев, 2000: 105].

Йомгаклап, югарыда күрсәтелгән ир-ат исемнәре ясалыш модельләренең бүгенге көндә дә исем ясауда төп модель булып торуын билгеләргә мөмкин. А.В. Суперанская фикерләре белән килешеп, шуны әйтә алабыз: «словообразовательные модели, существующие для одних имен, применимы и к другим, и потенциальное словообразавание возможно для всех (или, по крайней мере, для большинства) собственных имен, но все же оно ограничено реальным употреблением слов» [Суперанская, 1969: 144]. Бүгенге көндә фигыль+исем моделендәге ир-ат исемнәре ясалмыйлар һәм кулланылышта йөрми, ягъни һәм бу модельдәге татар ир-ат исемнәре бик борынгы чорларга карыйлар. Иң активы – исем+исем, исем+фигыль моделендә атрибутив, предикатив, комплетив бәйләнештәге татар ир-ат исемнәре ясыйлар. Казан шәһәренең 2000–2005 елгы ЗАГС материалларында *Аллабирде* һәм *Бикбулсын* исемнәренең кулланылышка керүе ачыкланды. Шулай ук компонентлары хәл бәйләнешендә булган ир-ат исемнәренең дә кулланылышлары чикле һәм сүз ясалыш моделе нигезендә ир-ат исемнәре ясалмый диярлек.

## § 20. Аббревиатур исемнәрнең ясалышы

Апеллятив сүзләрнең беренче элементларын, беренче авазларын яки хәрефләрен кушу юлы белән аббревиатур ир-ат исемнәре ясалалар. Татар телендә бу ысул белән ясалган беренче сүзләр XIX йөзнең ахырында һәм XX йөзнең башында барлыкка киләләр [Ганиев, 2000: 33]. Антропонимикада исә аббревиатур ир-ат исемнәренең кулланылышы 1920–1930 елларга карый. Октябрь революциясеннән соңгы еллар «антропонимик ташкын» еллары буларак билгеләнәләр. Бу чорда аббревиатур исемнәрнең артуы күзәтелә башлый. Аббревиация ысулы белән ясалган ир-ат исемнәрен, структур-ясалыш үзенчәлекләреннән чыгып, түбәндәге төркемчәләргә бүлдек:

1. Исемнәрнең беренче хәрефләрен кушу нәтиҗәсендә ясалган ир-ат исемнәре:

*Вил* –Владимир Ильич Ленин;

*Вилен* – Владимир Ильич Ленин;

*Владлен* – Владимир Ленин һ.б.

2. Инициалларга апеллятив лексиканың кушылып ясалуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән ир-ат исемнәре:

*Вилор* – В .И. Ленин организатор армии;

*Вилюр* – В .И. Ленин любит рабочих;

*Вилсор* – В .И. Ленин создатель Октябрьской революции һ.б.

3. Инициалларга традицион төрки һәм гарәп-фарсы чыгышлы антропокомпонентлар кушылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән ир-ат исемнәре: *Вилнур* – В.И. Ленин нуры;

*Вилданшаһ* – Вил +дан+шаһ һ.б.

4. Апеллятив лексиканың кыскаруы нәтиҗәсендә ясалган ир-ат исемнәре: *Ким* – Коммунистический интернационал молодежи; *Рэн* – революция, энергетика, наука; *Рэм* – революция, энергетика, механизация һ.б.

## § 21. Татар исемнәренең ономавариантлары

Татар ир-ат исемнәре системасында, традицион ир-ат исемнәре белән бергә, экстралингвистик, лингвистик факторлар тәэсирендә барлыкка килгән фонологик һәм график ономавариантлар да кулланыла. Галимнәр тарафыннан исемнәрнең Себер татарларындагы [Саттаров, 1990; Тумашева; 1978: 9; Айтбаева, 2004: 144], мишәр диалектында [Махмутова, 1978; Вагапова, 2002], урта диалекттагы [Саттаров, 1974; Галиуллина, 2000; Салимзянова, 2002] фонетик-морфологик үзенчәлекләре өйрәнелде. Төрле диалект һәм сөйләшләрнең фонетик үзенчәлекләре, рус һәм Көнбатыш Европа исемнәре тәэсирендә, шулай ук «алынмалар кабул ителә башлаган чорда исемнәрне язу кагыйдәләре ачыкланмаганлыктан» да [Галиуллина, 2000: 30] ономавариантлар барлыкка килергә мөмкин. «Вариантлылык – телдәге эчке мөмкинлекләрнең чагылышы булып тора. Телнең үзе кебек үк, объектив-реаль рәвештә яши, төрле чорларда, һәр чорның таләбенә ярашып, берникадәр дәрәҗәдә төрлерәк вазифа үтәп, һәрвакыт булган һәм булачак, димәк, тикшеренү-өйрәнү объекты буларак та игътибар үзәгендә торырга хаклы» [Бәширова, 1999: 431]. А.В. Суперанская «исемнәрнең вариантлылыгы антропонимнарның ясалыш үзенчәлегеннән, тел мөмкинлекләреннән килүен» билгели [Суперанская, 2005: 171]. Шуңа күрә, татар исемнәренең ономавариантларын өйрәнү телнең динамик һәм статик халәтендә барлыкка килгән үзгәрешләрне ачыкларга, тел тарихы, диалектология өлкәсендәге яңалыкларны күрсәтергә мөмкинлек бирә. «Сүз мәгънәсенең дифференциациясенә очрамаган үзгәреш сүз ясалышын тәшкил итми» [Ганиев, 1973: 9], шуңа күрә, исемнәрнең

фонетик ономавариантларын фонетик сүзьясалышыннан аерып карарга кирәк. Телләр арасында аваз системасының туры килмәве татар антропонимиконында ономавариантларн барлыкка китерә. Мәсәлән, төрек телендә [а] авазы, татар телендәге [а] белән чагыштырганда күпкә ачыграк, рус телендәге, мишәр диалектларындагы [а] авазына якын. Төрек телендәге *Аксу* антропонимында исә [а] авазы ачык әйтелешле. Рус телендәге *Александр* исемендә [а] авазы төрек телендә чагылыш тапкан [а] авазына караганда тагы да ачыграк әйтелә. Шуңа күрә, татар антропонимик системасында чыганак телдән алынган ир-ат исеме белән бергә, татар теле закончалыкларына буйсындырылган вариантлар да кулланылышта йөри. Ономавариантларга диалект һәм сөйләшләрнең фонетик системасына яраклаштырып ясалган, шулай ук XX гасыр башында ата-аналарның традицион ир-ат исемнәрен «эксклюзив авазлар» кертеп үзгәртү тенденциясе, яисә, киресенчә, алынма ир-ат исемнәрен милли исемнәргә охшатып ясау нигезендә туган иҗади исем вариантларын да кертеп карарга мөмкин.

Түбәндәге сузыклар күчешен аерып чыгардык:

-а/-ә: *Алик-Әлик, Сайфулла-Сәйфулла*; у-ү: *Расул-Рәсүл*. Сузыкларның күчешләре татар теленең калынлыкта-нечкәлектә ярашу кебек фонетик закончалыкка буйсындырылуга нигезләнә. Арткы рәт сузыкларның алгы рәт сузыклар белән чиратлашуы сингармонизм законына буйсындырылып барлыкка килә. Э(е)>и: *Ренат-Ринат, Ленар-Линар, Рафаэль-Рафаил*. Рафаил исеме Рафаэль исеменең татарчалаштырылган, милли җирлектәгечә яңгыраган варианты. Татар теленә хас булмаган авазларны татар теленә хас авазлар белән алыштыру күренеше чагыла;

и > э(еу) *Илдар-Эльдар, Иллар-Эльнар, Илнур-Эльнур, Ирек-Эрик; Ирек-Ирик*. Әлеге күчеш гасыр башы антропонимик системасында киң таралган төрләрнең берсе. Аның халыкның яңачалыкка омтылуы, татар теленә хас булмаган эксклюзив авазларның кулланылышка керү тенденциясе дип атарга мөмкин. Бу күчеш – XX һәм XXI гасыр материалларына караганда иң продуктив күчешләрнең берсе;

о > у: *Флор-Флур*. Рус теле аша кергән латин чыгышлы ир-ат исемнәрендәге аваз күчешләре «борынгы чорда рус теленнән кергән сүзләрдәге о авазының у белән алыштырылуы» [Җәләй, 1954: 37] кебек тарихи фонетик күчеш белән аңлатыла. Борынгы төрки ир-ат исемнәрендә исә бу күчешләр кара-каршы булып (о > у: *Кошкар – Кушкар, Куртбай – Кортбай*) борынгы урта сузыкларның тараюы

(о > у), тар ирен авазларының (у>о) киңәюе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Бу күчеш төрки телләрдәге антропонимик берәмлекләрнең аерымлануында да чагыла. Билгеле булганча, татар һәм башкорт телләрендә беренче иҗектә [о], [ө] авазлары килсә, борынгы төрки телләрдә [у], [ү] авазлары туры килә. Татар һәм башкорт телләрендә [и], [у], [ү] авазлары килсә, башкаларында [о], [ө] кулланыла. Мәсәлән, татар телендәге *Көнтуды* антропонимик берәмлеге казакъ телендә *Кунтоды* [Кульдеева, 2000: 203], төрек телендә *Гүндоуду* [Эрол, 1999: 56], кыргызларда *Күнтогды* [Жапаров, 1992: 18] кебек вариантларда кулланыла;

о > а: *Кошбай-Кашбай*;

у > ы: *Салтуган- Салтыган*';

а > и: *Фаздал-Фаздил*;

ә > и: *Сөембәк-Сөембик, Галимбәк-Галимбик-Галнмби, Кавәс-Кавис, Галибәй-Галиби*; Л. Җәләй борынгыда [ә] белән әйтелгән сүзләрнең байтагы татар телендә [и] белән әйтелүгә күчү дәгъвасыз, дип билгели [Җәләй, 1954: 50];

и > ы: *Ачи-Ачы, Мәдихша-Мәдыхша, Ширдан-Шырда*н;

и > у: *Баһадир-Баһадур*; Мишәр диалектында дифтонгларның исем уртасында монофтонгка күчүе фонетик үзенчәлекне тәшкил итә: *Сөләйман-Сөлиман, Садыйк-Садек*. Шулай ук беренче иҗектә кулланылган -*әй* дифтонгы монофтонгка күчә: *Хәйрулла-Хайрулла, Фәйзулла-Фәйзулла* [Вагапова, 2002: 13]. Һәр телнең фонетик системасы үзенчәлекле булганга күрә, алынма исемнәрне төгәл әйтү мөмкин түгел. Шуңа бәйле рәвештә телдә исемнәрнең фонетик вариантлары барлыкка килә. Мәсәлән, татар телендә [д] авазы сүз башында, интервокаль позициядә яңгырау килсә, сүз ахырына таба саңгыраулаша [Байчура, 1959: 111]. Борынгы тарихи фонетик материалларга карaганда, т > д күчеше «ике яклы булган һәм моның тарихи җирлеге гомумтатар теле формалашуга төрле кабиләләр, җирле диалектлар катнашкан булуы белән билгеләнә» [Байчура, 1959: 177, 74]. Татар теленең яңгырау тартыкларының сүз азагында саңгыраулашу закончалыгы нигезендә ир-ат исемнәре күп очракта саңгырау авазга тәмамлана.

Татар антропонимиконында нигез телдәге яңгырау тартык авазларның татар теле закончалыклары нигезендә, саңгыраулашу күренеше түбәндәге фонетик вариантларда чагыла:

г > х: *Тайхуҗа-Тайгуҗа, Солтанхуҗа-Солтангуҗа, Нурхуҗда-Нургуҗа*;

г > к: *Рафигъ-Рафыйк, Әскәр-Әсгәр;*

б > п: *Якуб-Якуп;*

з > т: *Азнабай-Атнабай, Азнакол-Атнакол.* з-д тәңгәллеген М. Кашгари билгели [Кашгари, 1960: 34];

Аваз күчешләре, әдәби тел йогынтысыннан тыш, диалект һәм сөйләшләр тәэсирендә дә барлыкка килә. Көнбатыш диалектының фонетик системасында ирен-ирен [w], увуляр [к], [г], [х] һәм фарингаль [h] авазларының булмавы диалекталь тирәлектә татар ир-ат исемнәренең адаптацияләшүенә һәм антропонимик системада трансформацияләшүгә, шулай ук күпвариантлылыкка сәбәп була. Мәсәлән, татар теленең көнбатыш һәм көнчыгыш диалектларында [г] авазын саңгыраулаштырылган [ң] рәвешендә әйтү дә очрый [Тумашева, 1961: 32];

җ > й: *Җомабай-Иомабай; Җәгъфәр-Ягъфәр* һ.б.;

х > к: *Хәниф-Кәниф; Хәбир-Кәбир.* Нигездә х> к күчеше гарәби-фарсы чыгышлы ир-ат исемнәрендә күзәтелә, чөнки төрки телләргә [к] авазы хас, [х] авазы исә чагыштырмача соң кулланылышка керә [Җәләй, 1954: 74]. Шуңа күрә [к] авазына башланган ир-ат исеме вариантлары чагыштырмача соңрак чорда барлыкка килгән дип әйтә алабыз;

ф > п: *Сәйфи-Сәйпи.* Бу күчеш Көнбатыш себер татарлары исемнәрендә күзәтелә [Тумашева, 1961: 29].

н > м: *Ганбәр-Гамбәр, Мәгъсун-Мәгъсүм*;

з > с: *Нияз-Нияс*;

Аваз күчеше белән беррәттән, аваз төшеп калу күренешен дә диалектлар һәм сөйләшләрнең тәэсире дип күрсәтергә кирәк: *Гадел-Адел, Габдулла-Абдулла, Гали-Али.* Фарингаль [h] авазының төшеп калуы, яисә [й] авазына алыштырылу күзәтелә: *Фәним-Фәйм, Шаниҗан-Шайҗан, Хуррамшан-Хуррамша.* Диалекталь күренеш буларак, ш > ч авазлары күчешен тартыклар ассимиляциясенең янәшә килүче тартыкларының күчеше дип карарга кирәк: *Шашур-Шачур.* Сүз ахырында [л'] > [л] күчеше Европа һәм рус алынмаларында очрый торган күренеш, [л] авазының татар теленә яраклаштырылуы исемне чыганак телдән ераклаштырып, татар теленә якын итә: *Рафаэль-Рафаил, Реваль-Ревал, Адель-Адил*, *Радель-Радил.* Исемнәрнең ясалма фонетик вариантларының күплеге халыкның иҗат мөмкинлекләрен, яңалыкка омтылышын күрсәтеп кенә калмый, татар антропонимиконының ясалма ир-ат исемнәре катламын тулыландыруга хезмәт итә. Телебездә ясалма ир-ат исемнәренең артуы ата-аналар тарафыннан исемнең, мәгънәви үзенчәлегеннән бигрәк, фонетик яңгырашына әһәмият бирелүен чагылдыра. Ир-ат исемнәренең башлангыч берәмлекләре,

аларның төрле фонетик һәм структур модификацияләр кабул итүе нәтиҗәсендә, танымаслык дәрәҗәдә үзгәрергә мөмкин. Татар антропонимикасында иркәләү-кечерәйтү кушымчалары нигезендә ясалган исемнәрне аерып күрсәтергә кирәк. Соңгылары исә структур яктан кыскартма исемнәргә охшашлык күрсәтсәләр дә, эчтәлек ягыннан төрлелегә белән аерылалар. Кыскартуның төп вазифасы кулланылышны җиңеләйтү омтылышыннан бәйле. Исемнәрне кыскарту структур, морфологик процесс итеп билгеләнеп, исемнең объектив бәясен бирсә, иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ялгану эмоциональ, психологик, социаль факторлар белән бәйле күренеш һәм, ул исемнәргә субъектив бәя мәгънә төсмерен өсти. Әлеге исемнәрне хезмәтебездә шартлы рәвештә объектив кыскартылма ир-ат исемнәренә һәм субъектив кыскартылма ир-ат исемнәренә аерып тикшердек. Төрле диалект һәм сөйләшләрдә гарәп-фарсы чыгышлы исемнәрнең икенче иҗегенең беренче тартыгына иркәләү-кечерәйтү кушымчасын өстәлеп, субъектив кыскартылма ир-ат исемнәре ясалалар. Л.Т. Мәхмүтова билгеләвенчә, мишәр диалектында, *-кай/-кәй* кушымчасыннан кала, барлык төр иркәләү-кечерәйтү кушымчалары да (*-ай/-әй, -и, -а/ә, -уш, -ук*) төп мәгънәләрен югалтканнар [Махмутова, 1969: 114]. Г.Ф. Саттаров исә татар антропонимик системасында иркәләү-кечерәйтү кушымчаларының 12 төрен күрсәтә һәм әлеге кушымчаларның иркәләү-кечерәйтү төсмере кайбер исемнәрдә ачык чагылыш тапса (*Галикәй, Тимеркәй*), кайберләрендә аз билгеләнә (*Балтай, Аднаш*), өченчеләрендә исә, гомумән, кушымчаларны исем составыннан аерып булмый (*Сәйдәш, Апанай*), дип саный [Саттаров, 1970: 212]. Х.Ф. Исхакова татар антропонимиконында иркәләү-кечерәйтү кушымчаларының сүз ясагыч вазифасын үтәвен билгели [Исхакова, 1999: 19]. Шулай да татар антропонимиконында ир-ат исемнәрендә стилистик кушымчаларның бары тик аерым бер аффикслары гына сүз ясауда катнашуларын (*-кай/ -кәй, гына/гена*), ә калганнарының исә кулланылышы чикле булуын билгеләргә кирәк. Әмма антропонимик берәмлекләрдә төрле фонетик һәм структур модификацияләр кабул итү үзгәреше нәтиҗәсендә барлыкка килгән исемнәр, җанлы сөйләм телендә, диалекталь һәм гади сөйләм сферасында гына түгел, гомумкулланылыш сферасында да кулланыла башлыйлар. Түбәндәге стилистик кушымчаларны билгеләргә мөмкин:

-тый: *Кустый, Чултый;*

-каш/-кәш: *Салкаш, Яркәш; Тиңкәш*;

-чык/-чек: *Уразчы, Исәнчек*;

-гына/-генә/-кына/-кенә: *Биккенә, Айгына, Ишкенә*; гына/генә чикләүче кисәкчәләре мишәр диалектында иркәләү-кечерәйтү функциясендә киләләр;

-ай/-әй/-ый/-и: *Нигъмәтулла-Нигъмәй, Габдулла-Габлай, Әлмөхәммәт-Әлми, Кашшаф-Кәшәй-Кашай-Кашфи, Мостафа-Мостай* һ.б. Ялгызлык исемнәрен шушы формада куллану мишәр һәм Себер татарлары диалектларында билгеле [Махмутова, 1978: 101; Тумашева, 1978: 68];

-ак/-әк/-ук/-үк: *Сираҗетдин-Сирук, Вәлиулла-Вәлүк, Шәмсетдин-Шәмүк, Ишмөхәммәт-Ишүк* һ.б.

-ш/-аш/-әш/-ыш/-еш/-уш/-үш: *Нигъмәтулла-Нигъмәш, Ибраһим-Ибраш, Акмулла-Акмуш, Җамалетдин-Ямалетдин-Ямаш* һ.б.;

-уч/-үч/-ач/-әч: *Нурмөхәммәт-Нурмач, Хәбибулла-Хәбүч, Хәйрулла-Хәйрүч* һ.б.;

-ук/үк: *Ярулла-Ярук, Хәйрулла-Хәйрүк, Ибраһим-Ибрук.* Мишәр диалектында еш очрый торган кушымча [Махмутова, 1978: 116];

-кай/-кәй: *Кәлимулла-Калкәй, Мәүли-Мәүләкәй, Сибгатулла-Сибкай* һ.б.

Татар ир-ат исемнәрендә *-кай/-кәй* кушымчасы, стилистик вазифадан тыш, морфологик вазифа да башкара. Бу кушымча иркәләү-кечерәйтү мәгънәсен бирү белән бергә, сүзьясагыч кушымча буларак, ир-ат исемнәрен ясауда катнаша: *Илкәй, Ишкәй, Иркәй, Тимеркәй* һ.б. Объектив кыскартылма ир-ат исемнәренә аферезис, апокопа, синкопа ярдәмендә ясалган ир-ат исемнәре керә. Әлеге фонетик ысуллар белән ясалган ир-ат исемнәрен карап китик.

1. Аферезис, ягъни бу очракта кушма төзелешле алынма ир-ат исеменең беренче өлеше тулысынча төшеп кала: *Габдрахман- Рахман, Габделхак-Хак, Габделхәй-Хәй, Хәбибрахман-Рахман* һ.б.

2. Апокопа, ягъни алынма исемнең икенче өлеше төшеп кала: *Сафиулла-Сафи, Гарифулла-Гариф, Сираҗетдин-Сираҗ* һ.б.

3. Синкопа, ягъни алынма сүзнең уртасында булган сузык авазларның һәм иҗекләрнең төшеп калуы очраклары: *Бикмөхәммәт-Бикмәт, Шаһимөхәммәт-Шахмәт, Мөхәммәтша-Мәтша, Аймәт-Амәт, Шаһиҗан-Шайҗан* һ.б.

Күзәтүләребезгә караганда, XX гасырда исемнәрнең кыскартылма формаларының вазифасы киңәя. Исемнәренең кайбер формалары альтернатив вариант булудан туктап, исем системасының гомумкулланылыш роленә күчәләр. Моның төп сәбәбе итеп, «XX гасырда

татарларда, бигрәк тә рәсми сферада русча атау формалары (отчество, фамилия) нык тарала башлавын күрсәтергә мөмкин. Бу хәл исемнәрнең тулы формалары югалуга китерә. Бик еш кына тулы исемнәрнең функциональ формалары һәм фонетик кыскартылган вариантлары мөстәкыйль исем булып әвереләләр. Революциядән соң идеологик юнәлешнең һәм тормышның шартлары үзгәрүе бу процессны тагын да көчәйтеп җибәрә» [ТТАС, 2005: 833]. Димәк, исемнәрнең кыскартылма формалары телдә эмоциональ-бәяләү коннотацияләрен югалтып, рәсми статус алырга да мөмкин.

## Кыскача нәтиҗәләр

1. Татар исемнәре структур яктан ике компоненттан гыйбарәт берәмлекләр. Бер составлы исемнәр антропокомпонент яки антропоформантка - *даш/-дәш, -лы/-ле, -кай/-кәй* кебек төрки чыгышлы һәм *-задә, -ман/-мән, -гир, -дар/-дәр,-ат/-әт* кебек алынма кушымчалар ялгану нигезендә ясалган исем модельләреннән гыйбарәт. Кушма ират исемнәре атрибутив, комплетив, предикатив бәйләнешле компонентлар нигезендә ясалганнар. Бүгенге көндә атрибутив, комплетив, предикатив бәйләнеш нигезендә исемнәр ясалу процессы дәвам итә. Фигыль + исем моделендәге татар исемнәре борынгы чорга карыйлар һәм бүгенге көндә кулланылышта йөрмиләр.

2. Татар антропонимикасында, традицион кулланылышта булган исемнәр белән бергә, экстралингвистик, лингвистик факторлар тәэсирендә барлыкка килгән фонологик һәм график ономавариантлар да кулланыла. Төрле диалекталь, сөйләм процессында, ата-аналарның иҗаты нигезендә барлыкка килгән аваз күчешләре фонетик ономавариантлар дип аталалар. Татар исемнәрендә о > у, ө > ү, а > ә, у > ү, з > д кебек аваз күчешләре билгеләнде, о > у, ө > ү кебек фонетик күчешләр төрки телләрдә ир-ат исемнәренең аерымлануында күзәтелә. Татар һәм башкорт исемнәрендә беренче иҗектә [о], [ө] авазлары килсә, кыргыз, казакъ, төрек, төрекмән исемнәрендә [у], [ү] авазы чагылыш тапкан. А > ә, у > ү күчешләре ике яклы килеп, татар теленең фонетик закончалыгына яраклашу нигезендә барлыкка килгәннәр. XX гасыр – XXI гасыр башы антропонимик системасында традицион татар теле авазларының телебезгә хас булмаган авазлар белән чиратлашуы исемнәрдә күп санда фонетик ономавариантлар ясалуга китерә. Бүгенге көндә и > э(е) күчешен иң продуктив күчеш буларак билгели алабыз. Иркәләү-кечерәйтү кушымчаларыннан ялганып, апокопа, аферезис, синкопа кебек аваз һәм аваз кушылмалары кыскартылып ясалган ир-ат исемнәре график ономавариантларны тәшкил итәләр.

## Бишенче бүлек
## ТАТАР ФАМИЛИЯЛӘРЕ

### § 22. Татар фамилияләренең формалашу тарихы

Фамилия – (familia латин телендә *гаилә, өй* дигәнне аңлата) кешенең аерым бер гаиләгә караганлыгын күрсәтә торган антропонимнарның бер төре [Подольская, 1978: 155]. Рус теле белемендә фамилияләрнең үсеше, формалашу этаплары, семантик үзенчәлекләре В.Д. Бондалетов (1983), А.М. Селищев (2003), В.К. Чичагов (1959), Ю.Ю. Марченкова (2006), И.А. Королева (2000), Н.Н. Парфенова (2002), Л.С. Плавинская (2013), Е.С. Еремина (2005), Т.Г. Смирнова (2003), В.И. Вершинин (2015, 2016) һ.б. ның хезмәтләрендә тикшерелә. Төрки тел белемендә, аерым алганда, карачай-балкар телендә [Биджиева, 2002], казакъ телендә [Ниетбаева, 1993], кыргыз телендә [Жапаров, 2009], төрек телендә [Şahin, 2016] фамилия антропонимик берәмлек буларак синхрон-диахроник аспектта өйрәнелә. Татар телендә фамилияләр Г.Ф. Саттаров, Ф.Л. Мәҗитова, Г.С. Тимирханова (2002), З.М. Хөснуллина (2006) хезмәтләрендә тарихи-лингвистик аспектта тикшереләләр.

*Фамилия* сүзе рус теленә поляк теле аша *нәсел* сүзенә синоним буларак кулланылышка керә, әмма XIX гасырда мәгънәсен үзгәртә һәм «гаилә» төшенчәсен белдерә башлый. Билгеле булганча, фамилия термины номинатив берәмлек буларак, Төньяк Италиядә XI гасырда кулланылышка керә. Фамилия Италиядән французлар, инглизләр һәм башка Европа халкы арасында киң тарала. Европа халкын «фамилияләштерү» XII – XIX гасырга кадәр дәвам итә. Алманнар арасында «фамилияләшү» күренеше XII гасырда башланып XIX гасырга кадәр дәвам итә.

Рус теле белемендә фамилияне белдерү өчен кушамат, прозвание терминнары кулланыла. 1818 елда Россия империясе Дәүләт советы *фамилия* сүзен гаилә, нәсел мәгънәсендә аңларга кирәклекне, әлеге сүзнең «кушамат» төшенчәсенә тәңгәл булмавын белдерә. Фамилия

термины «Ревизская сказка» материалларында 1849 елда беренче тапкыр теркәлеп, «гаилә кушаматы» төшенчәсен алыштырып килә башлый.

Татар телендә фамилияләр исемнәргә *-ов (ова), -ев (ева), -ин (-ина), -ский (ская)* кушымчалары ялганып ясалалар. Татар фамилияләрендә *-ов (-ова)* (*Габдриев – Габдирева, Хаков – Хакова*) кушымчасы белән беррәттән, *-ин (-ина)* кушамчасы да параллель рәвештә кулланыла. Кулланылыш ешлыгы ягыннан *-ов/-ова* кушымчасы татар фамилияләре составында ешрак очрый. Ә менә, рус телендә уртаклык исемнәрен ясауда *-ов (-ова)* кушымчасы продуктив түгел, *-ин* кушымчасы, киресенчә, туганлык атамаларында (мамин, сестрин, дядин и др.), кечерәйтү исемнәрендә (*Колин, Сашин, Сонин* һ.б.) тартым кушымчасы вазифасын үти.

Фамилияләр – кешене төгәл идентификацияләү ихтыяҗыннан барлыкка килгән антропонимик берәмлекләр [Фролов, 2005: 103]. XVI гасыр урталарында рус фамилияләренең күпчелегендә *-ов/-ев/ -ин* кушымчасы кулланыла. Русларда фамилия ясауда «крестильный» һәм көнкүреш исемнәре дә катнашалар. Бу исә, үз чиратында, омоним исемнәр кулланылышыннан коткара, чөнки крестиль исемнәр фондының кулланылыш мөмкинлекләре чикле була [Унбегаун, 1989: 16]. Рус антропонимик системасында кенәз һәм бояр фамилияләре – XV–XVII гасырларда, сәүдәгәр фамилияләре – XVI–XIX гасырларда, крестьян фамилияләре XVIII–XIX гасырда формалашып бетәләр [Фролов, 2005: 104]. Ревизия кенәгәләрендә фамилия 1849 елдан «гаилә прозваниесе» терминын алыштырып, кулланыла башлый. Паспортлашу чорында – XX гасырның 30 нчы елларында СССРда яшәүче барлык халык фамилияне киң кулланышка кертә.

Татар фамилияләре формалашуның беренче этабы борынгы төрки антропонимик система формалашу этабыннан башланып китә. Орхон-Енисей чыганакларында ук фамилия антропонимик берәмлегенең беренче яралгылары күренә башлый, ул социаль титулны, нәселне аерып күрсәтү, мирас мәсьәләләрен хәл итү максатында барлыкка килә: *Čur Tegin, Beg Čur, Kül Čur Ayluç Tarkan, Altun Tamgan Tarkan, Kegilinç Tarkan* һ.б. Өстәмә антропонимик берәмлек буларак, фамилия ата яки баба исеме, сословие титулы буларак исем янәшәсендә кулланыла. Мәсәлән, *Tutuq* «баш әмер бирүчесе» титулы түбәндәге исемнәрдә фамилия вазифасын үти: *Adak Tutuq, Alp Tutuq, Budak Tutuq* һ.б. Аерым бер гаилә әгъзаларының исемнәре янында нәселне аеру максатында

фамилия ролен бәк, бай, ай, иш, җан кебек компонентлар үти. Димәк, борынгы төрки антропонимик системада фамилия (ата яки баба исеме, кушамат яки сословие титулы) шәхесне идентификацияләү вазифасын башкара. Борынгы Орхон-Енисей язмаларында *elči čor kuč bars, atım el toγan tutuq, bag tarqan ögä tirig* һ.б. кебек фамилияләр функциясен алыштырган компонентлар булуы мәгълүм.

Ислам дине кабул ителгәч, Бөек Болгар дәүләтенең башка илләр белән икътисади-сәяси, дипломатик элемтәләренең ныгуы, гарәп факиһләре һәм мөгаллимнәре тарафыннан мәктәп-мәдрәсәләрдә татар теле аша мөселман диненең укытыла башлавы кешене идентификацияләүдә өстәмә чараларның кирәклеге ихтыяҗын арттыра һәм фамилия гарәп антропонимик системасы законнары нигезендә формалаша. Бөек Болгар дәүләтендә күренекле галимнәрнең, дин әһелләренең исемнәрендә түбәндәге антропонимик модельләрнең кулланылышын билгеләргә мөмкин: *Хуҗа Әхмәд әл-Болгари, Хәмид бине Идрис әл-Болгари, Якуб бине Ногман әл-Болгари, Сөләйман бине Даут әл-Саксани-Сувари, Борханетдин Ибраһим әл-Хәнәфи, Ибраһим әл-Казани, Ибраһим бине Сөләйман әс-Сараи* [Мәрҗани, 1989: 142].

Алтын Урда чорында фамилия функциясен башкара торган берәмлек рәсми антропонимик категория булмый, чөнки өстәмә антропонимик берәмлекләрнең атадан балаларга күчүе киң таралмаган була. Фамилия функциясен үти торган *улы / кызы* кебек өстәмә антропонимик берәмлекләр Алтын Урда чорына караган каберташ язмаларында, тарихи чыганакларда фамилия вазифасын үти: *Хәмәд угылы Хәсән угылы Мәчкә; Әхрәҗ угылы Әбхәм угылы Әршид угылы Мәхмүд; Ильяс угылы Исмәгыйль угылы Мөхәммәд; Бәчек угылы Мәмәк Йувари угылы Исхак угылы Йосыф хаҗи; Исмәгыйль угылы Хәсән угылы Муса угылы Мөхәммәд; Иләм угылы Хаҗи кызы Җәкәр* һ.б. [Становление..., 2011: 401]. Алтын Урда чорына караган хатын-кыз исемнәрен билгеләүдә дә шул ук антропонимик модель кулланылышта була: *Әхмәд хаҗи улы Хәсән Хаҗи кызы Рабига, Иләм угылы Хаҗи кызы Җәкәр, Әхмәд Хуҗа угылы Хәсән Хуҗа кызы Рәйзу* һ.б. Хатын-кызны идентификацияләүдә өстәмә антропонимик берәмлек булып ирнең исеме кулланыла: *Госман әл-Болгари кызы Хөсәен хатыны Җәкәр Әлти, Мур бәй хатыны Йосыф Йувари угылы Йосыф Йувари кызы Гафифә Заһидә* һ.б. [Становление..., 2011: 406 – 410]. Алтын Урда чыганакларына караган каберташ язмаларында урынга нисбәтле фамилияләрне дә очратырга мөмкин: *Садреддин әл-Ширвани, Хуҗа угылы Госман угылы*

*Ибраһим әл-Сувари, Юныс әл-Болгари* һ.б. [Нурулла, 2011: 12–24]. Алтын Урда чорында исламның төрле юнәлешләре киң таралган була [Мухаметшин, 2007: 14], әлеге юнәлешләр исә фамилия вазифасын үти торган берәмлекләрдә дә чагыла: *Борһанетдин Ибраһим Хозыр әл-Хәнәфи*. Дини юнәлешләрнең чагылышы *Хәнәфи, Шафи, Суфи* кебек фамилияләрдә сакланып кала. Хәзерге антропонимикада исә әлеге фамилияләр нигезендә кеше исемнәре дә шактый еш кулланылышта йөри: *Хәнәфи-Хәнәфия, Шафи-Шафия, Суфи-Суфия*.

Билгеле булганча, ислам дине кабул ителгәннән соң, антропонимик системада да гарәп исем системасына хас антропонимик модельләр кулланылышка кереп, урта гасырда һәм аннан соңгы чорларда кеше турында өстәмә мәгълүмат бирә торган төшенчәләргә (шәхеснең туган урыны, мәзһәбе, ата-бабасы) *-и/-ый* изафә кушымчасы нигезендә барлыкка килгән антропонимик берәмлекләр фамилия вазифасын башкаралар: *Мәхмүд Кашгарлы, Шиһабеддин Мәрҗани, Борһанетдин Ибраһим Хозыр Хәнәфи, Бәчек угылы Мәмәк Йувари* һ.б. Моннан тыш, урта гасырларда исем белән янәшә ата-баба исеме, бернинди кушымча алмыйча, патронимик фамилия функциясендә дә очрый: *Кадыйр Галибәк, Таҗетдин Ялчыгол*.

Казан ханлыгы чорына караган каберташ язмаларында фамилия вазифасын үти торган берәмлек *угылы / кызы* өстәмә антропонимик берәмлек чаралары ярдәмендә белдерелә: *Садир угылы Идегәй, Мансур Исхак угылы, Чура угылы Гали Мәрдән, Кунак Хуҗа бай угылы Җийан Хуҗа* һ.б. Атасы исеменнән тыш, хатын-кыз исемендә өстәмә идентификацияләү вазифасын иренең исеме үти: *Җәгъфәр кызы Гали хатыны Айбикәч, Әҗем угылы Бик-Бау хатыны Акбикәч, Шәех Галинең хатыны Нәүрүзсолтан* һ.б.

Казан ханлыгы руслар тарафыннан яулап алынганнан соң, шәхесне билгеләүдә аерым үзгәрешләр күзәтелә. Тарихи чыганакларда X – XVI гасыр урталарыннан башлап, татар антропонимик системасы рус антропонимик моделе нигезендә формалаша башлый. Тарихи чыганакларда кеше исемнәренә *-ов/-ев/-ин* кушымчаларының кушылып фамилия ясалышы күзәтелә. 1565–1568 елларда Н.В. Борисов һәм Д.А. Кикин тарафыннан язылган писцовый һәм межау кенәгәләрендә татар фамилияләренең төрле катлау арасында кулланылышын күзәтергә мөмкин: *Көнәй Чакмак ( Куней Чикмаков), Уразкилде Акъялов (Разгилдей Акьелов), Мостафа Байчирү (Мустапа Байчиреев)* һ.б. 1602–1603 елгы писцовый кенәгәләрдә йомышлы татарлар арасын-

да түбәндәге фамилияләр билгеләнә: *Кайбула Карамышев, Айтуган Янчурин, Карай Урусов, Текей Енчурин, Исекей Мусин, Ангильдиш Мусин, Салтанай Салтангулов, Курмыш Абдулов* һ.б. XVI–XVII йөзләрдә хатын-кыз фамилиясе иренең исеме белән күрсәтелә: *Кадышевская жена Девленей*. Димәк, рус антропонимик моделе нигезендә барлыкка килгән татар фамилияләре XVI–XVIII йөзләргә караган рус чыганакларында билгеләнә башлыйлар һәм төрле иҗтимагый катлауга караган татарларны идентификацияләү вазифасын үтиләр. Кенәз яки алпавыт катлавына караган татарларның шәхесен билгеләгәндә, фамилия белән беррәттән, ярымотчество да кулланыла башлый: *Тойгелдей князь Уразгелдеев сын, Кучюк Тегишев, Ишей Хозяшев сын Сюндюков, Емамаметка Юнгушев сын Турачиков* Галиуллина, 2014: 196].

Россиянең тарихи процессында яшәргә мәҗбүр ителгән Идел буендагы барлык рус булмаган халыкларның антропонимик системаларында үзгәрешләр билгеләнсә дә, гарәп-фарсы, төрки телләргә хас исем кушу, атау традицияләре, исем модельләре көнкүреш дөньясында яшәешен дәвам итәләр. XVII–XVIII гасырга караган ташбилгеләрдә традицион милли калыпка нигезләнгән антропонимик модельләрне очратабыз: *Кадрәк мирза угылы Исәнәк мирза, Айыш угылы Дусай, Килмөхәммәд Ишман угылы, Чирүче угылы Килмөхәммәд* [Әхмәтҗанов, 2011]. 1763 елгы Ревизия кенәгәләрендә мәгълүматлар фамилия + исем моделендә биреләләр: *«Салиха Хасанова 35 лет взята Казанского уезда деревни Тонсар Татаринов дочь; Муслима Мусалимова 20 лет взята Казанского уезда ихз деревни Нового Кызылъяр Татаринов дочь; Ишмамета ңена вдова Гуля Нормаметова 19 лет взята из Казанской губернии»* [Ревизская сказка, ф. 3, оп. 2, 438]. XVIII гасырга караган эш кәгазьләрендә татар фамилияләре байтак очрый: *Сәгыйть Хәлфин, Әхмәт Сөләйманов, Япей Ибраев, Яхъя Арсланов* һ.б.

XVIII йөз ахырында сәүдә элемтәләрен ныгыту максатында, йомышлы татарларга паспортлар бирелә башлый һәм анда фамилия рәсми атау берәмлеге булып йөри башлый. Казан ратушасының 22 нче фондында татарларга бирелгән паспортлар хакында приходной кенәгәләр, шулай ук паспорттагы мәгълүматларны үз эченә туплаган төргәкләр саклана. Шул рәвешле, рәсми документларда фамилияләрнең кулланылышы рус теленә хас, ягъни ата яки баба исеменә *-ов (-ова), -ев (-ева), -ин (-ина)* кушымчаларын кушу нигезендә барлыкка килеп, XIX йөзнең II яртысы – XX йөз башында тәмам формалашу

процессын кичерә һәм әлеге күренеш татар милли әдәби теленең формалашу чорына туры килә. XIX гасырга караган «Ревизская сказка» материалларында фамилия рус теленә хас антропонимик моделендә үсешен дәвам итә: *Рәхмәтулла Ишметов, Рәхмәтулла Ишекеев, Мөхәммәт Исхаков, Рәхматулла Мөхәммәтов, Ибәтулла Мөхәммәтрәхимов* һ.б.. [Ревизская сказка, ф. 3, оп. 2, ед. хр. 138]. XIX гасыр башларында, фамилия белән беррәттән, отчество антропонимик берәмлегенең дә тәгаенләнүен күрәбез: «*Сабухаккулы Бурханова сынъ Сагитдин, Сабуханкул Бурханов Тумашев, Мурадым Исхаков Уразгелдеев, Абубекир Халитов Уразгелдеев*» һ.б.

XX гасыр башында метрика кенәгәләрендә традицион милли антропонимик калып нигезендә кеше турында мәгълүматлар язылa: *Әхмәтвафа Сәйфи угылы Миңлехәят, Миңлеәхмәт атасы Нигъмәт Вәли угылы; Атасы Шиһабетдин Гыйззәтулла улы Сәләхетдин.* 1916 елгы «Оренбург Диния нәзарәтенең белешмәләрендә» фамилияләрнең татарлар арасында киң таралмавы, ләкин рекрутлыкны билгеләү өчен кирәк булуы турында әйтелә. Нәсел фамилиясе булмаган очракта, рәсми документларда *баба* исеме кулланыла. Затлы нәселләрдә яки йомышлы катлауда фамилия мирас буларак күчкән һәм метрикаларда да фиксацияләнгән.

Антропонимик категория буларак, татар фамилияләренең формалашуы төрле катлау вәкилләре арасында төрлечә бара. Татарларда рус антропонимик системасына хас фамилияләр XV–XVI гасырда югары катлау династияләрендә генә, төрле дәүләт эшләре белән идарә итүчеләр арасында барлыкка килә. Фамилия билгеле бер гаиләне берләштергәнгә, нәселдәнлек, аерымлыкны белдергәнгә күрә ханнар, морзалар арасында киң тарала.

Татарның ярлы катламы гражданлык хокуклары, законнар, милек мөлкәте белән эш итмәгәннәр, җәмгыять тормышында актив катнашмаганнар, шуңа күрә дә алар озак еллар фамилия йөртү хокукыннан мәхрүм булганнар. Түбән катлау вәкилләренең күбесе ерак авылларда яшәгәнгә күрә, фамилия алу аларга Октябрь революциясеннән соң гына мөмкин булган.

Шулай итеп, чыганаклар нигезендә шартлы рәвештә татар фамилияләре формалашуның түбәндәге этапларын билгеләргә мөмкин: борынгы төрки антропонимик системасына хас фамилияләрнең киң таралуы (V–X гасырлар); фамилияләр формалашуының урта гасырлар чоры (X–XV гасырлар); фамилияләрнең татар ханнарында, әмир, морзаларында

формалашуы (XIV–XVI гасырлар); фамилияләрнең йомышлы татарларда һәм татар сәүдәгәрләре арасында таралуы (XVII–XVIII гасырлар); фамилияләрнең урта хәлле шәһәр кешеләре катламында, мөселман руханилары һәм урта хәлле крестьяннар арасында таралуы (XVIII–XIX гасырлар); ярлы катлам шәһәр кешеләре арасында һәм крестьяннар арасында фамилияләрнең формалашуы. Фамилиянең тулысы белән формалашып җитү этабы (XVIII–XIX гасырлар).

## § 23. Татар фамилияләренең төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр

Татар телендә кеше исемнәре, кушаматлар, этнонимнар фамилияләр ясалу өчен нигез булып хезмәт итә торган төп ономастик категорияләрне тәшкил итәләр.

Татар фамилияләренең байтагы кеше исемнәренә (шәхеснең атасы, бабасы, ерак бабасы исеменә) нигезләнеп ясала. Казан шәһәрендәге 10 мең татар фамилиясенең 85% ы кеше исемнәренә нигезләнгән [Хуснуллина, 2009: 8]. Генетик яктан татар фамилияләренең нигезендә яткан кеше исемнәренең зур күпчелеген гарәп-фарсы исемнәре алып тора. Мәҗүси ышануларга, хайваннарны, кошларны, балыкларны, агачларны, үсемлекләрне илаһилаштыруга, ата-баба культына һәм башка дини ышануларга, йолаларга нигезләнгән борынгы төрки компонентлы фамилияләр дә татар исемиятендә аерым урын тоталар. Борынгы төрки кеше исемнәренә нигезләнгән фамилияләр: *Акташев* (Акташ), *Сарбашев* (Сарбаш), *Кучуков* (Көчек), *Сатлыков* (Сатлык), *Уразов* (Ураз) һ.б.

Ислам дине кабул ителгәч, татар исемиятендә гарәп-фарсы исемнәренең таралуы фамилияләрдә дә чагылыш таба: *Зарифуллин* (Зарифулла), *Сәйфуллин* (Сәйфулла), *Хаҗиев* (Хаҗи) һ.б. Гарәп-фарсы чыгышлы кеше исемнәренең мәгънәләре аңлашылмаганга, исем нигезенә төрле иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ялгана, шулай ук төрки нигезле исемнәргә хас кыскару формалары да кулланыла башлый. Шул рәвешле, тулы вариантлы исемнәргә нигезләнгән фамилияләр белән беррәттән, кыскартылган вариантка нигезләнгән фамилияләр дә кулланылышта йөриләр. Тулы вариантлы кеше исемнәренә нигезләнеп ясалган фамилияләр: *Мөстәкыйм – Мөстәкыймов, Кашаф – Кашафов, Бикмулла –Бикмуллин* һ.б.

Кыскарган формадагы исемнәргә иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ялганып ясалаган фамилияләрне дә очратырга мөмкин: 1) -ай, -әй, -ый, -и, -уй, -үй: *Әлмөхәммәт – Әлми – Әлмиев, Бикмулла – Бикмәй –*

*Бикми – Бикмиев* һ.б.; 2) -ак, -әк, -як, -ук, -үк : *Мөстәкыйм – Мөстәк – Мөстәков, Сираҗетдин – Сирук – Сируков* һ.б.; 3) аш, -әш, ыш, -еш, -үш, -уш, -юш: *Акмулла – Акмуш – Акмушев; Габдулла – Абдюш – Абдюшев*; 4) –уч, -үч, -ач, -әч: *Минһаҗ – Минач –Миначев*; 5) -кай/ -кәй *Мәуләкәй –Мәули – Мәуләкәев* һ.б.

Компонентларның кыскаруы нигезендә ясалган фамилияләр үзләре берничә төргә бүленәләр: 1) апокопа, ягъни алынма исемнең икенче өлеше төшеп кала: *Садретдин – Садри – Садриев, Гайнетдин – Гайни – Гайниев, Шәрифулла – Шәриф – Шәрифов* һ.б.; 2) аферезис күренеше ягъни кушма төзелешле алынма исемнең беренче компоненты төшеп кала: *Габденур – Нур – Нуров, Галисәлам – Сәлам – Сәламов, Габдеразыйк – Разыйк – Разыйков* һ.б. 3) синкопа, ягъни алынма сүзнең уртасында булган авазларның һәм иҗекләрнең төшеп калу очраклары: *Гаетмөхәммәтов – Аетмөхәммәтов – Аймәтов* һ.б. 4) әдәби телдә булып та, диалектка тулысынча кереп бетмәгән тартыклар белән бәйле аллонимнарга нигезләнгән фамилияләрдә: увуляр [г] авазының сүз башында яки сүз уртасында әйтелмәве: *Габбасов – Аббасов, Габлегалиев – Абделгалиев* һ.б.

Татарларда фамилияләр ясалышында роль уйнаган антропонимик берәмлек – кушаматлар. Татар фамилияләре арасында *Алабашев* ала+баш патронимик компонентларына, *Чапкынов* – чапкын, *Куркин* – күркә, *Сулагаев – Сулагай, Башмаков* – башмак кебек кушаматларга нигезләнгән фамилияләр билгеләнәләр. Көнбатыш диалектында һәм керәшен татарларында кушаматларны рус теленә тәрҗемә итү юлы белән ясалган фамилияләр дә очрый. Мәсәлән, тугыз – девять – *Девятков,* кучкар – баран – *Баранов*, кәҗә – козел – *Козлов* һ.б. Ясак түләүдән азат ителгән йомышлы татарларны, шул исәптән лашманчыларны казак дип атап йөрткәннәр. Шушы атамага мөнәсәбәтле *Казаков* дигән фамилия кулланыла. Кушаматлар нигезендә ясалган фамилияләрнең түбәндәге төрләрен билгеләргә мөмкин:

1. Кешенең физик һәм психологик халәтен билгеләгән кеше исемнәре: *Акбашев* (ак баш), *Начаров* (начар), *Саранов* (саран), *Батыров* (батыр), *Кылыев* (кылый) һ.б.;

2. Туганлык мөнәсәбәтләрен чагылдырган терминнардан ясалган фамилияләр: *Апаев* (апай), *Тутакаев* (тутакай, өлкән апа), *Бабаев* (карт кеше, бабай), *Атаев* (ата) һ.б.;

3. Чин-сословие титулларына, профессия атамаларына нигезләнеп ясалган фамилияләр: *Алпаутов, Баев, Йөзбашев, Тарханов, Биков,*

*Субашев* һ.б. Билгеле булганча -чы (-че) кушымчасы һөнәр, мәсләк атамаларын ясауда катнаша: *Бакырчин* (бакырчы), *Сунарчин* (сунарчы), *Урмачеев* (урманчы) һ.б.;

4. Хайван һәм балык кушаматларыннан ясалган фамилияләр: *Бурсыков* (бурсык), *Чуртанов* (чуртан), *Боланов* (болан) һ.б.;

5. Корт-кош исемнәреннән ясалган фамилияләр: *Чебешев* (чебеш), *Кучатов* (кучат, этәч), *Күгәрченов* (күгәрчен) һ.б.

Фамилияләр ясауда нәсел кушаматлары аерым урын тота. М.Я. Морошкин нәсел кушаматларының фамилияләргә әйләнүен затлы нәселләрнең геральдик традицияләренә нисбәтле карый, шулай ук укымышлылыкның һәм сәүдәнең алга китүенә бәйле аңлата [Морошкин, 1867: 34], Е.П. Карнович бу күренешне илнең сәяси үсешенә бәйли [Карнович, 1886: 21], А.М. Селищев исә, аерым бер феодалның нәселен билгеләү максатында кулланылган, дип саный [Селищев, 2003: 45]. Мәсәлән, татар шәҗәрәләрендә Дәүекаевлар нәселе билгеләнә. Әлеге нәсел Кырым ханнары даирәсеннән булган Дәүекәйгә нигезләнеп ясалган [ТШ, 2013: 202]. Тубыл татарлары арасында кулланылган *Аксаков, Алашеев, Аракчеев, Артаков, Артыков, Басманов, Беклемишво, Шадрин, Юшков, Алабышев, Барбашин* кебек фамилияләрнең дә нәсел кушаматлары нигезендә барлыкка килүләре билгеләнә [Вафеев, Выхрыстюк, Файзуллина, 2012: 33].

Татар фамилияләрен ясауда топонимик берәмлекләр аерым роль уйный. Әлеге төр фамилияләрнең ясалышы татар халкының күченүе белән аңлатыла. Топонимик берәмлекләргә *-ский, -ская* кушымчалары, яки татар теленә хас *-лы/-ле* кушымчалары ялганып, кайсы төбәккә караганлыкны ассызыклаган фамилияләр барлыкка киләләр: *Ф. Уральская, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Казанский, Самаров, Крымов, Амурский, Бухарский, Минский* һ.б. Шәрык халыкларының зур күпчелегендә, шул исәптән болгар-татарларда Урта гасырның IX–XIV йөзләрендә һәм соңрак әдәбият, сәнгать һәм фән эшлеклеләре фарсы теленнән алынган *-и, -ый, -ви* кушымчасы ярдәмендә туган урыннары һәм ата-бабалар исеменә нигезләнеп ясаган фамилияләр йөртәләр: *Мансур Вәли-Барҗалы, Мәхмүт Болгари, Мәүлә Колый, Г. Утыз-Имәни, Сәйф Сараи* һ.б. XX гасырның 30 нче елларында татар интеллигенциясе арасында фамилияне яки фамилия-тәхәллүсләрне (псевдонимнарны) топонимга нигезләнеп алу шактый активлаша.

Татарларда фамилияләр ясауның тагы бер чыганагы – этнонимнар. Татар антропонимик системасында этнонимнар нигезендә

ясалган фамилияләр аз күзәтелә.. Мәсәлән, *Нугаев* (ногай), *Башкиров* (башкорт), *Татарская* (татар), *Үзбәков (*үзбәк), *Болгарская* (болгар), *Чувашев* (чуваш), *Черкасов, Черкесов* (черкас – (черкес – Карачаево-Черкесс Республикасында яшәгән халыклар), *Байтирәков* (байтирәк – төрки нәсел исеме), *Чермешов* (элек мариларны шулай атаганнар) һ.б.

Апеллятив лексика нигезендә ясалган фамилияләр матур яңгырашлы һәм мәгънәви яктан эчтәлекле уртаклык исемнәренә нигезләнәләр. Аларны ясалма фамилияләр дип атарга мөмкин: *Чибәркәева, Матуров, Ильская, Ватнов, Айский* һ.б.

Татар халкында фамилияләрне калькалаштыру аерым урын тота. Әлеге төр фамилияләр татарларның төрле локаль мәдәниятқә хас вариантларында күзәтелә. Мәсәлән, калька фамилияләрнең зур күпчелеге мишәрләрдә һәм керәшен татарларында очрый. Нигезләрендә төрки сүз яткан фамилияләрне әйтү һәм язу русларда транслитерацион кыенлык тудырганлыктан, калька фамилияләр формалаша. Әлеге фамилияләр, нигездә, тәрҗемә итүдән барлыкка килә. Керәшен татарлары татар исемен яки фамилиясен русчага алыштырганда һәм чит телдән кергән нигезләрне тәрҗемә итеп булмаган очракта бөтенләе белән русчага алыштырганнар: *Зайцев* (куян), *Комаров* (черки), *Кукушкин* (күке), *Журавлев* (торна) һ.б.

Байтак татар фамилияләрендә локаль мәдәниятқә хас булган фонетик үзенчәлекләр чагылыш таба: *Дәрҗеманов (Тәрҗеманов), Рәзмәтов (Уразмәтов), Әднәгулова – Әзнәголова (Әтнәгулова)* – урта диалект вәкилләре; *Еналиева – Юналеева – Йаналеева (Җангалиев), Янишев – Чанишев (Җанишев), Миначев (Минһаҗев)* – көнбатыш диалект вәкилләре, *Шихов (Шәехов), Чаппарова (Җаббарова), Тусмөхәммәтова (Дусмөхәммәтова)* – көнчыгыш диалект вәкилләре.

Татар фамилияләренең семантикасы татар халкының кардәш һәм кардәш булмаган халыклар белән тыгыз мөнәсәбәтен, татар халкының тарихи үсешен, рухи һәм матди мәдәниятенең үзенчәлекләрен, дөньяга карашын чагылдыралар.

## § 24. Татар фамилияләренең орфографиясе һәм транслитерация мәсьәләсе

Татар фамилияләренең дөрес язылышы мәсьәләсе һәрвакыт актуаль булып тора. Фән һәм белем бирү учреждениеләрендә, дәүләт һәм муниципаль структураларда, паспорт, туу турында таныклыкларны әзерләүдә татар фамилияләрен стандартлаштыру мәсьәләсе һәрвакыт

көн кадагындагы мәсьәләләренең берсен тәшкил итә. Әлеге мәсьәлә тел сәясәтендә барган үзгәрешләргә бәйләнелешле рәвештә барлыкка килә, шуңа күрә кеше исемнәренең язылышында һәм транслитерацияләүдә туган кыенлыкларны хәл итүне, татарлар арасында яшәп килгән милли үзенчәлекләрне, фәнни приципларны исәпкә алган «Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге» (2006) дөнья күрә. Һәм хәзерге көнгә кадәр исем һәм фамилияләрнең дөрес язылыш приципları, татар телендәге фамилияләрне рус телендә бирү әлеге сүзлеккә нигезләнеп тормышка ашырыла. Әлеге параграфта фамилияләрнең дөрес язылыш һәм транслитерацияләү мәсьәләсе дә шул сүзлеккә нигезләнеп бирелде.

Татар фамилияләренең зур күпчелеге гарәп-фарсы сүзләреннән ясалган һәм төзелеш-ясалышлары телебезнең фонетик системасына яраклаштырылган. Фонетик принципка нигезләнгән фамилияләр орфографиядә әйтелгәнчә язылалар.

Кушма исемнәргә нигезләнеп ясалган фамилияләрдә исем компонентлары кушылып языла: *Дәүләткилдиев, Солтанбәков, Әхмәтвәлиев* һ.б.

Татар фамилияләрен язуда һәм рус телендә бирүнең аерым бер закончалыклары бар. Шулай да татар фамилияләрен рус телендә бирүдә абсолют төгәл схемалар белән эш итеп булмый.

Тартык аваз хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән ир кеше фамилиясе ясаганда *-ов* кушымчасы ялгана: *Сәфәр – Сәфәров – Сафаров, Әмир – Әмиров – Амиров, Булат – Булат – Булатов* һ.б.

[и], [ый], [ш] авазларына беткән һәм нечкә сузык янындагы [л] хәрефенә тәмамланган ир кеше исемнәреннән ир кеше фамилияләре ясаганда *-ев* кушымчасы ялгана: *Хаҗи –Хаҗиев – Хазиев, Бәдри – Бәдриев – Бадриев, Зәки – Зәкиев – Закиев, Садрый – Сад*рыев – *Садриев, Гамил – Гамилев – Гамилев, Сәйдәш – Сәйдәшев –Сайдашев* һ.б.

Кайвакытта *Хаҗиев, Галиев, Валиев* фамилияләре язуда түбәндәге вариантларын күрергә мөмкин: *Хаҗи – Хаҗеев, Гали – Галеев, Вәли –Вәлиев* һ.б. Мондый язылыш орфографик законнарга туры килми. Татар теленең орфографик кагыйдәләре буенча, кушымча сүзнең нигезенә ялганырга тиеш: *Хаҗи + ев – Хаҗиев, Гали + ев – Галиев, Вәли + ев – Вәлиев*.

Тартык аваз хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз фамилияләре ясаганда, *-ова* кушымчасы кулланыла: *Сәфәр – Сәфәров – Сәфәрова, Әмир – Әмиров – Әмирова, Булат – Булатов – Булатова* һ.б.

*И, ый, ш* һәм нечкә сузык янындагы *л* хәрефенә тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз фамилияләре ясаганда *-ева* кушымчасы кулланыла: *Хаҗи –Хаҗиев – Хаҗиева – Хазиева, Бәдри – Бәдриев – Бәдриева Бадриева, Зәки – Зәкиев – Зәкиева – Закиева, Садрый – Садрыев – Садрыева – Садриева, Гамил – Гамилев – Гамилева – Гамилева, Сәйдәш – Сәйдәшев – Сәйдәшева – Сайдашева* һ.б.

*А, ә* һәм *е* хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән ир кеше фамилияләре ясаганда, *-ин* кушымчасы ялгана. Исемнәрдәге соңгы *а, ә* һәм *е* хәрефләрен бу очракта *-ин* кушымчасы йота: *Гата – Гатин, Хәмзә – Хәмзин* һ.б.

*А, ә*, һәм *е* хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз фамилияләре ясаганда *-ина* кушымчасы кулланыла. Исемнәр ахырындагы *а, ә* һәм *е* хәрефләрен -ина кушымчасы йота: *Гата – Гатина – Гатина, Гайсә – Гайсина – Гайсина* һ.б.

*-улла*га тәмамланган ир кеше исемнәреннән ир кеше фамилияләре ясаганда, кагыйдә буларак, *-ин* кушымчасы ялгана. Бу очракта *-ин* кушымчасы исем ахырындагы *а* хәрефен йота: *Сәйфулла – Сәйфуллин – Сайфуллин, Миңнулла – Миңнуллин – Миннуллин, Гатаулла – Гатауллин* һ.б.

*-улла*га тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз фамилияләре ясалганда *-ина* кушымчасы ялгана. Бу очракта *-ина* кушымчасы исем ахырындагы *-а* кушымчасын йота: *Сәйфулла – Сәйфуллина – Сайфуллина, Миңнулла – Миңнуллина – Миннуллина, Гатаулла – Гатауллина* һ.б.

*-улла*га беткән ир кеше исемнәренә *-ов (а)* кушымчасы ярдәмендә дә фамилияләр ясалырга мөмкин: *Хәйрулла – Хәйруллова, Вәлиулла – Вәлиуллова.* Әлеге вариантлар норма булып килә алмыйлар, ләкин кулланылырга мөмкиннәр.

Татар фамилияләрен ясауда *-ский* кушымчасы күпчелек очракта әлеге фамилияне йөртүченеке булуын аңлата яки урын атамаларын белдергән нигезләргә ялгана. Мәсәлән, *Айский, Болгарский, Ильская, Корбанский, Минский, Казанский, Бугульминский* һ.б. Күпчелек очракта, бу антропонимнарның нигезендә топонимнар, матур эчтәлекле һәм яңгырашлы уртаклык исемнәре булган сүзләр яисә кушамат фамилияләр ята. Әлеге кушымча фамилиянең нигезендә нинди аваз булуына бәйсез ялгана.

Тартык аваз хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән ир кеше отчестволары ясаганда *-ович* кушымчасы ялгана*: Исхак – Исхакович, Якуп – Якупович, Нәсим – Нәсимович* һ.б.

Тартык аваз хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз отчестволары ясаганда *-овна* кушымчасы кулланыла: *Исхак – Исхаковна, Якуп – Якуповна, Нәсим – Нәсимовна*.

*А* һәм *ә* хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән ир кеше отчестволары ясаганда *-ович* кушымчасы ялгана. Бу вакытта *-ович* кушымчасы исем ахырында килгән *а* һәм *ә* хәрефләрен йота: *Сафа – Сафович, Мирза – Мирзович, Гата – Гатович* һ.б.

*А* һәм *ә* хәрефләренә тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз отчестволары ясаганда, *-овна* кушымчасы ялгана. Бу вакытта *-овна* кушымчасы исем ахырында килгән *а* һәм *ә* хәрефләрен йота: *Сафа – Сафовна, Мирза – Мирзовна, Гата – Гатовн*а һ.б.

*И, ый, я, у* һәм нечкә сузык янындагы *л* хәрефенә тәмамланган ир кеше исемнәреннән, *-евич* кушымчасы ярдәмендә ир кеше отчестволары ясала: *Гани –Ганиевич, Вәли – Вәлиевич, Барый – Барыевич* һ.б.

*И, ый, я, у* һәм нечкә сузык янындагы *л* хәрефенә тәмамланган ир кеше исемнәреннән хатын-кыз отчестволары ясаганда *-евна* кушымчасы ялгана: *Гани –Ганиевна, Вәли – Вәлиевна, Барый – Барыевна* һ.б.

Татар исемнәрендә фарсы чыгышлы *җан* компоненты рус телендә ике вариантта бирелә: *джан* һәм *зян* язылышында: *Габдуллаҗанов – Габдуллазянов, Шакирҗанов – Шакирзянов, Рәхимҗанова – Рахимзянова* һ.б.

*Җ* хәрефеннән башланган татар фамилияләре рус телендә *з* хәрефе белән бирелә: *Җәлилов –Зялилов, Җиһаншин – Зиганшин* һ.б.

Татар телендә *һ* хәрефе рус телендә *г* хәрефе белән бирелә: *Заһитов – Загитов, Борһанов – Бурганов* һ.б.

Фамилияләрнең татар язылышында сүз уртасында ике *л* язылса, рус телендә язылган татар фамилияләрендә дә ике л язылырга тиеш: *Сәйфуллин –Сайфуллин, Галимуллин – Галимуллин, Галиуллин – Галиуллин* һ.б.

Татар телендәге *ый* дифтонгы рус телендә *и* белән транслитерацияләнә: *Гыйбадуллин – Гибадуллин* һ.б.

Димәк, татар фамилияләренә хас орфографик законнар бар, икетеллелек шартларында барлыкка килгән транслитерация үзенчәлекләре дә билгеләнә. Фамилияләрнең язылыш законнары телнең үз төзеклеге өчен генә түгел, ә үз халкыбызның көндәлек аралашуында, бигрәк тә рәсми эшләр һәм аңлашулар барышында дөреслек, ачыклык һәм төгәллек өчен гаять дәрәҗәдә әһәмиятле.

## Алтынчы бүлек
# ТАТАР КУШАМАТЛАРЫ ҺӘМ ПСЕВДОНИМНАР

### § 25. Кушаматларның төрләре

Кушамат (кушама (кушма), ат (исем) сүзләреннән кушылу юлы белән ясалган) кешенең рәсми, төп исеменә кушма, өстәмә мәгълүмат бирә. Исем, ата исеме, фамилиягә образлы эмоциональ-экспрессив төсмерләр хас булмаса, кушамат коннотив, эмоциональ-экспрессив төсмерләргә ия мәгънә бирә. Кушамат – кешенең үзенчәлекле сыйфатларын яки җәмгыятьтәге урынын ачу максатында җәмгыять яки кешеләр тарафыннан бирелгән рәсми булмаган исем. Аерым очракларда кушаматлар, рәсми төс алып, исем, фамилия, ата исеме белән бергә дә килергә мөмкин, мәсәлән, *Петр Беренче*, *Бөек Патшабикә* һ.б. Кушаматларның шәхси яки төркемнәргә хас төрләрен аерып карыйлар [Энциклопедический словарь-справочник..., 2008: 146]. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә кушаматка конспирация өчен яки кешеләрдән көлеп, мәзәк өчен аталган исем дип аңлатма бирелә [ТТАС, 2005: 299]. Кушамат – антропонимның бер төре, ул үзенчәлекле характерга ия кешегә аерым бер тормыш шартларыннан бирелгән өстәмә исем [Подольская, 1978: 115].

Рус теле белемендә кушамат рус ономатологлары С.И. Зинин, Н.В. Подольская, А.М. Селищев А.В. Суперанская, Н.Н. Ушаков, З.П. Никулина тарафыннан өйрәнелә. Е.Ф. Данилина И.Ю. Карташева, Т.Т. Денисова, Ю.Б. Воронцова, Ж.Д. Маюрова Е.С. Шостка, А.Н. Лангнер, Н.В. Дранникова, Т.В. Шпар һ.б.ның диссертацияләрендә кушаматларның лексик-семантик үзенчәлекләре теоретик яктан нигезле итеп тикшерелә.

Татар антропонимикасында кушамат Г.Ф. Саттаров, С.И. Гасимова хезмәтләрендә җентекле итеп өйрәнелә. Беренчеләрдән булып, Г.Ф. Саттаровның 1973 елда «Совет мәктәбе» журналында «Татар кушаматлары» дигән мәкаләсе дөнья күрә. Әлеге мәкаләдә галим шәхси кушаматларның 21 төркемен аерып күрсәтә [Саттаров, 1973: 47].

С.И. Гасимова «Татар кушаматларына тарихи-лингвистик анализ» дип аталган диссертациясендә татар кушаматларына комплекслы анализ ясый, аларның лексик-семантик, структур-төзелеш үзенчәлекләрен яктырта, кушаматларның килеп чыгышларын, үсеш закончалыкларын тикшерә [Гасимова, 2006].

Төрки тел белемендә кушамат башкортларда – Г.А. Әмиргалина, кумыкларда – Р.А. Мусаева, каракалпакларда – Ю.Н. Хоҗалепесова, азәрбайҗаннарда – А. Курбанов, М.Н. Чобанов, үзбәкләрдә – Э. Бегматов, кыргызларда – Ш.Жапаров, казакъларда – Т.Ж. Жанузаков, төрек тел белемендә Ю. Кенан Караҗан, Мехмет Семих тарафыннан яктыртыла.

Рус теле белемендә Н.В. Подольская кушаматларның түбәндәге төрләрен аерып күрсәтә: мелиротив кушамат – кешенең аерым бер яхшы сыйфатын, дәрәҗәсен билгеләү өчен хезмәт иткән исем; коллектив кушамат – аерым бер кешеләр төркеменә, гаиләгә, нәселгә, этник төркемгә бирелгән исем; шаярту кушаматы – кешедән шаяртып көлү максатында кулланылган исем; түбәнсетү кушаматы – кешене кимсетү максатында, сүз белән түбәнсетү өчен бирелгән исем; мәктәп кушаматы – мәктәптә укыган чорда бирелгән кушамат [Подольская, 1978: 116]. Рус лингвисты А.М. Селищев исә, кешенең физик кимчелекләрен ачу һәм кешегә хас тискәре сыйфатларны күрсәтү кушамат белән исемне аеруда төп критерий, дип билгели [Селищев, 2003: 407]. Аның фикеренчә, борынгы чорда кушамат сүзнең мәгънәсенә тәңгәл килмәгән, ә сүз тамгасы функциясен генә үтәгән [Селищев, 2003: 408]. Рус теле белемендә локаль культурага бәйле кушаматлар Д.К. Зеленин тарафыннан аерыла. Җирле мәдәнияткә бәйле кушаматларны ул «присловье» дип атый һәм «бер затка гына түгел, ә географик яки этнографик берлектәге төркемгә хас кушаматлар» дип белдерә. Рус теле белемендә әлеге төр кушаматларны Н.В. Дранникова Себер территориясендә яшәүче рус халкының традицион мәдәнияте кысаларында өйрәнә [Дранникова, 2005]. Ул кушаматны тел һәм фольклор арасында торган антропонимик категория буларак билгели. Кушамат фольклоры йола контекстында интертекстуаль мөнәсәбәттә төрле жанрларның барлыкка килүенә китерә. Димәк, кушаматлар аерым бер лексемаларга, мәкаль һәм әйтемнәргә, шигъри текстка, нарративка бәйле килергә мөмкин [Дранникова, 2005: 21].

Т.В. Шпар индивидның тышкы кыяфәтен һәм физик үзенчәлекләрен, холкын-характерын, һөнәри эшчәнлеген яки социаль

статусын билгеләү семантик яктан мотивлашкан кушаматларны ачыклауда төп критерий дип саный. Кешенең физик үзенчәлекләрен чагылдырган кушаматлар күпчелекне тәшкил итеп, кешегә характеристика бирәләр, аның буен, фигурасын, чәч төсен, физиологик кимчелекләрен күрсәтәләр [Шпар, 2012: 14].

Кушамат термины составындагы *ат* сүзенең борынгы төрки телдә булуы аның бик күптәннән барлыкка килүен һәм төп исемгә өстәмә буларак элек-электән кулланылуын раслый. Борынгы заманнарда кушаматлар фамилия функциясен башкарганнар, ягъни кеше исеменә өстәлеп, шәхесне тагын да конкретлаштырганнар. Орхон-Енисей язмаларында, М. Кашгариның «Диване лөгатет түрк» хезмәтендә, исем белән бергә, кушамат та аерым функция үти. М.Кашгариның әлеге сүзлегендә *at* сүзенең беренче мәгънәсе исем дип күрсәтелсә, икенче мәгънәсе – *кушамат* [Махмут ал-Кашгари, 2010: 112].

Борынгы төрки язмаларда кушамат кешене төрле яктан сыйфатлап килә. Мәсәлән, Орхон-Енисей язмаларында кешенең физик һәм психологик үзенчәлекләрен сыйфатлаган кушаматлар төп исемгә ялганып, кешене төрле яктан характерлыйлар. Орхон-Енисей ташъязмаларында еш очрый торган *bilgä* кушаматы «акыллы» [Кормушин, 2008: 318; Orhun Yazıtları, 2008: 129; Древнетюркский словарь, 1969: 99], *alp* 1) «укчы; 2) герой, батыр; 3) курыкмас, кыю» [Кормушин, 315: Orhun Yazıtları, 2008: 120; ДТС, 1969: 36]; *küčlüg* «кыю, көчле» [Orhun Yazıtları, 2008: 156; Древнетюркский словарь, 1969: 323] дигәнне аңлаталар. Шул рәвешле, борынгы төрки чорның акыллы, көчле, кыю кеше образын реконструциялиләр. Исемнәрдән күренгәнчә, *bilgä* «акыллы» компоненты бинар исемнәрдә кулланыла. Эпитафик язмаларда чагылыш тапкан *Билге Каган* акыллы, сакчыл, йомшак күңелле кеше булган, шуңа күрә әлеге компонент, аның исем составында килеп акыллылык мотивын чагылдыра [Айдаров, 1971: 102].

Борынгы төрки язмаларда көч мотивы *Küč* [Orhun Yazıtları, 2008: 156; Древнетюркский словарь, 1969: 322] кушаматы нигезендә чагылыш таба: Küç Barlığ, Küç Kül Tutuk, Küç Tegin, Küç Temir, Kılıç Küç Kara, Küç Kıyagan. Борынгы төркиләр көчнең Тәңре тарафыннан бирелүенә ышанганнар һәм әлеге кешеләрнең дә Тәңре тарафыннан яратылуына инанганнар. Борынгы төрки антропонимик системада беренчел һәм икенчел антропонимик берәмлекләр арасында аерма булмаган, әлеге категорияләр бер вазифа башкарганнар.

922 елда ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүе антропонимик системага да сизелерлек йогынты ясый. Мөселман мәдәнияте тәэсирендә антропонимик системада кушамат һәм исем антропонимик категорияләре арасына чик куела. Гасырлар дәвамында мөселман анторопонимик системасы белән янәшә төрки антропонимик системасы да кулланылышта була. Кешенең тормышын күзалларга мөмкинлек биргән титуллар, кушаматлар озак вакытлар исем белән бергә кулланылышта йөри. Мәсәлән, Алтын Урда чоры чыганакларында да традицион борынгы төрки исемнәрнең кулланылышын күзәтергә мөмкин: *Биш Куртук, Бука Тимур, Бәк Тимур, Ильбука, Ильтутмуш, Караболат, Карабаһадир* һ.б. [Становление ..., 2011]. Алтын Урда чоры чыганакларында борынгы төркиләрнең исемнәрендә хайван атамаларының кушамат ролендә килүе күзәтелә: *Бука Тимур, Биш Бука, Арык Буга* һ.б. Хайван тотемнары белән бирелгән кушаматлар шәхеснең нәсел-нәсәбе, ыру башлыгының исеме турында да мәгълүмат бирәләр.

XVI–XVII гасыр писцовый кенәгәләрендә исем белән кушамат аерылып бетмәгән антропонимик компонентлар очрый: *Күчүк* (кечкенә), *Кәтүк* (кечкенә); *Тулыбай* < «тулы +бай»; *Күкеш, Сытыш* кушаматларының сәламәт булмаган балага бирелүе турында искәртелә [Писцовая книга – 1, Писцовая книга – 2].

XVIII гасырга караган «Ревизия кенәгәләрендә», исемнәр белән бергә, кушаматлар кулланылышы күзәтелә: *Карабаш Гали, Сабай Ишкенә* һ.б. *Карабаш, Сабай* кебек компонентлар кушамат ролен үтәп, рәсми кенәгәләрдә теркәлгәннәр. Тарихи чыганакларда төрки-татар исемнәренең зур өлешен кушаматлар тәшкил итәләр. Татар исемнәре, бер яктан, кушамат буларак кыскарып, үзгәреш кичерсә, икенче яктан, әлеге кушаматлар гарәп һәм рус теленең яңгыраш үзенчәлекләренә бәйле бозыла: *Мамай (Мәмеш, Мәмәд, Махмед, Мөхәммәд), Камай (Камалетдин), Колай (Коләхмәт), Малей (Мәли, Малик), Шамса, Шемай, Шәмәй, Шәмси (Шәмсетдин), Баһау, Багыш, Баһдан (Баһаветдин*). Тарихи чыганакларда кешенең үзенчәлекләрен сыйфатлаган кушаматлар да бирелгән: *Кылый Гали, Тупас, Чуан Төмән, Йомык, Алабаш, Елый Бирде, Каражан, Аксак Тимер, Тәбәнәк, Аңнамас, Артык* [Ревизская сказка, ф.3, оп. 2]. *Мамайның* (Олы Урда ханы) икенче исеме буларак язмаларда «Тетякъ» (Титәк, Тинтәк) атамасы да күрсәтелә.

Кушаматлар аралашуны җиңеләйтү, кем турында сүз алып баруны төгәл, ачык итү өчен ярдәм итә торган антропонимик чара булып

тора. Г.Ф. Саттаров кушаматларны зур өч төркемгә бүлеп карый: 1) нәсел-ыру кушаматлары, 2) шәхси кушаматлар; 3) җирле мәдәнияткә нисбәтле кушаматлар [Саттаров, 1973: 46]. Әлеге төркемнәрнең үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекләре бар. Әлеге кушамат төрләренә тукталып китик.

Нәсел-ыру кушаматлары бер генә шәхескә карамыйча, туганлык мөнәсәбәтләрендә торган бер төркем, берничә гаилә, нәсел кешеләрен үз эченә ала. Бу төр кушаматларның үзенчәлекле ягы булып, буыннан буынга күчүчәнлек, дәвамчанлык санала. Мәсәлән, *Чупай* кушаматы нәсел чылбырын бәйләү вазифасын үти [Татар шәҗәрәләре, 2013: 98].

Димәк, нәсел-ыру кушаматы кешене билгеле бер нәсел, гаилә эченә алып керә. Әлеге төр кушаматларның килеп чыгышын һәм мәгънәләрен татар халкының борынгы бабалары яшәгән чордан, болгар катлавыннан һәм башка кардәш һәм кардәш булмаган телләр материалларыннан эзләгәндә ачыклап була. Кушаматның төрләре әдәби әсәрләрдә кулланылып, этномәдәни текст вазифасын үтиләр һәм әдип иҗат иткән чорга хас үзенчәлекләрне, образлар системасын барлыкка китерүдә, персонажларның үзара мөнәсәбәтләрен интерпретацияләүдә зур роль уйныйлар. Татарларның җирле мәдәниятендә, аерым алганда Түбән Новгород татарларының Камка авылында *Нәмай, Тукай, Бакнәй* кебек нәсел кушаматларының билгеләнүе ассызыклана [Милли-мәдәни мирас, Түбән Новгород, 2011: 26]. Әдип тарафыннан әсәр тукымасына кертелгән кушаматлар әсәрнең әдәби-эстетик концепциясен тормышка ашыруның бер чарасы булып, аның темасын һәм тирән мәгънәви идеясен ачарга ярдәм итәләр. Мәсәлән, нәсел-ыру кушаматларына Г.Ибраһимов хикәяләрендә аерым игътибар ителә. Әлеге төр кушаматларны куллану авторга нәсел җебен барлауда оста әдәби алым буларак ярдәм итә: «Бара торгач, «ала» сы төшеп югала, «саескан» исеме «малайга кушамат булып ябышып кала. Зурайгач, бай крестьян булгач та төшми. Сөләйманнан нәсел буенча Нурыйларга күчә. Кимсетеп әйткәндә: *“Саескан”* дип, *“Саескан Нурый”* дип, *“Саескан Нурый Фәтхиясе”, “Саескан Нурый балалары”* дип йөртәләр».

Шәхси кушаматлар дип конкрет шәхескә караган кушаматны атыйлар. Конкрет шәхесне белдереп, шәхси кушамат һәрвакыт берлек санда гына кулланыла: *Шөлди, Кабартма, Морҗа, Нәкыйп Борчак* һ.б. Нәсел-ыру кушаматларыннан аермалы буларак, барлык шәхси кушаматларның да диярлек барлыкка килү мотивлары, сәбәпләре билгеле. Татар әдәбиятында язучылар шәхси кушамат тагуны аерым

әдәби алым итеп кулланалар, һәм әдәби әсәрләрдә кушамат тагылуның мотив-сәбәпләрен ачыклаган күп кенә матур үрнәкләр белән очрашырга мөмкин. Мисал итеп, Ә.Сәлах «Аккан сулар...» әсәрендә авыл җирлегендә кушамат тагу турында болай дип яза: «Безнең авыл халкы бер-берсенә кушамат куярга хирыс. Ялгыш авызың кыйшайса да сиңа кушамат чәпәп куялар. Капка Минач абзыйның кушаматы бер генә түгел берничә иде. Сугыштан яраланып аксак аяк белән кайткан-да бу абзый: «Мин бик зур елга – Кунай елгасын кичкәндә ранный булдым» – дип сөйләп йөргән өчен безнең мишәрләрдә шул җиткән. Ләкин алдан бирелеп дистәләрчә еллар буе аклап килгән «Камка» кушаматы үз позициясен тиз генә бирмәгән: *Минач* абзый элеккечә «Камка» булып калган, ә үсеп килгән улы Салихка «Кунай» кушаматы тагылып киткән» (Казан утлары, № 3: 7–8). Шәхси кушаматлар реаль чынбарлыкка туры киләләр һәм аның белән тыгыз бәйләнештә торалар. Әлеге төр кушаматлар шәхеснең яшь үзенчәлекләренә, мәсләгенә, характер сыйфатларына мөнәсәбәттә барлыкка киләләр. Кайберләре исә теге яки бу эшне башкарган вакытта да тагылып калалар: *Итекче, Тимерче, Кырык тартмачы* һ.б.

Мари Эль Республикасы Бәрәңге районы экспедициясендә түбәндәге шәхси кушаматлар тупланыла: *Кәтүкнекеләр, Мамыклар, Черки Зиннуры, Утыр Мәннан, Козгын Абдулы, Тукран, Көртлек, Чыпчык, Таракан Мансуры, Күкәлти, Эчәге Мансуры, Арыш Абдулы* һ.б.

Җирле мәдәнияткә бәйле кушаматлар туганлык мөнәсәбәтләрендә тормаган, ләкин территориаль яктан бәйләнелешле булган кешеләр тарафыннан берләштерелгән төркемгә әйтелә. Әлеге кушаматлар күплек санда бирелә, ә берлек санда кулланылса, шул төркемнең, коллективның бер вәкилен генә күрсәтә. Мондый кушаматлар аерым бер җирле берләшмәне идентификацияләүгә тәэсир итә торган төрле стереотип күзаллауларга нигезләнеп ясалалар. Мәсәлән, һәрбер коллективка кушамат «үз» һәм «чит» төркемнәре белән билгеләнгән берәр сыйфат буенча бирелә. Бер үк номинация төрле җирле төркемнәрдә төрле сыйфатларга ия булырга мөмкин. Томск татарларының топонимиясен өйрәнүче О.Р. Хисамов саз ягы татарларын «*тычкан тухум*», яки «*черки тухум*» дип аталып йөртүләрен билгели [Хисамов, 2016: 11]. Биектау районы Дөбьяз, Әрәз, Торнаяз, Каракүл авылларында яшәүчеләрне Казан базарына сөт, катык ташыгынга «әче катыклар» дигән кушамат белән йөртәләр. Әлеге кушаматлар локаль-территориаль кушамат төренә керә.

Димәк, татар антропонимик системасында кушаматлар, этномәдәни тирәлекнең мөһим берәмлеге буларак, исем йөртүче белән исем бирүче арасындагы уңай яки тискәре мөнәсәбәтне белдереп, кешегә хас характер үзенчәлекләрен яктыртып, аерым бер локаль-территориаль, нәсел-ыруга хас үзенчәлекләрне чагылдырып, исем бирүченең прагматик максатларын тормышка ашырып, шәхси һәм тирә-юнь, мохит, дөнья картинасын ачуда исем бирү сәнгатенең мөмкинлекләрен тулысы белән реальләштергән антропонимик берәмлекләрне тәшкил итәләр.

## § 26. Татар халкында кушамат бирү мотивлары

Кушаматлар, номинатив, шәхесне идентификацияләү, аеру вазифасыннан тыш, әдәби стилистик функция дә үтиләр. Вербаль-семантик яктан караганда, кушаматларда исем бирү сәнгатенең төрле мөмкинлекләре ачыла. Когнитив яктан кушаматлар милли үзбилгеләнү һәм милләтнең характер үзенчәлекләрен чагылдыру мөмкинлегенә ия. Прагматик яктан караганда, кушаматлар билгеле бер социаль катламның төрле коммуникатив шартларын яктырталар. Мәсәлән, татар кушаматлары арасында билгеле бер вакыйгаларга бәйле кушаматлар бар: *Капчык Мөхәммәтҗан* (колхозда арыш урлауга бәйле вакыйгага нисбәтле), *Баттат Фәүзия* (батат ашау вакыйгасына бәйле тагылган кушамат) һ.б.

Матур әдәбиятта кушаматлар әсәр тукымасында эмоциональ-экспрессив төсмерләрне куертып, образны тагы да калкурак күрсәтү максатында, татар авылы колоритының тулы бер палитрасын чагылдырдыруда язучылар тарафыннан отышлы кулланыла. Г. Ибраһимов әсәрләрендә кулланылган берничә кушаматка мисаллар: Буйга зурлыгы өчен аны *Озын Хафиз* дип йөртәләр (Г. Ибраһимов «Алмачуар»); Күршенең *Калын Низами* дигән берәү калага бара икән (Г. Ибраһимов «Тирән тамырлар»); «Аның артыннан Назлы килен Гыйззелбанат, Төхфәтнең хатыны *Усал тел килен Мәрфуга,* аларга ияреп бергә үскән кызлар...» (Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми»).

Әгәр язучы кушаматны милли антропонимиконының үзенчәлекләренә туры китереп кулланса, образның семантик-стилистик яктан мәгънә күләме арта яисә әсәр турында тулаем фикер тирәнәя. Кушамат шәхеснең яшен (*Йөз яшь Сафа*), җәмгыятьтәге урынын (*Тимерче Фатыйх, Пешекче Фатыйма*), физик һәм психологик кимчелекләрен (*Чатан Шәмси, Чукрак Хәлил*), шәхескә карата булган тискәре яки уңай мөнәсәбәтен (*Яхшы Рамилә, Яман Фәрит*) дә ча-

гылдырырга мөмкин. Нигездә, әлеге шәхес турындагы мәгълүматлар әсәр контексты эчендә ачылалар. Хәзерге татар әдәбиятында Ахир, Ф. Бәйрәмова, Р. Газизов, Н. Гыйматдинова, Т. Галиуллин, Ә. Сәлах, Батулла кебек күренекле язучылар иҗатларында кушаматлар әдәби алым буларак, оста файдаланылалар: *Кыргыз Әхмәдулла* (Ә. Сәлах «Аккан сулар...»); *Бәкер Вафич* (Р. Газизов «Гаян абый хат укый»); *Пытыр Хәлимәсе* (Ахир «Кәбисә елы») һ.б.

Тотемистик карашлар нигезендә барлыкка килгән кушаматлар традиция нигезендә хәзерге татар антропонимик системасында да саклaverалар. Шәхси кушаматлар исә теге яки бу шәхеснең төрле сыйфатларына нигезләнгән метафорик эчтәлек биреп, чыгышлары белән реаль чынбарлыкка тыгыз бәйләнештә булалар. Алар кешенең гомуми, хосусый, физик һәм рухи сыйфатларын, һөнәренә, яшәү урынына һәм башка мотивларга нигезләнеп кушылалар. Балага исемне, тугач ук, әти-әнисе бирсә, кушаматны кешенең яшәү дәверенең төрле этапларында коллектив, җәмгыять куша. Бу төр кушаматларның составы иҗтимагый һәм мәдәни тормыш контекстында даими үзгәреп, яңарып торалар.

Шәхси кушаматларның күбесе кешенең теге яки бу сыйфатын, рухи яки физик билгеләрен турыдан-туры атау юлы белән ясала: *Ут Җамал, Баламык Дания, Мыштыр Рушан, Пөхтә Камилә, Гамьсез Фәрит* һ.б. Кешенең рухи яки физик сыйфатларын теге яки бу предметка, күренешкә, кош-корт яки хайванга охшату нигезендә барлыкка килгән кушаматлар байтак. Мәсәлән, *Күсе* – төрле әйбер җыярга һәвәслек, *Борча* – кечкенә буйлы, бик хәрәкәтчән яки тиктормас кешегә тагылган кушамат, *Акылбай* – акыллы булганга тагылган кушамат, *Чүпрәкбаш Дилбәр* – надан булганга бирелгән кушамат һ.б. Шәхси кушаматлар кешенең һөнәренә (*Итекче Гата, Маляр Саҗидә* һ.б.), эшләү яки яшәү урынына (*Су буе Гайшә, Мамадыш Саимә, Түбән оч Лилия* һ.б.), милләтенә (*Үзбәк Сания, Әрмән Галиясе*), социаль чыгышына (*Зимагур Азат, Укытучы Алия* һ.б.), берәр сүзне еш кабатлау яки үзенчә әйтүенә (*Р-Р-Р-Р Әдилә, Ватык Трактор Сәмих*), рәсми исемен бозып әйтүгә мөнәсәбәтле (*Сәмук* – Сәмигулла, *Әптерүч* – Габдерәүф, *Шәмәй* – Шәмсетдин һ.б.) барлыкка килгән. Топонимнарга яки микротопонимнарга нигезләнеп ясалган кушаматлар, башлыча, шәхеснең нинди торак пункттан булуына яки кая да булса барып кайтуына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килеп, этномәдәни тирәлеген билгелиләр: *Норма Сәми, Норма Ягъфәр, Чишмә башы Газиз, Өчиле Зөлкамал, Көҗмә Микулай* һ.б.

Этнонимнарга нисбәтле кушаматлар кешенең теге яки бу милләт вәкиле булуына яки әлеге милләт вәкиленә физик яктан охшашлыгына ишарәли: *Чирмеш, Үзбәк бабай, Мишәр Галия* һ.б. Матур әдәбиятта исә әлеге кушаматлар шәхеснең милли чыгышына яки аның башка этник төркем вәкилләренә берәр ягы белән охшашлыгына яисә бәйләнешенә нисбәтле кулланылганнар.

Татар антропонимик системасында антропонимнарга мөнәсәбәтле кушаматлар билгеләнәләр. Әлеге төркемгә караган кушаматлар шәхеснең ерак бабасына бәйле яки аны икенче берәүгә охшату җирлегендә барлыкка килә: а) шәхеснең нәселенә нигез салган ерак бабасының исеменә нисбәтле кушаматлар: *Гайфи Исхагы, Шаһи Саниясе, Куян Сәхие, Куян Зарифы, Куян Кәримулласы, Куян Вакыйфы; Галәви Шакиры*; ә) шәхеснең үз исемен бозып әйтү нигезендә ясалган кушаматлар: *Сөләй Әмәт* (Әхмәтне бозып әйтү юлы белән барлыкка килгән кушамат), *Нурла* (Нурулла исеменнән), *Дәлтүн* (дальтон сүзен дөрес әйтә белмәгәнгә), *Прох* (Прохов Вадим).

Шәхеснең кәсебе-һөнәренә, профессиясенә яки эшләү урынына мөнәсәбәтле кушаматлар да чагылыш таба. Мондый кушаматлар күбесе хәзерге профессия атамаларына нигезләнеп ясалганнар. Шулай ук хәзерге вакытта онытылып бара торган һөнәр, кәсеп исемнәренә нисбәтле кушаматларның да очравы күзәтелә: *Сунарчы Сәбәк, Атҗабар Миннисα, Итекче Җиһанша, Тимерче Нотфый; Көтүче Хөснетдин, Прит Әлфинур, Силсәвит Мәдинә, Умартачы Равил* һ.б. Шәхеснең яки аның ата-бабаларының титулына, социаль чыгышына мөнәсәбәтле кушаматлар да очрый: *Зимагур Булат, Алпавыт Шәйхи, Зимагур* һ.б.

Кеше характерындагы аерата калку тискәре яки уңай сыйфатлар атамасы да, еш кына, аңа кушамат итеп тагыла: *Түтүт Гарифы, Сәдака Миңнехан, Шәвәли Шәвәлиеч; Канәгать Мыштым, Псих Сәлимгәрәевич; Кире Урай, Дуамал Касыйм, Җүләр Әйдүш* һ.б. Г. Ибраһимов әсәрләрендә персонажларның эш-хәрәкәтләре, төс-кыяфәте, сөйләшү манерасы, мәсләк үзенчәлекләре нигезендә тагылган кушамалар билгеләнә: «Аны һәммәсе кимсетәләр, яратмыйлар, җәберлиләр, теләгәнчә мыскыллыйлар, исеме белән дәшмичә башы зурлыктан «Тубал» дип кенә йөртәләр» (Г. Ибраһимов «Уты сүнгән җәһәннәм»). Биредә кулланылган *тубал* сүзе денотатның зур башлы булуын гына сыйфатлап калмый, ә хикәядә *Тубал*ның аң-белемгә, гыйлемгә омтылучан булуын ассызыклау өчен файдаланыла. Персонажның ку-

шаматы «тубал булу», ягъни артык күп уйлаудан яки шау-шудан баш авыраю дигән мәгънәгә дә барып тоташа.

Шәхеснең тышкы физик билгеләрен характерлый торган кушаматлар хәзерге татар әдәбияты әсәрләрендә зур күпчелекне тәшкил итәләр: *Бүдәнә Салих, Бәләкәй Камилә, Сары Сәвия, Агулы теш Миңлегали, Зур колак Иван, Ташмаңгай, Тимертән, Киңкүкрәк Иван, Таз, Чатан Хәниф, Шадра, Таз, Бөкре*. һ.б. Шәхеснең кайсы да булса әгъзасының җитешсезлегенә нисбәтле кушаматлар: *Кылый Нигъмәтҗан, Бөкре Гафият, Чулак Газиз, Чатан, Кылый, Аксак* һ.б.

Кушаматта кулланылган квалитативлар иркәләү-кечерәйтү төсмерләренең киң спектрдагы мәгънәләрен бирәләр, үз чиратында әлеге коннотатив мәгънәләр кешегә карата гына түгел, ә сөйләм субъектына карата да мөнәсәбәт чагылдыралар. Кешенең төс-кыяфәтен, хәрәкәтләрен, тормышка карашын характерлый торган кушаматлар арасында, нигездә, тискәре семантикага ия сүзләр урын алган. Әсәрдә башка кешеләрдән аеру максатында, квалификатив принцип нигезендә, теге яки бу сүзнең семантик тулылыгына басым ясаган кушаматлар персонажның тышкы кыяфәтенең үзенчәлекләрен сыйфатлыйлар: «Тирә-якта аларның авыллары Бикъярны "Көяз", дип, "Бикъяр көязләре" дип дип мыскыллап сөйлиләр» (Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми»). «Базарда юк кына нәрсә өчен теге Сыераяк Хәмди белән әрләшеп китте» (Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми»). «Тиле Әхмәт, үз ирке белән диярлек, килеп бирелде» (Г. Ибраһимов «Тирән тамырлар»).

Нәсел тамгасын белдерә торган хайван атамалары яки билгеле бер хайван, кош-корт ияләренә охшату нигезендә барлыкка килгән кушаматлар да очрый: *Бүре Гыйбадулласы, Бүре Бадул, Бүре Әскый, Күгәрчен Мөхетдин, Шимпанзе, Кабантеш Сәгъдәт, Чикерткә Рәхимәсе* һ.б. Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендә *Кәҗә Солтаны* кушаматы тагылуын болай дип аңлата: «Сабираның атасы Солтан заманында сунарчы булган, диләр. Бервакыт үзенең бер дус адәмендә әче балны эчеп, кызыбрак чыккан да зур мөгезле ак кәҗәне болан дип, поши дип, аты белән куып киткән, диләр. Авылдагы дошман байлары, җәй, кыш мәптекккә ятучы бер аксак хәлфәгә тутырган тавык, илле тиен акча биреп, зур бәет чыгарттылар. Бу бәетне, өйдән өйгә кереп, садака җыеп йөрүче бер сукыр хәерчегә ятлаттылыр. Халыкка бик кызык тоелды. Бер тиен акча, ике йомырка биргән һәркемгә сукыр хәерче Солтан турындагы бәетне укып чыга торган булды. Шуннан солтанга – Кәҗә Солтан дип ат куштылар».

Шәхес белән бәйләнешле берәр кызыклы вакыйга яисә аңа карата әйтелгән нинди дә булса көлкеле сүзгә нисбәтле кушаматлар да аерым урын тоталар. Кушаматлар көлке тудыру алымы буларак кулланылалар һәм әсәр тукымасына реальлек төсмерләре өстиләр. Мәсәлән, язучы Р. Газизов «Кичер, кичерә алсаң...» әсәрендә геройга кушамат тагылуын болай дип аңлата: «Безнең авылда Вәгыйз абыйның гына ике кушаматы бар. Берсе – Герман, чөнки бу – аның яраткан сүгенү сүзе. Икенчесе соңгы елларда гына тагылды. Анысы – Күкеле сәгать. Әйе шул. Нәкъ тәрәзәсе шалт итеп ачылып, аннан ялт итеп Вәгыйз абый башы атылып чыккач, авылдашлары таккан кушамат. Авыл тарихында булмаган байлык, бер кешегә ике кушамат». А. Хәлимнең «Сәер никрут» хикәясендә *Күгәрчен* Мөхетдин исемле персонажның кушаматы яраланган күгәрчен вакыйгасына бәйләнелешле аңлатыла. Әсәрдә Мөхетдин бодай өеменнән кошларны куганда, агач көрәк белән сугып, бер күгәрченне каты җәрәхәтли. Шул яраланган кошны ике учына алып, ул ярты көн елап утыра. Күгәрченне өенә алып кайта. Медпунктка фельдшер янына алып төшә. Шуннан соң гына күгәрчен исән кала. Әлеге вакыйгадан соң Мөхетдинне *Күгәрчен Мөхетдин* дип атый башлыйлар.

Кушаматлар эмоциональ-экспрессив тирәлектә барлыкка килеп, язучылар тарафыннан отышлы файдаланып, әдәби алым буларак кулланылалар. Хәзерге татар әдәбиятында әлеге әдәби алымның бик уңышлы мисаллары күзәтелә. Әдәби әсәр тукымасына кертеп җибәрелгән кушаматлар телнең этномәдәни тирәлегенең моделен гәүдәләндереп, әсәрнең төп мәсьәләләрен һәм тирән фикерләрен, әдәби-эстетик концепциясен чагылдыру ролен үтиләр. Кушаматларның антропонимик трансформацияләре сюжет линияләрен куерту, эмоциональ-экспрессив яки юмористик төсмерләр бирүдән тыш, геройга хас характер сыйфатларын ачарга да ярдәм итәләр.

## § 27. Псевдонимнар турында төшенчә

Ономастик система – һәрвакыт үсеш-үзгәреш кичереп, һәрдаим тулыланып торган күренеш. Иҗтимагый тормышта һәм әдәбиятта аерым урын тоткан социаль төркемнәргә (язучы, сәясәтче, журналист, артист, рәссам, галим һ.б.га) хас антропонимик берәмлекләр – псевдонимнар да һәрдаим тулыланып торалар. Татар тел белемендә XX йөзнең 60 нчы елларыннан башлап, кеше исемнәре, кушаматлар, фамилияләр антропонимиканың өйрәнү объектлары буларак төрле

аспектларда өйрәнелеп, системалаштырылып килсәләр дә, псевдонимнар антропонимик мәсьәләләр яссылыгында җентекле тикшеренүдән читтә кала бирәләр һәм лингвистик яктан гаять дәрәҗәдә кызыклы өйрәнү объектын тәшкил итәләр. Татар псевдономастикасының өйрәнелә башлау тарихы гомумономастик проблемаларның җанлану чорына – XX гасырның 60 нчы елларына туры килә. Билгеле булганча, бу чорда рус теле белемендә ономастика мәсьләләренең калкуы, аның объект-предметы билгеләнүе, төп концептологик терминнарның формалашып, кулланылышка керә башлау шаукымы башка милли телләрнең фәнни юнәлешләрендә дә чагылмыйча калмый. Псевдонимнарны өйрәнү мәсьәләсе Г. Саттаров, Ш. Абилов, М. Бурнашева, М. Мәһдиев, М. Бөдәйли, З. Рәмиев кебек галимнәрнең мақәләләрендә чагылыш таба. Газета-журналларда чыккан әдәби әсәрнең кайсы язучыныкы икәнлеген билгеләү максатында, әдәби әсәрнең тел-стиль үзенчәлекләрен ачыклау белән беррәттән, аның нинди псевдоним кулланyуын ачыклау да зур әһәмияткә ия. Шуңа күрә татар авторының псевдонимнарын ачыклап, өйрәнү эше, нигездә, текстологлар, әдәбиятчы галимнәрнең игътибарын күбрәк җәлеп иткән. 1960 елда М. Бурнашева, беренчеләрдән булып, псевдономастиканың фәнни нигезле методологиясен булдыра, аның өйрәнелергә тиешле фән булуын әйтә, псевдонимнарны беренчел итеп барлауның текстологиядә гаять дәрәҗәдә әһәмиятле эш икәнлеген ассызыклый, «бер язучының барлык әсәрләрен туплау өчен, иң башта аның нинди псевдоним белән язылганлыгын» билгеләүне мөһим дип саный [Бурнашева, б. 175]. Татар ономастикасына нигез салучы Г.Ф. Саттаров та псевдонимнар мәсьләсенә туктала, аерым бер язучыларның иҗаты мисалында аларның тел системасындагы әһәмиятен раслый. Псевдонимнар әдәбиятчы галимнәр, текстологларның (Ш. Абилов, Х. Госман, А. Әхмәдуллин, З. Рәмиев, М. Мәһдиев, М. Бөдәйли һ.б. ның) тикшеренүләрендә әдәбият, текстология фәннәренең метод-ысулларына нигезләнеп, әдәби чор, әдәби текст, язучы контекстында каралалар. Әдәбият, сәнгать, журналистика әһелләренең псевдонимнарын аерым бер сүзлек итеп эшләп чыгару эше М. Бөдәйли тарафыннан башкарыла. Әлеге сүзлек 1969 елда «Казан утлары» журналының 1 нче, 2 нче саннарында кыскартылган вариантта дөнья күрсә дә, аерым бер сүзлек буларак басылмый. М. Бөдәйлинең псевдонимнар сүзлегенең кульязмасы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. Әлбәттә, бүгенге көндә

татар псевдонимикасының кулланылыш сферасы киңәя һәм һәрдаим үсеп-үзгәреп тора. М.Бөдәйли, кулланылыш ягыннан чыгып, псевдонимнарны өч төргә бүлеп карый: күпләргә таныш булган язучы псевдонимнары; 2) заманында киң җәмәгатьчелеккә билгеле булган, әмма хәзерге көндә аз кешеләргә билгеле псевдонимнар; 3) хәзерге көндә аз билгеле булган псевдонимнар. М. Мәһдиев псевдоономастиканы әдәбият тарихының әһәмиятле тармагы дип билгели. Әлбәттә, псевдоономастиканың язучылар аның шәхесен тану өчен этрафлы мәгълүмат бирүдә әһәмияте зур булса да, псевдонимнар, беренче чиратта, антропонимик берәмлекләр, шуңа күрә алар лингвистик җәһәттән өйрәнүне таләп итәләр. Псевдонимнарны өйрәнү тел (этимология, концептология, этнолингвистика, когнитив лингвистика кебек тармаклар белән дә бәйләнеш-мөнәсәбәттә), әдәбият, текстология фәннәренең методчаралары ярдәмендә тикшерелеп, шул фәннәр белән системалы бәйләнештә торырга тиеш дип саныйбыз. Әдәбиятчы-текстолог З.З. Рәмиев текстология фәненең метод-ысулларын кулланып, Г. Тукай псевдонимнарын аерым өйрәнеп, аларга җентекле анализ ясый, Г. Тукайның 67 гә якын псевдонимын тикшерә. Ул 2004 елда Казан дәүләт университетында татар псевдономастикасы юнәлешендә фәнни яктан гаять этрафлы һәм кызыклы махсус курс та алып бара.

Билгеле булганча, лексик берәмлекләр һәм, шул исәптән антропонимик берәмлекләр дә, кешенең тирә-юнен чагылдыру белән бергә, татар халкының үзаңын, теләк-омтылышларын, тормышка карашын, автор позициясен, дөнья тирәлеген анализларга мөмкинлек бирә, шул җәһәттән, элеге хезмәтебездә татар псевдонимнарын когнитив, ономасиологик аспектта тикшерүне дә максат итәбез.

Псевдоним (грек сүзе, «ялган исем йөртүче» дигәнне аңлата) – иҗтимагый тормышта чын исем белән бергә, яисә аның урынына, кулланылу өчен уйлап чыгарылган исем [Подольская, 1988: 117]. Төрки халыкларда псевдоним сүзе урынына т ә х ә л л ү с, м а х л а с, м ө с т ә г а р исем терминнары кулланыла. Псевдоним урынына кулланылган төшенчәләр бар: к р и п т о н и м – билгеле бер шәхес белән бәйләнешен аеру мөмкинлеге булмаган язучының әсәр ахырына куелган имзасы яки авторның чын исемен яшерүгә корылган атама; г е т е р о н и м – авторның әсәре эчтәлегендә чагылдырган һәм аерым өлешләрендә кулланган исеме; а л л о н и м – автор тарафыннан башка бер шәхеснең исемен кулланып әсәр иҗат итү; н и к н е й м – интернет коммуникациясендә кулланылган яшерен исемнәр.

Рус әдәбиятында псевдонимнар дини язма китаплардан үсеш алалар. Беренче революция елларында псевдоним астында иҗат итү аеруча киң колач ала. Бу елларда В.И. Ульяновның *Ленин* имзалары белән мәкаләләре языла. Аның йөздән артык псевдонимы булган. Октябрь революциясеннән соң ул В.И. Ленин исемен даими куллана башлый. Русларның исем бирү традициясендә псевдоним фамилияне, исемне, отчествоны, хәтта исем формуласын да алыштырырга мөмкин. Псевдонимнар ясалма номинациянең актив берәмлекләреннән саналалар. Адресатка булган мөнәсәбәт апеллятив лексиканың вазифасы белән билгеләнә.

Псевдоним – сүз буларак, телнең аерылгысыз өлеше һәм аның законнарына буйсына, ул лингвистик методлар белән өйрәнелүне таләп итә. Ул кешенең күзаллауларын, телне тоемлауны гына чагылдырып калмый, юморга да ишәрәли. Псевдоним сайлау кешенең сөйләм сәнгатенә булган ихтыяҗын реальләштерә. Аның мәгънәсе экстралингвистик реальлекне, шул ук вакытта, телдәге эчке мөнәсәбәтләрне генә түгел, ә прагматик һәм психолингвистик юнәлеш белән дә бәйлелекне күрсәтә.

Псевдоним, уйлап чыгарылган, ясалма, яшерен сүз буларак, номинатив функция башкара. Аның номинатив-эзотерик роле иҗтимагый бәяләмә, экспрессив функцияләр белән тулылана төшә. Чын исемне яшерүнең объектив һәм субъектив сәбәпләре бар: бер яктан, чын исемне яшерү фамилиянең яки исемнең яңгырашы килешле булмавы белән аңлатылса, икенче яктан, цензурадан качу, чын фамилиянең полемикага сәбәп булуыннан курку белән аңлатыла.

Исемне яшерү йоласы бик борынгы чорлардан ук килә. Беренче псевдонимнар М.Кашгариның «Диване лөгатет төрк» әсәрендә үк теркәлгәннәр. Китапчылык барлыкка килү чорларында псевдонимнарны куллану тагы да активлаша. XIII–XIX гасырларда да әдипләрнең, галимнәрнең псевдонимнар куллануы билгеле: *Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Г. Кандалый, Акмулла, Мәрҗани* һ.б. Билгеле булганча, Беренче рус революциясеннән соң, татар тормышындагы зур җанлылык, татар матбугатының барлыкка килүе әдәби әсәрләр, тәнкыйть мәкаләләре язуга этәрә, псевдонимлыкка тагы да киң перспективалар өсти. Шул нәүбәттә XX гасырда татар псевдоономастиконының үсеше күзәтелә. Авторлар цензура тәнкыйтеннән куркып, исемне, фамилияне, кешенең җенесен, милләтен псевдоним астына яшерергә мәҗбүр булалар. Псевдонимнарның семантикасы мәгънә эчтәлегенең

күптөрлелеге белән билгеләнә. Псевдонимнар язучының милләтен, туган урынын, характер үзенчәлекләрен чагылдыруга хезмәт итәләр.

## § 28. Татар псевдонимнарының төрләре

Әдәби псевдонимнар телдә һәм сөйләмдә кулланылган функцияләреннән чыгып 1) характеристика бирә торган, 2) эмоциональ-экспрессив, 3) символик, 4) комик кебек төрләргә бүләргә мөмкин. Кеше дөньяны, тирә-юньне танып-белүдә төрле когнитив-ономасиологик чаралар куллана. Псевдонимнар, кешенең дөньяны танып-белүдә кулланган лексик чараларыннан чыгып, түбәндәге төркемнәргә бүленәләр:

1) кешенең физик үзенчәлекләрен чагылдырган псевдонимнар: *Кара күз* (Ш. Бабич), *Кечкентәй* (Т. Гыйззәтуллин), *Батыр күз* (Ф. Сәйфи-Казанлы);

2) кешенең рухи халәтен, эчке үзенчәлекләрен чагылдырган псевдонимнар: *Тиктормас, Дугъры, Сөемсез, Биик усал* (Г. Тукай), *Дәрдемәнд* (З. Рәмиев), *Чытырман* (Ш. Бабич), *Утмалай* (Г. Кутуй), *Рухи, Зәукый, Фикри* (Г. Сәгъди);

3) кешенең билгеле бер урынчыллыкка, территориягә бәйләнешен күрсәткән псевдонимнар: *Мөхәммәт Олыюлгави* (М. Галиев), *Фатих Сәйфи-Казанлы* (Ф. Сәйфуллин), *Г. Казани* (Г. Камал ) һ.б.

4) хайван һәм үсемлек атамаларына бәйләнешле псевдонимнар: *Кырмыска, Каз* (Г. Тукай), *Карт чаян*, *Черки, Борча* (Кәрим Әмири), *Шөпшә* (Ш. Бабич), *Шәрык Кигәвене* (М. Бөдәйли) һ.б.

5) мәсләк, профессия атамаларын чагылдырган псевдонимнар: *Адвокат, Мөтәрҗим Г. Тукай* (Г. Тукай), *Мәхбирегез* (Г. Ибраһимов), *Хәбәрче, Мөхбир* (М. Галиев ), *Иген игүче* (Ф. Бурнаш);

6) топонимнарга бәйле псевдонимнар: *Казбек, Һималай* (Г. Кутуй), *Фәез Идел* (Ә. Фәйзуллин), *Дим* (Ф. Кәрим);

7) мифопоэтик мәгънәгә ия псевдонимнар: *Шүрәле, Һөд-һөд, Җен, Мәҗнүн, Салам Торхан, Бичура* (Г. Тукай), *Өй анасы, Домовой* (Нәҗип Думави);

8) кешенең билгеле бер социаль катлавын белдергән псевдонимнар: *Ишан Кирамәт, Имам Хатыйб* (Г. Тукай), *Дамелла* (Ф. Әмирхан) һ.б.

9) кешенең сәясәт һәм партияләргә бәйлелеген чагылдырган псевдонимнар: *Бер Фикерле* (Г.Тукай), *Большевик* (М. Бөдәйли);

10) милләт, диалект вәкиле атамасына бәйле псевдонимнар: *Болгар* (Г. Тукай), *Мишәр* ( Ф. Бурнашев), *Таулы башкорт, Башкорт* (Ш. Бабич);

11) юмор-сатирага корылган псевдонимнар: *Гөмберррт, Дөбернуш, Шәкерт угы* (Г. Тукай), *Ташмөхәммәт, Зәмзәметдинов* (Ф. Әмирхан), *Мәлгунь, Күкташ, Башы Бозык, Дамелла Талпан* (Н. Исәнбәт), *Номерсыз урындык* Ф. Бурнаш;

12) тарихи атамаларга бәйләнешле псевдонимнар: *Себектәгин* – Һиндстанда, Әфганстанда яу башлыгы булып дөнья шаулаткан төрки ханнарының берсе (С. Рәмиев).

Ясалыш-төзелеш ягыннан псевдонимнар берничә төргә бүленәләр:

1) исемнең беренче хәрефләрен чагылдырган псевдонимнар: *Гъ.Т.* – Габдулла Тукай, *Д.* – Дәрдемәнд, *ШК* – Шәриф Камал, *ММ* – Мәхмүт Галәү һ.б.;

2) исем-фамилиянең беренче иҗегеннән, аларны үзгәртү яки кыскарту нигезендә ясалган псевдонимнар: *Сабур* – Сафа Борһан, *Буф* – Фәтхи Бурнаш һ.б.;

3) исем-фамилиянең ахыргы иҗекләреннән, яки аларны үзгәртү нигезендә ясалган псевдонимнар: *Сәләй* – Сәлах Атнагулов, *Рим* – Фатих Кәрим һ.б.;

4) исем-фамилияне кыскартып атау нигезендә ясалаган псевдонимнар: *Г. Тукай* (Г. Тукаев) *Г. Алпар* (Г. Алпаров), *Ф.Бурнаш* (Ф. Бурнашев), *Җ.Вәлиди* (Җ. Вәлидов), *Мәҗит Гафури* (М. Гафуров), *Г. Газиз* (Г. Гобәйдуллин), *Ф.Кәрим* (Ф.Кәримов), *Мәхмүт Максуд* (М. Максудов), *Һ. Такташ* (Һ. Такташев), *Кәрим Әмири* (Кәрим Әмиров), *Муса Җәлил* (Муса Җәлилов) һ.б. Псевдонимнарның әлеге структур-ясалыш төре татар әдәбиятында, сәнгатендә киң кулланыла;

5) сүзтезмәләрдән торган псевдонимнар: *Имзасыз Яраретдин, Счет төймәсе, Хәкыйрь Шүрәле, «Хәятел-хәйванат»тан күчерүче* (Г. Тукай) һ.б.

6) җөмләләрдән торган псевдонимнар: *Мин язмадым, Уральск җәмгыяте хәйриясенең бик усал бер члены, Уральскийда Г. Тукаев, Мөхәррир мин түгел, Шүрәле дию белгәйсез, Сәяхәте көбралар ясаучы Шүрәле* (Г. Тукай) һ.б.

Татар псевдоономастикасында коллектив псевдонимнар да очрый. Коллектив псевдоним бер яки берничә авторның бергә язылган әсәренә куелган атамасы: *Әүлия һәм компаниясе* (Г. Камал һәм Вәли Шәфигуллин), *Шагыйрь трест* (Кави Нәҗми һәм Һади Такташ), *Канәзагел* (Кави Нәҗми һәм Закир Гали) һ.б.

Әдәбиятта псевдонимнар язучы әсәренең жанры, эчтәлеге белән дә тыгыз бәйләнеш-мөнәсәбәттә кулланыла. Сатирик әсәрләрдә

кулланылган псевдонимнар: *Ташмөхәммәт, Т.-д.* (Ф. Әмирхан), әдәби критик әсәрләрдә кулланылган псевдонимнар: *Марксист, Дамелла* (Ф. Әмирхан), *Габди* (Г. Ибраһимов) һ.б.

Язучылар аерым бер псевдоним белән бастырылган әсәрләрен бергә туплап чыгара һәм шул җыентыгына язган сүз башында псевдонимының мәгънәсен ача: Г.Тукай, мәсәлән, «Яшен» журналында чыккан барлык әсәрләрен «Яшен ташлары» исеменә туплап бирә.

Татар әдәбиятында псевдонимнарның функциональлелеге төрлечә чагылыш таба. Кайбер псевдонимнар кулланылыш ягыннан чикле булып, кеше үз фамилиясенә кире кайта (*Разин* – Г. Бәширов, *Бичура* – А. Таһиров). Кайбер псевдонимнар халык арасында киң кулланылыш алалар: *Кандалый* (Габделҗаббар Габделмәҗит угылы), *Акмулла* (Мифтахетдин Камалетдин углы), *Х. Туфан* (Хизбулла Гөлзизин).

Псевдонимнар апеллятив һәм ономастик модельләр нигезендә барлыкка килә. Аларның үз ясалыш модельләре һәм традицияләре формалашкан. Псевдонимнар антропонимнарга хас үзенчәлеләргә ия, шулай да башка ономастик берәмлекләрдән аермалы булган үзенчәлекләре дә бар. Тел һәм сөйләм яссылыгында псевдонимнарның мәгълүмати үзенчәлекләре фонетик, лексик, грамматик яссылыкларда, сүзьясалышында ачыла. Әдәби уйдырма буларак, псевдонимнар экстралингвистик шартларның тәэсирендә дә барлыкка киләләр. Чор, аңа хас үзенчәлекләр, әсәрнең эчтәлеге, адресаты һ.б. күренешләр дә псевдонимнарның барлыкка килүенә этәргеч ясый. М.Мәһдиев фикеренчә, псевдонимнарны алуда прицишиаль закончалыклар юк, чөнки язучының манерасы, шәхесенә бернинди мөнәсәбәте дә булмаган псевдонимнар да шактый. Шулай да, антропонимиканың төп методысуллары белән эш иткәндә, һәрбер псевдонимның семантикасында, структур-төзелешендә лингвистик яки экстралингвистик сәбәпләрне ачыкларга мөмкин. Чөнки һәрбер антропоним (бу очракта псевдоним) лингво-, этномәдәни яссылыгында билге (знак) вазифасын башкара, ә бу очракта һәрбер билге телдә дөнья картинасын чагылдыруда мөһим роль уйный.

## Җиденче бүлек
# ТАТАР МИФОНИМИКАСЫ

## § 29. Мифонимика фәненә гомуми билгеләмә

Мифонимика – мифоантропоним, мифотопоним, мифофитоним, теоним, демоним кебек антропонимик берәмлекләрнең телдәге функцияләрен, мәгънәләрен һәм төзелешләрен, барлыкка килү закончалыкларын өйрәнә торган ономастиканың бер тармагы [Энциклопедический словарь-справочник..., 2008: 107]. Әкият, дастан, риваять, табышмак, мәкаль-әйтем кебек фольклор жанрларында төрле ышануларга, хыялга нигезләнгән онимнар тупламасы мифонимия дип атала [Суперанская, 2006: 180]. Ономастиканың аерым бер подсистемасын тәшкил иткән мифонимиягә кеше исемнәре, хайван, үсемлек, географик һәм космографик объект атамалары, шулай ук чынлыкта яшәмәгән предмет, объект исемнәре керә.

Когнитив аспекттан караганда, мифонимнар дөньяның мифологик моделен барлыкка китергән мифологик фикерләү формасын чагылдырулары белән аерылып торалар.

Этнолингвистик аспекттан чыгып караганда, мифонимнар мифологик фикерләүне имплицит шәкелдә чагылдырган этномәдәни тел тамгалары булып киләләр.

Семантик аспектта исә мифонимнар, денотатны атау белән бергә, беренчел эчтәлек планын үзгәртүләре һәм мәгънәнең төрле төсмерләрен контекст эчендә белдерә алулары белән билгеләнәләр. Ономастикада мифонимнарны төрлечә атау күзәтелә. Фольклор текстларының өйрәнү объекты булган мифонимнар фәнни хезмәтләрдә әдәби онимнар (Фонякова, 1990), мифонимнар [Подольская, 1988: 87; Суперанская, 2006: 180], фольклоронимнар [Калинкин, 1999: 40] дип тә аталып йөртеләләр.

Кайбер хезмәтләрдә мифонимнар уртаклык исемнәргә тиңләштереләләр. Бу исә билгеләмәдә дә чагыла.

Мифоним – илаһи көчләргә яки уйдырма каһарманнарга бирелгән уртаклык яки ялгызлык исеме. Мифонимнар әкиятләрдә, легенда, мифларда, героик эпоста, риваятьләрдә, шулай ук теологик трактатларда, мөселман һәм христиан, буддистларның изге китапларында чагылыш таба.

Рус теле белемендә XX гасыр ахырында Д.К. Зеленин, А.Н. Веселовский, О.М. Фрейденберг, П.Г. Богатырев хезмәтләрендә мифонимнарның үсеш-үзгәреш үзенчәлекләре лингвофольклористика кысаларында билгеләнсә, XX гасыр ахырына таба исә әлеге юнәлеш С.Е. Никитина (1993, 1999), А.Т. Хроленко (2008) хезмәтләрендә үстерелә. Славян һәм рус телендә мифонимнар мәсьәләсе этнолингвистика кысаларында Т.А. Агапкина (2002), Е.И. Алещенко (2008), О.В. Белова (2005), Е.Л. Березович (2010; 2016), О.В. Волощенко (2006), О.Г. Горбачевой (2008), Н.В. Дранникова (2006), Т.И. Кондратьева (1967, 2004), С.Е. Никитина (1993, 2009), В.Я. Пропп (1946), С.М. һәм Н.И. Толстой (2013), В.Н. Топоров (1974), А.В. Юдин (2007) тарафыннан тикшерелә. Е.Л. Березович топонимия һәм фольклор арасындагы тәэсир итешү проблемасына мөрәҗәгать итеп, болай ди: «Топонимнарның фольклор ремотивациясе гомумтел ремотивациясе белән аңлатыла, шул рәвешле топонимнарның эчке формасы халык авыз иҗаты ярдәмендә ачыла» [Березович, 2016: 159].

Төрки-татар мифонимнарын өйрәнә башлауның беренче тәҗрибәсен Ибне Фадланның сәяхәтнамәсендә күзәтергә мөмкин. Ул, беренчеләрдән булып, Идел буенда алыплар турындагы легендада мифонимнарның кулланылышы хакында бәян итә. Алга таба мифонимнарны өйрәнүнең беренче тәҗрибәләре Әбү Хәмид әл-Гарнати хезмәте (X–XI вв.), «Кодекс Куманикус» (XIV гасыр), «Казан тарихы» (XVI йөз) кебек тарихи ядкәрләрдә дә күзәтелә. XVIII гасырда исә Г.Ф. Миллерның «Описание живущих в Казанской губернии языческих народов» хезмәтендә текст ахырында мифологик эчтәлекле терминнарны аерып чыгару тәҗрибәсе күзәтелә һәм автор аларның рус теленә тәрҗемәсен дә китерә (*Бог – Тере Гудай, Дьявол – Шайтан, Гора – Ата, Бугор – Им-ата* һ.б.). Н.Ф. Катановның «Алфавитный указатель собственных имен, встречающихся в 1-м томе «Образцов народной литературы тюркских племен» [Катанов, 1888] хезмәте мифонимнарны өйрәнүнең әһәмиятле чыганагы булып санала, әлеге хезмәттә фольклор исемнәре тарихи-лингвистик аспектта тикшерелә. Ул төзегән күрсәткечтә фольклорда кулланыл-

ган каһарманнарның исемнәре, аларның вазифалары, исем семантикасында чагылыш тапкан традицион эпитетлар саналып китә. Н.Ф. Катановның әлеге хезмәте төрки мифонимика үсешендә җитди адым санала. XIX гасырның икенче яртысында К. Насыйри тарафыннан татар фольклористикасында беренче тапкыр мифологик персонажларны төркемләү (су астында торучы әкәмәтләр, җир өстендә яшәүче әкәмәтләр) омтылышы ясала, елан белән бәйле *Ак елан, Аждаһа, Юха елан* кебек персонажларның генезисы, функцияләре билгеләнә, татар халкының ышанулар системасында «ия»ле авыруларның үзенчәлекләре тасвирлана.

Совет чорында Н. Исәнбәт татар мифларыннан материал туплый һәм аларны татар халык иҗатының афористик жанрларына багышланган саллы томнарына һәм башка хезмәтләренә кертә. XX гасыр ахырында исә төрки-татар мифологиясен һәм аның мифонимнарын өйрәнүгә Х. Ярми (1967), Ф.И. Урманчеев (1980, 1984, 2015), М.Х. Бакиров (2001, 2008, 2012), Х.Ш. Мәхмүтов (2002, 2012), Г. Гыйльманов (1996, 1999), К.М. Миңнуллин (1998, 1999, 2000, 2001, 2003), Л.Ш. Җамалетдинов (2015), А.Х. Садыйкова (2014), Ф.З. Яхин (2000), Л.Х. Мөхәммәтҗанова (2002, 2015) һ.б. фольклорчыларның хезмәтләрендә җитди игътибар бирелә.

Татар теле белемендә мифонимнар Г.Ф. Саттаров, Ф.Й. Йосыпов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, М.И. Әхмәтҗанов һ.б.ның хезмәтләрендә төрле этник төркемнәрдә чагылыш тапкан мифонимнарны барлау, аларны классификацияләү максаты куела. Татар фольклорының кече жанрларында кулланылган мифонимнарны тарихи-лингвистик аспектта тикшерү Галиуллина (2009); Батталова (2011); Биктаһирова, Хаҗиева (2012); Мәхмүтов (1995, 2002, 2012); Хаҗиева (2017) хезмәтләрендә урын ала.

Мифонимнар якут (Филиппова, 2000), башкорт (Хисамитдинова, 2010; Бухарова, 2009), азәрбайжан (Халыгов, 2004), төрек (Caferoğlu, 1959: 59–80; Hüsenov, 2010: 48–49; Türkmen, 2010: 101–119; Şahin, 2016: 64–69), казакъ (Керимбаева, 2004; Керимбаев, 2004), шор (Токмашев, 2005) телләрендә өйрәнелә. И. Шаһин билгеләвенчә, төрек теле белемендә антропонимик терминологиянең тар мәгънәдә өйрәнелүе мифонимнарны фольлористика фәне кысаларында гына каралуга китерә. Ул мифонимнарның лингвистик, морфологик, семантик үсеш-үзгәрешләрен ономастиканы өйрәнү объекты буларак өйрәнү зарурлыгын бәхәссез дип саный [Şahin, 2016: 68].

Борынгы заманнарда кеше үзен табигать дөньясыннан аерып карамый һәм әйләнә-тирәдәге барлык җанлы һәм җансыз әйберләрне җанландырырга тырыша, аларны үзе кебек яши, кайгыра, көлә, сөйләшә белә дип исәпли. Ыруглык җәмгыятендә барлыкка килгән мифологик карашлар, реаль яшәеш белән берләшеп, табигать дөньясы һәм кешелек дөньясы арасында гармония барлыкка китерә. Билгеле булганча, мифологиянең нигезендә анимизм, тотемизм, антропоморфизм, магизм һәм фетишизм кебек борынгы фикерләү формалары ята. Беренчел яки башлангыч тойгы-тәэсирләргә таянып эш итүләре белән характерланган, конкрет әйбер-күренешләрдән аерылып торган фикерләү формалары татар исемнәрендә дә чагылыш таба. Татар исемнәренең борынгы төрки катламы тәңречелек концепциясендә кеше һәм табигать стихиясе бәйләнешен характерлый. Татар халкының мифологик мирасын югары мифологиягә һәм түбән мифологиягә бүлеп карау кабул ителгән. Төрки-татар мифологиясендә тәңречелек тәгълиматы белән бәйле югары аллаларга бәйле мифонимнарга – *Тәңре, Җир-Су, Умай, Алас* һ.б. кебек исемнәр керә. Күк-тәңре, Умай, Җир-Су тәңреләренең борынгы төркиләр күзаллавында «югары аллалар» пантеонын тәшкил итүе Орхон-Енисей язмаларында да ачык чагылыш тапкан. «Түбән мифология»гә исә Алла статусына ия булмаган ияләр, кара көчләр, рухлар, йола-гадәтләр, ышанулар, кешенең көндәлек яшәеше белән бәйле мифологик персонажларның исемнәре карала Түбән мифология персонажларының исемнәренә бәйләнелешле текстлар татар халкы мщдщниятенеж ьирле вариантларында чагылыш таба.

Тәңре – төрки халыкларда синкретик күренеш. Ул фәлсәфи субстанция буларак (Бер Тәңре!), һәрнәрсәне барлыкка китерүнең сәбәбе булып тора һәм, теистик субстанция буларак (Тәңребиргән!) нәсел башы, яхшылык һәм яманлыкның чыганагын тәшкил итә. Орхон-Енисей язмаларында, чынбарлык Тәңре тарафыннан яратылган, дип языла. Тәңре – борынгы төрки дөньяның югары хакимлеккә ия көче

Төркиләр аны Күк тәңре дип тә атаганнар. Галәмнең бер өлеше тәңре буларак руник текстларада kök tenri дип аталган һәм борынгы төрки чыганакларада төрле формада чагылыш таба, kök (kök qalyq, qalyq «һава»); шуңа күрә аның тагы бер мәгънәсе якын күк йөзе, кошларга якын күк йөзе белән дә бәйләнешле аңлатыла. Тәңре дөньядагы һәрнәрсә белән, кеше язмышлары белән идарә итә. Борынгы кеше галәмне яраткан Күк тәңрегә буйсына [Исхаков, 2007: 39; Дәүләтшин, 1999: 79]. Борынгы кеше галәм, хаос җиһанны тудырган Күк алласы-

на буйсына, Тәңре кулында яши. Илаһи көчнең атамасы булган Тәңре сүзе [Гумилев, 1994: 340; Дәүләтшин, 1999: 58–59] татар исемнәрендә (*Тәңребиргән, Тәңребирде, Тәңрегол* һ.б. кулланылган) һәм казакъ [Кульдеева, 2001, 117], үзбәк [Бегматов, 1965: 35], кыргыз [Жапаров, 1992: 132], төрек [Эрол, 1992: 61] һәм башка төрки халыкларның уртак хәзинәсен тәшкил иткән.

Анимистик ышануларга нигезләнгән мифонимнар күк җисемнәренә, айга, кояшка табынуга бәйле компонентлар нигезендә ясалганнар һәм фольклор текстларында еш күзәтеләләр. Кеше һәм табигать бәйләнеше турыдан-туры Күк тәңре атрибутларыннан саналган кояш, ай, йолдызлар культы атамаларыннан ясалган борынгы төрки исемнәрдә чагыла. Әкият персонажларының исемнәрендә кояш, табигать белән бәйләнелешле компонентларның исем составында кулланылышы билгеләнә: *Таңбатыр, Төнбатыр, Кичбатыр, Ташказар, Тимербатыр, Бакырбатыр, Айгалибатыр, Ташбатыр, Имәнбатыр* һ.б. Шулай ук батырларның исемнәрендә таш, имән кебек нык булуны характерлый торган компонентларның килеп чыгышы да анимистик күзаллауларга барып тоташа.

Тотемистик ышануларга бәйле исемнәр хайван, кош-корт атамаларына нигезләнеп ясалалар. Борынгы Орхон-Енисей язмаларында тотем хайван яки кош исемен кеше исеме итеп куллануның киң таралган булуы һәм татар фольклор әсәрләрендә дә чагылыш табуы әнә шул борынгы традицияләргә барып тоташа. Мәсәлән, «Кара Күкел» дастанында баш каһарман *Кара Күкел,* батырлык эшләгәннән соң, үз исемен *Кучкар Алыпка* алыштыра. «Баланың исеме Кучкар Алып. Кучкар Алып, шул җирдә атасыннан рөхсәт алып, алыплык эзләп китте» дип сөйләнә дастаннарда [Татар эпосы, 2004: 211]. Борынгы төрки ташъязмаларында qočүar компоненты qočүar töläs tirig исемендә очрый һәм әлеге исем борынгы төркиләрнең Күк тәңре белән бәйләнелешле космогоник ышануларга нигезләнгән [Саттаров, 1990: 56].

Татар фольклорында гомумтөрки *бүре* культына нигезләнгән татар мифонимнарын очратырга мөмкин. Төркиләр һәм монголларда бүре уртак тотем хайван саналып, аңа табыну борынгы ата-бабаларга хөрмәт белән карауны аңлаткан [Безертдинов, 2001: 52]. Борынгы Кытай чыганакларына караганда, төрки атлы гаскәрләренең иң яхшыларын «бүреләр» дип йөрткәннәр, борынгы төрки язмаларда «аларга күк көч биргәнгә күрә, минем атам каганның гаскәре бүре кебек» диелә. *Бүре* сүзе борынгы төркиләрдә кеше исемнәре ясалышында да киң

кулланыла. Моны аеруча затлы нәселдән чыккан кеше исемнәрендә күреп була. Болгар-татарларда *бүре* сүзен изге, илаһи сүз санап кешегә исем итеп бирү йоласы барлыкка килә. Әлеге сүз борынгы төрки телдә *бүре* сүзенең синонимы булган *кашкар, кашкур, корт*, монгол телендә *ашан* һәм *чаны* сүзләрен ир балаларга исем итеп кушканнар [Саттаров, 1990: 16]. Р. Әхмәтьянов бүре сүзенең борынгы ирани телләрдән алынуын һәм мари телендә *пириге, пирагу*, мокшыда *виргас* сүзләренең кулланылуын искәртеп китә [Әхмәтьянов, I т., 2015: 222]. Балага тотем исеме бирү гадәте тотем көчен балага юнәлдерү теләге белән бәйле карала. Баланы тотем хайван яки кош сакласын дигән теләк белән шундый исем биргәннәр [Саттаров, 1990: 14; Галиуллина, 2008: 55].

Төрки халыкларда жансыз предметларга табыну-ышану нигезендә барлыкка килгән мифонимнар да билгеләнәләр. Төрки халыкларда тимер җансыз предметларны олылау, изгеләштерү стихиясен чагылдыра. Тимер төрки халыкларның килеп чыгышы белән бәйле күп кенә легенда-риваятьләрдә дә телгә алына, «һуннар «Марс кылычы» булып саналган тимергә табыналар, кесәләрендә бөти урынында үзләре белән тимер пычакны йөртәләр. Төрки империянең чикләрендә Византия илчеләренә дини тантаналы кичәләр барышында тимер бүләк итәләр» [Гумилев, 1963: 123]. Борынгы төрки сүзлектә *Temür Tuya, Baj Temür, Eltemür, Esân Temür* кебек ир-ат исемнәре теркәлгән [Древнетюркский словарь, 1969: 533]. Димәк, тимернең ныклыгына ышану мотивы бүгенге көн татар исемнәрендә дә сакланган дип әйтергә нигез бар.

Борынгы төрки сүзлектә *таш – tas* компонентының 1) таш; 2) күренеш; тышкы күренеш [Древнетюркский словарь, 1969: 539] кебек мәгънәләре күрсәтелгән. Татар исемнәрендә әлеге компонент *таш* мәгънәсен белдерә. Бу антропокомпонентта борынгыларның ир баланың таш, тимер кебек нык булуын теләү мотивы сакланган. Борынгыдан яшәп килгән җансыз предметларга табыну, аларны изгеләштерү *Ташбакты, Ташкай, Ташкабан* кебек исемнәрдә чагылган [Саттаров, 1990: Галиуллина, 2009: 97].

Шулай итеп, мифонимнар халыкның менталитетын, аңын, мәдәни-тарихи һәм мифологик нигезләрен, аның бөтен потенциаль үзенчәлекләрен актуальләштерүдә, телнең этонмәдәни тирәлеген билгеләүдә мөһим роль уйныйлар. Мифонимнар фольклор дөнья картинасын ачуда билге (знак) ролен үтәп, аерым бер вакыт аралыгы өчен

контекст эчендә актуальләшәләр. Аларның мәгънә үсеше халыкның күзаллавын, матди һәм рухи тормышын ача. Мифонимнарның контекст эчендәге гомумиләштерелгән мәгънәләре ачыла, ассоциатив мәгънә үсешенең юллары ачыклана.

## § 30. Татар телендә мифонимнарны төркемләү

Төрки-татар мифологиясендә мифонимнар тәңречелек тәгълиматына нигезләнгән көчләргә, төрле ияләр һәм түбән рухларга аерымланалар [Татар мифлары, 1996: 8]. Әлеге бүленеш приципларын исәпкә алып, мифонимнарны тәңречелек тәгълиматы белән бәйле Югары алла атамаларына (Җир-Су, Ёомай, Алас һ.б.), «түбән көчләрне» тәшкил иткән Алла статусына ия булмаган ияләр, кара көчләр, рухлар, һәм йола гадәтләре, ышанулар, кешенең көндәлек яшәеше белән бәйле мифологик персонаж исемнәренә аерып карарга мөмкин. Г.Х. Гыйльманов билгеләвенчә, «аллалар сыйныфыннан аермалы буларак, түбән мифология Күк дөньясы белән түгел, күбрәк Җир дөньясы, кеше тормышы белән бәйләнгән» [Татар мифлары, 1996: 4]. Мифонимнарның «югары» һәм «түбән» көчләргә аерымлануларыннан чыгып, ике төре – т е о н и м һәм д е м о н и м нар билгеләнә. Ф.И. Урманчеев «Татар мифологиясе» сүзлегендә аллалар, алиһәләр, явыз затлар белән бәйләнелешле, «түбән» мифология каһарманнарын аерып күрсәтә [Татар мифологиясе, 2009: 17–25].

Теонимнар – мифонимнарның төре, илаһи көчләрнең исемнәрен тәшкил итәләр [Подольская, 1978: 125]. Теонимнар борынгы төрки чорда ук барлыкка килгәннәр. Билгеле булганча, төрки халыкларның рухи мәдәнияте катлаулы һәм зур үсешкә ия була.

Төрки-татар теонимнарыннан *Һомай* – борынгы төркиләрдә хатын-кыз башлангычын гәүдәләндергән уңдырышлылык алиһәсе. Һомай сүзе борынгы заманнарда – б.э.к. кергән булырга тиеш. Һомай сүзе татар телендә *омай* > *ымай* > *май* күчешләре кичерә. *Май* татар сөйләшләрендә «күп; муллык» сүзен аңлата [Әхмәтьянов, т. 2, 2015: 347]. Беренче тапкыр *Һомай* мифонимы VII–VIII гасырларда рун язмасында телгә алына. Күк алласы Тәңренең хатыны дип кабул ителә. Аерым галимнәр фикеренчә, килеп чыгышы ягыннан Һомай Иран мифологиясеннән Хумай-Һомай кош образы белән дә бәйле санала. Һомайның вазифасы төрле халыклар мифологиясендә төрлечә күзаллана. Себер татарларында Һомай турында мөһим мәгълүматлар сакланып калган. Мәсәлән, «Себер татарларында Һомайны бала кендеге

белән дә тиңләштерәләр. Моның нигезендә дә шул ук мәгънә ята: «кешенең асылын билгеләүче, аңа сулыш, җан өрүче» [Татар мифлары, 1996: 21]. Бу исә, үз чиратында, Себер татарларының башка төрки халыклар, бигрәк тә шул тирәдәге алтайлылар, хакаслар, телеутлар белән тыгыз этник һәм этник-мәдәни бәйләнелешләрдә булуын төгәл раслаучы күренеш [Татар мифологиясе, 2011: 148]. Татарларда Һомай турында карашлар кайбер башка төрки халыклардагы кебек төгәл һәм эзлекле түгел.

Төрки-татар дөньясында Урта дөнья алласы булып гәүдәләнгән *Җир-су, Йер-су(б)* җир һәм су гәүдәләнешен чагылдыра [Татар мифологиясе, 2009: 65]. Орхон-Енисей язмаларында беренче тапкыр Күлтәгин истәлегендә телгә алына: «Төркләрнең югары күге, төрекләрнең изге Җир-су шулай дип әйттеләр: «Төрки халкы юкка чыкмасын иде!» – дип әйттеләр». Изге Җир-су борынгы төркиләрне һәрвакыт саклап, һәрбер эшләрендә ярдәм итеп торган Җир-су – төрле урыннарның, табигать атрибутларының (тау, урман, елга, күлләрнең) рух хуҗасы булып та саналган. Г.Дәүләтшин фикеренчә, Җир-су –Урта җир, Урта дөнья, Җир йөзе – Җир өсте Алласы. Аның фикеренә, җирсу туган як тауларын, елгаларын, күлләрен, урманнарын һәм кырларын олылау, билгеле бер дәрәҗәдә илаһилаштыру белән бәйләнгән [Дәүләтшин, 1999: 56].

Мифологиянең түбән көчләрен төрле демоннар, кечкенә илаһи көчләр, ияләр, җеннәр тәшкил итәләр [Давлетшина, 2011: 60]. Демоннар белән кешеләр арасындагы туганлык һәм көнкүреш мөнәсәбәтләре дә билгеләнәләр. Мифологик тикшеренүләргә караганда, «түбән көчләр» «югары көчләргә» караганда борынгырак, чөнки әлеге катлам коллектив күзаллауга нигезләнә. Мифонимнарның «түбән» катлавын чагылдырган төрен демонимнар дип атап йөртәләр [Şahin, 2016: 67; Давлетшин, 2016; Завгарова, 2012: 53].

Демонимнарның көндәлек тормыш белән бәйләнгән төркеменә «түбән» көчләрнең атамалары керә: *Бичура, Өй иясе, Су анасы, Урам иясе, Тыкрык иясе, Ындыр иясе, Умарталык иясе* һ.б. Татар халкының традицион мәдәниятендә гомуми һәм борынгыдан килгән карашлар буенча, кешенең тирә-ягында булган һәрнәрсәнең, предметларның, хәтта табигать күренешләренең үз иясе була. Ияләр үзләренең төп вазифаларын башкарган урыннарда – өйләрдә, абзарларда, су, елга, күлләрдә гомер итәләр. Татар рухи мәдәниятенең җирле вариантларында атамаларда төрлелек күзәтелә. Томск татарларында Су ияләренең,

Урман иясе белән бәйле риваять-легендаларның күплеге билгеләнә [Татар мифлары, 1996: 127; Татар мифологиясе, 2011: 73].

Йорт иясе, абзар иясе турындагы сюжетларында Томск татарларының башка җирле төркемнәр белән аваздашлыгы әйтелә. Свердловск өлкәсе татарларында *Сыу ийәсе, Сыу инәсе, Урман ийәсе, Абзар ийәсе, Мал хуҗасы, Абзар хуҗасы, Өй хуҗасы, Йорт хуҗасы Мижа хуҗасы, Өй ийәсе, Йорт ийәсе, Урам ийәсе, Каралды ийәсе, Ат ийәсе* мифонимнары чагылыш таба [Баязитова, 2002: 351–358].

Төрле вариантларда аталып йөртелә торган Хозер Ильяс персонажын (*Хызыр, Хозер, Хозер бабай, Хызыр Ильяс* һ.б.) юл иясе дип йөртәләр [Давлетшина, 2011: 61]. Татар халкы ышануларында киң таралыш тапкан Хозер Ильясның юл иясе буларак кабул ителүе аның составындагы Ильяс образы белән бәйле буларак тәгаенләнә. *Хизр, Хидр* – мифик пәйгамбәр. Хидр дигән могҗизалы зат турында легендалар Шумер-Аккад заманнарыннан ук килә. Шумерча бу сүз «яшел кеше, мәңге яшел» мәгънәсендә дә булган [Әхмәтьянов, т. 2, 2015: 392]. Татар халкының ышануларында Хозер Ильяс юлчылырга юлдаш, адашкан кешеләргә ярдәм итә торган ак сакаллы карт буларак ачыклана. Ислам динендә Ильяс пәйгамбәр (христиан динендә Илья) буларак билгеле әлеге персонаж «җирдә һәм суда сәяхәт итүчеләрне яклаучы» итеп характерлана. Татар паремиологик фондында *Хозыр* компоненты белән бәйләнелешле «Авызына Хозыр төкергән» гыйбарәсе кызу канлы, акыллы кешегә әйтелә, татар телендә Хозыр Ильяс мифонимының тулы идиоматизация кичерүе күзәтелә [Галиуллина, 2008: 139].

Ислам мифологиясе белән бергә кергән демонимнарга *Җен, Шайтан, Иблис, Дәҗҗал* һ.б.ны кертеп карарга мөмкин. Мифологик караш буенча, алар җир өстендә, без яшәгән гадәти дөньяда гомер кичерәләр. Төрки-татар мифологиясендә ислам мифологиясеннән алынган демонимнарның берсе – *Җен* – явыз рух, Аллаһ тарафыннан барлыкка китерелгән өч төркем акыллы затларның берсе. Р.Г. Әхмәтьянов *Җен* демонимын түбәндәгечә аңлата «җен диал. йен «злой дух, бес, джинн» башк. *Йен* > мар. диал. *зын,* удм. *зин* < гар. *җин* «җен; яшерен зат» – *җен* «яшерү» фигыленнән. *Әҗинә* «хатын җен, җен хатыны» [Әхмәтьянов, т. 1, 2015: 265]. «Җен» – нинди дә булса вазифа үтәүгә карап, кеше кыяфәтенә, предмет, атмосфера күренешенә керә ала һәм күренми торган демонимик зат. Җеннәр безнең тормышыбызга үтеп, кешегә күренми генә гаиләләре белән параллель тормышта яши алалар. «Җен демонимы ислам дине белән килеп керә һәм киң тарала,

локаль мәдәнияткә нисбәтле трансформацияләнә һәм борынгы төрки мифологиянең архаик системасының җимерелү процессында яңа интерпретация ала» [Давлетшина, 2016: 27]. Коръән тәгълиматы буенча, Җеннәр төтенсез уттан яратылганнар, теләсә нинди кыяфәткә керә алалар; үтә катлаулы эшләрне җиңел башкаралар. Җирдә Адәм Галәйһиссәламгә кадәр үк яшәгәннәр, гадәттә кешеләрнең дошманы буларак сурәтләнәләр. Адәм балалары белән Җеннәрнең үзара мөнәсәбәтләре Коръәндә әйтелгәнчә, шактый кырыс юнәлеш ала. Җеннәрнең бер төркеме Корьәнгә иман китереп, ислам динен кабул итә һәм аңа тугрылыклы булып кала, икенче төркеме исә Иблискә ияреп, Аллаһка иман китерүдән баш тарта һәм мәҗүсилектә кала.

Борынгы гарәп һәм ислам мифологиясеннән төрки-татар мифологиясенә үтеп кергән Дәҗҗал (*гар.* алдакчы, ялганчы) демонимы христиан динендәге Антихристка туры килә. «Даджал (دَجَّالٌ гар. «ялганчы») – антихрист, антимессия, ахырзаманда килүче [Ислам: иллюстрированная..., 2010]. Гарәп телендәге *Дәтьял* русларда «антихрист; изверг» дигәнне аңлата. Р.Г. Әхмәтьянов карашынча, *Дәтьял* демонимының килеп чыгышы гарәпчәдән түгел, башка чыганакка да карарга мөмкин. *Дециал* «унынчы бала» исеме Дектиан дип әйтелгән, тарихта Дециал буларак билгеле [Әхмәтьянов, т. 1, 2005: 241]. Татар телендә дәҗҗал сүзе күчерелмә мәгънәдә «ялганчы, алдакчы» дигәнне дә аңлата [ТТАС, 2005: 154]. Дәҗҗал хәдисләрдә һәм ахырзаман белән бәйләнелешле дастан-кыйссаларда сөйләнелә. Мөселманнар карашы буенча, Дәҗҗалның эш-гамәлләре Иблис белән бәйләнгән.

Демонимнарның икенче төркемен аллалар дәрәҗәсендә торып, ниндидер гайре табигый көч-куәткә, кодрәткә ия көчләрнең атамалары тәшкил итәләр. Көндәлек тормышта очраган көчләрдән аермалы, алар башка дөньяда яшәеш күрәләр. Төрки-татар мифологиясендә төрле ияләргә багышланган мифологик хикәятләр җитди урын алып тора. *Су анасы* һәм *су атасы, су иясе* образлары барча төрки халыкларда (бигрәк тә кыпчакларда) очрый. Фольклордагы Сусылу образы татар-башкортларда гына чагылыш таба [Әхмәтьянов, т. 2, 2015: 176]. Татар диалектларында *суwәсе* «су иясе» [ТТЗДС, 2009: 582], *сумийә* «су иясе» [ТТЗДС, 2009: 586] кебек вариантларда борынгы фонетик яңгыраш һәм күчеш чагыла. Су асты патшалыгы белән бәйле *Су анасы* образы – киң таралган сюжетларның берсе. Әлеге образ озын чәчле, куркыныч хатын-кыз булып күзаллана. Шулай ук демонимнар арасында татар фольклорында *Су иясе, Су бабасы* образлары да очрый. *Су*

*кызы* образы татар халкының иң борынгы дастаннарыннан саналган «Түләк һәм Сусылу» дастанында чагылыш таба.

Татар мифологиясенең түбән көчләренә кергән *Бичура* демонимы төрки-татар дөньясында киң таралган. *Бичура* (*диал.* пичура, мичура, бисура, мисура) – русларда «домовой». *Бичен, Мичкәй, Присура, Мичура* вариантлары бичуралар мич тирәсендә яшиләр дигән мифның чагылышы [Әхмәтьянов, т. 1., 2015: 191]. *Бичура* – йорт иясе, йорт хуҗасы, йорт пәрие [ТТАС, т. 1, 2015: 545]. «Мич артында мичура билен буып утыра» (себерке) дигән татар табышмагында *Бичура* демонимы чагылыш таба. Бичура шактый катлаулы, каршылыклы, ул өй-йорт тирәсендә, хәтта урманнарда гомер итүче затларга (маймыл, Баба-яга) да якын торган хәшәрәт буларак билгеләнә. Татар мифологиясендә Бичураларның ике төре билгеләнә: бер төркеме кешеләргә вак-төяк явызлыклар эшләп торса, икенчеләре яхшылыклар кыла икән.

Димәк, мифонимнар илаһи көчләрнең, аллаларның, Алла дәрәҗәсендәге алиһәләрнең атамаларына һәм көндәлек яшәештә аллалар дәрәҗәсенә тиң торып, ниндидер гайре табигый көч-куәткә, кодрәткә ия көчләрнең атамаларына аерылалар.

## § 31. Мифонимнарның кулланылыш үзенчәлекләре

Мифонимнарның кулланылышы гаять дәрәҗәдә үзенчәлекле. Алар кече һәм зур фольклор жанр төрләрендә очрый. Фольклорның эпик жанрларында каһарманның исеме аның характер үзенчәлеген, яшен, эпик дөньядагы функциясен, уңай яки тискәре персонаж булу-булмавын ачыклый. Фольклор әсәрендә сүзнең мәгънәсе, контексттан тыш, мәгълүматка – мифларга, гореф-гадәтләргә, сынамышларга һ.б. га барып тоташа, текстның синкретик структурасында һәм контекст бәйләнешендә генә бөтен тулылыгы белән ачыла. Хәзерге татар прозасында да мифонимнарның кулланылышы күзәтелә. Л. Дәүләтшина билгеләвенчә, бер яктан, әдәби сүз сәнгатендә (Ә. Еники, М. Мәһдиев, М. Юныс, А. Гыйләҗев әсәрләрендә) мифонимнарны чагылдыруда архаик мифологик структура, борынгы архетиплар барлана, икенче яктан, әдәбият мифның әдәби трансформациясе процессына аяк баса, әдәби образлар һәм мотивлар хикәяләү юлында мифологик катламда ачылалар (Н. Гыйматдинова, Г. Гыйльманов, Ф. Бәйрәмова) [Давлетшина, 2005: 16].

Мифонимнарның кече афористик жанрларда кулланылышы милләтнең стереотип һәм архетип образларын, тел шәхесен, милләтнең

үзаңын ачыкларга ярдәм итә. Паремияләрдә кулланылган мифонимнар, гомумиләштерүдән тыш, индивидуальләштереләләр, шул рәвешле, этномәдәни мәгълүматны чагылдыралар. Татар паремиологик фондында *Сөләйман* пәйгамбәр белән бәйләнешле исемнәр дә зур күпчелекне тәшкил итәләр. Сөләйман исеме гарәп телендә «саклый торган» дигән мәгънәдә килә [Саттаров, 2006: 55; Мусульманские имена, 2007: 224]. Билгеле булганча, *Сөләйман* – Коръән сюжетына бәйләнелешле персонаж, акыллы һәм тәкъвалы патша, Библиядәге Соломонга туры килә, Алла тарафыннан бирелгән балдак көченә ия булган яхшы тылсымчы (Татарская энциклопедия, 2010: 5, 468). Сөләйман исеме түбәндәге паремиологик берәмлекләрдә урын алган: Сөләйман йөзеге; Йөзек кем кулында булса – шул Сөләйман; Йөзеге барда – Сөләйман, йөзеге юкта – сөмәйгән; Сөләйман үлде – диюләр котылды һ.б. [Татар халык мәкальләре, 2010: 554]. Ислам мифологиясендә Сөләйман пәйгамбәргә һәм аның Аллаһының 99 исеме язылган йөзегенә зур игътибар бирелә. Татар күзаллавында әлеге йөзеккә ия булган кеше бөтен дөньяга хаким була ала дигән фикер таралган. Шуңа күрә татар теленең паремиологик фондында да Сөләйман пәйгамбәргә нисбәтле мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар барлыкка килгән. «Суда – Сөләйманмын» (сөлек) [Татар халык табышмаклары, 2014: 96] табышмагы Сөләйман пәйгамбәр һәм сөлек арасында тыгыз бәйләнешне аңлата һәм ул су өстендә торган Сөләйман тәхете турындагы риваятьләргә барып тоташа. Татар телендә кулланылган «Сөләйман йөзеге» гыйбарәсе Сөләйман йөзегенә бәйләнешле чиксез хакимлеккә ия булу дигән мәгънәне аңлата [Мәхмүтов, 2008: 298]. Әлеге фразеологик берәмлек йөзеккә хас булган коннотатив мәгънә нәтиҗәсендә барлыкка килә. Корьәннең «Бакча» сүрәсенең 31–34 нче аятендә Сөләйман кичке намазы турында онытканга, Аллаһ аннан йөзеген тартып ала. Бер көнне Сөләйман йөзекне хатынына калдыра һәм Сөләйман кыяфәтендә җен килеп, йөзекне урлый һәм дөнья хакименә әйләнә. Сөләйман тәүбә итә һәм Аллаһ фатыйхасы белән йөзеген генә түгел һәм хакимлекне үзенә ала. «Йөзек кем кулында булса – шул Сөләйман» дигән әйтем Корьән сюжетларыннан чыгып семантик үзгәреш кичергән.

Татарларда ислам дине белән бәйләнелешле пәйгамбәр исемнәре нигезендә ясалган теонимнарның семантик потенциалы аерым бер этномәдәни тирәлек турындагы мәгълүматны чагылдыралар: «Һәркем Мөхәммәт пәйгамбәр булмый»; «Тау Мөхәммәт янына кил-

мәсә, Мөхәммәт тау янына килер»; «Ел – елга, ел Мөхәммәткә җиткәндә» һ.б. Ономатолог Г.Р. Галиуллина фикеренчә, татар мәдәниятендә *Мөхәммәд* исеменең эчке формасы киңәюе күзәтелә. Халык күзаллавында *Мөхәммәд* дин символы буларак чагыла һәм берникадәр дәрәҗәдә Аллага якынлыгы билгеләнә [Галиуллина, 2008: 133]. Әлеге исемнәрнең күбесе Коръән сюжетларыннан алынган, М.Ш. Мәхмүтов билгеләвенчә, «Коръәндәге һәр сүрә гаҗәеп гүзәл һәм гыйбрәтле риваять-легендалар белән бизәлгән, аерым аятьләре исә тапкыр һәм хикмәтле афоризмнар булып яңгырый» [Махмутов, 2008: 4]. Татар халкының мәкаль һәм әйтемнәрендә иң еш кулланыла торган исем Мөхәммәд пәйгамбәргә бәйләнелешле исемнәр: «Ел – елга, ел Мөхәммәткә җиткәндә»; «Син дә мин, Мөхәммәт әмин»; «Мөхәммәткә өммәт булмыйм». Мәкаль һәм әйтемнәрдәге кайбер мисаллар образлылык тенденцияләре хакында сөйли. Мәсәлән, татар телендә *Гайшә* исеме гарәп телендә «яшәүче, тере, имин, тыныч, чәчәк атучы» [Мусульманские имена, 2007: 306] дигәнне аңлата һәм «Минем кулым түгел, Әйшә-Батма кулы» дигән әйтемдә исемнең семантик көче ачыла төшә, денотат белән бәйләнеше барлыкка килә. Билгеле булганча, татар мифологиясендә *Айшә-Батма* барлык хатын-кызларның да яклаучысы булып тора [Урманчеев, 2008: 269]. Батма (Фатыйма) – шул ук вакытта Мөхәммәд пәйгамбәр белән Гайшәнең кызы. Татар мифологиясендә Әйшә-Батма кулы бөтен төрки дөньясына мәшһүр, шул ук вакытта ислам дөньясына танылган яхшылык, киң күнеллелек төшенчәләре белән бәйләнгән [Урманчеев, 2008: 270].

Коръән сюжетларында *Нух* – Мөхәммәд пәйгамбәрнең дәвамчысы буларак характерлана [ТЭ, 2008: 503]. Нух пәйгамбәр кешелек тарихын Туфан суыннан соң янадан башлап җибәрүче, шунлыктан аның образы ислам дөньясында, шул исәптән татар халкында, бигрәк тә татар язма әдәбиятында шактый зур урын били. Язма әдәбиятта да, фольклорда да Нух пәйгамбәр исеменә мөрәҗәгать итеlә икән, димәк, сүз бик борынгы заманнар турында бара. *Нух* антропокомпонентлы паремияләрнең семантикасы пәйгамбәр турындагы риваятьләргә барып тоташа: «Нух заманыннан бирле», «Нух заманнарыннан калма», «Нухтан калган»; «Нух каргасы» һ.б. Риваятьләрдә Нух пәйгамбәрдән тормыш турында сорагач ул болай дип җавап бирә: «Ике ишекле өй кебек, берсеннән кердем, икенчесеннән чыктым». Вакыт фәлсәфәсе түбәндәге гыйбарәләрдә урын ала.

*Алып* мифонимы реаль яшәүче кеше белән бәйләнелешле, көч, батырлык кебек төшенчәләргә ия. Ул – эпос, татар халык әкиятләрендә, паремияләрдә гиперболизацияләнгән формада чагылыш тапкан. «Алып орлыгы», «Алпамыш йокысы», «Алпамыш батыр йокысы белән йоклый» әйтемнәрендә Алып исеменең деонимизация кичерүен күзәтергә мөмкин. Этномәдәни үзенчәлеккә ия аппелятивларны Алып-батырга барып тоташкан оним барлыкка китерә. *Алып* мифонимы табышмакларда да очрый: «Алты аягы бар – Алып түгел, Дүрт күзе бар – дию түгел»; «Аркасында – кылдан җебе, Эрләп суккан җебе түгел» (үрмәкүч) [Татар халык табышмаклары, 2014: 139]; «Әнә бара Алып, Колакларын салып; Киндер күкрәге, Тимердер йөрәге (бүре)» [Татар халык табышмаклары, 2014: 112]. «Алпамыш» дастанының төп герое исеме дастанның төрле версияләрендә төрлечә бирелгән: алтай вариантында – *Алып-Манаш*, үзбәк вариантында – *Алпамыш*, казакъ вариантында – *Алпамыс*, татар вариантында – *Алпамша, Алпамыш, Алыпмәмшән*. Барлык исемнәр дә алтай вариантындагы – *Алып-Манаш* исеменә барып тоташа. Исемнәрнең төрле вариантта кулланылышы мәгънәнең метафоризация мөмкинлегенең киң булуы һәм исемнең поэтик табигате турында сөйли. Татар әкиятләрендә һәм дастаннарындагы *Алпамыш* исеме кыпчак эпосында кулланылган Алып-Манаш исеменең кыскартылган варианты булырга мөмкин. «Манаш» сүзе бераз карасы булган ак мәгънәсендә дә кулланыла, шуңа күрә Алып-Манаш исеме атка атланган батыр мәгънәсендә дә килә [Әхмәтьянов, т. 2, 2015: 69]. Татар телендә *Алпамша* исеме уртаклык исеменә күчеп, «зур гәүдәле кеше» дигән мәгънәне аңлата, татар теленең диалектларында алпамша сүзе «мифик образ; зур гәүдәле көчле батыр» дигәнне аңлата [ТТЗДС, 2009: 36]. Шулай ук татар диалектларында «алпамыш йокосо» дигән фразеологик әйтем киң таралаган [ТТЗДС, 2009: 412]. Алпамша-Алпамыш исеме татар телендә «алып» + «шаһ» компонентларыннан торган сүзләр нигезендә барлыкка килгән. Ф.И. Урманче фикеренчә, фарсы чыгышлы «шаһ» компоненты төп каһарманның затлы нәселдән булуына ишарәли [Урманчеев, 2015: 121]. Шул рәвешле, «алып», «батыр» компонентлары, исем составында килеп, эпик әсәрләрдә уртаклык исеменә әйләнә, персонажның физик, психологик үзенчәлекләрен чагылдыра, нәсел җебен барлау вазифасын үти. *Алып* антропонимы – гомумтөрки титул, XIII–XIV гасырларга караган эпитафияләрдә сакланган. Ибне Фадлан сәяхәтнамәсендә алыплар гигант тән төзелешенә һәм зур көчкә ия, могҗиза тудыруга сәләтле

кешеләр буларак тасвирлананалар. Борынгы чорларда Алып кешеләрнең яшәве турындагы ышану-легендалар хәзерге татарлар арасында да киң таралган. Мәхмүт Кашгарый «Диване лөгатет төрк» энциклопедик сүзлегендә «алп» сүзенә «көчле, алып, баһадир» дип аңлатма бирә [Махмуд ал-Кашгари, 2010: 85]. Татар риваятьләрендә Идел буе болгарларының килеп чыгышын Алып исеменә бәйле рәвештә аңлату да сакланып калган. Күренекле мәгърифәтче К. Насыйри болай дип яза: «Кая барсаң да Алып турында хикәятләр ишетергә була. Күп кенә авылларда Тау битендә Алып чабатасын каккан» дип тә әйтәләр. Шуңа күрә әлеге хикәятләр кайчандыр зур кеше яшәве турында дәлил булып торалар» [Насыйри, 1974: 83]. Шул рәвешле, тарихи һәм этнографик чыганакларда алыпларның реаль яшәеше исбат ителеп, әлеге күренешләр фольклор әсәрләренең сюжетларына килеп керә, образны гиперболизацияләүдә зур роль уйный.

Телнең этномәдәни тирәлегендә мифонимнар үзенчәлекле ономастик парадигманы реконструцияләп, халык турында мәдәни-тарихи, мифологик, этномәдәни мәгълүматны поэтик чагылдыру вазифасын үтиләр. Мифонимнар мәгънә бердәмлеген һәм кеше тарафыннан тирәюнь турындагы мәгълүматны гомумилеген белдерү чарасы буларак ачыла, шулай ук телнең этномәдәни тирәлеген ачыкларга ярдәм итә. Мифонимнарның диахроник семантик үсеше халыкның психологик торышын, күзаллауларын ачарга, әлеге әсәрне барлыкка китерүдә зур роль уйнаган гасыр үзенчәлекләрен барларга мөмкинлек бирә.

# ЙОМГАК

Ономастик киңлекнең форма һәм эчтәлек ягыннан башка антропонимик берәмлекләрдән үзгә гомумуниверсаль берәмлекләрен тәшкил иткән татар исемнәрен монографик планда өйрәнүнең аларның спецификасын, йола-традицияләргә бәйле кулланылышын ачыклауда, трансонимизация процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән ономастик берәмлекләрнең беренчел чыганакларын билгеләүдә әһәмияте зур. Татар исемнәре системасының төрле этномәдәни процессларны, борынгы культ һәм күзаллауларның традиция һәм исем бирү йола-гадәтләрен үз эченә алуы, экстралингвистик факторлар нигезендә формалашкан антропонимик модельләрнең күп гасырлар дәвамында тупланган кеше эшчәнлеге тәҗрибәсенең нәтиҗәсе булуы ассызыкланды. Татар исемнәренең этнолингвистик катламнарының антропонимик киңлеге, «катып калган» система гына булмыйча, ә күләме һәм составы ягыннан үзгәреп-үсеп торган рухи һәм мәдәни үсешнең этномәдәни мәгълүматларын тәшкил итүче, репрезентатив функция үтәүче категория булып саналырга мөмкин, чөнки ул этнос, тел һәм үзара мәдәни бәйләнештә килеп, исемнәрнең этномәдәни үзенчәлеген билгели. Шуңа күрә, татар исемнәре системасының милли-мәдәни үзенчәлекләрен күрсәтү теге яисә бу берәмлекнең антропосистемада этник «төсе»н чагылдырган экстралингвистик факторларны аерырга, шулай ук этносның һәм мәдәниятнең барлыкка килү, ономастик лексикага тәэсире кебек параметрларны да ачыкларга мөмкинлек бирде. Татар антропонимик системасында төрки, монгол, тунгус-маньчжур исемнәренең бергәлеген исбатлауда мөһим булган алтай катламы исемнәре билгеләнә: *Сайкай, Байтүрә, Бугаарслан, Алтын, Каракаш, Алакол* һ.б. Димәк, исемнәр, борынгы күренеш буларак, алтай чорыннан ук үсеш алганнар һәм төрки, монгол, тунгус-маньчжур телләрендә чагылыш тапкан уртак антропонимик берәмлекләрне тәшкил итәләр.

Татар исемнәренең төрки-татар катламы төрки телләрнең дифференциациясе белән билгеләнгән чорда барлыкка килеп, бердәм комплекс тәшкил итүче төрле субстрат һәм адстрат элементлардан

торган, үз эченә борынгы төрки, иске татар, яңа татар катламнарын берләштереп, бөтен төрки халыклар өчен дә уртак саналучы антропокомпонент һәм антропоформантлар нигезендә ясалган исемнәр системасыннан гыйбарәт. Татар исемнәрен башка төрки халыкларның (казакъ, башкорт, төрек, үзбәк, каракалпак, кыргыз һ.б.) антропонимик берәмлекләре белән чагыштырып өйрәнү процессында кешенең тирә-юньне күзаллавы белән бәйләнешле исемнәрнең (табигать, тирәлек, кеше) типологик уртаклыклары ачыкланды. Борынгы төрки катлам исемнәре гомумтөрки культураның борынгы классик үсеше чорында барлыкка килгән тәңречелек һәм аның культлары нигезендә формалаша. Космонимия, табигать, хайван, кош-корт культлары нигезендә ясалган бу катлам исемнәр борынгы патриархаль җәмгыятьтә ир заты өстенлегенең дифференциаль чагылышы булып тора. Борынгы төрки катламны тәшкил итүче антропокомонентлар һәм антропоформантларның бүгенге төрек, азәрбайҗан, төрекмән, кыргыз, гагауз, казакъ, башкорт телләрендә дә чагылыш табуы ачыкланды. Шулай да бу исемнәр төрки телләрдә кулланылыш төрлелеге һәм чиклелеге белән аерылалар. Иске татар катламы исемнәрендә татар һәм башкорт телләренең формалашуында нигез булган кыпчак, болгар, угыз телләренең элементлары сакланган. Мәсәлән, болгар аскатламы ир-ат исемнәренә *Алмыш, Алып, Алыптай, Болгар, Тутай, Чулак* һ.б. исемнәр керсә, структур яктан саф булуы, бүленешендә структур ачыклыгы төп үзенчәлек булган кыпчак исемнәренә *Ардак, Кайчура, Кайпач, Туматай* кебек исемнәр керә. Угыз аскатламын фигыльнең угыз формалары *–мыш/-меш* (*Сатылмыш, Аталмыш*), *-дык/-дек* (*Сатылдык, Сөендек, Куандык*) кушымчалары нигезендә ясалган ир-ат исемнәре һәм *Аслан, Курт, Куртай, Курташ, Янсывар, Хансывар* кебек татар исемнәре билгели. Яңа татар катламын, совет чорында яңачалыкка омтылыш буларак, татар теленең үз мөмкинлекләреннән ясалган исемнәргә яңа эчтәлек бирү нәтиҗәсендә барлыкка килгән ир-ат исемнәре тәшкил итә. Кардәш яисә кардәш булмаган халыкларның этномәдәни бәйләнешләре, идеологик һәм сәяси процесслар антропонимик системага алынма исемнәрнең фронталь рәвештә килеп керүенә төп сәбәп була. Гарәби чыгышлы ир-ат исемнәре барлык ир-ат исемнәренең 37% ын тәшкил итәләр. Дини эчтәлектәге ир-ат исемнәре Ислам, аның кануннары, Аллаһы Тәгаләнең 99 эпитетын, пәйгамбәр исемнәрен чагылдыралар. Дини эчтәлектәге гарәби чыгышлы ир-ат исемнәренең саны, хатын-кыз исемнәре белән чагыштырганда күбрәк.

Бу аерма, беренчедән, исламда ир-атның өстенлеге белән билгеләнсә, икенчедән, пәйгамбәр, Аллаһының 99 эпитетын белдергән исемнәрнең ир-ат исемнәре булуы белән ассызыклана. Конкрет гарәби чыгышлы исемнәргә һөнәр-кәсеп, көнкүреш кирәк-яраклары, атна көннәре һ.б. атамалардан ясалган исемнәрне керттек, абстракт мәгънәле исемнәрне исә акыл, зиһен, бәхет, байлык, шөһрәт, көч кебек семантик ояларга берләштердек. Фарсы чыгышлы ир-ат исемнәре катламы барлык ир-ат исемнәренең якынча 7% ын тәшкил итеп, ир-атның үзенчәлекле сыйфатларын тасвирлаган компонентлар (*Җангали, Хушдил, Минзадә, Рушан, Дилүс, Шанияздан*), титул компонентлары (*Ишан, Мирзанид, Шаһбаз, Гыйлемшаһ* һ.б.) нигезендә ясалган исемнәрне берләштерә. Рус һәм Көнбатыш Европа чыгышлы исемнәрнең антропонимиконыбызга үтеп керүендә матбугат, радио-телевидение, әдәбият-сәнгать, интернет челтәренең тәэсире зур була. Шулай ук алынма исемнәрне кушуда фонопсихологик аспектның өстен чыгуы да ассызыкланды. Гибрид исемнәрне чыгышы белән төрле телләргә караган семантик, асемантик бәйләнештәге компонентларның үзара берегү нәтиҗәсендә барлыкка килгән исемнәр тәшкил итәләр. Семантик бәйләнешнең исемнәрдә бүгенге көнгә чаклы сакланып килүе, әлеге антропонимик берәмлекнең борынгы чорларда ук ясалуына ишарәли.

Исемнең эчке һәм тышкы формаларының исем бирү мотивларының лексик-семантик төркемнәрендә чагылышы, аларның исем кушучы тарафыннан субъектив кабул ителүе билгеләнә. Исемнең эчке формасы апеллятивның исем бирүче тарафынннан яңа эчтәлек алуы белән билгеләнгән теләк, тасвирлама, багышлау исемнәрдә ачыла. Дескриптив (тасвирлама) исемнәр исем һәм кушамат кебек антропонимик берәмлекләренең әле аерылып җитмәгән чорында, кешенең борынгы күзаллаулары нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Бу төркем исемнәргә бөтен төрки халыкларның да исемиятендә билгеләнә торган кешенең төс-килбәтенә, кыяфәтенә, характерына, туу вакыты, урынына нисбәтле ясалган, ата-ананың хисләрен чагылдырган исемнәр кертелде. Дезидератив исемнәр, татар теленнән тыш, башка төрки телләрдә (төрек, казакъ, кыргыз, төрекмән, үзбәк) дә киң кулланылалар. Дезидератив (теләк) исемнәр өчен балаларга батырлык, кыюлык, ныклык, көчлелек, дәүләт-байлык, акыл иясе булу семантикасы хас булган исемнәр характерлы. Ир балага шундый семантикага ия булган сословие титулларының, кыргый һәм йорт хайваннары, корал, металл атамаларының исем итеп бирелүе ир-ат исемнәренең үзенчәлеген билгели.

Меморатив (багышлау) исемнәрдә билгеле бер субъектка, объектка юнәлү ассызыклана. Тотем, теофор исемнәрдә төрле ышанулар, дини идеологиянең патриархаль күзаллаулары бу төргә караган исемнәрнең спецификасын ача. Билгеле бер объектка яисә субъектка багышланган исемнәрнең антропонимикада кулланылышы төрек, кыргыз, казакъ, башкорт, төрекмән телләрендә дә күзәтелә. Исемнәрнең тышкы формасы төрле ассоциатив мотивларның исемдә чагылышы белән билгеләнә. Татар исемен кушуда аерым бер фонемаларның номинациядә нигез булуы фоносимволик мотивны тәшкил итә.

Популяр исемнәрдә сонор авазларның өстенлеге аларның эмоциональ төсмерләргә бай булуы белән аңлатыла. Исемнең гаилә әгъзалары исемнәре белән рифмалашып килүе, семантик синонимия күренеше тышкы форма чагылышы дип күрсәтелде. Шулай ук исем бирүдә билгеле бер исемне йөртүченең характеры, кыяфәте, язмышы белән бәйле ассоциацияләрнең исем кушучы тарафыннан кабул ителеп, башка бер балага исем бирүдә йогынты ясавы һәм исемнең яңа эчтәлеге тууы ачыкланды. Мәсәлән, *Адольф* исеме татарлар, руслар арасында да киң таралмады. Моны Адольф Гитлер белән бәйле ассоциацияләрнең йогынтысы дип билгеләргә мөмкин. XX–XXI гасыр башында *Тамерлан, Тамерлан, Чыңгыз, Чыңгызхан* кебек исемнәр дә турыдан-туры тарихи шәхесләргә бәйле ассоциацияләргә нисбәтле татар исемиятендә кулланыла башладылар. Структур яктан компонентларның составына карап, исемнәр бер составлыга, ике составлыга аерыла. Бер составлы исемнәр антропокомпонент белән кушымча (*Тимеркәй*) ике составлы ир-ат исемнәрендә антропокомпонент + антропокомпонент (*Нурмөхәммәтгали, Габденурсабах*) яисә антропоформант + антропокомпонент (*Габденур, Габделбаттал, Әбүбәкер, Әлмөхәммәт* һ.б.) модельләрендәге татар исемнәре анализланды. Тел үсеше процессында үзгәреш кичереп, компонентлар арасында ачыклаулы һәм хәбәрлекле мөнәсәбәт нигезендә кушма исемнәрнең татар телендә бүгенге көнгәчә ясалуы ачыкланды. Татар антропонимикасында, традицион кулланылышта булган исемнәр белән бергә, экстралингвистик, лингвистик факторлар тәэсирендә барлыкка килгән фонологик һәм график ономавариантлар кулланылуы билгеләнде. Төрле аваз күчешләре нигезендә фонетик ономавариантлар ясалалар. Татар ир-ат исемнәрендә *о < у, ө < ү, а < ә, > ү* кебек аваз күчешләре, *о > у, ө > ү* кебек фонетик күчешләр төрки телләрдә ир-ат исемнәренең аерымлануында күзәтелә. Татар һәм башкорт ир-ат исемнәрендә беренче иҗектә [о],

[ө] авазлары килсә, кыргыз, казакъ, төрек, төрекмән ир-ат исемнәрдә [у], [ү] авазы чагылыш табуы билгеләнде. *а > ә, у < ү* күчешләре ике яклы килеп, татар теленең фонетик закончалыгына яраклашу нигезендә барлыкка килгәннәр. XX гасыр – XXI гасыр башы антропонимик системасында традицион татар авазларының телебезгә хас булмаган авазлар белән чиратлашуы исемнәрдә күп санда фонетик ономавариатлар ясалуга китерә. Бүгенге көндә исемнәрдәге *и > э(е)* күчешен иң продуктив төр буларак билгели алабыз. Иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ялганып, апокопа, аферезис, синкопа кебек аваз һәм аваз кушылмалары кыскарып ясалган исемнәр график ономадублетларны тәшкил итәләр.

Ике торак пунктка нисбәтле татар исемнәренең үсеш тенденцияләрендә социаль дифференциация, региональ аермалары билгеләнә. XIX гасырдан алып – XXI гасыр башына кадәр татар исемнәренең үсеш тенденцияләрен билгеләү, төрле региональ җирлекләрдә аларны синхрония һәм диахрониядә тикшерү түбәндәге нәтиҗәләрне бирде: XIX гасырда ике региональ җирлектә дә ике составлы дини эчтәлектәге исемнәр кулланыла. Ике составлы исемнәрдә антропокомпонент булып килгән *Мөхәммәд* Казан шәһәре буенча 21,7%, Мамадыш өязе буенча 30,7% ир-ат исемнәре составында килгән. Мамадыш өязендә бу чорда бер составлы дини эчтәлекле исемнәрнең чагылышы азсанлы халык яшәгән территорияләрдә әхлакый, мәдәни-этик һәм дини күзаллауларның консервативлыгын билгеләргә мөмкинлек бирә. XIX гасыр ахырында ир-ат исемнәренең Мамадыш өязендә – 98,1%, Казан шәһәрендә – 99,3% ы гарәби-фарсы чыгышлы булуы ачыкланды. XX гасыр уртасында рус теле һәм аның аша үтеп кергән алынмаларның саны арту сәбәпле, ике регионда да ике составлы исемнәрнең кимүе билгеләнә. XX гасыр башының тарихи, социаль вакыйгаларының исемнәр составы үзгәрешенә китерүе ассызыклана. XX гасыр урталарында Казан шәһәрендә традицион исем кушу тенденциясенең дәвам ителүе билгеләнде. Тик XX гасыр ахырына таба Казан шәһәрендә исемнәр репертуары төрлелеге, генетик катламнарның чуарлануы күзәтелде. Безнең карашыбызча, бу – сәяси-икътисади, фәнни, мәдәни бәйләнешләрнең, туризм үсешенең киңәюенә бәйле тенденцияләрнең чагылышы булып тора. Якын Көнчыгыш һәм Кавказ илләрендә популяр саналган исемнәр Казан шәһәре исемиятенә кулланылышка керәләр (*Азамат, Кәмран, Анар, Эрхан, Шөкер* һ.б.). XXI гасыр башында ир-ат исемнәренең «европалашу»ы һәм «азияләшү»е, тео-

фор ир-ат исемнәргә мөрәҗәгать итү тенденцияләре нигезендә татар ир-ат исемиятендә яңару, тулылану процессы бара. «Европалашу» тенденциясе Көнбатыш Европа чыгышлы исемнәрнең еш кулланылуы һәм традицион исемнәрнең татар теленә хас булмаган авазлар өстәлү (*Илдар – Эльдар, Илнар – Эльнар, Илназ – Эльназ*) билгеләнә. XXI гасыр башында дини характердагы исемнәрнең (*Кәрим, Ислам, Исламнур, Габделгазиз, Нурмөхәммәтгали, Сәйфулла, Габдулла*) артуы күзәтелә (9,3%). Шулай ук «ил», «ир», «идел», «ай», «ал», «нур» кебек традицион антропокомпонентлар һәм антропоформантларның, яңа эчтәлек һәм форма алып, яңа татар исемнәре ясавын билгеләргә кирәк (*Илдан, Иделман, Айзат, Ират, Алнур* һ.б). Татар антропонимиясе үсешенең яңа этабында эвфония факторы исем бирү мотивларын билгеләүдә мөһим булып тора. Бу тенденциянең зур шәһәрдә чагылышы күбрәк булуы ономавариантларның саны артуга китерә. Ата-аналарның исем иҗатында мәгънәгә игътибар итмәүләре билгеләнә. Традицион ир-ат исемнәренең фонетик вариантларының артуы киләчәктә милли антропонимиконның үсешенә зыян китерер дип уйлыйбыз. Шулай да бүгенге ир-ат исемнәре системасындагы төрле тенденцияләр чагылышы борынгы исемнәребезнең кире әйләнеп кайтуына тәэсир итми. XXI гасыр башында *Тимер, Тимерхан, Тимербулат, Минтимер, Бикбулсын, Тимерлан, Тамерлан* һ.б. исемнәрнең кулланыла башлавы милли антропонимиконыбызның тотрыклылыгын саклый. Татар исемнәрен һәм аларның үсеш тенденцияләрен тикшерү татар этнокультурологик системасының бик борынгы булуы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Халык тарафыннан гасырлар дәвамында тупланып килгән, төрле мәгънәгә ия, исем бирү йолалары белән үзенчәлекле татар исемияте моңа дәлил булып тора. Исемнәрдә халыкның рухи дөньясы, сәяси-иҗтимагый торышы, милли үзаңы, уйлары чагылыш тапкан. Халыкның матди-рухи мәдәниятен, тел үсешен, тарихын өйрәнүдә мөһим чыганак булып торучы, милли үзенчәлеккә ия антропонимик киңлекне тәшкил иткән татар исемнәре телнең гаять мөһим мәсьәләләрен ассызыкларга ярдәм итәләр, шулай ук этногенез мәсьәләләрен дә чишәләр.

Димәк, һәр этносның, телнең, җирле мәдәниятнең үз антропонимик системасы була. Ул система фольклор, халыкның рухи мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә яши, шул ук вакытта тирә-юнь, кеше, җәмгыять турында мәгълүмат чыганагы да булып тора.

## ЧЫГАНАКЛАР

1. Акты о рождении г. Казани Авиастроительного района (2003–2006). – Архив ЗАГСа Авиастроительного района г. Казани.

2. Акты о рождении г. Казани Кировского района (1922–2006). Архив ЗАГСа Кировского района.

3. Акты о рождении г. Мамадыш (1930–2006). Архив ЗАГСа г. Мамадыш.

4. Акты о рождении Сабинского района (2000–2006). Архив ЗАГСа Б.Сабы.

5. Акты о рождении Тюлячинского района (2000–2006). Архив ЗАГСа Тюлячи.

6. Акты о рождении Чистопольского района (2000–2006). Архив ЗАГСа г. Чистополь.

7. Акты о рождении Ютазинского района (2000–2006). Архив ЗАГСа р.п. Ютазы.

8. Книга по учету прихода и расходов бланков свидетельств о государственной регистрации рождения Управления ЗАГС ИК МО г. Казани с 2000 по 2015 г.

9. Писцовая книга Казанского уезда 1647–1656 годов: Публикация текста. М.: Институт Российской истории РАН, 2001. 541 с.

10. Писцовые книги Казанского уезда 1685–1687 гг.: публикация описаний Зюрейской дороги / изд. подгот. Д.А. Мустафиной. Казань: Казанский государственный университет, 2009. 425 с.

11. Похозяйственная книга Бахигорского с/с Атнинского р-на ТАССР, ф. 4085, оп. 2, д. 46 за 1934 г.

12. Похозяйственная книга Тлякеевского с/с Актанышского р-на ТАССР за 1934 г., ф.р. 4800, оп. 1, д. 13.

13. Похозяйственная книга Базарно-Матаковского с/с Алькеевского р-на за 1936 г., ф. 90, оп. 2, д. 1855.

14. Похозяйственная книга Базарно-Матакского с/с Алькеевского р-на ТАССР за 1938 г., ф.р. 4855, оп. 2, д. 110. 23 л.

15. Похозяйственная книга Базарно-Матакского с/с Алькеевского р-на ТАССР, ф. р-4855, оп. 2, д. 109 за 1938 г.

16. Похозяйственная книга Норманского с/с Арского р-на, ф. 2, оп. 2, р-6182, оп. 1, д.13.

17. Похозяйственная книга Старо-Зимеевского с/с Актанышского р-на за 1936 г., ф. р-4799, оп. 1, д. 16.

18. Похозяйственная книга Субашы Атнинского с/с Арского р-на ТАССР за 1938–1939 г., ф. р-5796, оп. 2, ед. хр. 26.

19. Похозяйственная книга Акзигитовского сельского Исполнительного совета Нурлатского р-на ТАССР, ф. р-6176, оп. 1, д. 3–43 л. за 1935 г.

20. Похозяйственная книга Каракашкинского с/с. Ютазинского р-на ТАССР за 1931 г., ф. 4527, оп. 1, д.1

21. Похозяйственная книга Чистопольского р-на Змиевский с/с за 1934–1935 г., ф. р.-2055, оп. 1, ед. хр. 36, 37.

22. Похозяйственная книга Тетюшского р-на Алекино-Полянский с/с за 1934–35 гг., ф. р.-2592, оп. 1, ед. хр. 41, 42–44, 47

23. Похозяйственная книга Тетюшского р-на Богдашскинского с/с за 1934–39 гг. ф.р. 2582, оп. 2, ед. хр. 17–30, оп. 4, ед. хр. 1, оп. 5, ед хр. 8.

24. Похозяйственная книга Тетюшского р-на Большебисяринский с/с за 1934 г., ф. р.-2578, оп. 1, ед. хр. 28–31.

25. Похозяйственная книга Тетюшского р-на Большетарханского с/с за 1935–1942 гг., ф.р.-2591, оп. 1, ед.хр. 4, 7–16, 18–21, 26, 27, 36, 37, 44, 45.

26. Похозяйственные книги Мамадышского р-на Букмышынского с/с. за 1934–35 гг. ф. № р.-1826, оп. 2, ед. хр. 1–4, 5–12.

27. Похозяйственные книги Мамадышского р-на Большеарташского с/с, ф. р.-5321, оп. 2, ед.хр. 2,3–14, 15, 18–24, 30–33, 37.

28. Ревизская сказка (РС) г. Елабуги о купцах за 1811 г., ф.3, оп. 2, № 449.

29. Ревизская сказка г. Мамадыш за 1834 г., ф.3, оп.2, 54.

30. Ревизская сказка г. Чистополя за 1858 г., ф.3, оп. 2, № 389.

31. Ревизская сказка Елабужского и Сарапульского уезда за 1816 г., ф. 3, оп. 2, № 4.

32. Ревизская сказка Елабужского уезда Большеучинской волости за 1811 г., ф. 3, оп. 2, №456.

33. Ревизская сказка Елабужского уезда Граховской волости за 1850 г., ф. 3, оп. 2, № 285 а.

34. Ревизская сказка Елабужского уезда за 1811, ф. 3, оп. 2, № 450

35. Ревизская сказка Елабужского уезда за 1816. ф. 3, оп. 2, № 498

36. Ревизская сказка Елабужского уезда Сарсак-Омгинской волости за 1850 г., ф. 3, оп. 2, № 285 в.

37. Ревизская сказка Елабужского уезда Сосновой волости, ф. 3, оп. 2, № 463.

38. Ревизская сказка Елабужского уезда Хлыстовской волости за 1850 г., ф. 3, оп. 2, № 285.

39. Ревизская сказка Малмыжского мещанского помещенства 1763 г. ф. 3, оп. 2, д. №438.

40. Ревизская сказка Мамадышского уезда Ядыгерской волости за 1834 г., ф. 3. оп. 2, № 71.

41. Ревизская сказка Мамадышского уезда Старо-Икшурминской волости за 1834 г., оп. 2, ф. 3, № 65.

42. Ревизская сказка Мамадышского уезда Ермовской волости за 1834, ф. 3, оп. 2, №56.

43. Ревизская сказка Мамадышского уезда Ершовской волости за 1834 г., ф.3, оп. 2, № 57.

44. Ревизская сказка Мамадышского уезда Ключицянской волости за 1834 г., ф. 3, оп. 2, № 59.

45. Ревизская сказка Мамадышского уезда о помещичьих крестьянах и дворовых за 1834 г., ф. 3, оп. 2, № 55.

46. Ревизская сказка Мамадышского уезда Покровской волости за 1834 г. ф. 3. оп. 2, № 66.

47. Ревизская сказка Мамадышского уезда Покровской волости за 1834 г., ф. 3, оп. 2, № 66.

48. Ревизская сказка Мамадышского уезда Старо-Ошминской волости за 1834 г., ф. 3, оп. 2, № 69.

49. Ревизская сказка Мамадышского уезда Тавельской волости, 1834 г., ф. 3, оп. 2, №71.

50. Ревизская сказка о купцах мещанах и цеховых г. Казани русского и татарского сословиях (1891–1879) – ЦГА РТ, ф. 3, оп. 2.

51. Ревизская сказка о купцах мещанах Мамадышского уезда татарского общества (1870–1879). ЦГА РТ, ф.3, оп. 2.

52. Ревизская сказка о числах душ третьей ревизии Арской дороги Бакиловой, Тимофеева, Шариповой, Кульметьевой, Аптыковой, Абдулькаримова, Тимкиной, Бикеевой и прочих сотен 1762 г., ф. 3., оп. 2., д. № 434.

53. Ревизская сказка Чистопольского духовного правления за 1850 г., ф. 3, оп. 2, № 260.

54. Ревизская сказка Чистопольского и Казанского уездов за 1834 г., ф. 3, оп. 2, № 140.

55. Ревизская сказка Чистопольского уезда 1858 г., ф. 3, оп. 2, № 387.

56. Ревизская сказка Чистопольского уезда за 1815 г., ф.3, оп. 2, № 476.

57. Ревизская сказка Чистопольского уезда за 1816 г., ф.3, оп. 2, № 483.

58. Ревизская сказка Чистопольского уезда за 1816 г., ф.3, оп. 2, № 484.

59. Ревизская сказка Чистопольского уезда за 1834 г., ф.3, оп. 2, № 525.

60. Ревизская сказка Чистопольского уезда за 1858 г., ф.3, оп. 2, № 389.

61. Ревизская сказка Чистопольского уезда за 1858 г., ф.3, оп. 2, № 391.

62. Ревизская сказка Чистопольского уезда за 1858 г., ф.3, оп. 2, № 396.

63. Ревизская сказка Чистопольского уезда за 1858 г., ф.3. оп. 2, № 388.

64. Ревизская сказка Чистопольского уезда Касинской волости за 1850 г., ф. 3, оп. 2, № 262.

65. Ревизская сказка Чистопольского уезда Новошешминской волости 1834 г., ф. 3, оп. 2. № 141.

66. Ревизская сказка Чистопольского уезда о купцах и мещанах 1834 г., ф. 3, оп. 2, № 138.

67. Ревизская сказка Чистопольского уезда о помещичьих крестьянах, 1850 г., ф. 3, оп. 2, № 259.

68. Ревизская сказка Чистопольского уезда о помещичьих крестьянах 1834 г., ф. 3, оп. 2, № 139.

69. Ревизская сказка Чистопольского уезда Старошешминской волости за 1850 г., ф. 3, оп. 2, № 265.

70. Ревизская сказка Чистопольского уезда Степнобиляроозерской волости за 1850 г., ф.3, оп. 2, № 267.

71. Ревизские сказки на 1762 г., ф. 3, оп. 2, д. 432.

72. Ревизские сказки на 1762 г., ф. 3, оп. 2, д. 427.

## ФӘННИ-ТЕОРЕТИК ӘДӘБИЯТ

Абрамзон С.М. Отражение процесса сближения наций на семейно-бытовом укладе народов Средней Азии и Казахстана / С.М. Абрамзон //Советская этнография. – М. – 1962. – № 3. – С. 15.

Абрамзон С.М. Рождение и детство киргизского ребенка / С.М. Абрамзон. – М. – Л., 1949. – 104 с.

Айдаров Г. Язык орхонских памятников древнетюркской письменности VIII в. / Г.Айдаров. Алма-Ата: Наука, 1971. 376 с.

Айтбаева Л.Х. Историко-лингвистическое исследование антропонимии татар междуречья нижней Оби и Иртыша (XX век): автореф. дис.... канд. филол. наук / Л.Х. Айтбаева; Тюмен. гос. ун-т. -– Тюмень, 2004. 24 с.

Алдарова Н.Б. О зооморфных антропонимах в монгольском языке / Н.Б. Алдарова // Ономастика Поволжья. – Саранск, 1976. – С. 103–107.

Алеев Г.Р. Лингвистические и экстралингвистические факторы в антропонимии (на материале тюркских языков: азербайджанской, узбекской, казахской, киргизской, татарской, башкирской): автореф. дис.... д-ра филол. наук / Г.Р. Алеев. – Алма-Ата, 1989. – 48 с.

Алефиренко Н.Ф. Современые проблемы науки о языке: учебное пособие / Н.Ф. Алефиренко. – М.: Флинта: Наука, 2005. – 416 с.

Алиев В.Г. Причастие в азербайджанском и узбекском языках: автореф. дис. ... канд. филол. наук / В.Г. Алиев. – Ташкент, 1965. – 24 с.

Алишев С. Древний тюркский мир / С. Алишев – Казань, 2000. – 72 с.

Алишина Х.Ч. Историко-лингвистическое исследование ономастикона сибирских татар (на материале Тюменской области): автореф. дис.... д-ра филол. наук / Л.Х. Алишина. – Казань, 1999. – 48 с.

Англо-русский словарь / под ред. О.С. Ахмановой. – М.: Лист Нью, 2004. – 987 с.

Аннаклычев Ш. Мотивы выбора имен у туркмен / Ш. Аннаклычев // Ономастика. – М.: Наука, 1969. – 260 с.

Арабо-русский словарь / Сост. Х.Г. Баранов. – М., 1957. – 1187 с.

Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов / О.С. Ахманова. – М.: Советская энциклопедия, 1969. – 607 с.

Ахметзянов М.И. Татарские шеджере / М.И. Ахметзянов – Казан: Татар. кн. изд-во, 1991. – 152 с.

Ахметьянов Р.Г. Этимологические основы лексики татарского языка: дис. ... канд. филол. наук / Р.Г. Ахметьянов. – Казань, 1969. – 595 с.

Ахунзянов Э.М. Русские заимствования в татарском языке / Э.М. Ахунзянов. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1968. – 367 с.

Ашмарин Н.Г. Материалы по исследованию чувашского языка / Н.Г. Ашмарин. – Казань, 1898. – 392 с.

Әнвәрова М.Х. Татар телендә композит (кушма) кеше исемнәрен классификацияләү мәсьәләсе / М.Х. Әнвәрова // Милли мәдәният. – Казан: Гуманитария, 2006 – №10. – Б. 52–54.

Әхмәтҗанов М. XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре. – Казан, 2011. – 260 б.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г. Әхмәтьянов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. 1 том (А–Л). – Казан: Вакыт, Мәгариф, 2015. – 543 с.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 том (М–Я). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 567 б.

Байчура У.Ш. Звуковой строй татарского языка / У.Ш. Байчура. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1959 – 185 с.

Баскаков Н.А. Алтайская семья языков и ее изучение / Н.А. Баскаков. –М.: Наука, 1981. – 135 с.

Баскаков Н.А. Модели тюркских этнонимов и их типологическая классификация / Н.А. Баскаков // Ономастика Востока – М.: Наука, 1980 – С. 199–207.

Баскаков Н.А. Русские фамилии тюркского происхождения / Н.А. Баскаков. – М.: Наука, 1979. – 279 с.

Баскаков Н.А. Титулы и звания в социальной структуре бывшего Хивинского ханства / Н.В. Баскаков // Советская тюркология. – 1989. – № 1.

Батманов И.А. Язык енисейских памятников древнетюрской письменности / И.А. Батманов. – Фрунзе, 1959. – 219 с.

Баязитова Ф.С. Урта Урал (Сведловск өлкәсе) татарлары. – Казан: Фикер, 2002. – 416 с.

Баязитова Ф.С. Халык традицияләре лексикасы. Мифологик персонажлар, ышанулар (җирле сөйләшләр һәм фольклор текстлар яссылыгында) / Ф.С. Баязитова. – Казан, 2018. – 823 б.

Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: исем категорияләре һәм фигыль наклоненеиләрендә әдәби норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык / И.Б. Бәширова. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1999. – 576 б.

Бәширова И.Б. Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: татар лексикасында системалы бәйләнеш мөнәсәбәтләр / И.Б. Бәширова. – Казан, 2006. – 192 б.

Бегматов Э. Антропонимика узбекского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Э. Бегматов. – Ташкент, 1965. – 26 с.

Безертдинов Р.Н. Татары, тюрки – потрясатели вселенной / Р.Н. Безертдинов. – Новосибирск: ЦЭРИС, 2001. – 733 с.

Белецкий А.А. Лексикология и теория языкознания (ономастика) / А.А. Белецкий. – Киев: Изд-во Киевского ун-та, 1978. – 208 с.

Белова, О. В. Этнокультурные стереотипы в славянской народной традиции / О.В. Белова. – М.: Индрик, 2005. – 409 с.

Бендуков А. Исем. Балага күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафыйк китап / А. Бендуков. – Казан, 1899. – 46 б.

Березович Е.Л. Русская топонимия в этнолингвистическом аспекте: Мифопоэтический образ пространства / Е.Л. Березович. – М.: КомКнига, 2010. – 240 с.

Бестужев-Лада И.В. Исторические тенденции развития антропонимов / И.В. Бестужев-Лада // Личные имена в прошлом, настоящем и будущем. – М.: Наука, 1970. – С . 24–33.

Биджиева Ф.И. История возникновения и развития карачаевских фамилий, XVI – конце XX в.: автореф. дис. ... канд. ист. наук. – Карачаевск, 2002. – 27 с.

Биктимирова А. Р. Лингвистическая и ономастическая поэтика татарских народных песен: автореф. дис.… канд. филол. наук. – Казань, 2003. – 25 с.

Богатырев П.Г., Якобсон Р.О. Фольклор как особая форма творчества [Электронный ресурс] // Богатырев П.Г. Вопросы народного творчества. – М., 1971. – С. 369 – 383 (http://www.ruthenia.ru/folklore/jackobson1.htm).

Бондалетов В.Д. Русская ономастика / В.Д. Бондалетов. – М.: Просвещение, 1986. – 223 с.

Булатов А.Б. Личные имена у древних булгар / А.Б. Булатов // Ономастика Поволжья. – Горький, 1971. – С. 79–81.

Булатова М. Асыл сүзләр халкым телендә // Милли-мәдәни мирасыбыз. Мари Эл татарлары. Бәрәңге. – Казан: ИЯЛИ, 2012. – Б. 149–229

Булатова М.Р. Курмантауский говор среднего диалекта татарского языка в этнолингвистическом аспекте. – Казань: Магариф – Вакыт, 2016. – 384 с.

Вагапова Ф.Г. Историко-лингвистический анализ личных имен нижегородских татар XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Ф.Г. Вагапова. – Казань, 2002. – 20 с.

Вафеев Р.А., Выхрыстюк М.С., Файзуллина Г.Ч. Фамилии тюркского происхождения ревизских сказках города Тобольска XVIII века: структурно-

семантический аспект // Вестник Челябинского государственного университета, 2012, № 23 (277). Филология. Искусствоведение. Вып. 69. – С. 32–35.

Вежбицкая А. Язык. Культура. Познание / А. Вежбицкая. – М.: Русские словари, 1997. – 411 с.

Вельяминов-Зернов В.К. Исследование о Касимовских царях и царевичах / В.К. Вельяминов-Зернов. – СПб.: Тип. имп. Акад. наук, ч. 1, 1863. – 558 с.; ч. 2, 1864. – 498 с.; ч. 3, 1866. – 502 с.; ч. 4., 1887. – 178 с.

Вершинин В. И. Наши фамилии. – Йошкар-Ола, 2016. – 203 с.

Вершинин В.И. Антропонимы: Фамилии. Имена. – Йошкар-Ола, 2015. – 145 с.

Веселовский, А. Н. Историческая поэтика / А.Н. Веселовский. – М.: Высшая школа, 1989. – 408 с.

Вәлиуллина З.М. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе / З.М. Вәлиуллина, К.З. Зиннәтуллина, М.А. Сәгыйтов. – Казан, 1972. – 206 б.

Волощенко О.В. Языковые основы фольклора в свете явлений традиционной народной культуры: на материале русской волшебной сказки: автореф. дис. ... канд. филол. наук / О.В. Волощенко. – Воронеж, 2006. – 25 с.

Вопросы антропонимии / составитель и редактор А.И. Назаров. – Алматы, 2005. – 100 с.

Вороничев О.Е. Об устаревших фактах ономастики / О.Е. Вороничев // Русский язык в школе. –2000. – № 1 – С. 70–73.

Воронцова Ю.Б. Коллективные прозвища в русских говорах: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Екатеринбург, 2002. – 17 с.

Габишева Л.Л. Слово в контексте мифопоэтической картины. – М.: РГГУ, 2003. – 192 с.

Гаджиева Н.З. Словосочетание как объект сравнительно-исторической грамматики тюркских языков / Н.З. Гаджиева // Структура и история тюркских языков. – М.: Наука, 1971. – С. 209–222.

Галиуллина Г.Р. Антропонимия татар г. Казани в XX веке (на материале личных имен): автореф. ... канд. филол. наук / Г.Р. Галиуллина. – Казань, 1999. – 19 с.

Галиуллина Г.Р. Личные имена татар в XX веке / Г.Р. Галиуллина. – Казань: Матбугат йорты, 2000. – 112 с.

Галиуллина Г.Р. О формировании и развитии татарского антропонимикона (по материалам писцовых книг Казани и Казанского уезда XVI века) // Средневековые тюрко-татарские государства // Сборник статей. Вып. 6. Материалы международной научной конференции «Средневековые тюрко-татарские государства и их соседи в системе международных отношений (XV–XVIII вв.)» (г. Казань, 14–15 марта 2014 г.). – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2014. – С. 195–198.

Галиуллина Г.Р. Татар кеше исемнәрендә фонетик закончалыкларның чагылышы / Г.Р. Галиуллина // Фәнни язмалар – 2001. – Казан: Школа, 2002. – Б. 29–32.

Ганиев Ф.А. Образование сложных слов в татарском языке / Ф.А. Ганиев. – Казань: Печатный двор, 2002. – 192 с.

Ганиев Ф.А. Суффиксальное словообразование в татарском языке / Ф.А. Ганиев. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1974. – 230 с.

Ганиев Ф.А. Фонетическое словообразование в татарском языке / Ф.А. Ганиев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1973. – 40 с.

Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби теле: Сүзьясалышы / Ф.Ә. Ганиев. – Казан: Мәгариф, 2000. – 271 б.

Ганиева Г.Р. Фразеологические единицы с компонентом именем собственным в английском, русском и татарском языках. Нижнекамск: Нижнекамский химико-технологический институт (филиал) ФГБОУ ВПО «КНИТУ», 2012. – 109 с.

Ганиева Р.К. Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали / Р.К. Ганиева.– Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. –170 с.

Гарипов Т.М. О древних кипчакских именах в антропонимии башкир / Т.М. Гарипов // Ономастика Поволжья. – Уфа, 1973. – Вып. 3. – С. 52–54.

Гарипова Н.Д. Персидские элементы в именах башкир / Н.Д. Гарипова // Ономастика Поволжья. – Уфа, 1973. – С. 81–85.

Гарипова Ф. Исемнәрдә – ил тарихы / Ф. Гарипова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 263 б.

Гариф Н. Тарихи чыганакларда төрки-татар исемнәре һәм географик атамалар. – Казан: ТФА. Тарих институты басмаханәсе, 2011. – 240 с.

Гасимова С.И. Историко-лингвистический анализ татарских прозвищ: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2006. – 25 с.

Гафуров А. Имя и история / А. Гафуров – М.: Наука, 1987 – 220 с.

Гафуров А. Лев и Кипарис (о восточных именах) / А. Гафуров. – М.: Наука, 1971.–238 с.

Горбачева О.Г. Ономастическое пространство русских народных и авторских сказок: автореф. дис. … канд. филол. наук / О.Г. Горбачева. – Брянск, 2008. – 25 с.

Гордлевский В.А. Избранные сочинения / В.А. Гордлевский. – М.: Наука, 1968. – Т.4. – 609 с.

Гречко В.А. Теория языкознания: учебное пособие / В.А. Гречко. – М.: Высш. шк., 2003. – 372с.

ГТРАС – Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Казан: Иман, 1993.

Гумилев Л.Н. Древние тюрки / Л.Н. Гумилев. – М.: Товарищество «Клышников-Комаров и К», 1993. – 514 с.

Гумилев Л.Н. Хунну Срединная Азия в древние времена / Л.Н. Гумилев. – М., 1960.

Давлетшина Л. Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань. – 2005. – 25 с.

Давлетшина Л. Религиозно-мифологические представления о «нечистой силе» в традиции тюменских татар / Л. Давлетшина // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота, 2016. № 9. Ч. 1. – С. 25–27.

Давлетшина Л.Х. «Хызыр Ильяс» в традиционной культуре татар // Вестник Башкирск. ун-та. – 2011. – № 3. URL: http://cyberleninka.ru/article/n/hyzyr-ilyas-v-trad itsionnoy-kulture-tatar (дата обращения: 24.08.2017).

Давлетшина Л.Х. К проблеме изучения низшей мифологии: мифологический персонаж // Вестник КГПУ им. В.П. Астафьева. – 2011. – № 3. URL: http://cyberleninka.ru/article/n/k-probleme-izucheniya-nizshey-mifologii-mifologicheskiy-personazh (дата обращения: 24.08.2017).

Дарзаманова Г.З. Фразеологические единицы и паремии с антропонима и в русском, татарском и английском языках: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2002. – 21 с.

Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы / Г. Дәүләтшин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 512 б.

Дмитриев Н.К. Грамматика башкирского языка / Н.К. Дмитриев. – М., 1948. – 276 с.

Дмитриев Н.К. Строй тюркских языков / Н.К. Дмитриев. – М.: Изд-во вост. лит-ры, 1962. – 607 с.

Дранникова Н.В. Локально-групповые прозвища в традиционной культуре: функциональность, жанровая система, этнопоэтика: автореф. дис. ... д-ра филол. наук, 2005. – 56 с.

Древнетюркский словарь. – Л.: Наука, 1969. – 675 с.

Жаненова З.Р. Историко-лингвистический анализ казахского антропонимикона 40–90-х годов 20 столетия: автореф. дис. ... канд. филол. наук / З.Р. Жаненова; Казан. гос. ун-та – Казань, 1994. – 17 с.

Жанузак Т. Есімдер сыры. – Алматы, 2004. – 208 б.

Жанузаков Т. Лично-собственные имена в казахском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Т. Жанузаков – Алма-Ата, 1960. – 18 с.

Жанузаков Т.Ж. Обычаи и традиции в казахской антропонимике / Т.Ж. Жанузаков // Этнография имен. – М., 1971. С. 100–103.

Жапаров Ш. Адам аттары – эл байлыгы. – Бишкек: «Текник» ББ, 2009. – 560 б.

Жапаров Ш. Киргизская антропонимия: автореф. дис. ... д-ра филол. наук / Ш. Жапаров; АН Казахской ССР. Ин-т языкознания. – Алма-Ата, 1989. – 53 с.

Жапаров Ш. Кыргызская антропонимика / Ш. Жапаров. – Бишкек: Илим, 1992. – 188 с.

Жапаров Ш. Кыргызская антропонимия. – Бишкек: Илим, 1992. – 188 с.

Жирмунский В. М. Тюркский героический эпос. – Л.: Наука, 1974. – 727 с.

Жуковская Н.Л. Заметки о монгольской антропонимии / Н.Л. Жуковская // Ономастика Востока. – М.: Наука, 1980. – С. 9–15.

Журавлев А.П. Фонетическое значение / А.П. Журавлев. – Л.: Изд-во Ленинградского ун-та, 1974. – 158 с.

Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар / Л. Җәләй. – Казан: Татар. кн.изд-во, 1954. – 108 б.

Җәүһәрова Ф.Х. Татарларда мал тоту традициясенә бәйле мифологик күзаллаулар / Ф.Х. Җәүһәрова. // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре (фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы). – 7 китап. – Казан: Ихлас, 2012. – Б. 50–53.

Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка / М.З. Закиев. – Казань, 1963. – 345 с.

Закирова И. Г. Дастан «Ак Кубек» тюркских народов // Вестник Чувашского университета. – 2009. – № 4. – С. 296–301.

Залялиева М.А. Историко-лингвистическое исследование татарских личных имен русского и западноевропейского происхождения: автореф. дис. ... канд. филол. наук / М.А. Залялиева. – Казань, 1982. – 21 с.

Залялиева М.А. Историко-лингвистическое исследование татарских личных имен русского и западноевропейского происхождения: дис. ... канд. филол. наук / М.А. Залялиева. – Казань, 1985. – 297 с.

Залялиева М.А. Татарские личные имена русского и западноевропейского происхождения / М.А. Залялиева // Ономастика Татарии. – Казань, 1989. – 120 с.

Зеленин, Д. К. Восточнославянская этнография / Д.К. Зеленин. – М.: Наука, 1991. – 511 с.

Зенков Г.С. Вопросы теории словообразования / Г.С. Зенков. – Фрунзе, 1969. – 164 с.

Зәкиев М. Татар теленең барлыкка килүе / М. Зәкиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 207 б.

Зәкиев М. Төрки-татар этногенезы / М. Зәкиев. – Казан: Фикер; Мәскәү: Инсан, 1998. – 624 б.

Зима Д. Тайна имени: как назвать вашего ребенка? / Д. Зима, Н. Зима. – М.: Ринал Классик, 2004. – 639 с.

Золотницкий Н.И. Корневой чувашско-русский словарь, сравненный с языками и наречиями разных народов тюркского, финского и др. / Н.И. Золотницкий. – Казань: Тип. Имп. Университета, 1875. – 279 с.

Иванова А.М., Хазиева-Демирбаш Г.С Сравнительно-сопоставительный анализ антропонимов коранических персонажей в афористических жанрах татарского и турецкого фольклора / А.М. Иванова, Г.С. Хазиева-Демирбаш // Вестник Чувашского университета. – 2017. – № 2 . – С. 203–207.

Иванова А.М., Хазиева-Демирбаш Г.С. Сравнительно-сопоставительный анализ охранительных имен в тюркских языках / А.М. Иванова, Г.С. Хазиева-Демирбаш // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – 2017. – № 5. – Ч. 3. – С. 87–90.

Ивашко В.А. Как выбирают имена / В.А. Ивашко. – Минск: Вышэйш.шк., 1988. – 287 с.

Игошина Ю.В. Оппозиция мировоззрений и онтология имени в философии П.А. Флоренского: автореф. дис. ... канд. филос. наук / Ю.В. Игошина. – Киров, 2003. – 19 с.

Илизаров А.С. О внутренней форме и происхождения арабских имен / А.С. Илизаров, Б.А. Старостин, А. Хейри // Личные имена в прошлом, настоящем, будущем. – М.: Наука, 1970. – С. 290–300.

Имаева Г.З. Типологические сближения в восточнославянских и тюркоязычных сказках. – Казань: ИЯЛИ, 2009. – 216 с.

Исмагулова Б.Х., Баяндина С.Ж. Ономастическое пространство казахского фольклора / Б.Х. Исмагулова // Материалы международного конгресса «Актуальные проблемы комплексного исследования алтаистики и тюркологии. – Кокшетау, 2009. – С. 187–192.

Исме Әгъзам китабы: Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 111 б.

История татар. Т. I. Народы степной Евразии в древности. – Казань: Рухият, 2002. – 552 с.

Исхакова Х.Ф. Сопоставительная грамматика татарских и русских собственных имен / Х.Ф. Исхакова. – М.: Наука, 2000. – 110 с.

Калинкин В. М. Поэтика онима. – Донецк, 1999. – 408 с.

Карнович Е.П. Родовые прозвания и титулы в России и слияние иноземцев с русскими. – СПб., 1886. – 248 с.

Карташева И.Ю. Прозвища как явление русского устного народного творчества: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Челябинск, 1985. – 17 с.

Касимов Э.С. Сатира и юмор в татарских народных сказках: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1966. –26 с.

Катанов Н.Ф. Алфавитный указатель собственных имен, встречающихся в первом томе Образцов народной литературы тюркских племен, собранных

В.В. Радловым: Представлено Акад. в заседании Ист.-филол. отд. 22 сент. 1887 г. / сост. Н.Ф. Катанов. – СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1888.

Керимбаев Д.М. Состав и этнолингвистическая характеристика собственных имён казахского фольклора: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Алматы, 2004. – 28 с.

Керимбаева С.Е. Ономастическая экспликация мифологической модели мира в казахском языке: автореф. дис. канд. филол. наук / С.Е. Керимбаева. – Алматы, 2004. – 28 с.

Кондратьева Т.Н. Собственные имена в месяцесловах, пословицах, поговорках, загадках, заговорах и сказках русского народа / Т.Н. Кондратьева. – Казань, 2004. – 340 с.

Кондратьева Т. Н. Собственные имена в русском эпосе. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1967. – 244 с.

Кормушин И.В. Тюркские енисейские эпитафии: грамматика, текстологи. М.: Наука, 2008. – 342 с.

Королева И.А. Становление русской антропонимической системы: автореф. дис. ... д-ра филол. наук, 2000. – 56 с.

Косточков Г.В. Историко-лингвистическое исследование шорской антропонимии: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Г.В. Косточков. – Казань, 1995. – 21 с.

Кошгари Махмут. Туркий сузлар девони: в 3-х томах / С.И. Муталлибов. – Тошкент, 1960.

Кульдеева Г.И. Антропонимическая система современного казахского языка / Г.И. Кульдеева. – Казань: Изд-во «ДАС», 2001. – 239 с.

Кульдеева Г.И. Антропонимическая система современного казахского языка: автореф. дис. ... д-ра филол. наук / Г.И. Кульдеева. – Казань, 2001.

Кульдеева Г.И. Антропонимия казахов г. Кзыл-Орды и его окрестностей (на материале личных имен): автореф. дис. ... канд. филол. наук / Г.И. Кульдеева. – Казань: Казан гос. ун-т. 1994. – 17 с.

Курбанов А. Основы Азербайджанской ономалогии. II т. – Баку: Нурлан, 2004. – 504 с.

Курышжанов А.К. Исследование по лексике старокыпчакского письменного памятника XIII в. – «Тюрко-арабский словарь» / А.К. Курышжанов. – Алма-Ата. – 1970 – 223 с.

Кусимова Т, Бикколова С. Башкирские имена. – Уфа: Китап, 2005. – 224 с.

Кусимова Т.Х. Древнебашкирские антропонимы: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Т.Х. Кусимова. – Уфа, 1975. – 19 с.

Лангнер А.Н. Функционально-семантические и словообразовательные особенности прозвищ: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Белгород, 2010. – 25 с.

Леонтьев А.А. Основы психолингвистики / А.А. Леонтьев. – М.: Смысл; Издательский центр «Академия», 2005. – 288с.

Личные имена в прошлом, настоящем и будущем – М.: Наука, 1970. – С. 201–206.

Лосев Л.Ф. Философия имени / Л.Ф. Лосев. – М.: Изд-во Моск. ун-та, 1990. – 270 с.

Магазаник Э.Б. Ономапоэтика или говорящие имена в литературе. – Ташкент: Фан, 1978. – 146 с.

Магницкий В.К. Чувашские языческие имена / В.К. Магницкий. – Казань: Тип. ун-та, 1905. – 101 с.

Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности: тексты и исследования / С.Е. Малов. – М.; JL, 1951. – 451 с.

Марченкова Ю.Ю. Фамилии Рославльского края: синхронический и диахронический аспекты: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Смоленск, 2006. – 26 с.

Махмуд ал-Кашгари. Диван лугат ат-турк (Свод тюркских слов): в 3 т. / пер. с араб. А.Р. Рустамова, под ред. И.В. Кормушина, прим. И.В. Кормушина, Е.А. Поцелуевского, А.Р. Рустамова; Институт востоковедения РАН: Институт языкознания РАН. – М.: Вост. лит., Т. 1. – 2010. – 461 с.

Махмудов В.М. Имя собственное в дагестанских и русском языках: дис.... канд. филол. наук / В.М. Махмудов; Краснодар, 2001. – 190 с.

Махмутова Л.Т. Опыт исследования тюркских диалектов / Л.Т. Махмутова. – М.: Наука, 1978. – 269 с.

Махпиров В.У. Древнетюркская ономастика / В.У. Махпиров. – Алма- Ата: Гылым, 1990. – 158 с.

Маюрова Ж.Д. Сложные прозвища у бурят: Структура и семантика: автореф. канд. филол. наук. – Иркутск, 2001. 26 с.

Мәхмүтов М.И. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге / М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин: ике томда. – Казан: Иман, 1993. – Т. 1. – 448 б.

Мәхмүтов М.И. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге / М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин: ике томда. – Казан: Иман, 1993. – Т. 2. – 854 б.

Мәхмүтов Х.Ш. Гыйбәрәләр тарихыннан сәхифәләр (Этимологик эзләнүләр) / Х.Ш. Мәхмүтов. – Казан, 2008. – 464 б.

Миннуллин К.М. Басма сүз һәм татар җырлары / К.М. Миннуллин. – Казан: Мәгариф, 2000. – 157 б.

Миннуллин К.М. Һәр чорның үз җыры / К.М. Миннуллин. – Казан: Мәгариф, 2003. – 400 б.

Миннуллин К.М. Песня как искусство слова: автореф. дис. ... д-ра филол. наук: 10.01.09, 10.01.02 / К.М. Миннуллин. – Казань, 2001. – 56 с.

Миннуллин, К.М. Шигърият һәм җыр / К.М. Миннуллин. – Казан: Мәгариф, 1998. – 287 б.

Миңнегулов Х.И. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар / Х.Й. Миңнегулов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1988. – 196 б.

Митрошкина А.Г. Бурятская антропонимия / А.Г. Митрошкина. – Новосибирск: Наука, 1987. – 220 с.

Молчанова О.Т. Мотивированные личные имена у алтайцев / О.Т. Молчанова // Личные имена в прошлом, настоящем и будущем. – М.: Наука, 1970. – С. 189–194.

Морошкин М. Я. Славянский именослов. Собрание славянских личных имен. – СПб., 1867.

Мөслими Х. «Рисаләи тәварихы Болгария» фи зикри мәүляна хазрәте Аксактимер вә харәбе шәһәре Болгар / Х. Мөслими – Казан: Хәмзин, 1286. – 76 б.

МРС – Монгольско-русский словарь. – М.: ГИС, 1957. –715 с.

Мусаев К.М. Тюрко-иранские языковые связи / К.М. Мусаев // Советская тюркология. – 1989. – № 1. – С. 26–35.

Мусаев К.М. Тюркская лексикология / К.М. Мусаев. – М.: Наука.

Мусаева Р.А. Кумыкская антропонимика: прозвища и имена: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Махачкала, 2008. – 22 с.

Мусульманские имена. Словарь-справочник. – СПб.: Изд-во «Диля». 2007. – 448 с.

Мухаметзянова Л.Х. Книжный дастан в творчестве казанских татар // Вестник ТГГПУ. – 2011. – № 4 (26). – С. 247–249.

Насыйри, К. Сайланма әсәрләр / К. Насыйри. – Ике томда. Беренче том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 339 б.

Невоструев К. И. Список с писцовых книг по г. Казани с уездов / издан Советом Казанской духовной академии к IV Археологическому съезду в Казани. – Казань: Тип. Имп. ун-та, 1877. – 88 с.

Нигматуллов М.М. О некоторых кыпчакских и огузских элементах в топонимике и антропонимике / М.М. Нигматуллов // Ономастика Поволжья. – Уфа: Изд-во БГПУ, 2006. – С. 154–157.

Ниетбаева К.А. Историко-лингвистический анализ казахских фамилий: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1993.

Никитина С.Е. Устная народная культура и языковое сознание / С.Е. Никитина. – М.: Наука, 1993. – 189 с.

Никонов В.А. Задачи и методы антропонимики / В.А. Никонов // Личные имена в прошлом, настоящем и будущем. – М.: Наука, 1970. – С. 3–10.

Никонов В.А. Имя и общество / В.А. Никонов. – М.: Наука, 1974. – 278 с.

Никулина З.П. Из наблюдений над группой прозвищ по внешнему признаку // Имя нарицательные и собственное. – М.: Наука, 1978. – С. 173–180.

Новикова О.Н. Об одном имени В башкирском именнике / О.Н. Новикова // Ономастика Поволжья. – Уфа: Изд-во БГПУ, 2006 – С. 85–86.

Һадиев И, Мәрдәнов Р. Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре / И. Һадиев, Р. Мәрдәнов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 199 б.

Ономастика Поволжья. – Саранск, 1986. – 150 с.

Ономастика Поволжья. – Ульяновск, 1969. – 280 с.

Ономастика Поволжья. – Уфа: Изд-во БГПУ, 2006. – 372 с.

Ономастика Поволжья. – Уфа, 1973. – 431 с.

Ономастика Средней Азии. – М.: Наука, 1978 – 226 с.

Ономастика Средней Азии. – Фрунзе: Илим, 1980 – 310 с.

Ономастика Татарии. – Казань, 1989 – 118 с.

Ономастика. Проблемы и методы. – М., 1978. – 238 с.

Парфенова Н.Н. Русские фамилии конца XVI–XVIII вв.: По архивным источникам Зауралья: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – М., 2002. – 26 с.

Персидско-русский словарь / под ред. Ю.А. Рубинчика. – М.: Советская энциклопедия, 1970 – Т. 1. – 782 с.

Петровский Н.А. Словарь русских личных имен / Н.А. Петровский. – М.: Русские словари: Астрель, 2000. – 477 с.

Плавинская Л.С. Фамилии рязанского дворянства XVI–XVIII вв. и их отражение в местной топонимии: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Смоленск, 2013. – 26 с.

Подольская Н.В. Словарь русский ономастической терминологии / Н.В. Подольская. – М.: Русские словари: Астрель, 1988. – 135 с.

Подольская Н.В. Словарь русской ономастической терминологии / Н.В. Подольская. – М.: Наука, 1988 – 135 с.

Проблемы словообразования в тюркских языках: материалы конференции. – Казан: Фикер, 2002 – 368 с.

Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки. – Л.: Изд-во Ленинградского ун-та, 1946. – 340 с.

Пропп В.Я. Морфология сказки. – М.: Наука, 1969. – 167 с.

Пропп В.Я. Русский героический эпос. – М.: Государственное издательство художественной литературы, 1958. – 604 с.

ПРС – Персидско-русский словарь / под ред. Ю.А. Рубинчика. – М.: Советская энциклопедия, 1970. – Т.2. – 848 с.

Радлов В.В. Опыт словаря тюркских наречий. – М., 1963. – Т. 1, ч. 2. – 969 с.

Рәхимова А. Төрек грамматикасы / А. Рәхимова. – Казан, 2002 – 344 б.

Русско-немецкий, немецко-русский словарь / Ида Бастрон-Сухарь. – М., 2000. – 543 с.

Русско-французский словарь / сост. Л.Р. Шерба и др. – М.: АСТ: Астрель, 2003. – 800 с.

Рыбакин А.И. Словарь английских личных имен / А.И. Рыбакин. – М.: ООО «Издательство Астрель»: ССС «Издательство АСТ», 2000. – 224 с.

Салимзянова Ф.С. Историко-лингвистический анализ татарской антропонимической системы нагорной стороны РТ: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Ф.С. Салимзянова – Казань, 2002. – 25 с.

Салимов Х.Х., Осипова Л.Ф. Фонетическое значения антропонимов / Х.Х. Салимов, Л.Ф. Осипова // Ономастика Поволжья. –Уфа: Изд-во БГПУ, 2006. – С. 333–336.

Саттаров Г.Ф. Антропотопонимия Татарской АССР: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Казань, 1975 – 90 с.

Саттаров Г.Ф. Бөек Октябрьдан соң татар ономастикасы үсешенең кайбер тенденцияләре / Г.Ф. Саттаров // Вопросы тюркологии. – Казань, 1970. – 283 с.

Саттаров Г.Ф. Булгарский пласт топонимии и антропонимии казанских татар / Г.Ф. Саттаров // Ономастика Татарии, Казань, 1989. – С. 5–28.

Саттаров Г.Ф. Категория ласкательности в татарских личных именах / Г.Ф. Саттаров // Антропонимика. – М.: Наука, 1970.– С. 211–218.

Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы / Г.Ф. Саттаров. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1990. – 276 б.

Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? / Г.Ф. Саттаров – Казан: Раннур, 1998. – 486 б.

Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге / Г.Ф. Саттаров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989 – 2 56 б.

Саттаров Г.Ф. Татарларда кушаматлар / Г.Ф. Саттаров // Совет мәктәбе. – 1973. – № 9. – С. 46–49

Саттаров Г.Ф. Татарская антропонимия и этнолингвистические связи / Г.Ф. Саттаров // Советская тюркология. – 1978. – №3. – С . 22–32.

Саттаров Г.Ф. Этнолингвистические пласты татарского именника / Г.Ф. Саттаров // Советская тюркология. – 1982. – № 3. – С. 23–29.

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен) / Ф.С. Сафиуллина. – Казан: «Хәтер» нәшрияты, 1999. – 288 б.

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология, фразеология, фонетика, графика һәм орфография, орфоэпия, сүз ясалышы, морфология, синтаксис / Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 1994. – 320 б.

Селищев А.М. Труды по русскому языку. Т. 1. Язык и общество / сост.: Б.А. Успенский, О.В. Никитин. – М.: Языки славянской культуры, 2003. – 632 с.

Семенова Г.И. Именные композиты в чувашском языке: автореф. дис. ...канд. филол. наук / Г.И. Семенова. – Чебоксары: Чувашский гос. ун-т, 2005. – 50 с.

Сиразиев И.И. Арабский пласт современного литературного языка: дис. ... канд. филол. наук / И.И. Сиразиев. – Казань: КГУ, 2002 – 177 с.

Смирнова Т.Г. Фамилии Тамбовской области в антропонимической системе языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Тамбов, 2003. – 26 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина тюркского этноса по данным языка / отв. ред. Э.Р. Тенишев, А.В. Дыбо. – М.: Наука, 2006. – 908 с.

ССТМЯ – Сравнительный словарь тунгусо-маньчжурских языков. – М., 1975. – Т. I; 1977. – Т. II.

Становление и расцвет Золотой Орды. Источники по истории Улуса Джучи (1266–1359 гг.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. – 438 с.

Стебелева И.В. Поэзия тюрков VI–VIII веков. – М.:, 1965

Сулейманова Р.А. Антропонимы современного башкирского языка и тенденции их развития: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Р.А. Сулейманова. – Уфа, 2006. – 25 с.

Суперанская А.В. Общая теория имени собственного. – М.: Наука, 1973. – 261 с.

Суперанская А.В. Словарь русских имен / А.В. Суперанская – М.: Изд-во Эксмо, 2005. – 448 с.

Суперанская А.В. Структура имени собственного: фонология и морфология / А.В. Суперанская. – М.: Наука, 1969. – 208 с.

Суперанская А.В. Теоретические основы практической транскрипции / А.В. Суперанская. – М.: Наука, 1978. – 284 с.

Супрун В.И. Ономастическое поле русского языка и его художественно-эстетический потенциал. – Волгоград, 2000. – 122 с.

Суслова А.В. О русских именах./ А.В. Суслова, А.В. Суперанская. – М.: Лениздат., 1991.–219 с.

СЯИФ – Словарь японских имен и фамилий. – М.: Гос. изд-во иностранных и национальных словарей, 1958. – 1207 с.

Татар грамматикасы: өч томда – М: Инсан; Казань: Фикер, 2002 – Т. 2. –448 б.

Татар грамматикасы: өч томда – М.: Инсан; Казань: Фикер, 1998 – Т. 1. –512 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977 – Т. 1 – 475 б.; 1979. – Т. 2. – 726 б.

Татар теленең диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 459 б.

Татарско-русский словарь личных имен и фамилий = Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге / авт.-сост.: Г.Ф. Саттаров, Р.Г. Ахметьянов, Ф.А. Ганиев и др. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. – 375 с.

Татарско-русский словарь: в 2-х. т. 1 (А–Л.). – Казань, Алма-Лит, 2007. – 727 с.

Тенишев Э.Р. О методах и источниках сравнительно-исторических исследований тюркских языков // Советская тюркология. – 1973. – № 5. – С. 119–124.

Тимирханова Г.С. Антропонимия татар г. Набережные Челны Республики Татарстан в XX веке: на примере личных имен и фамилий: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Елабуга, 2002. – 25 с.

Тимканова Г.Ф. Историко-лингвистический анализ личных имен татар г. Тюмени XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Г.Ф. Тимканова. – Казань, 2005 – 23 с.

Токмашев Д.М. Антропонимы в героическом эпосе: Сравнительно-исторический аспект. – Новокузнецк, 2005. – 220 с.

Толстая С.М. Пространство слова. Лексическая семантика в общеславянской перспективе. – М.: Индрик, 2008. – 527 с

Толстой Н.И., Толстая С.М. Славянская этнолингвистика: вопросы теории. – М.: Институт славяноведения РАН, 2013. – 240 с.

Топоров В.Н. Исследования в области славянских древностей: Лексические и фразеологические вопросы реконструкции текстов / В.Н. Топоров. – М.: Наука, 1974. – 342 с.

Топорова Т.В. Язык в зеркале культуры: древнегерманские двучленные имена собственные. – М.: Школа «Языки русской культуры», 1996. – 253 с.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 с.

ТТЗДС – Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 836 с.

Тумашева Д.Г. Көнбатыш Себер татарлары теле / Д.Г. Тумашева. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961. – 240 б.

Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле: Морфология / Д.Г. Тумашева – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1978 – 222 б.

Угрюмов А.А. Русские имена / А.А. Угрюмов. – Вологда: Книжное изд-во, 1962. – 118 с.

Унбегаун Б.О. Русские фамилии. Под общ.ред. Б.А. Успенского. – М.: Прогресс, 1989. – 444 с.

Ураксин З.Г. Башкирские антропонимы из этнонимов / З.Г. Ураксин // Ономастика Поволжья. – Уфа – 1973 – №3– С. 86–89.

Урманче Ф. Тюркский героический эпос. Казань: ИЯЛИ, 2015. – 448 с.

Урманчеев Ф. Имя эпического героя / Ф.И. Урманчеев // Советская тюркология. – 1986. – № 4. – С. 22–34 .

Урманчеев Ф. Сказание «Йир Тюшлюк» у тюркоязычных народов / Ф.И. Урманчеев // Советская тюркология. – 1978. – № 1 – С. 53–63.

Урманчеев, Ф. Традиции тюркского эпоса в сказании «Джик мэрген» / Ф.И. Урманчеев // Советская тюркология. – 1980. – № 4 – С. 34–42.

Урманчеев Ф.И. Тюркский героический эпос / Ф.И. Урманчеев. – Казань: ИЯЛИ, 2015. – 448 с.

Урманчеев, Ф.И. Эпические сказания татарского народа / Ф.И. Урманчеев. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1980. – 118 с.

Ушакова Н.Н. Прозвища и личные неофициальные имена (К вопросу о границах прозвища) // Имя нарицательные и собственное. – М.: Наука, 1978. – С. 146–173.

Флоренский П. Философия культа / П.Флоренский. – М.: Мысль, 2004. – 686 с.

Фонякова О.И. Имя собственное в худоңественном тексте. – Л.: ЛГУ, 1990. – 103 с.

Хабибуллина Э.Х. Краткий тематический словарь французских заимствований в русском языке / Э.Х. Хабибуллина – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2001. – 72 с.

Хаҗиева Г.С. Телнең этнокультур пространствосында татар кушаматлары / Г.С. Хаҗиева // Актуальные проблемы современной фольклористики. Вып. 1. – Казань: Ихлас, 2017. – С. 231–235.

Хаҗиева-Демирбаш Г.С. Г. Ибраһимов идиостилендә кушаматлар / Г. Хаҗиева-Демирбаш // Наследие Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рожд. Г. Ибрагимова / сост. Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – С. 297–301.

Хазиева-Демирбаш Г. С. Антропонимическое пространство татарских и турецких загадок // Вестник Челябинского государственного университета. – 2014. – № 3. – С . 128–130.

Хазиева-Демирбаш Г.С. Изучение онимов в тюркской фольклорной ономастике / Г. С. Хазиева-Демирбаш // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота. – 2016. – № 6. – Ч. 1. – С. 174 – 176.

Хазиева-Демирбаш Г.С. Татарские личные имена в этнокультурном пространстве языка. – Казань: Магариф –Вакыт, 2017. – 444 с.

Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык / Ф.С. Хакимзянов. – М.: Наука, 1987. – 191 с.

Хаков В. Тел – тарих көзгесе / В.Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 295 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы / В.Х. Хаков. – Казан ун-ты нәшр., 1993. – 325 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы буенча очерклар / В.Х. Хаков.– Казан: Казан ун-ты нәшр., 1965 – 119 б.

Хаков В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше / В.Х. Хаков. – Казан, 1972. – 224 б.

Халиков А.Х. Татар халкының килеп чыгышы / А.Х. Халиков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 127 б.

Халыгов, Ф. Р. Фольклорная ономастика азербайджанского языка: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Баку, 2004. – 55 с.

Халыгова Р.Ф. Пути развития современной азербайджанской антропонимии (в социолигвистическом аспекте): автореф. дис. ... канд. филол. наук / Р.Ф. Халыгова – Баку, 1992. – 22 с.

Хигер Б.Ю. Имя человека, его характер, судьба / Б.Ю. Хигер // Тайна имени-. – Харьков: Основа, 1995. – С. 306–605.

Хисамитдинова Ф.Г. Мифологический словарь башкирского языка / Ф.Г. Хисамитдинова.– М.: Наука, 2010. – 456 с.

Хисамов Н. Исемең матур, кемнәр куйган? / Н. Хисамов // Мәдәни җомга.– 2004 – 30 гыйнвар – Б. 14; 6 февраль – Б. 14.

Хисамов О.Р. Антропонимнарга нисбәтле ойконимнар / О.Р. Хисамов // Татар теле һәм әдәбиятының актуаль проблемалары: Фәнни-методик мәкаләләр җыентыгы. – Стәрлетамак: Стәрлетамак дәүләт педагогия академиясе, 2004. – 291 б.

Хисамов О.Р. Тюрко-татарская топонимия Томской области / О.Р. Хисамов // Милли-мәдәни мирасыбыз. Томск өлкәсе татарлары. – Казан, 2016 . – С. 11–52.

Хисамова Ф.М. XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре: (Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышына кагылышлы материаллар буенча) / Ф.М. Хисамова– Казан: Казан университеты нәшрияты, 1981. – 164 б.

Хожалепесова Ю.Н. Прозвища в системе каракалпакской антропонимии: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Ташкент, 1996. – 26 с.

Хуснуллина З.М. Историко-лингвистический анализ татарских фамилий г. Казани: автореф. дис. ... канд. филол. наук / З.М. Хуснуллина,. – Казань, 2006.

Чобанов М.Н. Основы азербайджанской антропонимики: автореф. дис. ... д-ра филол. наук / М.Н. Чобанов – Баку, 1992 – 54 с.

Чурсина И.С. Развитие антропонимикона английского языка (морфонологические и социокультурные аспекты): дис. ... канд. филол. наук / И.С. Чурсина. – Тула, 2002 – 203 с.

Шайхулов А.Г. Башкорт һәм татар исемдәре = Башкирские и татарские имена собственные / А.Г. Шайхулов, З.Раемгужина. – Уфа: 2006 – 92 с.

Шайхулов А.Г. Татарские и башкирские личные имена тюркского происхождения / А.Г. Шайхулов – Уфа, 1983 – 72 с.

Шакуров Р.З. Рифмование имен у башкир / Р.З. Шакуров // Ономастика Востока. – М.: Наука, 1980 – С. 43–48.

Шатинова Н.И. Рифмование личных имен у алтайцев / Н.И. Шатинова // Ономастика Востока. – М.: Наука, 1980 – С. 9–15.

Шерцль В.Ш. О названиях цветов / В.Ш. Шерцль // Филологические записки. – Воронеж, 1884 – №2 – С. 60

Шостка Е.С. Прозвища Тамбовской области: языковой и социокультурный аспект. Автореф. канд. филол. н. – Тамбов, 2009. – 26 б.

Шпар Т.В. Прозвищные антропонимические номинации в социолингвистическом аспекте. Автореф. канд. филол. н. – Уфа, 2012. – 26 с.

Щетинин Л.М. Слова, имена, вещи. Очерки об именах. – Ростов-на-Дону, 1966. – 119 с.

Энциклопедический словарь-справочник лингвистических терминов и понятий. Русский язык.: в 2-х томах / А.Н. Тихонов, Р.И. Хашимов, Г.С. Журавлева и др. / под общ. ред. А.Н. Тихонова, Р.И. Хашимова. – М.: Флинта: Наука, 2008. – Т. 1. – 820 с.

Энциклопедический словарь-справочник лингвистических терминов и понятий. Русский язык.: в 2-х томах / А.Н. Тихонов, Р.И. Хашимов, Г.С. Журавлева и др. / под общ. ред. А.Н. Тихонова, Р.И. Хашимова. – М.: Флинта: Наука, 2008. – Т. 2. – 816 с.

Юдин А.В. Ономастикон восточнослаянских загадок. – М.: ОГИ, 2007. – 120 с.

Юсупов Г.В. Антропонимы в булгаро-татарской эпиграфике / Г.В. Юсупов // Личные имена в прошлом, настоящем, будущем. – М.: Наука, 1970. – С. 248–252.

Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику / Г.В. Юсупов. – М.: Наука, 1960 – 165 с.

Юсупов Ф.Ю. Морфология татарского диалектного языка: категория глагола / Ф.Ю. Юсупов. – Казань: Фэн, 2004 – 592 с.

Язык и этнос на рубеже веков: Этносоциологические очерки о языковой ситуации в Республике Татарстан. – Казань: Магариф, 2002 – 208 с.

Языкознание. Большой энциклопедический словарь / под ред. В.Н. Ярцева. – М.: Научное изд-во «Большая Российская энциклопедия», 2000. – 688 с.

Яхин Ф. Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология / Ф. Яхин. – Казан: Татар. дәүләт гуманитар ин-ты, 2000. – 286 б.

Яшь галимнәр карашы.–Казан: РИЦ «Школа», 2006. – 224 б.

Akalın, Ş. Türk kişi adlarının kaynakları / Ş. Akalın // Tarih. – Istanbul. – 1998. – № 6. – S. 15.

Aksoy, Ö.A. Ata sözleri ve deyimler sözlüğü / Ö.A. Aksoy. Deyimler sözlüğü. – 2 cilt. – İstanbul: İnkilabkitapevi, 1994. – 1205 s.

Aksoy, Ö. A. Ata sözleri ve deyimler sözlüğü. Ata sözleri sözlüğü / Ö. A. Aksoy. – 1 cilt. – İstanbul: İnkilab kitap evi, 1994. – 486 s.

Albayrak, N. Ansiklopedik Halk Edebiyatı Sözlüğü / N. Albayrak. – İstanbul: Kapı Yayınları, 2010. – 590 s.

Alfontso, M. E. Onomastika. – Vitoria-Gasteiz: Servicio Central de Publicaciones del Gobierno Vasco, 2005. – 85 p.

Alford, R. D. Naming and Identity: A Cross-Cultural Study of Personal Naming Practices. – New Haven: HRAT Press, 1998. – 190 p.

Aydın Abi Aydın. Türk mənəşli şəxs adları sözlüyü. – Baku: Nurlan, 2007. – 464 s.

Baskakov, N. Oghuz, oghuz-kaghan – etimologici üzerine // Istanbul Universitesi Edebiyat Fakültesi Türk dili ve edebiyati dergisi. – Istanbul, 1986. – S. 35–37.

Calp, M. Kişi Adları Üzerine Dilbilimsel Bir Çalışma (Ağrı ili örneği) //

A. Ü. Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü Dergisi-52. – Erzurum, 2014. – S. 27–49.

Çobanov, M. N. Azerbaycan kişi adları. – Erzurum: Atatürk Üniversitesi Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü, 1993. – 88 s.

Çopuroğlu, F. Öz Türk Adları. – İzmir: Yeni Matbaa, 1933. – 31 s.

Çoruhlu, Y. Türk Mitolojisinin Ana Hatları / Y. Çoruhlu. – İstanbul: Kabalcı Yayıncılık, 2011. – 260 c.

Dilçın, Ç. Adlar Sözlüğü. – İstanbul, Kültür Yayınları, 2014. – 440 s.

Elçin, Ş. Halk edebiyatına Giriş / Ş. Elçin. –Ankara: Feryal Matbaası, 1998. – 762 s.

Erol, A. Adlarımız / A. Erol.– Istanbul: Turan Kültür Vakfi, 1999. – 610 s.

Farhad Javadi. Glossary of Turkish names. – Orogmen, 2001. – 310 p.

Gençosman, K.Z. Ansiklopedik Türk İsimler Sözlüği. – İstanbul: Hürriyet Ofset, 1975. – 234 s.

Gülensoy, T. XXI. Yüzyılda Türkiye Kişi Adlarına bir Bakış / T. Gülensoy // İDİL. – 2012. – Cilt 1. – Sayı 5. – S. 1–7.

Huschka, Denis, Wagner Gert G. Statistical Problems and Solutions in Onomastic Research Exemplified by a Comparison of Given Name Distributions in Germany throughout the 20th Century / Huschka Denis, Wagner Gert G. // Onoma Volume 47, 2012. – P. 329–365.

Karadavut, Z. Kırgızlarda Ad Verme Geleneği / Z. Karadavut // Türk Edebiyatı İncelemeleri. Saim Sakaoğlu Aramağanı. Ed. Dr. Metin Ergin. – Ankara: Türk Kültür Araştıma Ensititüsü, 2013. – S. 277 – 288.

Karaoğuz, A. Öz Türk Adları Kılavuzu / A. Karaoğuz. – Zonguldak: Karaelmas Matbaası, 1935. – 80 s

Kaya, N. Çocuk isimleri ansiklopedisi / N. Kaya. – Istanbul: Laleli, 2000. – 536 s.

Kaya, N. Çocuklarımız ve İsimlerimiz / N. Kaya. – İstanbul: Nizam Yayınev, 1992. – 500 s.

Kazak Türklerinde kişi adları / T.J. Januzaqov, K.S. Esbayeva; aktaran Nurettin Aksu. – Ankara: Türk Dil Kurumu, 2003. – 102 s.

Kemal Zeki Gencosman. Türk isimleri sözlüğü. – İstanbul: Hürriyet Yayınları, 1975. – 234 s.

Kibar, O. Türk kültüründe ad verme: kişi adları üzerine bir tasnif denemesi / Osman Kibar. – Ankara: Akçağ Basım Yayım Pazarlama A.Ş., 2005. – 239 s.

Kurbanov, A. Onomastiğin Esasları / A. Kurbanov. –Ankara: Türk Dil Kurumu. 1 Cilt., 2014. – 440 s.

Kurbanov, A. Onomastiğin Esasları / A.Kurbanov. – Ankara: Türk Dil Kurumu. 2 Cilt., 2014. – 414 s.

Kutlu, Ş. Türkçe Kadın ve Erkek Adları / Ş. Kutlu. – Ankara: Ankara Üniversitesi Basımevi. – 107 s.

Langendonck Willy van. Theory and typology of proper names. Berlin, New York Mouton de Gruyter, 2007. – 341 с.

Lezina, L.N., Superanskaya, A.V. Bütün Türk halkları / L. Lezina, A. Superanskaya. – İstanbul: Selenge Yayınları, 2009. – 579 s.

Morarasu, N., Druga, L. Projecting the Ethnic Identity of Romanian Gypsies/ Roma through Contemporary First Name-giving Practices // Onoma. Vol. 46, 2011. – P. 77–93.

Məmmədov, I. Azərbaycan dilinin etnografık leksiksı / I. Məmmədov. – Baku, 2006. – 200 s.

Nuessel, F.H. The Study of Names: A Guide to the Principles and Topics. – Westport, Connecticut, L.: Greenwood Press, 1992. – 154 p.

Orbay, K.Ş. Öz Türkçe Adları ve Sözleri. – İstanbul: Marifet matbası, 1935. – 80 s.

Orozbakoğlu Sagınbay. Kırgız Destanları VI. Manas Destanı. – Ankara: Türk Dil Kurumu Yayınları, 2007. – 528 s.

Paşayeva, M. Azərbaycanlıların ailə mərasımında etnık ənənəkeri. – Baku, 2008. – 324 s.

Püsküllüoğlu, A. Seçilmiş Çocuk Adları Sözlüğü. – Ankara: Maya Matbaacılık Yayıncılık Limited Şirketi, 1996. – 132 s.

Rásonyi, L. Kuman isimler // Türk Kültürü Araştırmaları. – Ankara: TKA Enstitüsü yayınları, 1966 – 1969. – S.141 – 144.

Rásonyi, L. Onomasticon Turcicum. – T. 2. – Indiana University Denis Sinor Institute for Inner Asian Studies, 2007. – 492 p.

Rasonyi, L. Onomasticon Turcicum. – Bloomington: Indiana University and Denis Sinor Institute for Inner Asian Studies, 2007. – 836 p.

Rásonyi, L. Türk Kadın İsimleri / L. Rásonyi // Türk Dili Araştırmaları Yıllığı-Belleten, 1963, Ankara. – S. 63– 87.

Reichel, K. Türk Boylarının destanları. Çev. Metin Ekici. – Ankara: Türk Dil Kurumu, 2002. – 441 s.

Saffet, M. Cavit-O. Türk Adları. – Muğla: Halk Matbaası, 1934. – 18 s

Şahin, İ. Adbilim (Çerçeve, Terim, Yöntem ve Sınıflandırmalarıyla) / I. Şahin. – Ankara: Pigem Akademi, 2015. – 144 s.

Şahin, İ. Adbilim (Çerçeve, Terim, Yöntem ve Sınıflandırmalarıyla) / I. Şahin. – Ankara: Pigem Akademi, 2016. – 155 s.

Sakaoğlu, S. Türk Ad Bilimi / S. Sakaoğlu. – Ankara: Türk Dil Kurumu, 2001. – 156 s.

Sakallı, E. New Trends in Name-Giving in Turkey / Sakallı E // Voprosy onomastiki. – 2016. – Vol. 13. – Issue 1. – 171 – 177 pp.

Sanater, E. Soyadı Kanunu ve Öz Türkçe Adlar / E. Sanater. – İstanbul: Bozkurt Matbaası, 1935. – 12 s.

Şevki, A.I. Öz Türkçe Adları. – Balıkesir: Vilayet Matbaası, 1934. – 56 s.

Tekin, T. Orhon Yazıtları / T. Tekin. – Ankara: Türk Dil Kurumu, 2008. – 200 s.

The Oxford Handbook of Names and Naming Front Cover CaroleHough. – United Kingdom Oxford University Press, 2016. – 832 p.

Tuncay, A. Türk Adları Klavuzu / A.Tuncay. – Ankara: Bilgi Yayınevi, 2010. – 175 s.

Ülkütaşır, M. Türküye Türklerinde Ad Verme İle İlgili Gelenek ve İnançlar / M. Ülkütaşır // I Uluslararası Türk Folkloru Kongresi Bildirileri. Gelenek-Görenek ve İnançlar IV Çilt. – Ankara, 1976. – S.369–370.

Useev, N. Yenisey Yazıtlarındaki Erkek Kişi adlarında Geçen kelimelere Göre Eski Türk Erkeği / N. Useev // Uluslararası Türkçe Edebiyat Kültür Eğitim Dergisi. – Sayı: 4/1. – 2015. – S. 25 – 38.

Vural, M. Zeki Öz Türkçe Kadın ve Erkek Adlar. – İstanbul: Şirketi Mürettibiye Basımevi, 1934. – 16 s.

Yalçın, Toker. Türk isimleri (anlamlar) / Y. Toker. – İstanbul: Toker Yayınları, 1995. – 263 s.

Əsgərov, H. Azərbaycan dilində maddi mədəniyyət leksikası / H. Əsgərov. – Baku, 2006. – 90 s.

Caferoğlu, A. Türk onomastiğinde ‘köpek’ kültü / A. Caferoğlu // Türk dili araştırmaları yıllığı. Belleten. – Ankara, 1962. – S. 1 – 11.

. ان بر سملری. – Казань: Типография Б. Л. Домбровского,1908. – 8 с.

هذا کتاب فی بیان اون بر احمد اسملری. – С.-П.: Типография, 1896. – 10 с.

اسم. بالاغه کورکم اسم بیرورکه کیکاش هم اوقوجی صبیلرغه هدیه قیلورغه موافق کتاب. – С.-П.: Типография Б. Л. Домбровского, 1899. – 8 с.

Türk edebiyatında mahlaslar, takma adlar, tapşırmalar ve lakaplar. / Mehmet Semih. – İstanbul : Anahtar Kitaplar Yayınevi, 1993. 84 s.

## Шартлы кыскартмалар

бол.-т. – болгар-татарча
бор.-т. – борынгы төрки
бор. яһ. – борынгы яһүдчә
г. – гарәпчә
г.-ф. – гарәп-фарсыча
ингл. – инглизчә
иск. т. – иске татарча
исп. – испанча
ит. – итальянча
кып. – кыпчакча
лат. – латинча
монг. – монголча
нем. – немецча
р. – русча
т. – татар
т.-г. – татар-гарәпчә
т.-ф. – татар-фарсыча
төрек.– төрекчә
ф. – фарсы
ф.в. – фонетик вариант
чаг. – чакыштыр

ЭЧТӘЛЕК

**Кереш** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

**Беренче бүлек. Татар кеше исемнәренең этнолингвистик катламнары** . . . . . . . . . . . . . . . . . 16

§ 1. Татар кеше исемнәренең алтай катламы . . . . . . . . . . . . 18

§ 2. Татар кеше исемнәренең борынгы төрки чор катламы . . . . . 21

§ 3. Татар кеше исемнәренең гарәп катламы . . . . . . . . . . . . 38

§ 4. Татар кеше исемнәренең фарсы катламы . . . . . . . . . . . 46

§ 5. Татар кеше исемнәренең Көнбатыш Европа һәм рус катламы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52

**Икенче бүлек. Татар кеше исемнәренең үсеш-үзгәреш тенденцияләре** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58

§ 6. XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башы татар антропонимик системасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58

§ 7. XVIII гасыр татар исемнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63

§ 8. XIX гасыр татар исемнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65

§ 9. XX гасыр татар исемнәренең үсеш тенденцияләре . . . . . . 70

§ 10. XXI гасыр башы татар исемнәренең үсеш тенденцияләре . . . 73

Кыскача нәтиҗәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82

**Өченче бүлек. Татар исемнәрен бирү йола-мотивлары** . . . . . . 83

§ 11. Татар телендә исем кушу лексикасы һәм йолалары (диалекталь һәм этнографик текстлар контекстында) . . . . . . . 83

§ 12. Антропонимиядә исемнәрнең лексик-семантик төрләрен өйрәнү торышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92

§ 13. Дескриптив (тасвирлама) татар исемнәре . . . . . . . . . . . 95

§ 14. Дезидератив (теләк) татар исемнәре . . . . . . . . . . . . 107

§ 15. Меморатив (багышлау) татар исемнәре . . . . . . . . . . . 116

§ 16. Ассоциатив мотивлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122

Кыскача нәтиҗә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129

**Дүртенче бүлек. Татар исемнәренең морфонологиясе** . . . . . . 131
§ 17. Татар исемнәренең структур үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . 131
§ 18. Морфологик ысул белән ясалган татар исемнәренең модельләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
§ 19. Синтаксик ысул белән ясалган татар исемнәре . . . . . . . . 136
§ 20. Аббревиатур исемнәрнең ясалышы . . . . . . . . . . . . . . . . 139
§ 21. Татар исемнәренең ономавариантлары . . . . . . . . . . . . . 140
Кыскача нәтиҗәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
**Бишенче бүлек. Татар фамилияләре** . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
§ 22. Татар фамилияләренең формалашу тарихы . . . . . . . . . . 147
§ 23. Татар фамилияләренең төзелеш-ясалышында төп үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
§ 24. Татар фамилияләренең орфографиясе һәм транслитерация мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
**Алтынчы бүлек. Татар кушаматлары һәм псевдонимнар** . . . . 160
§ 25. Кушаматларның төрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
§ 26. Татар халкында кушамат бирү мотивлары . . . . . . . . . . 166
§ 27. Псевдонимнар турында төшенчә . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
§ 28. Татар псевдонимнарының төрләре . . . . . . . . . . . . . . . . 174
**Җиденче бүлек. Татар мифонимикасы** . . . . . . . . . . . . . . . . 177
§ 29. Мифонимика фәненә гомуми билгеләмә . . . . . . . . . . . . 177
§ 30. Татар телендә мифонимнарны төркемләү . . . . . . . . . . . 183
§ 31. Мифонимнарның кулланылыш үзенчәлекләре . . . . . . . . 187
**Йомгак** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
Чыганаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 198
Фәнни-теоретик әдәбият исемлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Шартлы кыскартылмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217

Научное издание

**Хазиева-Демирбаш Гузалия Сайфуллловна**

**ТЕНДЕНЦИИ РАЗВИТИЯ
ТАТАРСКОЙ АНТРОПОНИМИЧЕСКОЙ СИСТЕМЫ**

(на татарском языке)

Редактор *Я.М. Абдулкадырова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 12,8. Уч.-изд. л. 12,1. Тираж 200 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12